КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ
ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН
БАШЛАП ЧЫГА

# Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Илсөяр ИКСАНОВА. Көтәм көн туганын... *Шигырьләр.* ...3
Вахит ИМАМОВ. Теләкәй чишмәсе. *Тарихи роман.* ...8
Булат ИБРАҺИМ. Тайгакланган дөнья, юллар тая... *Шигырьләр.* ...83
Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ. Иблис коткысы. *Кыйсса.* ...88
Илһам НОГМАН. Кан хәтере җанны бимазалар... *Шигырьләр.* ...123
Зөфәр ДӘҮЛӘТОВ. Эретер сыман йөрәгем котыпның карын... *Шигырьләр.* ...148
Илгиз ЗӘЙНИЕВ. Бәхет. *Хикәяләр.* ...151

ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ

Айгөл ӘХМӘТГАЛИЕВА. Күз нурларым. *Драматик хикәя.* ...127

КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫ

Маралтай ЫБЫРАЕВ. Бер улыңмын, и кадерле Ватаным! *Шигырьләр.* (*Казакъ теленнән Рафис КОРБАН тәрҗемәләре).* ...157

«СЕЗ ИҢ ГҮЗӘЛ КЕШЕ ИКӘНСЕЗ!» ӘДӘБИ КОНКУРСЫ

Наил ШӘРИФУЛЛИН. «Шагалиев шәүләсе». *Хикәя.* ...160

ЯҢА ИСЕМНӘР

Ризәлә ИСМӘГЫЙЛЕВА. Сугарасым килә халкымны... *Шигырьләр.* ...164

ЕРАКТАГЫ УТЛАР

Радик ХӘКИМҖАН. Хәтеремдә – янган учаклар... *Шигырьләр.* ...167
Нурислам АЙБУЛАТОВ. Яшем арткан саен уфтанамын… *Шигырьләр.* ...168

ХӘТЕР

Гали АРСЛАНОВ. Дөнья җәүһәрләре Минзәлә театрында
*(Сабир Өметбаевның тууына – 115 ел).* ...171

*Китап күзәтү:* Ландыш ӘБҮДӘРОВА. Чытырманлыкта бар да тәртип.
*(Марсель Галиевның «Чытырманлыкта» тәрҗемәләр җыентыгына күзәтү).* ...175

*Фотоархив:* Каһарман-шагыйрь Абдулла Алишның тууына – 115 ел. ...178

*Хатлар яздым утырып:* Аяз Гыйләҗевнең Марсель Галиевка язган хатлары. ...180

*2023 ел – Россиядә Укытучылар һәм остазлар елы:*
Лилия ЯРУЛЛИНА. «Туган тел дип яшәдем». ...186

*Газиз тавышлар:* Гармуннар падишаһы *(Фәйзи Биккининның тууына – 125 ел).* ...188
Халык җырларына гомер бирде. *(Әзһәр Абдуллинның тууына – 100 ел).*
Сәхифәне «Татарстан» радиосының шеф-мөхәррире Нәсим АКМАЛ алып бара. ...189

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ...190

КАЗАН УТЛАРЫ
*№ 10 (1212) 2023*

*БАШ МӨХӘРРИР –*
**Рөстәм Госман улы ГАЛИУЛЛИН**

*ИДАРӘ:*
**Ирада Әюпова**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Искәндәр Гыйләҗев**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Ркаил Зәйдулла**
**Илгиз Зәйниев**
**Илфак Ибраһимов**
**Зиннур Мансуров**
**Ким Миңнуллин**
**Газинур Морат**
**Рүзәл Мөхәммәтшин**
**Айдар Сәлимгәрәев**
**Равил Фәйзуллин**
**Илсур Һадиуллин**
**Данис Шакиров**
**Ленар Шәех**

---

*Баш мөхәррир урынбасары:* **Вакыйф Нуриев.**
*Җаваплы сәркатип:* **Ландыш Әбүдәрова.**
*Бүлек мөхәррирләре:* **Фәнил Гыйләҗев, Рафис Корбан.**
*Мөхәррирләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Гөлия Сәлахова.**
*Сайт мөхәррире:* **Ләйсән Зарипова.** *SMM-белгеч:* **Алинә Хәбибуллина.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова** (өлкән бухгалтер)**.**
*Машина йөртүче:* **Наил Кадыйров.**

---

✉✉: Редакция адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Кабул итү бүлмәсе – 222-09-83 (өст.1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Җаваплы сәркатип – 222-05-50 (өст. 1617).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1267), касса – 222-09-84 (өст.1874).*
Сайт: kazanutlary.ru; электрон почта: kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче адресы: 420097, Казан, Академия урамы, 2.
Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 29.09.2023, график буенча 29.09.2023, басылып чыгу вакыты 05.10.2023
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 $^1/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ С-2661. Тираж 5545.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2020 елның 13 ноябрендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79467.
Индекслар: ПО277 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен),
П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), П2368 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
12+

© «Казан утлары», 2023 ел



Илсөяр
Иксанова

# КӨТӘМ КӨН ТУГАНЫН...

## Рух көймәсе

Коя яңгыр.
Коя гына!
Күк түбәсе тишелгәнме?!
Нух көймәсен барлагандай,
Барлап куям Рух көймәмне.

Ниләр алыйм бу көймәмә,
Батмый агып китсен өчен, –
Упкыннарга юлыкмыйча,
Киләчәккә җитсен өчен?

Парлап-парлап салам сайлап:
Намус-вөҗдан, милләт-өммәт.
Өмет-хәтер, акыл-фикер,
Илаһият-шигърият.

Киләчәккә китәр көймәм
Иңләп-буйлап дәрьяларны.
Нух туфаннан коткарган күк,
Коткарсын ул дөньяларны!

## Китә казлар...

*Китә казлар Донбасска.*
Халык җыры

Кара көзләр килде безгә, –
Казлар китә Донбасска.
Ярар иде кайтавазы
Йөрәгемне ярмаса...

---

Илсөяр ИКСАНОВА (1966) – *шагыйрә, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Һ.Такташ исемендәге әдәби премия лауреаты. «Ышанасы килә», «Кырык кыл», «Гомер сурәте» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Ниләр көтә,  шул өркетә, –
Җилләр исә гарештән.
Җил иркенә бөгелүдән
Саклый күрсен фәрештәм.

Башын игән ак каеннар,
Кара болыт кабара.
Ерак кошлар кайтавазы
Хәтеремдә яңара.

Китә күрмәгез Донбасска,
Китмәгез, кошкайларым! –
Кара табына буылып,
Сыгылып елый каен...

***

Дөньябыз шомлы вә кымкырыч, –
Сүзләргә салырга куркыныч.
Түзалмас ак кәгазь, –
Каралыр.
Карадан караңгы яралыр.

Күңелнең халәте – сызлану,
Саташкан дөньяны кызгану.
Түзалмас ак кәгазь, –
Саргаер.
Сискәнеп, өметләр сагаер.

Кешелек мең төрле битлектән, –
Бүреләр куркалар этлектән.
Кыйбласын җуйган ил,
Кызган үч.
...Язарга ак кәгазь кызганыч.

## Бүгенем

Бер карадым күккә,
Бер карадым төпкә.
Күкләр болыт иде,
Төпләр тонык иде.

Болыт артларында
Бардыр, бәлки, Ай да.
Бәлки, Кояш анда,
Бәлки, кургаш анда.
Бәлки, төн пәрдәсе,
Давыл әвәрәсе...
Күкне тарткан болыт,
Шомлы пәрдә булып.

Тонык төпкелләрдә
Бардыр үткелләр дә.
Бардыр биеклек тә,
Бардыр бөеклек тә.
Ни булса да анда
Калган бары канда.
Төпкә яткан инде,
Упкын япкан инде.

Күк йөзләре – болыт,
Офыкларда – томан.
Өметкә җан өреп
Күккә карап торам, –
Ертып таң томанын,
Көтәм көн туганын.

***

Кар ява. Яңа ел таңында
Акларга телиме күңелне?
Бу елда кешелек җанына
Никадәр авырлык бөелде!

Кар ява. Яңа ел таңында
Акларга телиме җиһанны?
Яралы кешелек җанына
Ябасы килә бу ак карны!

***

Шомырт ап-ак,
Шау чәчәктә шомырт!
Шомырт салкыннары адашкан, –
Җәй уртасы кебек җылы иртә, –
Дөньясында нидер алмашкан.

Яп-якты яз,
Чалт аяз күк – зәңгәр.
Хыялларга канат куй гына!
Ап-ак чәчәкләрне каралтырдай
Авыр гамьнәр керә уема.

Күңелдәге шомлы күкрәүләрне
Ишетәдер кебек бу шомырт.
Дөньяларны сөрем сарган чакта
Калып буламы соң ак булып?!

Ак шомыртка карап сызды күңел,
Бәгыремә әрнү саркыды.
Табигатьнең кануннары төгәл, –
Кайтып сугар шомырт салкыны...

***

Гомергә җитәрлек
бу төннең яктысы!
Яралы сөюне
килдеме яклыйсы, –

Тулган Ай нурында
ак күбек чияләр!
Саташкан язгы хис
һәм... көмеш чигәләр.

## Сыналу

Зур сынаулар сагалаган, көткән безне дә.
Сыналабыз. Бу сынаулар бетмәс тиз генә.

Сыналган дуслар сыналды тагын бер кабат.
Гаҗизлеккә төшермәде – сынмады канат.

Без,  күрәсең, канатлылар – кошлар ыруы.
Сөйрәлүчеләр янында кыен торуы.

Канатлы ат. Еланның да канатлысы бар.
Барска канат куюны кабатлыйсы бар!

## Сагыну

Урамда көз.
Күзем тәрәзәдә.
Күз алдымда үткән көзләрем, –
Мәктәп юлы,
Нәни кызым бара,
Шаян яфрак үбә эзләрен.
Күзләремне алмый карап калам,
Борыла да чаттан югала.
Кызым минем,
Чаттан борылдың да,
Чыгып киттең ерак юлларга.

Урамда яз.
Күзем тәрәзәдә.
Истәлекләр язгы ташкындай.
Үсмер кызлар көлә чырык-чырык, –
Язга алгысына-ашкына.
Кызым минем,
Кыска язларыңны
Йөгреп кенә үттең шикелле.
Күз алдымда – алкын бөдрәләрең,
Кояш үпкән битең –
Сипкелле.

Урамда җәй.
Күзем тәрәзәдә.
Юкәләрдән татлы бал тама.
Машинасы белән өй каршына
Җиткән кызым кайтып туктала.
Кызым минем,
Әле кай арада
Дөнья куар чагың җитте лә?!
Сизеп торам,
Күңел җилкәннәрең
Чиксез киңлекләргә җилкенә.

Урамда кыш.
Күзем тәрәзәдә.
Казанымны күмә ак буран, –
Әкияттәй серле, тылсымлы кич,
Үзәк өзгеч моңсу
Буш урам.

Кызым минем,
Син яшәгән ерак,
Җылы ул илләрдә җитмидер
Кышын – буран,
Җәен – яшел урман.
Миндә – сагыш,
Синдә – җирсүдер.

## Йөрәгеңне тыңла!

Авырмы?
Авыртамы?
Сыкрыймы, сызлыймы, сызамы? –
Тыңла йөрәгеңне!

Сакыз сүз,
          яман күз,
Яла-ялагайлык
          Яралый.
Явызлык
Йөрәккә кагылмый калалмый.

Аерылу, сагыну,
Гаҗизлек, ялгызлык
          Сызлата.
Хаксызлык, көчсезлек,
Чарасыз калулар
          Әрнетә, елата.

Аһ, авыр,
Авырта йөрәгең.
Ишет йөрәгеңне, –
Йөрәгең сулышын тоеп кал!
Һәркемдә йөрәк бар!
Кагылма, яндырма,
Әрнетмә, сызлатма,
Беркемне елатма!
Тыңла йөрәгеңне!



Вахит
Имамов

# ТЕЛӘКӘЙ ЧИШМӘСЕ

ТАРИХИ РОМАН

**Беренче бәйләм**

**1**

Теләкәй морза нәни Акайны мыек очы белән кытыклап уятты.

– Кояш өй түбәсенә менеп җитте бит инде, күзеңне ач, олан. Бүген зур-зур кунаклар каршылыйсы бар, синең очлым[1]-көбәләреңне мин киярменмени? Алай бик юмарт кылансаң, Наяныңның биленә дә мин сикереп атланырмын әле.

Арада «Наян» дигән сүз нәни Акайның йөзенә су бөркегәндәй тәэсир итте ахры, икенче мизгелдә үк ул бабасының муенын кочып алды.

– Мин юри генә йоклаганга сабышып яттым, бабакай. Наянны да, көбәмне дә бирмим. Минем көбә синең терсәгеңә кияргә дә ярамый ла ул. Син имән агачы сыман алагаем дәү бит.

Теләкәй оныгын күкрәгенә кочты. Акай да ялындырып тормады, күз ачып йомганчы, бабасының кочагына томырылып, кул-аяклары белән үк кочаклап та алды.

– Син, чынлап та, бүген матур көбәңне дә ки, очлымыңны да эләктер, балакаем. Кунакларым бик күп булачак бит. Пәнҗәрдәге Гайни, Әгерҗедәге Халик старшиналарны чакырдым. Аллаһ боерса, Бакалы кирмәне янындагы Ногай бәк тә килми калмам, дигән хәбәр салды. Тагын Минзәлә ягыннан да килеп җитәчәкләр. Сөн буендагы Байсар белән Кыргыз, Ык вә Агыйдел ягыннан Мөшегә һәм Өшәр хуҗалары – берсе-бер килми калмас. Әйдә әле, без синең белән аларны җиренә җиткереп каршы ала белик, шулаймы, балакаем?

– Шулай, бабам, син тотынсаң, иң карт наратны да тамыры белән йолкып аласың бит.

[1] Очлым – шлем.

Вахит ИМАМОВ (1954) *– язучы, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, «Ир канаты», «Татарларның Ватан сугышы», «Утлы дала» һәм башка китаплар авторы. Казанда яши.*

– И-и, арттырасың инде, арттырасың.

– Һи, үзең дә очлымыңны киям, Наянымны үзеңә алам, дип арттырасың ласа.

Кочакларыннан аерылмаган килеш көлешә-көлешә, бабай белән онык олы якка чыкты, ә анда Күчем морза елмаеп тик тора.

– Болай иркәли-иркәли, валлаһидыр, минем улымны бозып бетерәсең инде, эткәй.

– Бәла юк, улыкаем. Бабай куенында үскән затлы оланны зәмһәрир салкыннарда да кырау суга алмас. Бәхете белән камил зиһенле вә исән-сау үссен.

Акай атасы Күчем кочагына күчкәч, Теләкәй кырысланып калгандай тоелды, йөзенә төбәлмичә генә улы белән киңәшкәндәй итте.

– Без Тәтеш күле буендагы Гайзетдин, Табын авылындагы Киек морзаларга да чапкын куган идек бит, берсе – малайны сөннәткә утыртам, икенчесе билемне кузгаттым, дип хәйлә тапкан. Алдан көйләнгән каекка тиешле сандагы ишкәкчеләр кереп утырмаса, каекның бер якка каерып йә салулап хәрәкәт итүе дә бар. Каегыбыз барыбер дә капланмас, ярга да борыны белән төртелеп тукталмас. Иллә мәгәр һәр адәмнең урында булуы күпкә хәерлерәк.

– Кайгырма, эткәй, чакырган вакытка килеп җитми калмаслар. Сылтау табулары да үзләренең бәясен күтәрү генә булмагае.

– Әкәмәт, шул хәчтерүшләр дә Теләкәй морза белән бил алышмакчымы?

– Алай түгел инде. Шөлләмичә, синең белән кайсы сантый гына бил алышсын?

Берникадәр дәшми басып торгач, барыбер дә ата кеше иң беренче дәште.

– Әйдә, кунакларны каршы алырга әзер торыйк, улым...

Ваемсыз рәвештә кеткелдәп куярга да өлгерә алмый калдылар, утар капкасы янында әүвәл ат пошкырган, аның артыннан ук сөрән салган аваз ишетелде.

– Теләкәй бәк! Ваевуда-баяр Коркытдиныф хәзрәтләренең шәхси чапкыны мин. Ул үзенең кул астындагы барча ыстаршиналарны да Казый мәчете янына дәшә. Мәскәүдә Иван белән Пётр патша җәнаплары яңа фәрман чыгарган, ул тәү чиратта Теләкәй кеби морзаларга кагыла, андый олуг фәрман игълан ителүне барча ил агалары да килеп тыңларга тиешле, ди...

Ялан якка чыгып, Күчем капканы ачып куярга өлгергән иде инде, йөгән очын капкадагы тимер ыргакларга да эләктереп тормыйча, ихатага сакалмыеклары бик үк чалармаган чапкын узды. Шактый озак һәм каударланып чапкандыр, чалбар балаклары урыны-урыны белән тозланып ук тора. Куллар биреп сәламләшүгә үк, лапас ягында аунаган бүкәннәргә тезелеп утырдылар.

– Мәркәздә Фёдор падишаһ берничә көн элек кенә дөнья куйган, дигәннәр иде бит, – дип көрсенгәндәй тавыш чыгарып, сүзне, әлбәттә, Теләкәй хуҗа үзе башлап китте. – Әле яңа падишаһларны антка китерү, аларга таҗ кидерү турында бер хәбәр дә килеп ирешмәде, ә җиһанның яңа кендекләре кай арада гына фәрман чыгарырлык зиһен җыеп өлгерде икән соң?

Билгеле ки, улы Күчем дә, чапкын ир-егет тә бертөрле дә җавап кайтармады. Ничарадан бичара рәвештә Теләкәй морза һаман үзе тезде.

– Ул Каркадин воевода эргәсендә дә яңа фәрман турында сыңар гына да сүз булмадымыни? Безнең халыкка ниндидер ташлама ясардай вә тураеп басардай фәрман булуы бик тә икеледер. Шулай булгач, мотлак, мөселманга зыян-зәүрәт салырдай фәрман гына яңгыравы мөмкин. Мотлак, хәвефледер...

Воевода чапкыны аталы-уллы морзаларны юатырдай мәгълүматка ия түгел иде, кул да бирешмичә сүзсез генә хушлаштылар.

**2**

Бәрсуан елгасы буендагы Казый мәчете – Агыйдел, Өфе, Дим вә Әй елгалары буенда яшәгән барча мөселман өчен истәлекле һәм дә изге урын. Уфа, Минзәлә, Бөре вә Бәләбәй тирәләрендә, яисә Уфа белән Казан арасындагы барча олысларда яшәүче, авыллар тотучы барча старшиналар вә ил агалары һәр ел саен диярлек шунда җыела торган изге бер гадәт бар. Анда иң танылган сәет вә ишаннарның Коръән шәрифтән сүрә вә вәгазь укуларын гына тыңлап калмыйлар, мөселман халкына падишаһ галиҗәнаплары төшергән фәрманнарны, алдагы мәгыйшәттә булачак үзгәрешләр белән дә танышалар иде. Шунда ук барча олысларга җиткерелгән салым күләме дә тикшерелә, хөкүмәт ниндидер елга өстендә күпер төзү, кайсы кирмәннәр арасында киңәйтелгән юллар күтәрү өчен ирләр вә олаулар, гаскәргә дип сайланган яу атлары, көбә яисә шайман[2] таләп итсә, андый йөкнең барчасын старшиналар арасында бүлешәләр иде. Кайсыбер елларда Уфа белән Казан арасындагы авыллардан җыеп, аерым алай вә нөгәрләр[3] озату турында да фәрман төшерделәр. Шундый бер фәрманнан соң Теләкәй морзаның да ун ел чамасы элек кырым татарларына каршы яуга китеп, андагы бер кылыч орышында сыңар күзле пәһлеван белән алышка чыкканы да булды...

Көтмәгәндә килеп чыкты ул хәл. Теләкәй үзе белән алган өч аргамагының берсе янында буталып калган иде. Атның бәкәл асты юлда ниндидер ярык таш яисә такта арасына сыдырылып шешкән дә үлекли үк башлаган. Көтүче һәм пешекчеләренә генә ышанмыйча, Теләкәй шул аргамакны чатырлар корылган аланлыктан читкә алып чыкты да, туснаклар[4] йөгән вә ялларыннан тотып торган чакта, пычак белән сызып, бәкәл астындагы шешне ярып җибәрде, ә аннары инде атны биетә-биетә, җыелган бар үлеген тышка сытып чыгарды. Соңыннан җәрәхәт өстенә күп итеп көл сипте, аю мае сөртте. Менә шушы бәладән котылганнан соң гына ул алыш булачак мәйдан түренә атлап узган иде. Караса, сыңар күзле пәһлеван ниндидер рус укчысын аркан ташлап, кармакка эләктергән дә, ияренә таккан корбанын үкертә-чината, үз гаскәре ягына өстерәп бара.

– Әй, син, Салам торхан! Бергә-бер алышны синең кебек аркан ташлап уздыралармыни? Йөзгә-йөз килеп орышырга кодрәтең җитмиме? – дип оран салды Теләкәй ул чагында.

Тугандаш халык морзасының гөбедән чыккандай яңгыравык тавышын сыңар күзле пәһлеван да ишетми калмады. Ул, кырт борылып, әрсез дошман

[2] Шайман – сугыш киеме. Шул ук вакытта хәрби коралларны да элек шундый ук бер сүз белән атаганнар.
[3] Алай вә нөгәр – полк һәм отряд.
[4] Туснак – шыр хәерче, ялланып көн күрүче.

ягына исән калган күзен төбәде дә, ихахайлап көлә-көлә, Теләкәй өстенә үт әчесен койды.

– Ә син, кәрлә, мине акылга утыртырга җөрьәт итәсеңме?

– Син чебеш кебек өтек рус укчысын түгел, менә миндәй карт имәнне тамырыннан кымшатып кара, – дип, Теләкәй инде мәйдан уртасына атылып та чыкты.

Кырым пәһлеваны кулындагы арканны ычкындыруга ук әсир рус укчысы тиен кебек кенә итеп элмәктән ычкынды да күз ачып йомган арада үз сугышчылары арасына чумып юк булды. Җирле пәһлеван «кәрлә» дип кимсетергә маташса да, Теләкәй буйга чынында да әлләни зур түгел, әмма җиргә йөзәрләгән тамыры белән ябышкан имәндәй нык иде. Җайдаклар бер-берсенә каршы чаба башлауга ук Теләкәй кулындагы имән чукмар белән сугып, Кырым пәһлеванын ияреннән очырып төшерде. Теге иссезһенен җыйган арада Теләкәй аның бугазына кыска саплы сөңге угын китереп терәде, аннары шук малайга сабак биргән хәлфә тавышы белән соңгы сүзен әйтте.

– Мин монда үз туганымның башына җитәргә дип килмәдем. Мине яу сәфәреннән котылып кала алмау мескенлеге, чарасызлык куып китерде. Кырымлыларның бездәге татарга да, башкорт илә чирмешкә дә зыян салганы юк, мин дә зәүрәт салмыйм. Иллә мәгәр орыш-яулар кузгаласы булса, миндәй кәрләдән ерактарак йөр, яме, туган...

Молоствов атлы полк башлыгы мондый сатлык орыш остасын соңыннан үз янына чакырып пешермәкче булган иде дә, каршында ике як җилкәсенә дәү-дәү ирләрне утыртып әйләндерердәй Теләкәйне күргәч, кул гына селтәде.

– Русского стрельца спас от неминуемой смерти, за это тебе огромная благодарность...

Соңыннан теге рус укчысы аны үзе эзләп килде.

– Ул сукыр төрек мине үз лагерьларына алып чыгуга ук суеп үтерер дип, шыр җибәргән идем, ярый син коткардың.

– Каян килгән төрек икән соң ул, ничек уйлап таптың, кем котыртты? – дип, Теләкәй бар ачуы белән инде моның өстенә ябырылган иде, бичара укчы аптыраудан үзе дә җебеп төште.

– Соң, монда бөтен бояр вә кенәзләр безне «кырымлылар төрек янычарларын яллаган, алар үзләре генә безнең өч-дүрт полкка да каршы тора алмый», дип, гел-гел котырта бит. Чынлыкта мин төрек белән кырым татарын да, хәтта сине дә кырымлылардан һич аера алмыйм.

Беркадәр тын алганнан соң гына янә кулын сузды.

– Миңа үз укчыларым янына кайтырга вакыт. Алай-болай булса, ярдәмгә атлыгу өчен хәзер минем чират.

Аннан өстәп куйды:

– Коры кул белән килгәнгә гаепләмә инде. Мөгаен, кирәгем дә чыкмас. Әмма барыбер белеп кал, минем исемем Фёдор.

Теләкәй кул сузды.

– Ә мин – Теләкәй морза. Хәер, синең өчен морза түгел инде...

Гаҗәп, ул чакта яу сәфәрендә шактый озак айлар йөрделәр, ә укчы Фёдор бүтәнчә бер дә күзгә чалынмады...

## 3

Уфага төбәп юлга чыгуга ук, Чәрмәсән елгасы буенда төн кунарга тукталгач, Теләкәй морза җитәкләгән нөгәргә Чакмагыш, Бүздәк белән Тәтешле яугирләре килеп кушылды.

– Нинди җәдид фәрман икән соң ул, берәр озынколак аның турында хәбәр китереп ирештермәдеме? – дип сорашырга ябыштылар.

– Без дә сезнең кеби гади инсаннар шул, – дип, гәрәйлеләр дә иңбашларын сикертеп куярга мәҗбүр булды...

Казый мәчете Уфага җитәргә ике фәрсах ара якынрак урнашкан. Гәрәй, Елан, Байлар олысларыннан кузгалган җайдаклар килеп җиткәндә, Бәрсуан елгасы буендагы уйсулыкны дистәләгән чатыр каплап алган иде. Гади яугирләр һәм туснак көтүчеләр хуҗалар өчен чатыр кора башлады, ә Теләкәй морза камчысын итек кунычына кыстырып кына, өлгеррәк аксакаллар белән күрешергә китте. Себер юлындагы Бүләкәй олысыннан ук кузгалган ахун Сәгыйт Җәгъфәр хәзрәтне Теләкәйнең инде дүрт-биш ел чамасы күргәне юк иде, билгеле, янына килеп җитүгә үк аны кочагына алды.

– Ихтирамым чиксез сиңа, шанлы Җәгъфәр углы. Аллаһы Тәгалә үзеңне ярдәменнән генә аермасын.

Сәгыйт хәзрәт Теләкәй белән бергә теге вакытта Кырым походына да барган иде. Анда ахун булып йөрде, әмма төнге учак тирәсендә моңланып утырган чагында тезгән сүзләре үтә сәер вә әрнүле иде.

– Казан каласын аяк астына салып, барча болгар-татар җирләренә хуҗа булып алгач, мин ошбу кяферләрне безнең халыкны талаудан туктар, адым саен күзебезгә төртеп, ата-бабаларыбыз үз ирегә хакына алып барган җан саклау яулары өчен үч алмас, динебезне рәнҗетмәс, тулаем әйткәндә, безне үз тиңедәй күреп гомер итәсенә өмет баглый идем. Безне, болгар-татар халкын, шулар «бүре баласын бүреккә салсаң да, ул урман ягына карый», дип мыскыл иткән була. Ә үзләре чүл бүресеннән дә гожрак, тиреңне генә түгел, сөякләреңне дә калдырмый...

Казый мәчетендә уздырылган намазларның берсен шушы Сәгыйт хәзрәткә тапшырдылар. Ә мәчеттән чыксалар, Уфа каласыннан инде дворяннар да килеп җиткән. Арада Теләкәйгә бик күптәннән таныш бояр Молоствов та бар. Ун ел элек Кырым походына шуның кул астына басып барганнар иде бит, бернинди җиңүгә дә ирешә алмыйча, көзге яңгыр астына эләккән чебеш көтүе урынына куып кайтардылар. Ә хәзер, әнә, Молоствов түрә койма өстенә менеп кунаклаган күркәгә тиң. Якасы чәшке тиреләре белән каймаланган затлы җиләнгә төренгән. Кулында – ап-ак бишбармаклар, асылташлар белән бизәлгән көмеш таяк. Аягы тузанга батмасын йә таеп китмәсен, дигәннәрдер инде, ул килеп туктаган көймәле арба белән калкулыктагы биек мөнбәр арасына кызыл келәм дә җәеп куйганнар.

Молоствов – воевода түгел, аның төп ярдәмчесе генә. Воевода үзе вакланмаган. Ул юк икән, димәк, мөселман старшиналары һәм морзалар алдында Молоствов – иң зур түмгәк. Ниндидер бер укчылар сибае[5] мөселманнарны кисәткәннән соң гына, җыен мөнбәренә шушы түрәне чакырып чыгардылар.

– Мин сезнең бик күбегез белән Кырымга кадәр сузылган яу походын

[5] Сибай – офицер яисә хәрби төркем башлыгы.

кичтем, сезнең нинди батырлар токымыннан икәнлекне үз күзләрем белән күреп беләм, – дип, татар, башкорт, мари, чуваш старшиналарының салпы ягына салам кыстырудан башлап җибәрде ул. – Менә өч ай элек илнең мәркәзендә бөек падишаһыбыз Алексей Михайловичтан соң аның урынына тәхеткә утыртылган угылы Фёдор Алексеевич та көтмәгәндә, егерме яшендә вафат булып куйды. Мәрәсим атналарыннан соң боярлар думасы тәхетне мәрхүм Фёдор Алексеевичның бертуган энекәшләре Иван белән Пётр Алексеевичларга тапшырырга карар кылды. Ошбу тарихи җиде мең дә өч йөз туксанынчы елның[6] егерме алтынчы июнь көнендә генә, менә, бертуганнарның икесенә дә Мәскәү Кремленең Успенья соборында изге таҗ кидерделәр. Падишаһларыбызның икесе тиң рус дәүләтенә тугры хезмәт итәргә ант китерде.

– Нишләп бер тәхеттә ике патша соң ул? Ошбу гамәл бер хатынның күңелен ике ир чиратлап күргән шикелле була лабаса ул, – дип, Йәнәй олысыннан килгән старшина үзалдына сөйләнгәндәй кыбырсып алган иде дә, тавышының гайрәтен чамалап өлгермәгән, ахры, сүзләре дилбегә буе ераклыкта торган ирләргә дә ишетелерлек булып яңгырады. Байтак ирләр җиң очларына гына пырхылдап көлеп алды, мөнбәрдәге хуҗа үз тавышын яман кырыслатты.

– Мәрхүм падишаһыбыз Фёдор Алексеевич гел-гел чирләп торгач, авыр туфрагы җиңел булсын, яңа җирләр яулау ниятеннән бер генә әрсез күршебезгә каршы да сугыш алып барырга җөрьәт итмәде, нәтиҗәдә ил казнасы таба өстедәй такыр хәлдә торып калды. Шул сәбәпле яңа падишаһларыбыз олы гамәлләргә кузгалырдай мая туплау өчен иксез-чиксез илебез биләмәләренең бер өлешен чиркәү вә монастырьлар карамагына бүлеп бирергә мәҗбүр булды. Иван Алексеевич белән Пётр Алексеевич галиҗәнапларының изге фәрманы Казан илә Уфа воеводалыкларын да урап үтә алмый. Ошбу олуг фәрман буенча, Чулман белән Агыйдел буенда да яңа монастырьлар барлыкка киләчәк, моңарчы падишаһларның кулы килеп җитә алмаган берничә салада изге чиркәүләребез калкып чыгачак...

– Монысы ни дигән сүз тагын? Боярлар хөкүмәте Әләкси патшаның кырык-илле санә элек олуг фәрман белән беркеткән безнең кануни биләмәләребезне чиркәүләргә саткан булып акча сугамыни? Әләкси патша безгә биргән фәрманнарга борын аслары да кипмәгән ике малай ант иткән буламы? Уң кул ни кылганны сулы белми, ниткән уен соң бу? – дип, инде артык түзеп тора алмыйча, Теләкәй морза да үз сүзен кистереп әйтте.

Аны шундук башка старшиналар да эләктереп алды.

– Мөселманнар җиренә китереп, чиркәү илә монастырлар салырга, безне яңа кирмәннәр илә уратып алырга җыенасызмы әллә?

– Мөселманны талап, һаман да шул нәсара[7] атакайларын баету гына бит бу!

– Тәхеткә яңа падишаһлар менде дигәч тә, алар үз аталары язып калдырган фәрманнарны, аның антын аяк астына салып таптый икән!

– Бүгенге падишаһларның ошбу гамәле мөселман халкына бирелгән

[6] Христос туудан башлап саналган 7390 ел Юлианча 1682 елга туры килә.
[7] Нәсара – татарлар христиан дине вәкилләрен элек шулай атаган.

биләмәләр хисабына боярлар кесәсен генә баету була лабаса! Кайсы яклап борып карасаң да, бу бит безне, мөселманны талау!..

Воевода ярдәмчесе Молоствов старшиналарның дәһшәт тулы йөзен, йодрык болгауларын күреп алуга ук өшәнеп калган иде, куркуын сиздермәс өчен янындарак басып торган бер офицер белән ни турындадыр пышылдашкан булды. Аннары Уфа каласы ягына борылды, көмеш таягын югары күтәреп, кемгәдер хәбәр салды, берникадәр мизгелдән соң ук Бәрсуан елгасы ярында бер йөз чамасы укчы пәйда булды. Аларның кулында утчагыр мылтыклар шәйләүгә, янә Теләкәй морза корычтай аваз салды.

– Без ваевуда Каркадин чакырган җыенга коралларсыз килдек, илләмәгәр ялчы Молоствов ише боярны гына бөгәрлек егәребез бардыр.

Теләкәй икенче мизгелдә үк сикереп кузгалды да, бер кулы белән Молоствовны үзенең кочагына сосып алды, аннары итек кунычыннан ялтырап торган хәнҗәр тартып чыгарды һәм аны боярның бугазына илтеп терәде.

– Сак көчекләреңә кире чигенергә әмер бир, югыйсә иң әүвәл үзеңне суячакмын!

– Укчылар, чигенегез, чиген! Ялгыш ут ачмагыз! Старшиналар коралсыз килгән булган...

Ике-өч минуттан соң Молоствов көймәле арбасына кереп утырды да, ике пар ат җигелгән олы олау Уфа каласы ягына чабып китеп барды. Теләкәй морза әүвәл ым кагып кына үз янына Сәгыйт хәзрәтне чакырып алды да башка старшиналарның һәммәсенә ишетелерлек итеп, соңгы сүзен әйтте.

– Боярларның этлегенә барчагыз да шаһит булдыгыз. Без – коралсыз килгән халык, заяга кан түкмәс өчен бүген таралабыз. Ләкин тиз арада кара тунга төренгән, җирән сакаллы атакайлар килеп җитми калмас, шул чагында морзалар да үз авазын салыр. Моннан ары Казый мәчете янында түгел, шаукымлырак җирдә тупланырбыз...

## 4

Теләкәй морза су өстенә карап, үз йөзен күргәндәй белеп торган икән. Шәбез буендагы утарына кайтып, атна-ун көн чамасы да вакыт узмагандыр, Чулман ярындагы Сарапул ягыннан хәбәр килеп җитте.

«Пермь каласыннан ун баркаска утырган укчылар вә поплар килеп төште. Аларның бер кыйсеме Зыязетдин морза биләмәсендәге җирләрне казып, баганалар утырта башлады, анда ирләр монастыре төзеләчәк икән. Калган икенче зур нөгәр Ижау янәшәсендәге Пәрәү бистәсенә таба төбәп китте, алары Яуш морза биләмәсендә хатыннар монастыре төзергә ният итә икән...»

Янә бер атнадан тагын яңа хәбәр:

«Пәнҗәр авылында Талби морза биләмәсенең уртасында агач чиркәү төзи башлаганнар...»

Теләкәй морза утардагы зур йорт эчендә аранга ябылган айгыр шикелле әрле-бирле йөренә, кайчагында ике як чигәсен кысып, сындай катып кала. Ни эшләргә, нинди генә гамәл кылырга соң? Ул – Агыйдел буендагы иң зур җирбиләүче. Биләмәсенең мәйданы илле мең дисәтинә булып исәпләнә. Бер өлеше атасы Улакайдан ук мирас булып калды, аңа өстәп, әллә ни кадәр

җирләрне туснаклардан, өлешенә тигән яланнарны да эшкәртмичә яткан эт борчасыдай ялкау кавемдәшләреннән сатып алды. Шул биләмәләрендә бүген гомум саны ун мең башка тулган елкы көтүләре утлап йөри. Аның байлыгыннан йөзәрләгән старшина һәм сәүдәгәрләр көнләшә. Ләкин нәкъ менә шулар Теләкәй морзадан иң беренче итеп сүз көтә бит. Чөнки иң саллы, иң гаярь үгез кузгалса гына, көтүдәге сыер, сарык-бәрән, инеш суына егылып төшкән йомычка шикелле, аның давылына сосылып иярәчәк. Әгәр инде син дә олы башың белән кузгалмыйсың икән, ярлы-ябагайлар, яртылаш җиргә сеңгән йорт аламасының түбәсе тишек булмаганга шөкранә кылып утыручы вак-төяк куркак җаннар да таяк күрсәтүгә кача торган эт өеренә иярәчәк түгел. Димәк, син әйдәүче, син әләмче булсаң, хуш, меңләгән елкы көтүләре, хуш, буйсынуны белмәс газиз башым!..

**5**

Менә шулай бәргәләнгән көннәрнең берсендә Теләкәй утарына Агыйдел елгасы ярында эләктергән бер рус качагын тотып китерделәр. Теләкәй аңа текәлде дә артына ава язды. Фёдор! Кырым сәфәрендә Теләкәй котылгысыз үлемнән йолып калган мескен укчы Фёдор!

Дөрес, ул хәзер инде печән чүбе, токмач калдыгы, балчык белән аралашкан сакал-мыекка баткан. Теткәләнеп беткән киемнәренә дә, ябыгудан кибеп каткан йөзенә дә кызганмыйча карарлык та түгел. Күзләре дә тоз сипкәндәй тоныкланган сыман. Ләкин ул күзләрдә барыбер эчтән кабынган бер очкынны чамаларга була. Кием сәләмәләре арасыннан күгәреп беткән тәне, алардагы яра эзләре ачык күренеп торса да, укчы Фёдор карашындагы тәвәккәллек, карак бәндәләргә генә хас елгырлык исән.

– Безнең тарафка нинди җилләр китереп ташлады сине, сәфәрдәшем Фёдор? Син ничек мөселманнар арасына килеп чыгасы иттең әле болай?

Фёдор үзе дә гаҗәпләнүдән катып калган иде, ике кулы белән яңаклары буйлап аккан күз яшьләрен сөртә-сөртә, ниһаять, телгә килде.

– Теге чакта сиңа ярдәмгә килү – минем чират, дип шапырынган идем дә, мәгәр бу юлы да, менә, синең капкыныңа мин килеп каптым, мине үлемнән йолып калу да янә синең карамакта. Ә сөйләсәң, озак, аһ, бик озактыр, морза. Кырым походыннан әйләнеп кайтканнан соңниләр генә күрмәдем дә нинди яман болганышларны кичеп чыкмадым мин! Барын-барын да төкми-чәчми сөйләп бирим дисәм, озын төн дә җитмәс.

– Ә минем ашыгасы җирем юк, балаларым да имчәк сорап, еламсырап ятмый. Вакыт – тик безнеке. Менә, ашарыңа гына китертәм дә, күңел бушатканчы сөйләшеп утырырбыз. Син Мәскәүнең үзендә гомер иткән кеше бит, ә мәркәздә бәян итәрдәй гыйбрәтле хәлләр күптер. Тез дә тез генә. Миндәй томанага Мәскәү хәлләрен якыннан белеп тору үтә фарыз бүген...

Асылдан да, тамак ялгап алгач, мунча эченә бикләнеп, озак утырдылар. Фёдор үзе дә атна-айлар буе кеше күрми йөргәч, сөйләшүгә бик нык сусагандыр, катлап-катлап, кайта-кайта тезде.

– Мин Мәскәүдән түгел, ә үлемнән качып котылдым бит. Минем язмыш шундый хәерсездер. Ә Мәскәүдә хәлләр аңлатып та бетерә алмаслык яман. Анда ата – улны, ана – кызны белми. Фёдор патша үлеп киткән иде,

тәмам мәхшәр купты. Бояр Милославский белән сәнәктән көрәк булган Нарышкиннар нәселе пычакка-пычак килеп, туктаусыз сугышалар.

Теләкәй кыяр-кыймас кына:

– Ничек сәнәктән көрәк була алган икән соң алар? – дип, сүз кыстырып куярга мәҗбүр булды.

– Син аңлап та бетермәссең инде, Милославскийларның Мария атлы кызы – мәрхүм патша Алексей Михайлычка беренче булып чыккан хатын. Ул үлеп киткәннән соң Алексей патшага икенче тапкыр өйләнергә туры килә, бу юлы аңа дворян Нарышкиннар үз кызлары Наталияны бирә. Алексей патша үзе үләр алдыннан тәхетне улы Фёдорга бирүне васыять итеп калдырган. Фёдор үзе исә чирләшкә бер йолкыш. Биш ел чамасы гына утырып тора алды да, аннан каюк.

– Һе, менә ничек ансат, –  дип, Теләкәй янә сүз кыстырып куйды.

Фёдор аңа игътибар да итми генә янә дәвам итте.

– Вәт менә шуннан соң Милославскийлар белән Нарышкиннар арасында сугыш башланды да инде. Алексей патшаның исән калган хатыны Наталия тәхеткә үз малаен, ун яше яңа гына тулган Пётрны бердәнбер патша итеп утыртмакчы булган. Исәбе буенча Пётр бәләкәй чагында, ил белән шәхсән үзе идарә итәргә исәпләгән. Мәгәр Милославскийлар да бирешергә, майлы тагарактан читтә торып калырга һич тә теләми бит, шулар нахак юллар белән тәхеттәге Пётр янәшәсенә мәрхүм Мария Ильиничнадан калган Иванны төртеп кертте. Анысына уналты яшь булса да, ул да Фёдор кебек үк чирләшкә һәм мокыт, үзенең мәнфәгате өчен сугыша да белми. Аның бәхетенә, патша Алексей Михалыч исән чакта дөнья куйган Мария Ильиничнаның беренче баласы Софья атлы ирдәүкә кызы да бар бит әле. Менә шул Софья дигән азгынны берәр боярга кияүгә дә бирә алмадылар. Ә егерме биш яшенә җиткән, өстәвенә үгез сыман ажгырып торган ялгыз хатын ни эшләсен? Тоткан да стрелецлар приказының башлыгы булып торган Васька Голицын белән өегә башлаган бу. Әнә шул Васька белән аның төнге сандугачына әверелгән Софья түнтәреш тә корып өлгергәннәр. Шулар котыртуына кушылып, без ахмаклар Кремльнең эченә бәреп кердек. Әллә ничә боярны сөңгеләр өстенә ыргыттык. Нарышкиннар нәселенең атаманы булган Артамон Матвеевның җанын шулай өздек...

– Әстәгъфирулла, йа Ходаем! – дип, Теләкәй борын астыннан гына пышылдады.

– Менә шундый хәвефләрдән шөлләп, Нарышкиннар тәхеткә Иванны утыртып куярга да ризалашты. Хәзер тәхеттә, кеше көлдереп, борыннары юеш ике малай утыра, ә дилбегәнең асылы азгын Софья кулында. Без, бер күнегеп киткәч, фетнә давылын туктатмаган идек, Софья дворяннар гаскәре җыярга, дигән фәрман әзерләгән. Ул бит явыз, аның эче еланныкы төсле, кырыкмаса-кырык мәкер белән тулы. Дворяннар кузгалдымы, димәк, безгә каюк. Мин бит, сантый, Кремльгә иң беренче бәреп керүчеләр арасында булдым, Долгорукий дигән боярны да сөңгеләр өстенә үзем ташлаттырдым. Дворяннар белеп алса, иң беренче чиратта, мине дар агачына асып куячаклар, йә тегеләр шикелле үк сөңге очына ташлап, җанны кыячаклар. Менә шуңа чыгып шылдым да инде, Теләкәй морза. Тоташ гөнаһлы мин...

**Икенче бәйләм**

**1**

Укчы Фёдорның Теләкәйгә тезгән хикәяте хакыйкатьтән ерак түгел, ул айларда Мәскәү, асылдан да, кан күленә кереп чумган иде.

Чирләшкә Фёдор Алексеевич аттан егылып имгәнүдән интегә-интегә вафат булып куйгач, патриарх Иоаким, тол патшабикә Наталия Кирилловнага ярарга тырышып, көнендә үк әле яңа гына ун яшен тутырган, колгадай яп-ябык Пётр атлы малайны Кремль янәшәсендәге бер чиркәүдә яңа падишаһ дип игълан итәргә ашыкты. Югыйсә әле кичә генә патша булып торган Фёдорны мәңгелек дөньяга да озатмаганнар, атакайлар олы соборларда аның белән хушлашу мәрәсиме дә уздырмаган бит. Фёдорның җәсәде әнә Архангел соборында хушлашу һәм данлау сүзләрен көтеп ята. Аны җирләүне үткәргәч, боярлар думасын җыеп киңәшсәләр һәм шуннан соң гына кайсы энекәшенең тәхеткә менәчәге турында игълан итсәләр дә, ярар иде әле. Юк шул, дилбегә кулдан ычкына дип ашыкканнар, ахры...

Билгеле ки, моны Фёдорның анасы Мария ягыннан туганнары – бояр Милославскийлар да белеп алган. Араларында иң елгыры – Софья. Шул кичтә үк сөяркәсе Василий Голицынның приказ йортына барып җиткән бит бу. Ә наз күрмичә интеккән сазаган кыз җырны матур суза.

– Энекәшем Иванга уналты яшь тулды, собор кануннары буенча тәхеткә, иң беренче чиратта, тик ул гына дәгъва итә ала. Ләкин әнә Иоаким атакай хәерче Нарышкиннар кубызына тотып биегән бит. Нәселе затсыз Наталия шәп котырткандыр, әле Кремльдәге патша-туп кадәрле алтын-көмеш белән күмәргә вәгъдә итеп, Иоакимны үз ягына аударган булуы да мөмкин. Иоаким чиркәүдә тәхеткә тәне туктаусыз тартыша торган тилемсә Пётрны утыртып куячагы турында вәгъдә биргән. Атаем Алексей утыз өч ел элек булдырган Собор уложениесен аяк астына салып таптаганнар. Чиркәү кануннарын оятсыз рәвештә бозу бара. Тәхеткә иң беренче чиратта хокуклы Иван энекәшне якларга, хәерче Нарышкиннар нәселен Кремльдән куып чыгарырга кирәк, йә, нишлибез, Василий бәгырькәем?

Василий Голицын – җиһанга фәкать җилбәзәк хатын-кызларның башын әйләндерү, аларны үз кубызына биетү өчен генә яратылган чибәрләрдән-чибәр ир үрнәге. Түшәктә бик кыю һәм чамасыз назлы булса да, үзбаш гамәлләр кылудан качып кала белә. Бу юлы да патша кызы Софья сазаганга җавапларны урап кына дәште.

– Синдә да, миндә да яшен төсле ялтырап йөрүдән качып кала белү, ә утлы күмерне чит-ят куллар белән тоту отышлырак. Ходайныкын ахыргача алдан белеп булмый, аның исә синең үзеңә дә тәхеткә юлны ачып куюы бар. Алай-болай булып, Иван энекәшең белән Пётр шалапут та дөньядан китеп барса, шәхсән синең үзеңә дә патшабикә камыты насыйп булмагае.

Софья читән өстенә сикереп менгән этәч шикелле бер кагынып алды.

– Авызыңа бал да май, Василий бәгырькәем. Андый бәхет миңа килеп җитсә, син дә патша тәхетенә менеп утырачаксың. Әмма аңа чаклы, колга Пётрны әйләндереп ату өчен, ни генә уйлап табыйк?

Василий да Софья сүзләреннән соң бер карышка үскән иде инде, тәрәзә яктысына борылып ысылдады.

– Чит-ят куллар кирәк, дидем, чит-ят куллар. Мин приказ сараена

стрелецларның баш полк командиры кенәз Хованскийны чакыртып китертә алам. Чуртан сыман үтә шома һәм туймас тамак булса да, аның стрелецлар каршында абруе зур. Чөнки тегеләргә үз утарында казынырга, яңа йорт салырга яки базарда сату итәргә кирәкме, һәммәсе дә Иван Андрееч каршына килеп тезләнә, аннан рөхсәт ала. Яу походына кузгалсак та, шулай. Баш бирмәгән, бил бөкмәгән ирләрне дошман белән бәрелешкә кергәч, үлем белән йөзгә-йөз киләчәк алгы сафка билгели, үзенә баш игәннәрне обозда яшереп калдыра. Аңлашыла инде, тегеләр Хованскийның үзенә дә рәхмәт сүзләрен капчык-капчык яки мичкә тулы байлык белән кайтара. Дошманнан талап алган ганимәт[8] турында инде әйткән дә юк.

Софья иләмсез зур күкрәкләрен кашый-кашый кыбырсый башлады, моны шәйләп, Василий да дилбегәне тизрәк тарткалады.

– Мин Хованскийны приказ йортына чакыртып китертәм, ә син япа-ялгыз калгач, аны нык игәүлә. Дөрес аңла, бәгърем, икебезнең бер сүздә булганны хәтта Хованскийга да сиздермәскә кирәк, шуңа мин күренмим. Ә син аңа нәкъ миңа әйткән шикелле үк аңлат. Пётр тәхеткә абыйсы Иванны узып утырырга тырыша, ә канун буенча Иван тиеш, диген. Егерме стрелец полк командирларының егермесен дә үгетләү һич мәҗбүри түгел. Хованскийга биш-алты полковникны чакырып сындырса да җитә. Ә ике мең биш йөз яисә өч мең укчы бер йодрык булып тупланса, бу инде Кремльнең астын-өскә әйләндереп атарлык куәт. Әүвәл шул биш полковникны җыеп, табада биетсен, аннары тегеләре ипләп кенә, чылбыр буенча, астагы йөзбашларга да төгәл җиткерсеннәр. Кремльгә бәреп керә алсак, хәчтерүш Нарышкиннарны аяп йә кызганып маташу – ул хыянәт. Ә тәхет юлыннан Пётр хөрәсәнне алып атсак, полковникларның һәркайсын алтын һәм бүләкләр көтә. Менә шулай итеп үгетли белсәң иде, минем тиздән тәхеттә күрәчәк, кадерле патшабикәм!

Бетте, эреде, җебеп акты, Софья инде Голицын кая күрсәтсә, шул тарафта чишенеп ятарга да әзер иде. Патша кызы укчылар гаскәре бригадирын бармак очларына кадәр үбеп тәкрарлады:

– Тәхеткә менүгә ирешсәм, Ходаем да, падишаһым да син!

**2**

Фетнә Софья белән Голицын ниятләгәннән дә яман булып купты. Ачыгавыз Нарышкиннар сакны көчәйтү турында уйлап та карамаган, һавадагы бәхет кошын тулысынча үз кулыбызга эләктердек, хәзер аны ничек кирәк, шулай биетәбез дип, җиде кат болыт өстенә очып менгән, ахры. Ә укчыларның өч меңлек нөгәре Кремль капкаларын җимереп яки диварларына үрмәләп тә, көч әрәм итмәде, саны белән бер йөзгә дә тулмаган сакчы ирләрне ярсу үгез айкап ташлаган салам кибәне шикелле генә әйләндереп атты. Шылт иткән аваз да чыкмаган иде кебек, менә шул чагында бояр Милославский белән аның туганы, яшүсмер Толстой укчылар бистәсе буенча ат өстеннән сөрән салып узды.

– Нарышкиннар тәхеткә утырырга тиешле кануни патша Иванны буып үтергәннәр!

– Нарышкиннар патша улы Иванны юк иткән!

[8] Ганимәт – трофей.

Җиһанда әле май уртасы гына бит, беркемнең дә беркая да ашыкмаган чагы. Патша сараендагыларны да йокыдан менә шушы сөрән салган шашкын аваз уятты. Яшүсмер Иванның кайсы бүлмәгә кереп йоклавына игътибар итүче дә булмаганга күрә, Нарышкиннар нәселе дә зур хафага төште. Иң беренче булып, аны эзләп, Кремль баскычына чал сакаллы бояр Артамон Матвеев атылып чыккан иде, аны Бутыр полкы укчылары эләктереп алды да дивар өстеннән урам якка атты. Ә анда сөңгеләрен урман урынына өскә каратып баскан укчыларның сафы көтеп тора. Күк йөзенә сыңар гына аваз яңгырады:

– Ы-ы-ыһ!

Теткәләнеп беткән Артамон картның гәүдәсен кирмән алдындагы тирән чокырга болгап ыргыттылар. Ә кан исеннән исергән укчы ирләр, котырган кондыз урынына, яңа корбан эзләп, Кремль эчендәге сарайлар эченә атылды. Әллә каян гына баскычка тагын бер карт кенәз – Михаил Долгоруков атылып чыкты. Үзе туктаусыз кычкыра:

– Сез – җинаятьчеләр, сез – җәлладлар! Алексей Михалычның улы Иванга сыңар гына кеше дә тырнак очы белән дә кагылмады, ул Пётр олан янәшәсендәге бүлмәдә гырлап ята!

Ләкин кан түгүдән котырган укчыларны туктатмалы түгел иде инде. Михаил картны да кул-аякларыннан эләктереп алдылар да дивар артындагы сөңгеләр өстенә очырып төшерделәр.

Шул чагында Кремль баскычында инде Наталия Кирилловна үзе пәйда булды. Бер кулы белән – Иванны, икенчесе белән Пётрны җитәкләгән. Күзләрендә тоташ яшь кенә.

– Нинди Иванга кул сузу, ниткән үтерү турында шәрран ярасыз сез? Менә бит, патша улы Иван да, аның энекәше Пётр да бер дәрәҗәдә исән! Нигә нахак бәла ягасыз да, ни хакына мондый канлы фетнә белән үзегезне тапка батырдыгыз?

Көтмәгәндә, кинәт укчыларның йөзбашы Никита чәчрәп чыкты.

– Безгә синең абыең Афанасий Кириллыч белән энекәшең Иван хәбәр җибәрде бит. Димәк, безне кан белән таплау ниятен синең туганнарың корып куйган. Стрелецларны куып тараттыру, үзләре кубызына биюче яңа солдатларга алыштыру өчен түгелме икән? Әйдә, туганнар, шул мәкерле гайбәтияләрен эзләп табыйк та үзләреннән сорыйк...

Котырган укчылар сарай бүлмәләренә кереп тулды. Наталиянең энекәше Иванны патшабикәнең йокы бүлмәсендәге карават астыннан тартып чыгардылар. Аңа да, бер-ике минуттан эзләп табылган Афанасий картка да авыз ачып сүз әйтергә ирек бирмәделәр. Афанасий картны диварлар артындагы сөңгеләр өстенә болгап ыргыттылар, бичара Иванны кылычлар белән тураклап үтерделәр. Укчыларның икенче төркемнәре Нарышкиннарга туган тиеш булган бояр Языковны, кенәз Григорий Ромадановскийны, элек стрелецлар приказында башлык булып йөргән Юрий Долгоруковны да эзләп тапты. Бичараларның һәммәсе дә янә сөңгеләр урманы өстенә очып төште.

Патшабикә Наталиянең әтисе Кирилл Полуэктович та исән икән әле, ул да иң түрдәге чоланнарның берсендә качып яткан. Бичараның айлар буена кайчы күрмәгән чәчләре пумаланы хәтерләтә, ләкин акшар яккан шикелле чап-чал. Гәүдәсе дә бакчаларга карга көтүен куркытырга куйган карачкы

кебек, шыр сөяктән тора. Аның сыңар чиләк күтәрерлек, үзе белеп тун киярлек егәре дә калмагандыр инде, аз гына төртсәң дә, авып китәр төсле. «Моңа сөңге очы да, кылыч йөзе дә әрәм», – дип, бөтенләй тимәделәр. Укчыларның гына кайсыдыр сарык йонын кырка торган олы кайчы белән чәч һәм сакалларын кискәләп бетерде. Соңыннан йөзбашы Никита актык сүзен әйтте:

– Белоозёрск монастырена озатыгыз моны...

Укчыларның елгыр бер төркеме сарайда лекарь булып йөргән килмешәк немец фон Гаденны да эзләп тапкан. Укчыларны тотып торышлы түгел, бәйләнер сәбәбен дә уйлап чыгарганнар:

– Фёдор патша егерме яшендә гүргә кереп ятты, аны менә шушы нимес агулап үтерде бит.

Бу юлы да йөзбашы Никита сүзсез кул селтәде. Немец лекареның башын кыеп төшерделәр...

Башкалар арасында посып кына йөргән Фёдор әле патшабикә Наталиянең энекәше Иванны йокы бүлмәсеннән сөйрәп чыгарганда һәм аны кылычлар белән тураклаган чагында ук игътибар иткән иде. Анасының биленә чытырдап ябышкан Пётр агарынып каткан. Күзләрендә яшь тамчыларының эзе дә юк. Ләкин ун яшьлек малайның тәне генә түгел, берьяк яңагы да өянәк ябышкан шикелле туктаусыз тартыша, ә ул үзе кулын күтәреп, йә шул яңагын ышкып куя, йә тынычландыра алмый. Кан күрүдән мондый мескен хәлгә төшкәнме ул, әллә туган агасының һәлакәтен авыр кичерәме? – бәяләрлек түгел. Әле ярый, Ромадановский, Долгоруковларның, шушы ук немец фон Гаденның соңгы минутларын күреп өлгермәде. Кем белә, әгәр шаһит булса, бөтенләй һушын югалтып егылуы, йә тартыша-тартыша, үзенең дә китеп баруы бар иде...

**3**

Өч көннән соң укчы полкларның башлыклары «падишаһ» Пётр галиҗәнапларына, стрелецларның бирән боярлар тарафыннан йотып бетерелгән жалование күләмен язып, «үтенеч» кәгазе илтеп бирде.

– Фёдор патша түләмичә килгән жалование бурычы өч ел эчендә ике йөз кырык мең тәңкә күләмендә җыелган. Әгәр шуны бер ай эчендә кайтарып бирмәсәгез, стрелецлар Мәскәүдәге барча байбәтчәләр йортын талап чыга!

Наталия Кирилловна белән Пётр гына түгел, Кремль тирәсендә чуалган барча бояр һәм кенәзләр дә таракан капкандай тоташ кара көйде.

– Казнада стрелецлар өчен каралган сыңар тиен дә юк бит!

Менә шул көннәрдә фәрманнар чыгарырга бер хокукы да булмаган Софья – патша кызы, көтелмәгән карар игълан итте:

– Ашыгыч рәвештә бөтен ил буенча көмеш һәм алтын савыт-сабаларны җыярга да, аларны эретеп, стрелецлар алдындагы бурычны кайтарырга!

Мондый карар, билгеле ки, укчыларның йөрәгенә сары майдай ятты, ике-өч көннән соң ук Кремльгә яңа петиция язып китерделәр:

– Стрелецлар авырыбрак торган Иванны да – патша итеп, ә ул тулысынча савыкканчы патшабикә Софьяны ике хакимнең дә регенты итеп билгеләвегезне, ә Пётрның тавыш-гауга чыгаруга юл куйган анасы Наталия Кирилловнаны Кремльдән читләштерүегезне үтенәбез. Янә дә бер

гозер: стрелецлар гаскәре өстенә күләгә төшмәсен өчен хөкүмәт май ае уртасында юк ителгән боярларны җинаятьче һәм карак дип танырга, шул карарны аерым хәтер тактасына язып, Кремль каршындагы җәза мәйданына урнаштырырга тиеш...

Хөкүмәт капкынга эләккән, аның тыпырчынырлык та егәре юк иде. Егерме бишенче июнь көнне Успения соборында, асылда да, Иван белән Пётрның икесенә дә таҗ кидереп, халыкны алар алдында ант иттерделәр. Патшабикә Софья ике таҗдар туганының да регенты булып игълан ителде. Хәзер аңа Голицын гына түгел, соңгы атнада стрелецлар гаскәре башлыгы итеп үзе үк билгеләгән кенәз Хованскийның да кочагында берсеннән-берсенә күчеп назлану өчен күк капусы ачылган иде инде...

**4**

Кремльдәге шушы мәхшәрне нинди элемтә аша чамалап алганнардыр, август уртасында Мәскәү каласы әллә каян гына әйләнеп кайткан динне искечә тотучы кавем белән тулды. Аларның башлыгы Никита Пустосвят атлы кеше икән, шуның котыртып торуы нәтиҗәсендә әллә ничаклы чиркәү эчендә искечә динне яклап кычкыручы мөнәдиләр[9] акырышып йөрде.

– Өч бармак белән чукыну – ул иблисләр эше! Успения соборыннан куып чыгарылган Никон атакайны һәм дә ике бармак белән чукынуны кире кайтарыгыз!

Кремль эчендәгеләрнең күпчелеге әлеге мәхшәр уены белән ниндидер сихерле кул идарә итүен дә нык чамалый, әмма өзеп кенә, кемнеңдер өстенә гаеп ташларга һич тә кыймый иде. Шул вакытта янә, барысын да шаккатырып, патшабикә Софья аваз салды:

– Хөкүмәт эчендәге кайбер боярлар дворяннар ополчениесен төзү яклы, ә дворяннар сәхнә түренә менсә, алар стрелецларны куып таратачак!

Шул сүздән күкерттәй кабынган укчылар Пустосвят атлы иске динчене эләктереп алып, аның башын кыеп төшерде. Яңадан кан түгелүне сәбәп итеп, Софья үзе, барча кыз туганнарын җыеп, Мәскәүдән Ярославль ягындагы Коломенское авылына чыгып качты, ахыр чиктә Троице-Сергиев монастыреның таш диварлары артына кереп томаланды. Ул моннан укчылар башлыгы кенәз Хованскийны ашыгыч рәвештә очрашуга чакырып хат юллаган иде, тегесенең пырдымсыз җавабы регент галиҗәнапларын тораташтай итте.

– Син кабат кенәз Голицын кочагына кергәнсең бит инде, азгын айгыр кирәксә, тот та шуны чакыр.

Ике тәүлек вакыт үтүгә инде яңа хәбәр: Софья үз сеңелләре белән качып йөргән чакта иске динчеләр дә тик ятмаган, алар кенәз Хованский белән аның улы Андрейның башын кыеп аткан...

Софья качкач, берәр атнадан соң, аның янына боярлар думасындагы бүтән башлыклар да килеп җитте. Сергиев монастырена бикләнгән килеш кенә Софья Мәскәүгә көтелмәгән яңа фәрманын юллады.

– Мәскәүдәге бунт мәхшәрен туктатырдай бүтән көч юк, дворяннар ополчениесен чакырырга кирәк. Шунсыз стрелецлар гаскәрен хөкүмәткә буйсындырып булмый...

[9] Мөнәди – глашатай.

Сергиев монастыре белән Мәскәү арасында чабулап йөрүче олаулар стрелецларның үз гомере һәм ата-анасы белән ант иткән хат вә үтенечләр белән тулды. Алар, чыннан да, баш бирмичә маташкан булып ялгышуларын өстәмә аңлатмаларсыз да сизенә бит. Ирләрне гаскәрдән куып чыгардылармы – аларга хөкүмәт тарафыннан аккан акча елгасы шундук туктаячак. Ә аларның күпчелеге хуҗалык алып барырдай йә сәүдә белән мантырдай эшем иясе түгел. Ниндидер чит илләр өстенә яу белән барасы, гомереңне балта астына куеп, үлем белән алыш-биреш уйныйсы юк. Мәскәүдә яткан өчен, тиктомалдан дигәндәй, акча килеп тора. Ят мич башында иплә́п, тыныч кына...

Үкенү тулы хатлар капчык-капчык җыелгач кына, Софья монастырьның үтә яшерен бер бүлмәсендә барча укчылар исеменнән баш иеп килгән кенәз Фёдор Шакловитыйны кабул итте. Боларның яшерен сер алышуы таңга кадәр сузылды, аның каравы, күндәм кунак үз кулына бик кадерле фәрман тотып чыкты.

– Кенәз Фёдор Леонтий улы Шакловитый галиҗәнаплары стрелецлар приказының башлыгы итеп билгеләнә, моннан ары ул – хөкүмәт таянычы.

**Өченче бәйләм**

**1**

Teләкәй морза Фёдорны үз яныннан аткару турында уйлап та карамады. Тәүге көннәрдә, кырыкмаса-кырык яктан сораштырып, ул аның үзәгенә үткән иде инде.

– Син Мәскәүдән Агыйделгә тикле араны ничек исән-сау көе үтә алдың да, ничек бер генә рус сатлыгы да сине үзеңдәй стрелислар кулына илтеп тапшырмады?

– Мин Мәскәүдән чыгып качкан чакта ук бояр ялчылары, төрле калалар янында төнге каравылга чыга торган атлы дозорлар кулына эләгергә һич тә ярамауны чамаладым инде. Рус авыллары яныннан узып барышлый түтәлләрдән кәбестә белән кыяр, бер-ике йорт абзарыннан тавык белән каз чәлдереп тә тамак ялгадым. Безнең кавемдә койма кою дигән тәртип юк бит, аларыннан чәлдерү күп тир сорамады. Ә менә Малмыж белән Кукмара, алардан соң Мамадыш шикелле сезнең татар авылларыннан, дөресе көтүләреннән сарык чәлгән чакта ике-өч урында тотып кыйнадылар. «Мин стрелец бит, стрелецлар башлыгы Васька Голицын фәрманы буенча Уфа каласы ягына хезмәткә барып ятам», дип аклангач кына, бик яман ярсалар да, ахыр чиктә барыбер җибәрделәр. Сезнең халык гаҗәп: патша эше белән йөргән кешеләргә изгеләштереп, фәрештәдәй карый...

Уйланып йөри-йөри дә Теләкәй морза бу качактан Мәскәү хәлләренә әйләнеп кайтмыйча да калмый.

– Менә син Суфия патшабикәгез стрелисларга акча түләү өчен көмеш савыт-саба җыярга фәрман бирде, дидең. Ул алтын-көмешләрне кара халыктан гына җыйдылармы, әллә боярлар да өлеш чыгардымы?

– Җыйды, пычагым! – дип, Фёдор ярып салды. – Кайсы бояр гына үзен талаттыра инде? Аларның берсе дә кул-аякларын арканнар белән бәйләп, суярга егып салган сыер яисә сарык түгел ләбаса. Алар Софья фәрманын ишетеп алуга ук барча алтын-көмешләрен йә базларына төшереп яшерде,

йә сандыкларга бикләп, урманнарның иң чытырман җиренә илтеп күмде. Җыйсалар да, шул вак-төяк кенәзләрдән, дворяннар ихатасыннан гына талап чыга алдылар. Софья вәгъдә иткән ике йөз кырык мең урынына йөз мең тирәсе генә түләү тараттылар.

Шушы сүзләрне ишеткәч, хәзер инде Теләкәй ярсып купты.

– Тукта, тукта! Ул явыз патшабикә боярлардан акча җыя алмагач, хөкүмәт бурычын бездәй мөселманнар, беренче чиратта, татар сыртына күчереп салган була түгелме соң? Әнә ул тоткан да татар авылларының биләмәләрен чиркәү илә монастырьларга өләшә башлаган. Шул юл белән казна өчен акча туплый, имеш. Ә чиркәү сала йә монастырь калкыта башлаган авыллардагы татар игенчеләре кая гына барып сугылсын да, кайда төпләнсен, ди? Безнең авылны чиркәүгә биргәннәр дип, алар кайсы гына күршесенең ихатасына йә биләмәсенә кереп сыена ала? Һәрбер адәм баласына, беренче чиратта, үз күлмәге, үз милке кадерле. Шуңа күрә бер үк яланлыкны икегә бүлеп чабарга, бер күлдән биш-алты, хәтта ун гаилә балык тотуларга, йомгаклап әйткәндә, бер бозау тиресен җиде кешегә бүлеп таратырга бер генә татар гаиләсе дә риза булмаячак.

– Әйе, әфәндем, син дөрес сукалыйсың. Софья боярлар сыртыннан затлы тунын салдырып алу урынына, ул тун хакын сездән түләтергә җыена булып чыга. Мәгәр, мәгәр...

Фёдор тынды, ә Теләкәй аңа текәлде дә нык сагаеп калды.

– Нәрсә «мәгәр»? Сөйлә, сөйлә, әйдә.

– Мин бу елан кеби явыз Софья сезнең авылларга чиркәү йә монастырь салу белән генә туктамас, дип уйлыйм. Әгәр сезнең халыкны да шул чаңлы чиркәүләр һәм кирмәндәй монастырьлар эченә тартып кертә алмаса, ул аларны шып-шыр далада яисә иксез-чиксез ком чүлендә төзегән кебек була. Чиркәү дә, монастырь да меңәрләгән адәм баласын үз эченә йоту, каршы торганнарны көчләп чукындыру, ахыр чиктә хөкүмәт кубызына биетү өчен кирәк. Чиркәү калыктымы, аның поп вә игуменнары сезнең халыкны мәҗбүриләп чукындырмый калмаячак.

– Ничек итеп, ничек?

– Ысулларын тиз уйлап табарлар. Кемдер менә минем шикелле караклык өстендә тотылыр. Кемдер үзе дә белми-чамаламыйча хатынын яки күршесен сугып үтерер. Сезнекеләр турында «атларны бик оста, аякларына киез урап йә бүрек кидереп тә урлыйлар», дигән дан чыккан бит. Менә шул ат урлаган өчен дә каракларны каен ботагына асып куймаска мөмкиннәр. Кеше үтергән өчен тимерчыбыклар аралап үрелгән камчылар белән тотып ярганнан соң чиркәүдәге атакай каршына китереп бастырырлар. «Йә үзеңне богаулап, Себергә сөрәбез, йә син изге тәрене тагарга ризалашасың», дип, бичара татарларны ике ут арасына кертеп газаплarлар. Бәндәләр арасында эченә корт төшкәне, сыгылма биллесе, куркак җанлысы бар. Татарларның һәммәсе дә Теләкәй морзадай башын җуйса да, ирeгeн вә рухын сатмый торган пәһлеваннар түгел. Начарлык юрагандай ялгышудан куркам, әмма синең туганнарың арасында да Коръән урынына тәре үбә башлаячак сатлык җаннар бик күп булыр әле.

Качак Фёдор нотыгын тәгалләгәндәй, тып-тын утырды да янә кыяр-кыймас кына өстәп куйды:

– Сиңа элегрәк әйтергә кыймаган идем дә, утлы күмерне куенда яшереп йөртүе дә кыен. Мин әле качып киткәнче, Мәскәүдә чагында ук стрелецлар башлыгы Васька Голицын бүлмәсендәге бер сөйләшүне ишетеп калдым. Башыннан азагына кадәр түгел, ярты-йорты гына. Уфада утырган воевода Коркодинов яшь патшалар исеменә атап, хат юллаган. Аны әүвәл юха елан Софья эләктергән, аннары хатны Голицын кулына биргән. Коркодинов татар морзалары өстенә чиләк-чиләк дегет сибеп чыккан. «Морзалар волость старшиналарын да, тулаем халыкны да патша хакимиятенә буйсынмаска, кирәк була калса, корал белән каршы торырга чакыра». Мин бу сүзләрне мич артына кереп баскан җиремнән генә, чак ишетеп калдым. Бу як калалардагы воеводалар, Софья хөкүмәте белән сүз беркетеп, сезгә каршы тагын яңа этлек әзерләмәсә генә ярар иде инде.

– Алар соңгы елларда болай да чамасыз күп этлек кылып өлгерде, – дип, Теләкәй бер учының бармакларын җәйде. – Юри санап карыйк. Чулман аръягында чик линиясен төзибез, дигән булып, Чаллыдан башлап, Сәмәргә чаклы ничәмә-ничә кирмән корып куйдылар. Һәр кирмәндә даими гарнизоннар, стрелисләр нөгәре тупланды. Барчасын берьюлы әйләндереп атарга кодрәтебез җитми. Патша бурзайлары татарларга тимерче алачыклары булдыруны, корал ясауны тыйды. Без ат дагалатырга, арба тәгәрмәченә тимер кыршау кидерергә кирәк булса да, йә башкорт, йә чирмеш тимерчеләре алдына барып тезләнәбез. Шул сәбәпле, ахры, һичбер авылда да корал базлары, корал келәте юк. Ә коры кул белән, чамалыйсың булыр, күк йөзен дә төртеп тишеп булмый...

Инде аягүрә торып баскач кына, Теләкәй үз күңелендә туган иң зур хәвефне ярып салды.

– Татарлар иленә тагын көчләп чукындыру афәтенең әйләнеп кайтуы бар...

## 2

Теләкәй тиз арада әүвәл Чулман аръягындагы Пәнҗәр авылына, шуннан кайтышлый ук күршедәге Агыйдел яры буйлап сузылган Өшәргә юл алды. Хәл коточкыч харап, Пәнҗәр мескен колга әверелеп калган, аның исеменә тикле «Пьяный Бор» дигән ярлык тагып куйганнар. Үзләренчә, монда гасыр буена яшәп яткан татар авылына исереклектә, азгынлыкта гаеп такмакчылар. Хәзер инде авыл түрендә, биек яр өстендә, күзгә кергән печән чүбе йә бөтен тавык келәтлегенә хуҗа булып алган шәпле әтәч сыман, корсагын як-якка көмәнле хатындай җәеп салган, чаң манарасын торна сыман күккә сузган бик зур чиркәү чекрәеп утыра. Аның тирәсендәге барча йорт вә абзарлардан татарларны куып чыгарганнар, аларга күкрәкләрен киереп, кып-кызыл борыннарын югарыга чөеп кенә атларга яратучы ирләр һәм итәк-чабуларын ачып йөрергә гадәтләнгән хатыннар кереп тулган. Элек татар базары булган мәйданны да хәзер аерырлык, бәяләрлек түгел. Элек читтәге рәтләрдә каклаган каз, казылык, катык, бал, май, как, оекбаш, чигүле шәл, ыңгырчак, камыт, тәгәрмәч, тагын әллә нинди шөшлеләргә, ышкы вә балталарга хәтле сузып салган сәүдә өстәлләре тезелешеп торса, хәзер уртада, иң югары урында тозланган кәбестә, гөмбә, кыяр, дуңгыз башы белән дуңгыз чәкәннәре, мал эчәгеләре, әче бал, көмешкә, сынган

тарак, әллә кайларга бәрелеп чүкелүдән әтәч кикриге хәленә килгән кылыч, чалгы, урак...

Авыл читенә чыккач, Теләкәй, сулыкка төшәргә дә хәлләре калмаган казлар шикелле, өянкеләр күләгәсенә качып утырган ике-өч картка сүз каткан иде, тегеләр өметсезлек белән кул селтәде.

– Безнең төбәктәге берничә авылга исән көе ясин укыдылар бугай, ир узаманнары давылдагы нарат сыман сынды. Мәчетебезне ошбу кяферләр вә аларны озата килүче солдатлар җимерә башлагач, «бер тәүлек кенә булса да вакыт бирегез, Аллаһ йортын үзебез икенче урынга күчерәбез», дип, ул кабих җаннарны туктатырга ымсынган кеше дә табылмады. Әллә үзебез шундый таркау, өметсез без, әллә «балта сабын салам көлтәсе белән сугып кына сындырып булмый», дип, һәммә ирләр күнде, кул селтәде.

– Гасыръярым меңәрләгән татар авыллары элеккечә тереклек итә, мәчетләрен җимереп ташлауга да күз йомып тормыйлар, – дип, Теләкәй пәнҗәрләләр күңелендә иман нуры, мин-минлек уятырга да омтылып карады, тик файдасыз.

– Без инде җиденчене дистәне кырлыйбыз, тәнебездә кодрәт, җегәр дигәннәре мыскаллап кына калды. Ә балалар, угыллармы? Аларын да мичәүләп җигәрдәй айгыр итеп үстерү насыйп булмагандыр. Мәчетнең манара такталарын каерып ата башлагач, биш-алты ир сәнәк-көрәк тотып каршы чыккан иде дә, өчесен елга уртасында батырып үтерделәр, калган өчесенең кулларына зынҗыр салып, катарга дип, Себергә озаттылар. Ул бичараларның хатыннары илә балалары, аларга ияреп, тагын унбишләп гаилә Шаршады дигән авыл куенына күчеп китте. Монда шул без, җегәрсез карт-корылар гына торып калдык...

Өшәргә барып җитсә, күз тимәсен, анда хәл яхшырак. «Чиркәү күтәрәбез!» – дип ажгырып килгән өч дистәдән артык ирне авылга кертмәгәннәр. Авыл башлыгы булган Ярхәм горурланып сөйли.

– Без Бакырташ тавының түбәсенә каравылчы ирләр бастырып куйган идек, шулар «дошман килә» дип, учак яндыруга ук, барча йортлардан җыелышып, ике йөзгә якын ир-ат, аларга ияреп, янә йөз иллеләп хатын Ямалы юлына тезелешеп басты. Озын чылбыр, ә кулларда күсәк, чалгы, сәнәк. Имам Касыйм хәзрәтебез алга чыгып басты. «Шушында бер-беребезне кырып бетергәнче орышабыз, мәгәр авылыбыз урамына аяк бастырмыйбыз, Аллаһ йортына да кул тидерергә ирек бирүчеләр булмаячак!» – дип, усал тавыш белән өздереп кенә әйтте. Чалгы-сәнәк тоткан ике йөз ирне күрүгә үк шыр җибәрде. «Безнең кулда указ, авылыгыз Савва Сторожев монастырена бирелә, без сезнең җирдә чиркәү күтәрергә тиеш», – ди бер җирән сакаллысы. «Патшалар фәрманына каршы төшәргә сезнең башыгыз икеме соң әллә?» – дип, инде челәндәй яп-ябык гәүдәле икенче җирәне безне өнсез калдырмакчы була. Шуннан җыйнаулап акырдык. «Авылга кертмибез, кая кирәк, шунда олагыгыз!» Сындылар. Без Сәүз атлы озын күлнең урман, болын ягында утырабыз бит. Ә тегеләр Агыйделгә таба чигенде дә, күлнең бөтенләй капма-каршы ярында чатыр корды. Хәзер инде беләк юанлыгы япь-яшь усаклардан төзеп куйган өйләре алты-җидегә тулды бугай. Булачак чиркәүләренең ниргәләрен бүкәннәр өстенә утырта башлаганнар. Эшләре кызу бармый, тагын

күрше-тирә авыл ирләре җыелышып килеп, үзләрен куып җибәрүдән нык шүрлиләр сыман.

– Булды, аңлашылды, – дип түгәрәкләде Теләкәй. – Ярхәм кордаш, авылның башлыгы һаман синдер инде. Халык каршында бер карарымны да ачып салмыйм. Өч тәүлектән соң Шәбез елгасы ярындагы утарымда көтәм.

**3**

Тирә-юньне куе караңгылык чолгап алганда, Теләкәйнең утарына җыелган ирләр саны егермедән артты.

– Ниһаять, тупландык, – дип, тыйнак кына елмаеп куйды хуҗа. – Ялгышмаганмын икән, берегез дә чакыруны аяк астына салып таптамады.

Теләкәй теләсә-теләмәсә дә, кунаклары буйлап күз йөгертте. Күпчелеге белән бик күптәннән таныш. Байсар авылыннан килеп җиткән Гафур, Әмәкәйле Фәрхәт, Кормаш узаманы Талип белән алар ун ел элек, патша Алексей Михайлович нияте буенча, Кырым ханы Мәхмүт-Гәрәйнең Тын елга ярындагы барча төмәннәрен туздырып бетерергә, берочтан шул Тын тамагындагы Азак кирмәнен дә кулга төшерергә дип җыелып барганнар иде. Дөрес, татар белән башкортлар ул сәфәрдә бер дә Кырым җайдаклары өстенә баш югалтып вә дуамалланып ташланмады, орышулары да шул – исәпкә бар, санга юк иде. Орышудан, кан коюдан бигрәк, чит-ят тарафларны, «кенәз белән бояр – иң беренчел дошман», дип сүккән кардәшләрен күреп кайттылар, шунысы да файда.

Теләкәй кабызачак очкынны сизенеп, әнә Өшәрдәге Ярхәм дә, Ямалы авылы башлыгы Миргали дә килгән. Икесе дә дөрес чамалый. Әгәр лапасыңа кергән сасы көзәнне иң тәүге омтылышында ук сугып үтермәсәң, ул синең кетәклегеңдәге тавыкларны соңгысына тикле буып чыга. Болар да бакчаларына көзән кергән хәлдә. Сәүз күле аръягына урнашып алган утыз килмешәк гаиләнең маңгаена вакытында күсәк белән ора белмисең икән, иртәгә алар өшәрнекеләрне дә, ямалыларны да яшәгән туфрагыннан куып җибәрәчәк, йә үз кавеменә йотып бетерәчәк...

– Сүзне озакка сузмыйк, ул бит сагыз түгел, – дип, Теләкәй җитдиләнде. – Аннары минем күңелемдә сезгә чит-ят бер генә ният тә юк. Һәммәгез дә белә: безнең йортка дошман кавем керде. Әнә Пәнҗәр илә Бөре кирмәненә терәлеп торган Аскында, Агыйдел аръягындагы Березняк-Каенлы уртасында кара тунлылар өр-яңа чиркәүләр аякка бастырды. Ул авыллар хәзер иртәнге азан урынына биек манаралардан яңгыраган чаң тавышын тыңлый. Менә, Өшәр авылына да нәсаралар килде, Аллаһның рәхмәте вә авыл ирләренең бердәмлеге илә аларны мөселманнар арасына әлегә кертмәделәр. Иллә мәгәр «әлегә» генә бит ул, тик «әлегә». Чөнки алар чигенергә дип килмәгән, чөнки без – инде бер мәртәбә тезләндерелгән вә җиңелгән халык. Мәгәр гасыръярым буе алар безгә авызлык кидертә алмады, без үз динебезне сатмадык. Алар моны кичерә дә, гафу итә дә алмый. Алар яңа төрле һөҗүм белән килә. Хәзер алар безнең арага үтеп кермәкче, мөселман кавемен эчтән агуламакчы. Безнең җирне бүлгәләп, күкрәк уртасына пычак кадаган төсле, алар үзәк авылларда чиркәү манаралары калкытырга, чаң тавышлары белән аңны томаларга ниятли...

Теләкәй тагын бер мәртәбә һәммә ирләргә күз атты, бил каешындагы көмеш аелны рәтләгәндәй итте.

– Башка юлыбыз юк, без үз кордашларыбыз гына түгел, угыл-оланнарыбыз алдында да бурычлы бит. Йә без хәзер үк алар төзегән чиркәү вә монастырьларны җимереп атабыз, йә алар мөселман җиренә нәсара каешы кидереп, безне буып куя.

– Чиркәүләрен әйләндереп атсак, алар яңадан, бәлкем, килеп тормаслардыр? – дип, Кыргыз авылы хуҗасы Котлыкай сүз кыстырды.

Теләкәй имән бармагын күк йөзендәге билгесез затка төбәп болгады.

– Анысы бездән тора. Бездән соң киләчәк оланнарга нинди өлге бирәбез, алар шул ук юлны сайлар. Ошбу җан бирмәк орышта сукмак күрсәтер тарафлар күп түгел. Йә тезләнеп муеныбызга тәре асып куябыз да, аннары нәсара ирләре безне гомер буе әнә шул тышау-муенчактан тартып йөртә. Йә газиз ата-бабаларыбыз иңдерелгән туфракка нәсара чиркәве кертеп җанны тапламыйбыз. Үзем шушы юлда шәһит булырга да риза.

– Без дә, без дә, – дип, ике-өч ир әләктереп алып, шундук аваз бирде.

– Канга – кан, үлемгә – үлем! Олуг бабаларымызның васыяте.

Теләкәй сыңар кулын күтәреп тавышларны басты.

– Мин менә мондыйрак хәрәкәт отышлы булыр, дип күрәм. Иң әүвәл, авылларыгызның һәркайсында зур булмаган, мисалга, илле-алтмыш җайдаклы гына нөгәрләр туплап кую, аларны тиешле корал вә юллык ризык белән тәэмин итү фарыз. Моны ике көннән дә озаккарак сузу гөнаһ, ә өченче тәүлектә – юл. Бер канунны бүген үк мәңге онытмаслык итеп ятлап куюыгызны таләп итәм. Татарларның иң яман, иң чиркандыргыч чире шулдыр – без шәхси мәнфәгатен үз кавеменнән өстен куючы сатлык җаннарның тамырын корыта алмаудан гомер буе газап кичерәбез. Менә шул бәла аркасында дәүләтсез калдык, коллыкка төштек, әле булса шул хафа җәтмәсеннән ычкына алмыйбыз.

Әллә үзенең артык кыза башлавын чамалап өлгердеме, Теләкәй түгәрәк сакалын сыйпап куйган булып, аз гына тын алды.

– Һәрберебезгә тәртипкә, саклыкка, уяулыкка өйрәнмичә булмый. Шуңа күрә юлда бервакытта да олы нөгәр булып, кырык-илле ирне бер йодрыкка туплап, ачыктан-ачык күчеп йөрүгә һич тә юл куймагыз. Без никадәр яшеренебрәк йөрсәк, дошман өчен шулкадәр үк көтелмәгән һөҗүм килеп чыга. Тач менә зәһәр елан сыман, көтмәгәндә ташланып, ахыргача чагу. Инде кирәк ноктага килеп төртелү алдыннан гына бергә кушылыгыз. Әле ул очракта да, авыл яки кирмәннең тау итәгенәме, әллә чокыргамы урнашуын чамалап, берьюлы ике-өч яктан бәреп керергә, дошманга тын алырга, уш җыярга ирек калдырмаска кирәк. Ә ахыргы максат – татар туфрагында калыккан чиркәүләрнең берсен дә калдырмыйча җимереп бетерү. Аты да калмасын, нигезе вә хәтта көле дә!..

Бар тараф та күздән кичерелгән шикелле булгач кына, Теләкәй һәрбер авыл башлыгына аерым әмер тезде.

– Хәким илә Халит, сез ике көннән соң ук таңда Пәнҗәр авылына төбәп, юлга чыгыгыз!

– Байсар белән Пучы ирләре, аерым-аерым, Җәнҗегет илә Такталачык янында Агыйделне кичә. Аннары юлыгыз Каенлы-Березнәк саласына.

Ахыр чиктә мин үзем дә сезнең нөгәрләр янына килеп кушылмаммы икән?

– Садри, Рамай! Минзәлә алдындагы Кәҗә авылында чиркәү калкытканнар, шуңа юнәлегез. Котлыкай илә Ябалак, сезгә Агыйдел буендагы Әндерәй саласы кала. Әле мин бәләкәй чакта гына ул Бишбүкән атлы татар авылы булып санала иде, әнә хәзер аның башына Әндери дигән капчык кидерделәр. Шуның уртасында күтәрелгән чиркәүне юк итегез!..

Ирләр иярләргә сикереп менгәч кенә, Теләкәй көр тавыш белән соңгы әмерен яңгыратты:

– Авылларны яулап, чиркәүләрне юкка чыгаруга ук, мин фәкыйрегез тарафына хәбәр китерергә дә онытмагыз!

**Дүртенче бәйләм**

**1**

Воеводалар оясында – матәм. Бояр Коркодинов сараена уттай хәбәрләр калай түбәгә йодрык зурлыгындагы боз яугыры койган шикелле, бертуктамый агылып кына тора.

– Әгерҗе янындагы Пьяный Бор авылында, Минзәлә белән Уфа арасындагы юлның Ык ярында урнашкан Кәҗә авылында ике ай элек кенә корып куелган чиркәүләрне Сөн елгасы буйларында яшәүче татарлар оештырган отрядлар яндырып юк иткән.

– Ижау белән Әгерҗе арасында, Пәрәү авылы янында корыла башлаган хатыннар монастырен Агыйдел ягыннан килгән татар җайдаклары пыр туздырып аткан.

– Бөре кирмәне янәшәсендәге Андреевка авылында изге Иоан, Чулман елгасы буендагы Березники авылында изге Николай чиркәве барча христианны үзенә тартып вә рух өстәп тора иде, ул ике изге учакны да җайдаклар отряды пыран-заран китереп бетергән. Ике авылга кергән отрядны да йөзенә кара битлек киеп килгән бер пәһлеван җитәкләгән, аның көбәсе дә көмеш тәңкәләр белән генә бизәлгән булган...

Коркодиновның йөзенә корым сөрткән сыман. Уфа урамнарына түгел, хәтта ихатага чыгып күренерлек тәвәккәллек, куәт, абруй да калмаган. Офицерлар яки стрелецлар каршына чыгып бастыңмы, шулары да синең чыраеңа төкерерләр кебек.

Сарай хезмәтчеләре арасында да бер-берсенең йөзенә төбәлеп караучы юк, һәммәсе диярлек, май урлап тотылган азгын мәче сыман, шылт иткән тавыш чыгарырга да шүрләп, шыпырт кына йөри.

Воевода бүлмәсеннән әледән-әле күбенгән сыер сыман уфылдаган тавыш ишетелә. Андрей Михайлович анда берьялгызы. Әле бүлмә буйлап әрле-бирле йөри, әле йомшак кәнәфиенә барып төнәшә дә, йөгәнен салып ташларга җыенган ат шикелле башын чайкап куя.

Эшләр хөрти. Әгәр Уфа биләмәләрендәге буза-фетнә яшь патшалар, аларыннан да бигрәк Софья колагына барып ишетелсә, ул ирдәүкә бичара Коркодиновны ике уйлап тормыйча да воевода кетәклегеннән алып ыргытачак.

Ә кәнәфи бик тә кулай иде әле. Аның воевода сараендагы идән асты келәтләренә берәүнең дә борын тыкканы юк. Коркодинов атлы бояр

воеводалык biләмәләрен нинди волостьларга бүлеп бетергән, ул олыс башлыкларының һәркайсына ясак күләмен нинди зурлыкта билгеләгән, моны тәгаен эт тә белми. Ә мөмкинлек чиксез. Әнә, Кошчы олысындагы бер старшина аламасы Бүләр җиреннән качкан җиде-сигез типтәр гаиләсен үз биләмәсенә керткән дә шыпырт кына казна сүлен имеп ятарга җыенган бит, каһәр. Качаклар болай да моңа бушлай гына печәнен чапкан, урман кискән, яхшатланып, хәтта сигез бүлмәле, унике тәрәзәле өр-яңа хором да төзеп биргән. Татарлар үзләре үк: «Симергән саен тавыкның арт ягы бөрешә», – дип юкка гына тәтелдәми. Теге старшина да, бирән, авылның ярты халкыннан җыйган төлке, кеш, кондыз тиреләрен, тәпән-тәпән балны күрше олыс базарларына чыгарып сата башлаган. Ә салымчылар борын күрсәттеме – һаман бертөрле зар:

– Җәй гелән-гелән кире килеп тора бит, әле айлар буе тоташ яңгыр коя, әле аны гына азсынгандай, яңа җәйдә челләдәй корылык китереп бәрә. Халык түл, мая җыя, ә салымын ике-өч ел буена түли алмый. Аларның абзарыннан соңгы сарык бәрәннәрен талап чыгардай кансыз түгел бит инде мин!..

Әле монысы, бизмәннәргә салсаң, хәтәр намуслы старшина. Таш Билбау ягындагы Кәсле волостена хуҗа Макар әнә, үз кул астына тулы бер караклар өере туплаган. «Алар белән күршедәге Саткы юлында бер кенәз олавын көймәле арбага тикле талаганнар, ә Эрбет базарыннан Тубыл ягына таба кайтырга чыккан һәм Кәсле җирендә гаип булган сәүдәгәр Мансур хәзрәтләренең гәүдәсен дә таба алмаганнар» кебек хәвефле хәбәрләр Уфага да килеп җитә иде. Элеккеге воевода Пётр Скуратов та, аның урынына менгән Дмитрий Коркодинов та Таш Билбау ягына баштанаяк коралланган өчме-дүртме хәрби отряд юллап карады. Байтак атналар буе иснәнеп йөргәннән соң гына, кайсыдыр сәүдәгәр олы серне чишкән. Бактың исә Макар старшина биек тау кыясы астындагы мәгарә эченә исәпсез-хисапсыз хәзинә кертеп яшергән булган икән. Укчы солдатлар шул кыя тирәли таптанган арада, Макар юлбасар берничә мичкә алтын тәңкәләрен чәлдереп, Төркестан ягына ук чыгып качкан...

Мәгарәдә калган хәзинәне тавыш-тынсыз гына «юкка чыгардылар». Үзбаш старшиналар кысып калдырган ясаклар да әкренләп, воевода келәтенә күчте... Әй, ул уңнан-сулдан бер келәткә аккан инеш-дәрьяларны санап кына бетерерлек идемени?!.

Ниһаять, Коркодинов үз янына ярдәмчесе булып торган кенәз Молостовны чакырып әмер бирде.

– Дмитрий Пантелееч, бүген үк, хәзер үк Андреевка белән Березники салаларына ике отряд стрелецларны озатырга кирәк. Алар анда эт кебек иснәнсен, борыннары белән казынсын, иллә мәгәр ул битлекле атаманның кем икәнен ачыкламый торып, кире кайтмасыннар. Мондый очракта әрсез татарлар «буш кулны эт тә яламый», дип такылдамый калмый. Ошбу отряд башлыкларына да өч-дүрт кадак көмеш тәңкә биреп җибәрмичә булмас. Әле андый бүләк тә аз, әйдә, биш-алты кадак көмеш биреп җибәрегез. Безгә акча түгел, ә газиз башыбыз вә хәвеф-хәтәрсез тормыш күпкә кадерлерәк.

Молостовның алай тиз арада аякларын кыймылдата башлавы ошамады бугай, Коркодинов кулы белән кискен ишарә ясады.

– Туктале, туктале син, чабыш аты сыман кая ашыгасың? Сүзем бетмәде бит. Әле ике төбәккә стрелецлар озату гына җитми, аларга өстәп, мәгәр аерым рәвештә биш-алты шымчы җибәрсәк тә, артык булмас иде. Рус крестьяннарын йә Уфадагы һөнәрчеләрне юлласак, хәтта ачыгавыз татарлар да алар каршында туарылып төшмәс. Димәк, димәк, безгә бер-ике сатлыкҗан йә гөнаһка баткан татарны кармакка эләктереп, әле өстәвенә, аларның хатыннары белән балаларын да зинданга бикләтеп, үзләренә мул гына ришвәт-бүләк шикелле акча вәгъдә итеп, кавемдәшләре арасына озату артык булмас. Татарларның елгырлары синең-минем түгел, хәтта стрелецлар алдында да ачылачак түгел. Ә үз кавемдәшенә безнең өчен иң отышлы серне дә ычкындырып куюы бар. Әлеге тарафны да колагыңа киртлә, аңладыңмы, Дмитрий Пантелееч?

Коркодинов бермәлгә туктап калды, үзе пуф-пуф килә. Молоствовның да һичбер ашыгыч эше юк, бар тарафны хуҗа күзалласын, шулай хәвефсезрәк.

– Аннары, аннары, Дмитрий Пантелееч, стрелецлар отряды артыннан ук икешәр-өчәр йөз җайдактан хасил яу отрядлары юлласак та була.

– Каян алабыз соң?

– Әлегә дворяннар арасыннан һәм дә килеп, сәүдәгәрләр, һөнәрчеләр арасыннан тупларга тотынырбыз. Уфадан кул сузымында гына Благовещенск бистәсе, алагаем рус крестьяннарыннан гына торган Аскын, Богородское, Иглино авыллары бар. Бер яктан үзебез берникадәр акча вәгъдә итсәк, икенче яктан үзләре татар авылларыннан талап кайткан ганимәт тә аларныкы булыр. Ә ул арада...

– Кичекмәстән Казан, Минзәлә воеводалары янына да ярдәм сорап, чапкын юллау кирәк, – дип, ашыга-кабалана сүз кыстырды кенәз.

– Алар тарафына чапкыннар юлларбыз, анысы бездән качмас, – дип, баш кашыды үзбаш воевода. – Әле бу фетнәләр турында яшь падишаһларга хәбәр итмичә дә ярамый бит. Мин кырык төрле бизмәннәргә салдым. Үз биләмәңдә фетнәләргә юл кую өчен баштан сыйпамаслар анысы, мәгәр яшереп калсаң да, яман. Безнең кенәзләр, боярлар, хәтта сәүдәгәрләр арасыннан да берәрсе Мәскәүгә чишми калмас. Ә җинаятьне яшердеңме, аеры кансыз җәза! Нинди хәвеф булып кайтачагын чамалау да читен. Ләкин рапорт язарга кирәк, монысы гел бәхәссез. Анысы миңа кала.

## 2

Теләкәй ут эчендә. Әле атна-ун көн элек кенә барча сәфәрнең зур гаугасыз үтеп китүенә, «бисмиллалы юлга чыккан инсанның кулына алган балчыгы да алтынга әверелә», дип, күңел юата иде. Хәзер менә Уфа ягыннан Әндери авылына, Әгерҗе ягына юнәлгән җәза нөгәрләре хакында хәбәр алгач, үпкә-бавырлары утта көя кебек.

– Морза хәзрәтләре, Әндери авылына килеп төшкән кораллы нөгәр, җәзага тартырдай инсан таба алмагач, Сөн буена таба юлга чыккан. Хак булса, Ябалак авылыннан качкан бер хөрәсән татар аларга юл күрсәтүче булып ялланган, ди.

Ике җайдак Теләкәй күкрәгеннән тутырып янган утка менә шундый куз китереп өстәгәч, морза инде каударланып, улларына дәште.

– Күчем, Җәүдәт! Тиз генә атларыгызга сикереп атланыгыз да Аештагы

Хәсән белән Шәммәттәге Фәрхи янына элдерегез! Дүрт-биш авыл ирләрен җыеп, Сөннең аръягына чыксыннар. Дошман кай тарафка юнәлә, шунда өсләренә карчыга булып кадалырга кирәк. Яшерен тозак корып каршылый белсәләр, анысы тагын да шәп...

Икенче кичтә үк хәбәр кайтты.

– Аеш белән Шәммәтнекеләр Өфе ялчыларын Тыңламас авылы янындагы чокырда тулысынча диярлек кырып салган. Ни үкенеч, бер әфисәр илә теге Ябалак сатлыгы җайдаклардан качып котылган, ди. Ирләр ачыклаган: теге кабахәт җан күршеләренең биш сарыгын урлаган өчен авылдан Өфе ягына куылган җүнсез карак икән...

Теләкәй кызган түбә өстеннән төшеп, биек өянкеләр күләгәсенә кереп утыргандай булды, ләкин күңеле белән сизенә – мең мәртәбә усалрак орышларга чыгу, мең мәртәбә куәтлерәк учакларда яну әле алда иде.

**3**

Көзге салкыннар юлларны катыруга ук, Уфа тарафыннан күк күкрәгәндәй хорафат яңгырады:

– Воевода Каркадин галиҗәнаплары старшиналарны Казый мәчете янындагы яңа җыенга дәшә. Пайтәхеттәге Иван патша белән Пётр патша татар морзаларына нисбәтле яңа фәрман игълан иткән. Падишаһлар морзаларның ихтыяри рәвештә нәсара диненә күчүен таләп итә. Үз ирege илә килгән морзаларны чукындыру өчен Уфа каласына Мәскәүнең үзеннән махсус епископ җибәрелә. Ә үз ирege илә чукынмаган морзаларның барча биләмәләре тартып алына, аларның кул астында булган крестьяннар ирекkә җибәрелә. Ихтыяри хәлдә чукынган морзалар гына үз биләмәсенең хуҗасы булып кала. Морзаларга ахыргача хәл итү өчен ярты ел вакыт!..

Казый мәчете янына барган ирләр кайтып сөйләде, җыелган старшиналарның саны ике йөздән артып китә алмаган. Тәфсилләп тору да артык, күпчелеге яшьләр, алары да үз гомерләрендә тәүге тапкыр чакырылгач, ялтырарга дип тә, кызык эзләп тә килгәннәрдер инде. Әмма бу юлы да Коркодинов үзе күренеп вакланмаган, әлеге дә баягы Молоствовны гына юллаган. Тик ул тезгән нотыкның да атасы-анасы юк, ди. Башны иеп тыңлаганнар инде.

– Иван патша белән Пётр патша тәхеткә менүгә үк, иң беренче булып, менә мондый фәрманга кул куйды. Татар морзаларының нәселләре Казан ханлыгы чорында ук әллә нинди хәйлә белән эләктергән өстенлекләрдән файдаланып яши, элеккеге ханлык белән бүгенге рус дәүләтендә бернинди уртаклык юк. Рус кешеләренә дворянлык яки бояр дәрәҗәләре аларның дәүләт иминлеге, дәүләт бөтенлеге хакына кылган каһарманлыклары һәм үз-үзләрен корбан итүләре өчен бирелә, ә татар морзалары бернинди нигезсез рәвештә үз өстенлекләрен ике-өч хатыннан туган җиде-сигез баласына мендәр, юрган, комган, чиләк рәвешендә тапшырып кына калдыра. Яңа падишаһлар әлеге гаделсезлек белән ризалаша алмый һәм үз фәрманын бирә. Морза дәрәҗәсен йөртүчеләр, үзләренең рус дәүләтенә һәм рус тәхетенә бирелгәнлеген раслау өчен Уфага юлланган махсус епископ каршында ярты ел эчендә чукынырга тиеш. Ярты ел эчендә чукынмаган морзаларның крестьяннары да, биләмәләре дә талап алыначак!..

Барча ирләрнең тәннәре чымырдап куйды, аркалары буйлап салкын тир йөгерде. Әстәгъфирулла! Болар татар морзаларын коллык читлегенә куып кертмәкчеме, әллә һәрбер морза муенына, мәҗбүриләп, тәре тагып чыкмакчымы? Үз иреге белән хатын һәм балаларыннан, көтү-көтү ат, сыер вә сарыкларыннан, ахыр чиктә, үзе аунап үскән чирәмлектән, суын эчеп, тәненә куәт алган салкын сулы чишмәләрдән, үзе колач салып йөзгән күлләреннән, аның өчен генә сайраган тургай-былбыллардан тулысынча баш тарту өчен бер генә морзаның да башына тай типмәгән ләбаса!..

Әтисе Теләкәй кушуы белән иснәнергә килгән Күчем, фәрманны тыңлаган чагында ук игътибар итеп торды – әфисәрне әллә нинди яңа киемле укчы солдатлар озата килгән. Кулларында озын сапка утыртылган ярымайдай балта. Билләрендә юка гына, яланкул сугып та сындырырдай кылыч. Икеме-өчме солдатның билләрендә каеш астына тыгып куйган пистольләре дә бар. Киемнәре дә гади. Аякларында кызыл читекме, әллә кунычлары кызыл төскә манган киез итекме ул? Әмма барча укчылар да карап торышка бик тә кайгыртучанлык вә тәрбия күргән шикелле тоела, өс-башлар ертык түгел, битләре түм-түгәрәк. Мәскәүдән үк килеп җиткән өстәмә полк солдатларымы бу, әллә Өфедәгеләрне шулай өр-яңадан киендереп кенә куйганнармы?

Серне Казый мәчете янындагы бер генә җыенны да калдырмыйча йөргән Сәгыйт хәзрәт чиште.

– Теләкәй узаманга бәйнә-бәйнә җиткер. Коркодин ваевуда Минзәлә илә Казандагы әшнәләре белән бәйләнешкә кереп, тегеләрдән ике йөз иллешәр укчы соратып алган. Аларны Өфедә аерым полкка туплап куйганнар, төрле ысулдагы күнегүләр дә үткәрелә икән. Тегеләр Өфегә арба-чаналарга гына салып йөртә торган, мортира атлы бәләкәйрәк туплар алып килгән, кала читендәге кырларда шулардан атарга да өйрәнәләр, имеш. Мондый хәзерлек чаралары күрелгәч, хәлләрнең катлауланып китүе дә мөмкин. Безгә дә мөселман алайларын алдан туплап тормыйча, яшьрәк егетләрне кылыч илә сөңге орышына, капылт һөҗүм илә бердәм чигенү, дошманга тозак кору, аркан ташлау, янә әллә никадәр алымнарга да өйрәтмичә булмас.

– Син үзең дә минем аша гына эш йөртмәсәң иде, мөхтәрәм Сәгыйт хәзрәтләре. Алайса, бүрәнә аша бүре куган сыман килеп чыга. Безнең атай сине күрүгә һәр очракта шат бит. Әйдә, миңа ияреп китәсеңме, беразданрак ялгыз киләсеңме, безнең тарафны да бер кат ура.

– Сузарга ярамый, синең илә китәм...

**Бишенче бәйләм**

**1**

Агыйдел уртасындагы утрауда Күчем морза кордыртып куйган чатырлар уртасына илледән артык ир тезелеп утырды. Уртада пыскып кына, нәни учак дөрли, ә ирләрнең һәркайсы алдында түгәрәкләнеп төренгән камчылары ята. Барча кунаклары килеп җитүдән Теләкәй морзаның йөзе бик канәгать, әмма түгәрәк эчендә үз урынын алгач, күзләренә бәреп чыккан кырыслыкны яшерә дә алмый. Ирләр күптән, кайсыберләре еллар буена да күрешмәгән бит, тавышларын күтәрмичә генә бер-берсенең хәлен белешәләр. Арада ник туганына үкенгәндәй сөмсерен коеп, үзләрен чит-ят дастархан артына

кереп утыргандай тоючылар да бар. Аңлашыла булыр: Агыйдел буеның иң эре морзасы Теләкәй батыр чакыргач, аларның берсе дә мондый түрә сүзенә буйсынмый булдыра алмый. Теләкәй морза белән араны бозу өчен кушйөрәкле түгел, ә чүбек башлы, тинтәк булу кирәк.

Шулай да, Теләкәйнең кәефе бүген шактый күтәренке. Аеруча Сәгыйт Җәгъфәр хәзрәтләре ягына борылып, еш елмая, кулларын күкрәк өстенә күтәреп тә, аңа хөрмәт-ихтирамны күрсәтмичә калмый. Кереш сүзендә дә ул шушы хәзрәт исемен кат-кат телгә алды.

– Бисмилла әйтеп, бөек Аллаһымыз алдында баш иеп, сөйләшүне башлыйк. Мин фәкыйрегез дәшкән барча узаман ир дә, азамат егетләр дә уртак чишмә, уртак учак эргәсенә җыелышып бетте. Мин аеруча Сәгыйт хәзрәт алдында баш ияргә мәҗбүр. Әүвәл ният корган чакта аны истә тотарга онытканмын, ә ул менә үз ихтыяры, үзенең җан тартуы белән бирегә килеп төште. Үтә камил, төзек уйлары бар, аларга мин фәкыйрегез ялгыз көе генә ирешә алмас идем. Сәгыйт хәзрәт Өфе эргәсендә без кузгаткан ихтилалның[10] уң кулы булырга ниятли, аңа машалла вә афәрин!

Ирләрнең һәммәсе дә Сәгыйт хәзрәт тарафына текәлеп бакты, күпләр кулларын күкрәккә куеп алырга да онытмады. Әмма бүген дилбегә Теләкәй морза ихтыярында бит, игътибарның зурысын аңа юнәлттеләр.

– Мәскәүдәге тәхеткә менеп алган ике япь-яшь малай безнең ата-бабаларыбыздан мирас булып калган изге ватаныбызны хәкарәләү адымнарын кылды, мине аңлыйсыздыр. Гасырлар дәвамында безнеке булып саналган Ак Идел вә Чулман ярын әле Кастырама, әле Сүздәлдәге монастырьларга өләшеп, чип-чиста мөселманныкы булган тарафларда өр-яңа чиркәү илә монастырьлар кора башладылар. Чулман буендагы Пәнҗәр, Ак Иделгә терәлеп утырган Бишбүкән, Ык дәрьясының биек яр өстен үз нигезе иткән Кәҗә авыллары халкының сыңар инсаныннан да сорап тормадылар. Үз өендә сыман, ошбу авылларның һәркайсында изге мәсҗедләремезне вәйран китереп ташладылар, алар урынына бакыр чаңнар аскан чиркәүләр калкыттылар. Татар халкын мин фәкыйрегез санап үткән барча авыллардан да куып чыгардылар, алай гына да түгел, алар карья-салаларның татарча атларын да алыштырып чыктылар. Пәнҗәр хәзер Пьяный Борга, Бишбүкән – Әндерәйгә, Кәҗә авылы Матвейга әйләнде. Ижау эргәсендә монастырь калкыта башлаган Пәрәү саласы да хәзер Пакрау авылына әверелеп килә. Димәк ки, ошбу килмешәкләр татарларны туган авылларыннан да куып чыгармакчы, ә аннары мөселман атларын да кяфернекенә алыштырып, татар илендә тәре бастырмакчы...

– Эһем-эһем, – дип, йомшак кына тамак кыра-кыра, Сәгыйт хәзрәт үз алдындагы камчыны түгәрәк уртасына таба этеп куйды. «Мин сүз сорыйм», дигән мәгънәне аңлаткан бу йоланы һәркем белә иде, кунак хәзрәт тарафына борылып төбәлделәр.

– Син, Теләкәй морза, безнең тәнне кисәкләргә телгәләп, бәгыребез, йөрәгебез, ашказаны, үт куыгы, бавырыбыз өстенә моннан берничә сәнә элек кенә күтәреп куелган кирмәннәр, асылда исә болгар-татар халкын өркетеп вә изеп тоту, муеннарыбызга тәре тагу, ахыр чиктә тәмам йотып

[10] Ихтилал – бәйсезлек, азатлык өчен көрәш.

бетерү өчен салынган кальгалар турында бер сүз дә әйтмәдең. Ошбу мәҗлескә чакырылганнарның җәмгысы да белә, соңгы кырык-илле сәнә дәвамында гына да газиз ата-бабаларыбыздан калган безнең изге болгар-татар биләмәсендә, элеккеге ханлыгымыз уртасында Чаллы, Зәй, Яңа Чишмә, Кичү, Җирекле, Бөгелмә, тагын да арырак атласак, Тиен илә Үзән кирмәннәре хасил булды. Әле аларга чаклы ук Минзәләдә, Бөре, Бәләбәй, Өфе, Каракүлдә дә тирән зинданнары булган кирмәннәр, алар эчендә чиркәүләр дә төзегәннәр иде. Алар безне барча яклап туплар белән коралланган кирмәннәр чылбыры белән уратып алды. Каршы тормадык түгел, утыз ел чамасы элек Чаллы кирмәнен нигезенә тикле яндырып, азау тешебезне дә күрсәтергә өлгердек. Мәгәр аңа карап кына туктамады бит бу эт өере. Былтырлы-быеллы безнең төбәктә калкып чыккан чиркәү илә монастырьлар да – газиз болгар-татар милләтемез өчен яңа зынҗыр, яңа тозактыр ул.

Сәгыйт хәзрәт камчысын үз тарафына тартып куйгач, дилбегәне янә Теләкәй морза үз кулына алды.

– Синең сүзләреңнән бик мәмнүнмез, сиңа олуг ихтирамымыз, Сәгыйт хәзрәт. Алга дәвам итсәк, хәл болайрак. Без инде Пәнҗәр, Бишбүкән яисә Әндери, Кәҗә, Березнәк-Каенлыдагы чиркәүләрне юкка чыгарып кына калмадык, ваевуда юллаган стрелис нөгәрләре белән дә орышка кереп, алар җилкәсендә коралларымызны вә ихтилал сукмагына баскан җайдакларымызны да сынап карарга өлгердек. Ходайга мең шөкер, егетләремез – узаман вә батыр, араларында һичбер куркак, җебек җан юк. Мәгәр безнең өчен сөенү, тынычлану олы язык булыр, чөнки менә Сәгыйт хәзрәтемез дә, озынколаклар да гел кисәтеп тора – өстемезгә баскыннарның эрерәк нөгәрләре, хәтта хәрби алайларның да килеп җитүе бар. Хәзер кайсы төбәк, кайсы авылның ошбу көрәшкә нинди өлеш, нindәй отышлы гамәл кертә алуы хакында бәйнә-бәйнә ачыклап чыгу лазем...

Киңәш-табыш итү төн уртасына кадәр сузылды, кунаклар таң атканда гына туган төбәкләренә юл алды.

**2**

– Әндери юлы буйлап синең эргәңә таба биш йөз укчы тупланган олы алай бара. Туп, ядрә вә дарылары, атлар өчен – солы, ирләргә дип әзерләнгән ризык аерым олаудадыр.

Шул хәбәрне алуга ук Теләкәй утарыннан бар тарафка шәп җайдаклар очты. Икенче таңда кораллы җайдакларның бер нөгәре Тыңламас белән Аеш авыллары арасында, Сөн елгасының яр астына төшеп яшеренде. Теләкәй утары янында да Шәбез буе уйсу, анда әрәмәлек, югарырак атласаң, куе наратлык бар, икенче нөгәр шунда кереп посты. Табигатькә кыш кереп килә, көннәр бер саплам җептәй гаҗәепләр кыска, бер катлаулырак гамәл дә кылырга өлгермисең, нәкъ халык әйткәнчә, күз йомып ачкан арада таң ата да кич була. Вакыт кысмырлыгы – ихтилал юлына басканнарга файда. Җәза олавындагылар күз бәйләнүгә тирән шомга чумып кына бара башлый: берәр калкулык артыннан яки яндагы чокырлардан татар ирләре албастыдай чыгып, стрелецлар өстенә ташлана күрмәсен. Шуңа күрә хәвеф-хәтәр белән алыш-биреш уйнарга яратмыйлар,

хуҗаларының ризалыгын сорап та тормыйча, якындагы бер авылның йорт вә мунчаларына, хәтта каралты-кура эченә кереп яшеренәләр. Ә ихтилалчыларга зур юаныч. Тирә-юньне караңгылык сарып алуга ук, әле теге, әле бу уйсулык йә әрәмәлек эчендә нәни учаклар кабына. Татар җайдагы сәфәргә казылык, итле сумса, эремчек, сыр, түгәрәк икмәк, казүрдәк, алар булмаса тавык муенын, канатын, ботын, кайчак тулаем килеш түшкәсен бөгәрләп салмыйча чыгып китә белми. Учак ялкынында шул нигъмәтне кайнарлап алалар, инеш йә чишмәдән сөзгән суларын калай чәркә йә чиләктә кайнаталар, аннары, ашап туйгач, боларның һәркайсы куак ботакларыннан табылган гөлҗимешне, чия йә карагатны тел очында әйләндерә-әйләндерә, озак итеп чәйләр эчә инде. Истирәхәт!..

Теләкәй күптән юлларга уткүзләр таратты, хәер, татар дөньясында озынколаклар болай да аз түгел. Ил өстенә кара болыт төшсә, аны күпләр аксакалларга яисә хуҗаларга үз вакытында җиткерә дә белә. Менә Тыңламас авылына озатылган чапкын да көтелмәгән хәбәр алып кайтты:

– Каратларны бу юлы да теге Ябалак качкыны Әшрәф-кабих алып килә икән.

– Бу сатлыкҗанны кулдан ычкындыру – гафу ителмәслек җинаять вә гөнаһ! – дип, Теләкәй әүвәл үзалдына гына пышылдады, аннары улы Күчем тарафына борылып күз атты.

– Синнән дә ышанычлырак таянычым юктыр, углым. Чирканмыйча гына юлга җыен, авыр эш тапшырам. Безнең һичкайсыбыз – син дә, мин дә – тизәккә батып беткән, хөрәсән вә шакшы бәрәнне суярга җан тартмыйбыз анысы. Андый хәшәрәтләрнең ите дә керле буладыр, шулпасыннан да күңел болгаткыч зәһәр ис киләдер сыман. Иллә мәгәр җиһан өстен шундый шакшы җаннардан арындыру да фарыз, чөнки иleңне вә халкыңны сату – иң явыз гөнаһ кына түгел, адәм баласыннан адәм баласына күчә торган бик яман чир дә ул. Менә Ябалак авылындагы бер хәсис тә кяфер баскыннар ягына сатылган, аларның безгә каршы юнәлгән олавына да шул кабих җан юл күрсәтә икән. Иң сыналган сунарчыларыңны ал да Тыңламаска юнәл. Ул хәшәрәтне исән-сау көенә кулга төшерә алсаң, шундук гомерен кыйма. Аны барча халык алдында каен ботагына асып кую күпкә отышлырак. Башкаларга гомерлек сабак, олы гыйбрәт булыр.

– Мин болай да андый шакшы белән кулны пычратырга җыенмаган идем, – дип елмайды Күчем. – Мин синең ниятләреңне ярты сүздән аңлыйм. Бәйнә-бәйнә сөйләп, үзеңне бик ярсытма.

– Аһ, шушы ачыгавызлыкны, аһ, бу наданлыкны! Ә мин һаман сине җиткән ир, олы гаилә башлыгы дип менә мондагы чүбекләргә һич сеңдерә алмыйм.

Икесе дә рәхәтләнеп, туарылып көлеште. Аннан соң гына Күчем бер кулы белән әтисен кочагына кысты да урамга атлады.

**3**

Ихтилалчылар алаеның бер өлеше каратларны Теләкәй авылының сул як кулындагы текә тау өстендә, куе наратлык эченә, икенче нөгәр Шәбез елгасы буендагы уйсулыкка посып каршылады. Теләкәй үзе ярсу аргамак өстендә, киң урам башындагы калкулыкка баскан. Ике як йортлар каршына

да ирләр тезелешкән. Болары – Теләкәй утарында көтүче, ат караучы, шул маллар өчен кирәкле камыт, ыңгырчак, дирбияләр әзерләп бирүче осталар инде. Алар арасында арба, чана, тәгәрмәч ясаучылар да аз түгелдер. Сәер, берсенең дә кулларында сөңге-кылыч, хәтта сәнәк тә юк.

Теләкәй дә өстенә көбә-очлым түгел, төлке тиресеннән тегелгән бик затлы тун кигән. Башында да арткы итәкләре иңнәренә төшеп яткан төлке бүрек, кулларында тире бияләйләр. Йөзе үтә кырыс. Сунарчыныкыдай елгыр карашы белән каратчылар төялгән чаналарның берсеннән-берсенә күчә-күчә, ул Күчем ирләрен йә, һич югы, сатлык татар Әшрәф йөзен эзли. Чаналарның өч-дүртендә дилбегә тартып килүче татар олаучылары бар-барын, моны башларына элгән түгәрәк һәм капкачсыз бүрекләреннән, кыска итеп һәм түгәрәкләп кыркылган сакалларыннан чамалап та була. Алар башларын түбән иеп, йөзләрен яшергән. Ирләрнең ихтыяри түгел, мәҗбүриләп олау бирергә һәм малларын саклап калу хакына каратлар әмеренә буйсынуын төпченеп тормыйча да җиңел аңлау мөмкин. Ә Күчем кайда соң, газиз улы кайда? Нишләп аның бер генә төрле дә хәбәре юк?..

Нәкъ шул минутта каратлар тылында, Шәрип авылы янындагы биек тау өстендә кибәндәй учак кабынды. Әһә, Тыңламас ягындагы нөгәр белән алдан ук беркетеп куйган ният барып чыккан, алар каратларның туп вә дары олауларын кулга төшергән бит!..

Теләкәй үз утарына таба алып килә торган юлга хәзер инде бөтенләй икенче күз белән караш ташлады. Әнә өченче, кузлалы чанадан баш түбәсенә өчпочмаклы кәпәч элгән бер әфисәр күтәрелә. Кулында сабыйлар чыбыгыдай нечкә генә, әмма озын кылыч аламасы, аны укчылар үзләре шпага дип йөрткән була да бит, Теләкәйгә калса, чебен илә черки куарга да ярамый ул. Мәгәр әфисәр шуны күккә чөйгән булган, үзе олаудагыларны кузгатмакчы булып оран сала:

– С обоза долой! Построиться во фланг и вперёд, в атаку! Заранее предупреждаю, сволоча мурзу взять только живым!

«Һе, акылың кот икән!» – дип, хәзер инде Теләкәй үзен дәртләндереп алды, аннары бүреген салып, наратлыкка таба кул изәде. Ике-өч минут та вакыт узмагандыр, наратлык эченнән, әллә никадәр бүреләр өерен хәтерләтеп, биш йөз җайдак атылып чыкты. Ялан өстендә берничә мизгелгә генә туктап, сафларга тезелделәр. Сафлар өстендә күл читләрен баскан мәгъруур камышлардай куе сөңгеләр урманы хасил булды. Аннары гаярь ташкын булып, дәһшәт бөркеп, алга ташландылар. Кышкы буш һаваны күк күкрәгәндәй аһәң каплап алды:

– Урап ал, ура, ура!

– Аллаһы әкбәр!

– Гәрәй, Мең, Елан, Байлар, Кыргыз, Бүләр, Йәнәй, Балыкчы!..

Гади укчылар да, аларның офицерлары да алдан сизенмәде. Теләкәй яугирләре ялангагы кар катламын кичә үк таптап куйган, ат вә ирләр эзен калдырмас өчен аларны ылыслы ботаклар белән себереп чыккан иде. Җайдаклар җәйге юл өстеннән котырынып чапкандай очып кына килеп җитте дә олауларыннан сикереп кузгалган каратларны сөңге очына алды, кылыч белән чапты. Чанадан төшәргә өлгермәгән ирләрне сөңгеләр ыргагына эләктереп, ялан читендәге көрт буенча сөйри башладылар.

Әмма укчылар – хәрби орышларга өйрәтелгән тәҗрибәле, елгыр сугышчылар шул. Олау ахырындарак чаналарга утырган укчылар күз ачып йомган арада тыгыз дүртпочмаклык ясап басты. Ул дүртпочмаклыкның һәркайсы озын саплы сөңгеләрен алга сузып, керпе рәвешен алды. Ул да түгел, су өстендәге каек шикелле җитез хәрәкәтләнеп, татар җайдакларының сафын тиз арада җимерә башладылар. Әллә ничә урында саф өзелде, дистәләгән җайдак сөңге очына эләгеп, иярләреннән үк чыгып очты.

Каратларның офицерлары шул керпеләр эчендә, әмерләре колакны ярып керә:

– Уңга, уң тарафка таба ташланыгыз! Әнә теге, сарык тиреле тунлыларның тылда сакчысы юк, шулар өстенә ташланып, басурманнар сафын икегә өзү кирәк!

– Килгән юлны бу мокытларга бирмәгез, аның буйлап безгә ярдәм килә.

– Әгәр обоз килеп өлгерсә, ошбу азиатларны туплар белән тетеп атачакбыз!..

Офицерлар юкка хыяллана, юкка гына укчыларның күзенә төтен җибәрәләр. Әнә Шәрип юлында инде ихтилалчыларның икенче нөгәре дә күренде. Ерактан ук бүредәй улый-улый, таудан ишелгән таш өеме сыман дәһшәт бөркеп, һаман якынаялар. Тагын ике-өч чыра янып бетәрдәй ара узып китәр дә, яңа көч тә дошман өстенә ябырылыр, явыз каратлардан күмер вә көл дә калмас...

Барып чыкмады шул. Күчем ияртеп килгән нөгәр теләкәйлеләргә килеп кушылса да, дистәләгән орышларда чыныккан офицерлар әмере буенча, укчы солдатлар бушап калган чаналарның байтагын үз олауларындагы үрәчәләргә бастырып, тиз арада калканнар артына кереп кача алды. Аннары якындагы иң беренче калкулык өстенә менеп алдылар да, елан урынына җитез шуыша-шуыша, Андреевкага илтә торган юлны эләктерделәр. Теләкәй белән Күчем җайдаклары аларны Сөн елгасын кичкәнче эзәрлекләп барды, әмма янә ике-өч дистәдән дә артык каратны кырып салудан гайре гамәл кыла алмадылар.

Теләкәй утарына әйләнеп кайтсалар, корбаннарны яланның ике як читенә тезеп салырга өлгергәннәр. Морзаның шәхси аргамакларын караучы Госман хисап бирде:

– Без ике йөз дә җитмеш каратны кырырга өлгергәнбез.

– Ә безнең як?

– Сиксән җайдагыбыз шәһит булган.

– Начар, начар, начар!..

Теләкәй морза башын аска иеп, берничә минут буе тын торды да яңа сорау ташлады:

– Каратларның безнең кулга төшкәннәре дә бармы?

– Уналты инсан, хуҗам.

Теләкәй морза уйсулыкка, урман авазына карап күз йөгертте, таныш булмаган бер генә сынны да эзләп таба алмады. Атчы Госман дөрес чамалады, аның морзасы әсир төшкәннәрне күзли булыр.

– Без аларны Галимәрдән агай вафатыннан соң бушап калган өй эченә яптык. Бер-икесе яралы, суны кайнарлап, шуларны чистарталар.

– Йорт тирәли, һичшиксез, сак куегыз, – дип кисәтергә онытмады морза.

– Байларча булмаса да, ризыктан өзмәгез. Ошбу орыш ялгыш кына да иң соңгысы булмас. Әсирләрнең алыш-биреш өчен кирәге чыкмый калмас.

Шул вакытта Теләкәй сораулы караш белән Күчемгә текәлде.

– Син теге хәшәрәтне ычкындырдыңмыни?

– Рәнҗетәсең, атам.

Күчем кичә үзе алып киткән төркем җайдакларына күз ташлады.

– Әшрәф атлы эт аламасын монда китерегез.

Әле көндез генә аяусыз яу булып узган зур яланда түгәрәкләнеп баскан мәйдан пәйда булды. Сүс арканга бәйләнгән сатлыкҗанны эт урынына сөйрәп, мәйдан уртасына керттеләр. Ул хәшәрәт үзен кулга да алалмый, көзге яңгыр астында калган көчектәй дер-дер килә, авыз читеннән агып чыккан селәгәен дә сөртеп куюны белми.

Теләкәй морза аңа төбәлеп, берникадәр мизгел генә тын торды да бар мәйданны яңгыратып әйтте:

– Татарларның иң яман, иң чиркандыргыч чире шулдыр – без шәхси мәнфәгатен үз кавеменнән өстен куючы сатлыкҗаннарның тамырын корыта алмаудан гомер буе газап кичерәбез. Мондый сатлыкҗанның үлеме дә башкаларга сабак булырга тиеш. Фёдор, бирегә кил! Бу җәзаны синнән дә остарак ерып чыгардай инсан табылмастыр. Каен ботагына ошбу этне, каен ботагына!

## Алтынчы бәйләм

### 1

Падишаһлар сараенда атна саен кәмит, атна саен уен. Кайсыдыр йомрыбаш тәкъдиме буенча, Иван белән Пётр өчен ике кеше сыярлык махсус тәхет ясап өлгерттеләр. Моны белеп алуга, Софья өлеш кертте.

– Тәхетнең арка ягына, уртада бер тишек ясагыз да, ошбу малай-шалай падишаһлар булып уен корган чакта, мин арткы якта качып утырырмын, алар кайтарырга тиешле җавапларны үзем әйтеп торырмын. Шунсыз бер генә боярлар думасы утырышын да, чит ил илчеләрен кабул итүне дә кеше рәтле уздырып булмас сыман.

Әйткән сүз – аткан ук, ә ниятләр патшабикә тарафыннан чыкса, монысы инде канун. Шуннан соң, асылда да, Софья корган уен гадәткә кереп китте. Беркөн швед илчесен кабул итү булды. Әлеге кунак, әкияттәге кебек, сакалы чаларган өлкән боярларны да гаҗәпкә калдырды.

– Швед короле Фридрих Нева елгасы түрендә, Ладога буенда ук яңа порт төзергә җыена, Ниеншанц кирмәне белән ике арада сәүдә кораблары йөртергә ниятли. Ладога күленең барча ярларын да безнең карамакка бирегез, ди.

Пётр – кызу канлы, ак кәгазь битедәй дер-дер калтыранып, шундук сикереп торды.

– Юк, Ладога да, Нева ярлары да борынгыдан бирле русныкы ул! Безнең кенәзләр әллә ничә гасыр буе, корабларын Скандинав җирләренә кадәр куып, тыгыз сәүдә иткән!

Ә Иван падишаһ колга буедай үсеп җитсә дә, акыл шәрифләре койма башына кибәргә дип элгән мичкә эчедәй буп-буш. Аны Никита Зотов шикелле оста мөгаллимнәр укытмый шул, наданлык нык сиздерә.

– Сәүдә безгә акча китерә бит, Ладогада да, Нева ярында да портлар төзесен, безне баетсын, мин мондый эшкә риза, – дип әйтеп салмасынмы!

Тәхет ярыгыннан артка кереп поскан Софья үгез кебек ажгырырга мәҗбүр булды.

– Иван, син авызыңны яп! Пётр гына торып сөйләсен. Нева – гомер буе руслар елгасы ул. Ладогага шведларның һичбер дәхеле юк. Без мондый килешүгә юл куя алмыйбыз, дисен...

Илче вә швед короле нәфесен шулай шома гына ябып куйганнар иде дә бит, ләкин һәр очракта да тәхет уеннары татлы җимеш белән генә тәмамланмый икән. Боярлар думасы җыелгач, яртылаш комы коелган әфәнделәр хозурына Казан белән Минзәлә калаларында утыручы ике воевода – бер-берсенә туганнан туган тиешле кенәз Барятинскийларның шикаятьләрен укыдылар. Минзәләдәге Иван Фёдоровичның хаты тоташы белән зарланудан һәм чит-ят йөзенә корым ягудан гына хасил.

– «Уфадагы воевода Коркодинов галиҗәнапларыннан бер тынгы юк. Әле бер ел чамасы элек мин фәкыйрегезне туп, дары һәм яу атлары сорап кына тинтерәтә иде, ике ай элек бездән ике йөз илле укчыны да талап алды. Аның биләмәсендә татар крестьяннары фетнә кузгаткан, әйдәман-каракларыы[11] гел морзалар икән. Мин фәкыйрегез Коркодинов талап алган стрелецлар урынына шәһәр гарнизонын Смоленскидан куып китерелгән шляхтичлар арасыннан сайлап тутырырга мәҗбүр булдым. Минзәлә гарнизоны бик тә көчсезләнде, шул сәбәпле падишаһларыбыз галиҗәнапларыннан өстәмә туплар һәм гарнизон өчен өстәмә жалование күләме сорарга батырчылык итәм».

Казан каласында утырган бояр Данила Афанасьевич та Уфа воеводасы Коркодиновның пошмас һәм ачыгавыз булуыннан нык зарлана.

– «Күршедә кабынган учактан төтен генә түгел, очкын һәм янган кисәүләр дә очып килә. Казан янәшәсендәге авыллардан әллә ничә дистә крестьян фетнә белән тулы Уфа воеводалыгына чыгып качты. Стрелецлар Казанда тупланган бит, ә мин качаклар артыннан эт шикелле йөгереп йөри алмыйм. Сез, галиҗәнапларым, бер-ике полк гаскәр озатсагыз, фетнә утын Казан төбәгенә кертергә ирек бирмәс идек».

«Казан белән Минзәләгә берешәр полк стрелецларны озатабызмы, юкмы», дигән тәкъдим булуга ук, боярлар арасында ызгыш-талаш купты.

– Һәрбер пүчтәк кала воеводасы да шылт иткән авазга без мич башыннан сикереп төшә башласак, илебез казнасында ел буена сукыр тиен дә мая туплап булмаячак! – дип, әүвәл әрвах Нарышкиннар ягындагы Фёдор Матвеев өстәл төя-төя сүз ташлады. Аңа Милославскийлар ягыннан кенәз Долгоруковларның берсе чәчрәп чыкты.

– Безнең дәүләтебездә пүчтәк калалар юк! Ярым җимерек сала булса да, русныкы һәм падишаһ Иваннныкы бит ул! Ярдәм сорыйлар икән, ике-өч полкны Кубань яисә Архангел янына тикле җибәрербез!

– Аһ, рус дәүләте фәкать Иваннныкы гына да, безнең Пётр падишаһ урамнан кертеп утыртылган хәерче малаймыни?! Ипи шүрлегеңне ике якка аерып атмагаем!..

Шуннан китте, китте. Ике-өч боярны бер-берсенең якаларыннан көч-хәл

[11] Карак – ул заманда җинаятьчеләрне шундый исем белән атаганнар.

белән генә аера алдылар. Мәгәр Фёдор кенәз ишек тарафына атласа да, чәр кычкырып, соңгы сүзен әйтеп сала белде:

– Бу хәшәрәт боярны куып чыгармыйча торып, башка бер дума утырышына да аяк басмыйм!

Долгоруков та – тел шомарткан бояр, җавап сүзен әйтми каламы соң?!

– Килмә, йөрмә! Сыерга кидергән көянтә шикелле кирәгең бар иде!

Үз бүлмәләренә кайтып бикләнгәннән соң гына Пётр әнисенең иңенә капланып ялвара:

– Качыйк без бу мәркәздән, анакаем? Үзләре шыр надан, үзләрендә күркәдәй мин-минлек, мондый боярларны күрмәс өчен мин җир читенә китәргә дә риза!

**2**

Патшабикә Софьядан кисәтү килеп төште, Коркодиновның астына су йөгерде сыман. Азгын ирдәүкә бик яман кизәнгән, үгез сораудан, утар киртәләрен, араннарны җимереп качарга әзер сыер урынына котырына бугай.

– Яки син, карт алаша, үзеңә тапшырылган биләмәдә тәртип урнаштырасың, яки мин синеңише бурны Себергә олактырам!..

Коркодинов сарай тирәсендә буталып йөргән тегүчеләрнең берсен якасыннан алып, үзенә затлы бер офицер мундирын әзерләргә кушып әмер бирде. Воевода «хурлыкны кан белән юарга кирәк» дигән канунны колагына да элеп тормый инде, аның өчен якын-тирә кенәзләр һәм Уфа сәүдәгәрләре каршында үзен сәргаскәр итеп таныту отышлырак. Әйе, әйе, бар каланың һушы китсен әле, воевода-бояр, окольничий вә кенәз Андрей Михайлович Коркодинов галиҗәнаплары аның биләмәсендә фетнә кузгатырга батырчылык иткән әтрәк-әләмнәрнең нәселен корыту өчен яу сәфәренә шәхсән үзе бара!..

Софья тарафыннан кисәтүле һәм ут чәчкән хатлар Барятинскийларга да килеп җиткән бугай. Алар икәү. Берсе Минзәләдә утыра, Иван Фёдорович белән Коркодинов бик күптәннән таныш. Әлегә таушалмаган, яше белән кырыкка гына якыная сыман. Ул сирәк-мирәк Уфага килеп чыккалый. Хатыннарны, аеруча яшь кызларны бик ярата, кайчагында берничә кәнизәк белән мәче туе да оештыра, имеш. Уфага бер килгәндә, сәүдәгәр Мосолов йортына төшкән икән. Өч-дүрт кәнизәк чакыртып, мунча түрендә «парлы биюләр» дә оештырганнар, ди. Берәү дә белми кала, дип өмет багласаң да, гайбәт кар бөртекләре шикелле бит, хәтта муеныңа да, түшеңә дә үтеп керми калмый...

Казандагы Данила Афанасьевич Барятинский турында Коркодинов ишетеп кенә белә. Әлеге кенәз Степан Разин фетнәсен бастыруда зур дан алды. Аннары да байтак еллар буе Әстерхан каласын ипкә китерү белән мәшгуль булган, аннан соң гына «чәчәк атучы» Казан каласына күчерелгән икән. Ләкин, менә, элекке казанышларын да исәпкә алып тормаганнар, Софья аңа кичекмәстән бер полк стрелецны Коркодинов карамагына озатырга әмер биргән. Димәк, Казаннан – бер, Минзәләдән икенче тулы полк. Атлары һәм ядрә, туп, дарылар белән бергә. Бик хуп, бик хуп! Хәзер Коркодиновның үзенә Уфа тирәсендәге авыллардан яңа полк туплау

бурычы гына кала. Аннан алга! Сәргаскәр Коркодинов галиҗәнаплары ихтилалчылар булып дөнья сасыткан әтрәк-әләмнәр өерен он-талкан китереп бетерәчәк! Сине дар агачы көтә, морза Теләкәй мөртәт!

**3**

Уфа каласы язгы җылылыктан җепшеп, урамнары ерганаклар белән тулган бер көндә атын ак күбеккә батырган чапкын килеп керде.

– Воевода йорты кайда, кай тарафта? – дип сөрән салуы белән үк узгынчыларны хәвефкә күмеп өлгерде ул.

Ике-өч хатын күркә сыман гөлдердәп җавап бирде.

– Нишләп бистәләр буенча буталып йөрисең? Кирмән эченә кер.

– Кирмәндәге чиркәү янында ук бик затлы йорт. Аны башка алачыклар илә бутарлык түгел инде.

Уфаның кирмән эчендә кечкенә тугыз урам аламасы. Алар нәкъ уртада урнашкан Троицк чиркәвеннән кояш нурларыдай чәчелеп китә. Воевода йорты – чиркәү янәшәсендә. Узгынчылар бутамаган, чапкын йортын җитез генә тапты.

Воевода, муенына ашъяулыклар урап, бер каз башы кимереп утыра иде. Яртылаш ләпеккә баткан чапкынны өстәл яныннан кузгалмыйча да кабул итте.

– Күз-башларың тонган, әллә янгын бармы? Әйдә, сөйлә.

– Һе, күз-башым да тонар, иллә мәгәр янгын гына түгел, олы давыл. Себер юлында Сәгыйт Җәгъфәр атлы мулла баш күтәргән. Дөресе, ул – атаман. Ә фетнәчеләр саны ике меңгә тулыр. Әүвәл Богородское, Никольск атлы авылларның чиркәүләрен яндырып бетергәннәр. Аннары Көңгер ягына борылып, тагын дүрт авылның чиркәвен юк иткәннәр. Бүген иртән Көңгернең үзенә җитеп, инде шул имән кирмән диварларын да яулый башладылар. Мин Көңгер команданты, капитан җәнаплары Вонючев әмере буенча елга яры буйлап кына чыгып ычкындым да менә сез галиҗәнап каршына килеп бастым.

Коркодиновның бугазына әле йотып та җибәрә алмаган ризык килеп тыгылды, диярсең, ул порых-порых килде.

– Ниткән Ягуфар, нинди мулла ул тагын? – дип, зәңгәрле-кызыллы тавышлар белән үкерә дә башлады. – Авылларны яулаулары кулларыннан килә, моңа аптырамыйм. Мәгәр алар кирмән кадәр кирмәннәргә һөҗүмгә ташланудан ничек куркып тормый? Туплары, ядрәләре бармы? Штурм белән нинди ил ялчылары идарә итә ала?

Чапкын ирнең күзләре маңгаена менде. Нинди чит ил, нинди яллы көчләрне искә ала соң бу картлач? Әллә воевода сараенда аракы чөмерә-чөмерә акылдан ычкынганмы?

– Юк, бернинди чит ил инсаннары да күзгә чалынмады. Барча фетнәчеләр – үзебезнеке. Юк, үзебезнеке түгел инде, күпчелеге – татар. Өсләрендә сырган бишмәт йә кайры тун, башларында бәрән тиресеннән тегелгән түм-түгәрәк бүрек. Араларында башкорт җайдаклары да бик аз түгел. Аларның күбесенең кулларында җәя. Шәп аталар, шайтан алгырлары. Берсенең угы минем бишмәт итәген үтәли тишеп чыкты.

Артыграк җәелеп китүен шәйләп өлгергәндер, чапкын капылт тынды.

Коркодинов теше сызлагандай арлы-бирле йөренә башлады. Үзе атлап бара-бара да, тискәре ат шикелле, башын чайкап куя. Маңгае белән чигәләренә салкын тир тамчылары да бәреп чыккан.

– Аһ, син, Вонючев, Вонючий! Көңгер каласын мулла кулына бирсәң, дар агачы элмәгеннән котылып калуың бик икеле. Йә мулла тотып асачак сине, йә мин үзем асам!..

Икенче таңда яңа чапкын килде. Воевода дөрес сукалаган: фетнәчеләр Көңгер кирмәнен яулап алганнар да капитан Вонючевны дар агачына мендергәннәр икән. Йа Ходаем, тагын нинди бәлаләр турында ишетергә, нинди тәкъдирләргә сарырга туры килер?!.

**Җиденче бәйләм**

**1**

Сәгыйт хәзрәт һич тә онытмыйча, Теләкәй морза эргәсенә дә елгыр чапкын куган.

– Хәбәр алдыңмы икән, юкмы, синең нөгәреңне дә, үзеңне дә юкка чыгару өчен зур әзерлек бара. Миңа Иштирәк хәзрәт хәбәр салуынча, Казан каласыннан сиңа каршы бер зур стрелецлар полкы юлга чыккан. Минзәләгә дә Мәскәүдән фәрман килгән, андагы Барятинский да сиңа каршы аерым полк юллый. Сиңа ярдәм йөзеннән мин монда буза куптардым, хәзер Өфе воеводасы гаскәрен икегә бүлмичә дә булмас. Минем кулда – Көңгер кирмәне, биредә кяферләрне озак вакыт якын китермичә, арканга бәйләгән шикелле тотып, хәтта шанлырак гамәлләр кылырга да була. Син дә кичекмәстән зур әзерлек башла, үзеңне яшь колын урынына тозакка төшерә күрмәсеннәр. Корган ниятләрем барып чыкса, мин синең белән кушылу өчен кузгалырга әзер. Кирәкме, юкмы, хәбәр кайтарырсың...

Теләкәйнең җанын ике яклап та елан талый сыман. Бер уйласаң, Сәгыйт хәзрәтнең үз төбәгендә фетнә кузгатып, патша көчләрен икегә бүлгәләргә маташуы бик тә кулай хикмәт. Ә икенче яктан, хәзрәт воеводаларны да хәвефкә төшерерлек фетнә кузгатып, үзен үлем элмәгенә якын китерә бит. Без беребез дә бала-чага түгел, тәхет иминлегенә куркыныч тудыру берчакта да бармак белән янау, хәтта талчыбыклар белән тотып суктыру белән генә төгәлләнәчәк түгел. Тәхеткә кул күтәргән һәммә кешене фәкать җәллад балтасы яки дар агачы гына көтеп тора. Безнең милләттә тәхетне әйләндереп каплардай, йә аны үз файдаңа алыштырып куярдай һичбер көч юк. Ә дошман капкыны, дошман басымы астында яшәргә теләмәгән гаярь бөркетләр, дистә еллар буе мәет ите белән чемченгәнче, бер көн, бер ай булса да, үз корбанының кайнар каны белән туенуны күпкә өстен күрә. Теләкәй морза да тезләнеп гомер итмәс өчен хөррият юлына басты, шушы адым өчен үзен үлем элмәге көтеп торуын да белә, ул үз халкы хакына баш җуярга әзер. Ә ул Сәгыйт хәзрәтне дә шушы элмәк сукмагына илтеп кертмәдеме? Хата Теләкәйдә икән, Сәгыйт хәзрәтне ничек коткарасы?..

Теләкәй үзе ихатага атылып чыкты да катгый аваз салды:

– Күчем илә Җәүдәт угылларым кайда йөри, тиз арада табып китерегез!

Имәндәй ике егет пәйда булуга, ым белән генә дәшмәкче иде дә артык түзә алмады.

– Атларыгызны иярләгез дә, әйдә, юлга!

Ике-өч чакрым чамасы юыртып баргач кына, морза янә телгә килде.

– Воеводалар сыңар һөҗүм белән генә туктаячак түгел. Аларга Мәскәүдән фәрман төшеп җитте. Минем уйлавымча, Минзәлә илә Өфе полклары кайсы урындадыр бергә кушалачак та безнең өскә очып куначак. Воеводаларга моны татарлар язгы чәчүгә төшкәнче башкарып кую күпкә отышлырак. Яу кыласы, безнең нөгәрне тар-мар итәсе бар дип, алар халыкны икмәксез калдыра алмый. Чөнки шул ук крестьяннардан салым җыймасалар, воеводаларның үзләрен утлы табага бастырып биетәчәкләр. Әгәр, әгәр шулай дип уйласак, майның унынннан, унбишеннән дә калмыйча килеп җитәчәкләр. Ә без әзер түгел. Менә шуңа булачак яу кырын тәгаенләп кую лазем безгә. Воеводалар сайлаган тозак эченә барып кермик, алар үзләре без көйләгән утлы таба өстенә кереп биесен иде.

– Акыллы фикер, акыллы, – дип, ике угыл да сүз катмакчы булды, әмма Теләкәйнең ялагайлыкны җене сөймәвен беләләр бит, сүзсез баш кактылар...

Ык елгасы буйлап озак кына баргач, Теләкәй морза судан ике йөз адым чамасы читтәрәк җәелеп яткан гаҗәеп бер тигезлеккә таба кулын сузды.

– Менә бу каян килгән үтә такыр мәйдан, гөманлый аласызмы? Элегрәк килгән чакларда да шушы кыр уртасына басып, уйга чумганым бар. Әле җәяүләп тә кат-кат үлчәп карадым. Теге якка да, ошбу тарафка да төп-төгәл өч йөз адым. Бу дүртпочмаклыкның һәр ягында тирән ерым, аның артында инде җиргә сеңә башлаган урлар. Кемнәр корган бу сихерле дүртпочмакны, нинди җеннәр ошбу мәйдан өстен җеп тарткандай тигезләп чыга алган? Еллар буе уйлыйм, җавап таба алмыйм.

– Әттәгенәсе, асылда да тел белән ялап чыккандай тип-тигез, – дип, кече улы Җәүдәт сүз кыстырды, Күчем исә күтәреп алудан барыбер тыелып калды.

Ялан буйлап шактый вакыт буе аптырашып йөргәч, янә Теләкәй үз гөманын бүлеште.

– Әнә, күрәсезме, елганың ике як ярында да игезәктәй ике тау утыра. Озынлыгы белән утыз, биеклеге белән унбиш адымга җиткән мондый ике игезәк тауны җил-давыллар гына корып куя аламыни? Юк, ышанмыйм. Елганың әнә теге ягында Бикбау авылы, аны беләсездер. Мин андагы картлардан да кат-кат сораштырдым. Алар элек, бик борынгы заманнарда моннан сармат атлы бер кабилә узып киткән, диләр. Шулар җирле халык белән орышка да кергән. Шул орышта корбан булганнарны аерым-аерым ике каберлеккә җирләгәннәр, имеш. Берсе – сармат корбаннары, каршы яктагысы – җирле халыкныкы. Бер дә тынгылык тапмагач, бер җәйдә Бикбау ягындагы татарлар бу тау битен казып та караган, ди. Корбаннарның көмеш көбәләре белән бергә җирләнгән, яннарына кылыч илә сөңгеләр дә куелуын күргәч, тирәнрәк казудан шүрли башлаганнар, каберлек тишеген томалап куйганнар, шуннан ары һичкемгә дә тидертмәгәннәр, ди. Имеш, андый каберлеккә тисәң, корбаннарның тынычлыгын бозып бимазаласаң, мондый сансыз гамәл көрәк тотып килүчеләрнең гаиләсенә кайгы-хәсрәт булып әйләнеп кайта икән.

Егетләр баш чайкап тик торды. Теләкәй морза ошбу хатирәне янә үзе түгәрәкләп куйды.

– Мондый ысулда булдырылган таучыкларны, гадәттә, курган, диләр.

Кырым походына барган чакта безгә күп очрады моңа охшаш таулар. Кайберләренең өсләренә балбал да бастырганнар, ә алары курган эчендәге корбаннарның иминлеген саклап тора, имеш. Кем белә, бәлки, менә бу курганнар өстендә дә кайчандыр балбаллар торгандыр, әмма кайсыдыр бер җүнсезе аларны йә елга эченә, йә берәр базга илтеп ыргыткандыр. Ә мин сезне бу тарафка нигә алып килдем, әйтә аласызмы?

– Безгә курганнар күрсәтергә һәм дә нотык сөйләргә генә түгелдер инде, эткәй. Син ул хәтле үк эшсез инсан түгел, – дип, Күчем этисенең мин-минлеген песи баласын сыйпагандай җайлап куйды да сорауны урап узды.

– Безнең воеводалар нөгәре белән яңа бәрелеш менә шушы тигез мәйдан өстендә булыр, дип күзаллыйм, угылларым. Шушы тигез яланның дүрт ягына да чи вә үтә юан бүрәнәләрдән дивар бастырып кую мәслихәт. Кирмән икән, аның һәр почмагында биек манаралар басып торырга, ким дигәндә ике як диварга күтәрмәле капкалар да көйләнергә тиеш. Мөгаен дә, кирмән эчендәге бер почмакта – дары, ядрә базы, икенче мөйештә яраланган ирләрне яшерердәй ызба-келәт әзерләү дә артык түгелдер. Ә аннары... аннары бер-ике урында тирән чокыр казып, алар эченә дары тутырылган мичкәләр яшерү дә артык булмас. «Егыласы җиреңне абайласаң, ул җиргә алдан ук салам түшә», дип, шаяртып кына әйтмәгән бит безнең бабакайлар. Яу корганда, чигенү юллары турында да уйлау фарыз. Без үз башыбыз белән генә шаярмыйбыз, ничарадан бичара рәвештә хөррият әләме эргәсенә тупланган туганнарыбызны саклап калу, юкка харап итмәү турында да баш вату бик тансыктыр.

– Машалла! – дип тел шартлатты Күчем. – Валлаһидыр, син – сәргаскәр, эткәй. Яуны да, булачак кирмәнне дә ничек шулай алдан ук күз алдыңа китерә беләсеңдер.

Теләкәй елмаеп куярга мәҗбүр булды.

– Башыңа төшсә, башмакчы буласың, диләр бит. Менә син дә берзаманны шулай бер чакрым алдан күреп гамәл корырга өйрәнерсең әле. Әмма ошбу бәла синең өлешеңә дә төшмәсен иде, улым. Ихтилал – ул бер мәртәбә йодрык болгап алу гына түгел. Әлеге ут һәрбер инсан күңелендә дә кабына алмый. Ә бер кабындымы, аны сүндереп тә булмый, качып та котыла алмыйсың. Хөррият әләмен күтәрердәй тәвәккәллек, ахыр чиктә ташбашлык, фидаилык ул сирәкләргә генә эләгә. Азагы халкыңны азат итү белән тәгәлләнмәс тә, бәлкем. Иллә мәгәр ошбу юлдан кире борылу юк. Йә җиңү, йә дар агачы! Сезгә мондый тәкъдир язмаса иде инде.

– Син әллә нишләп ясин тыңларга әзерләнгән сыман, – дип, инде Җәүдәт тә үпкәле вә ярсулы караш ташлап алды.

– Бу – тәкъдир ул, тәкъдир, балакаем! Аннары мин бернинди ясинга да әзерләнмим. Миңа, ерак бабам Карабәк шикелле, хөррият ләззәтләрәк!

**2**

Ык буеның, яшь киленнәр әле яңа гына, бик нечкәләп юып, чит-ятлар күзеннән ераккарак, бакча эченә элгән эчке күлмәк шикелле, керләнмәгән, тапланмаган чагы. Тирә-юнь оҗмах сыман. Әле сабый көлүедәй челтерәп,

әле ак яулыклы әбиләр сүрә укыгандай пышылдап, Ык сулары алга ашкына. Яр буендагы таллар шул сүрәләрне тыңламакчы булып, куян койрыгыдай үзе йомшак, үзе ап-ак песиле ботаклары белән су өстенә иелгән дә гүя тынып калган. Ык хуҗасы да үзенең болытлардай биек каегына утырып, елга буйлап сәяхәткә чыккан чакта, «сез дә уяныгыз», дигән шикелле, дәү ишкәге белән яндагы ялан-тугайлыклар өстенә су чәчрәтеп узган. Эрелеваклы күлләргә әверелгән ул ишкәк сулары хәзер әнә, кояш нурлары белән шаяра-шаяра, җиһанга күз кыса. Яр өсләре, күл яннары түбәтәйтүбәтәй булып таралган чәчәк түтәлләре белән тулган. Тик чәчәкләре генә, бишектәге нарасыйдай, вакыты-вакыты белән генә уянып елмая шул, күбесенчә бөреләргә төренеп, һаман йоклый.

Бикбау авылы каршындагы тугайлык бүген янә кояштан да иртәрәк уянгандыр. Әүвәл кечерәк ике күлне әйләндереп алган арбалар чылбыры астыннан өлкәнрәк яшьтәге агайлар мүкәләп килеп чыкты. Алар күл суында бит чайкап, самавырларга һәм учакларга ут элдерә башлагач кына, ниһаять, яшь егетләр дә кузгалды. Берзаманны инде Бикбау белән ике арадагы елга өсте дә, әлеге тугайлыкка таба сузылган дистәләгән сукмак та, көймә һәм олаулар белән тулды. Ык ярларын умарта күчедәй туктаусыз чыжлаган пычкы тавышлары, йөзәрләгән балта тукылдаган авазлар сарып алды.

Теләкәй дә, билгеле, бередә, халык уртасында. Кулына балта тотып, бил бөгүдән дә чирканмады, көрәк белән җир дә казыды. Ләкин аңа озаклап тән язарга ирек бирмәделәр шул. Йә Уфа ягыннан чапкыннар килеп җитә, йә күршедәге авыл агайлары чеметкәләп китә.

– Олан, олан! Үзең шушындый, мең дошман да үтеп керә алмаслык кирмән калкытасың. Ә кяферләр бик хәтәр уратып, йөзәрләгән ирләр кирмән эчендә торып калса, алар каян алып кына су эчәр соң?

– Морза углан! Каратларның дивар башына баскычлар терәтеп, ыргаклы бау ыргытып та үрмәләве бар бит. Алар өстенә кайнаган сумала илә чиләкчиләк су кою хәстәрен әзерләп өлгердеңме?..

Теләкәй андыйларны кайчакларда эт өстереп куардай хәлгә килә, әмма агайларга үпкәләп тә булмый, гаеп үзендә бит. Өлкәннәр күзгә төртеп торган бар ярыкны ямарга һәм төзәтергә кирәк. Алар да уртак эш, күмәк җиңү турында кайгырта, ни әйтәсең?..

Бер кичтә елкылар суеп, учаклар өстенә казаннар элеп маташалар иде, Теләкәй янына кыяр-кыймас кыяфәт белән алты-җиде старшина якынайды. Теләкәй аларның һәрберсен дә таный, күпчелеге Сөн, Калмия буеннан. Кайберсе белән элек үк, Аеш, Уразай базарларында очрашканы бар иде. Янә берсе – Шәбез Сабан туенда ике-өч ел элек Күчем белән көрәшкә чыккан егет. Теләкәй морза, билгеле ки, ул вакыт үз угылы өчен җан атып утырды, тирләп чыкты. Гайрәтләнеп, тәмам хәлдән тайганчы, озак көрәштеләр. Ахыр чиктә, барыбер, Күчем җиңеп чыкты. Бу Шәбез егете Күчемгә морза булганы өчен, аның йөзен саклыйм дип бирелде микән инде, әллә, асылда да, Теләкәйнең улы шәбрәкме – кемнән сорашасың? «Бүләк бирүченең битенә бакмыйлар», дигән шикелле, җиңүчедән дә күп төпченеп булмый.

Җыйналган старшиналарның инде килеп терәлгәч тә тын торуын күргәч, Теләкәй морза үзе телгә килде.

– Мин ниндидер хата җибәрдемме соң әллә? Төзелешнең рәтен бик белмимме? Әйтегез сез, мин дә Алланың кашка тәкәсе түгел бит, сезнең кебек үк инсан.

Шул чагында Шәбез Сабан туенда Күчем белән бил алышкан егет алга чыкты.

– Мин үзем Шәрифҗан. Минем тагын игезәгем дә бар, ул – Гарифҗан. Мин менә монда, син кабызган учак уртасында. Гарифҗан туганым да янәшәмдә булыр иде, иллә мәгәр ул тоткынлыкта. Аны аманат[12] итеп алып киткәннәр иде дә, мәгәр ул Минзәлә зинданында мәхбүскә әверелде. Аяк-кулларына тимер зынҗыр кидертеп, аны кала юлларын вә кирмән диварларын төзәтү йөгенә җигәләр. Күптән әллә кемнәр аша хәбәр юллады, «ашарыма юк, киемнәрем калмады, үзем яланаяк», дигән. Минзәлә базарына барган чакта үзем дә бер-ике мәхбүсне шулай күргәләдем, кешелекләре калмый, шунда кибә алар...

Шәрифҗан уттай эш вакытында Теләкәйне борчып йөрүе өчен, чыннан да, кыенсына иде, ахры. Ул терәк көткәндәй бер тын иптәшләренә күз йөгертеп алды, аннары чигенмичә, барыбер дәвам итте:

– Син безне «ат дагалаганда бака боты кыстырып йөрисез», дип, сүгәрсең, мөгаен. Галәмәт хәвефле учак кабызуыңны да чамалыйм, аның ялкынында иң әүвәл үзеңнең дә канатларың көяр. Барча якны беләм. Иллә мәгәр миңа Минзәлә зинданында аманат булып ятучы туганым тынгы бирми. Без – игезәкләр. Йә мин аны коткарырга, йә аның урынына үзем барырга тиеш. Нишлим, морза ага, әйдә, акыл бүлеш.

Теләкәй түгәрәк сакалын учына алды, байтак тынып торды.

– Сезнең эчтә нинди ут януын мин дә беләм, туганым, – дип, ниһаять, телгә килде. – Сез беренче түгел, әле ике-өч ай элегрәк шушы ук гозер илә килүчеләр дә булды. Ат дагалыйм, димим, бака ботын да телгә алып маташмыйм. Мәгәр мин кузгаткан давыл гаҗәеп көчле, олы туфан бит ул. Менә сез дә үз ихтыярыгыз илә килеп кушылдыгыз, берегезне дә, берәү дә көчләмәде. Без шушы ихтилал буранын кузгатмасак, айлар-еллар буе җиребезне талаулар, бәгыребез уртасына чиркәү салып куюлар, безне илсез-җирсез, телсез вә динсез калдыру тагын да көчлерәк дәвам итәр. Без менә шушы кирмәндә ихтилал вә хөррият әләмен күтәрмәсәк, шул ук аманат алып китүләр, безнең туганнарны зинданнарда газап чиктерү, хәтта йортларыбызга кадәр кереп талау, менә мондый бәләкәч сабыйлар ак сакаллы картка әйләнгәнче дәвам итәр.

Теләкәй йомры итеп, матур итеп сөйләүдән үзе дә туйды бугай, кискен рәвештә камзулын салып атты. Кирмән дивары өстендә тук та тук килгән балта осталарына күз йөгертеп, әмма Шәрифҗанның йөзенә текәлеп тезде:

– Ике көймә койрыгын сыңар кул белән тотып булмый, җегетләр, сез аңлагыз инде. Әйдә, әүвәл менә шушы кирмән янында каратларны җиңик. Кулыбыз бушап калса, безгә Минзәлә кирмәнен генә урап кайту берни тормас. Түзегез инде, зинһар? Менә монда җиңү – иң төп бурыч. Ә җиңүгә ирешмәсәк, аманат алулар, зинданга ябып мәсхәрә кылулар гына көтә безне, сез аңлагыз инде?..

Теләкәй йөрәкләре януга түзмичә килгән Сөн буе ирләрен менә шулай

[12] Аманат – тоткын.

үгетләп озатты, ләкин зиндандагы газапларны кичерүче мәхбүсләр хәлен дә төгәл итеп күз алдына китерә иде.

– Түзик, түзик әлегә, туганнар, инде күп калмады, – дип юатты ул үзен...

Ә икенче кичтә Сәгыйт Җәгъфәр яныннан чапкын килеп җиткән.

– Әйдаман хәзрәтемез Өфедән Тубылга тиклем сузылган араны җәдид Болгар ханлыгы дип игълан итәргә ниятли. Морза борадәрем – Алтын Сарайда каһан булып торган Карабәк туруны бит. Җәдид мәмләкәттә үзен хан киезе өстенә күтәрүгә ул ризамы? Җавап алып кайт, ди.

Теләкәй гаҗәпләнүдән тораташтай калды. Йа Хода! Нинди акылсыз гамәл, ниткән хыялый сүз бу? Теләкәйнең башына тай типкәнме әллә, юнегерме, ярар, бер йөз, ике йөз авыл өчен нинди хан булу, ди? Казан ханлыгын кабат торгызу өчен дә ике йөз генә түгел, ике мең авыл халкының да бүген куәте, дәрте җитми. Чөнки ул инде йөз дә утыз ел буена тапталган, рухы имгәтелгән, сүле коргаксыган. Аның шәп гаскәр төзеп куярдай егәре дә, баш бирүне белмәс ирләре дә калмаган. Өстәвенә, Казан түгел, ә Болгар ханлыгын кире кайтару нияте илә шигарь ташлыйсың икән, якын-тирәңдә бер йөздән дә артык җайдак калмаячак. Болгар ханлыгы дип игълан иттеңме, димәк, синең халкың да «болгар» атын йөртергә тиеш була. Күлмәк яки бишмәт яңартудан ир-ат белән хатын-кызның җенесе дә, акылы да үзгәрми бит. Нинди файда? Кяферләр синең муеныңа китереп таккан зынҗырны «болгар» йөртсен дә, «татар» сөйрәсен ни, шуннан ни яңара? «Әһә, татарлар үз атын «болгар»га алыштырды, болары инде безнең дошман түгел», дип, синең өчен читлек капкачын ачып куя, зынҗырларыңны салдырып аламыни? Тот капчыгың! Аһ, Сәгыйт хәзрәт, аһ, син, саран бәндә! Нишләп асылыңны аера алмадым соң?..

Теләкәй морза чапкынга таба борылды да усал ярып салды.

– Хәзрәт миңа бүтәнчә чапкын юлламасын. Ул минем өчен вафат.

**Сигезенче бәйләм**

**1**

Уфа юлын тотырып, Ык буена дошман якынлаша. Бер йөз җайдак, уткүз отряды итеп, ун чакрым чамасы алга җибәрелгән. Биш чакрым арада – тагын бер йөзлек. Меңьярым чамасы җайдак – төп гаскәрдә. Бу юлы гаскәр башлыгы булып Андрей Михайлович Коркодинов галиҗәнаплары шәхсән үзе бара. Аның көймәле, бәллүләп бара торган затлы арбасы – иң уртада. Аны яңа сауган сөттә коендырып чыгарылгандай ап-ак төстәге сигез чаптар тарта. Көймә тирәли тезелешеп, офицерлар баскан. Алардан чак кына калышып, берничә старшина белән морзалар тезелешкән. Иңсәләре салынып төшкән, йөзләре боек һәм караңгы, юл буена хәтта үзара да бер сүз сөйләшмиләр. Коркодинов әледән-әле аларга күз йөгертеп алырга һич онытмый. Тегеләрнең генә керфек күтәреп, воевода галиҗәнапларына таба борылырга исәбе юк. Аңлашыла да сыман.

Коркодинов ошбу бәндәләрне сындыру һәм үз кубызына биетә башлау өчен бер ай чамасы вакыт сарыф итте. Әүвәл поплар, офицер белән стрелецлар, хәтта Уфа дворяннарын да җәлеп иткән иде. Фәрманны Иван белән Пётр падишаһлар игълан иткән бит, воеводага аны дворян һәм офицерлар каршында кабатларга гына туры килә.

– Морзаларны ярты ел эчендә чукындырып бетерергә, чукынудан баш тартканнарны биләмә һәм ялчыларыннан коры калдырырга!

Офицерлар ике-өч тарафка юнәлеп, унбиш-егерме авылны урады, иллә мәгәр һәр сәфәрдән кул кушырып кайтты.

– Үз ихтыяры белән тәре үбәргә атлыгучы сыңар морза да юк. Бер-икесен станга салып, чыбыркылар белән ярып та карадык, берсе-бер һич сынмый.

Шуннан соң воевода дүрт-биш морза нәселен, зынҗыр салып, Себергә озаттырды. Аларның барча мал-мөлкәтен талап, Уфага алып кайттылар, ә өй бүрәнәләре ике яңа авылда чиркәү салу өчен кулланылды. Мондый сабак тәэсир итте, ахры, Таш Билбау ягындагы ике морза Агыйдел читендәге суга чумдырылды, муеннарына көчләп тәре таккан чагында да йолкып атмадылар. Дөрес, моңа карап кына морзаларның берсе дә үз төбәгендә рус атын күтәреп йөрергә дә, рус ирләре белән янәшә басып, чиркәү эчендә поплар җырын тыңларга да ашыкмады. Тәрене тагуын-тактылар, ә хак булса, алар өйләрендә һаман намаз укый, Коръән шәриф укуны дәвам итә икән.

Буйсынганнарын тәмам сындыру һәм бүтән татарларга гыйбрәт бирү өчен воевода аларны Уфа бистәләре эченә күчерттерде. Воевода бүлеп биргән өйләре шәп, өстәвенә затлы кафтаннар һәм акчалар өләшенде, чукынган морзаларның һәммәсен салым түләүдән дә, гаскәр яки ямщик хезмәте өчен олаулар бирүдән дә азат иттеләр. Ә чукынудан баш тарткан өчен шыр-ялангач көенчә урамнарга куып чыгарылган тискәре морзаларга яңа ат тагылды:

– Чабаталы морза!

Шул хәбәрне ишеткәч тә, сөенүдән воевода кат-кат кулын уды.

– Чабаталы морза! Вәт шәп тагылган бит!

Әмма тора-бара воевода барыбер уйга калды. Бу татар атлы халык ныклы хуҗалык корып яшәүгә күнеккән. Болар өчен мал-мөлкәт вә байлык – культ дәрәҗәсендә. Малларына тисәң, алар өчен сугышырга һәм үләргә дә әзер. Ә менә җиткән кызларын талап, аны рус стрелецына яки сәүдәгәр малаена кияүгә бирәсең һәм шул вакытта гына чукындырасың икән, боларның бик сирәге генә балтага ябышырдай хәлгә җитә, әниләре күз яшенә батса да, әти дигән тараф ахыр чиктә барыбер ризалаша. Угыл, малай дигәндә дә шулай. Боларның малайларын гаскәргә дип, сугышка дип алып китәсең, юк бит, мал югалткан төсле елашмыйлар. Аннары болар туган телен алыштыруга да тиз күнегә. Коркодиновның ничә сәүдәгәр келәтенә барып кергәне бар, приказчикларның күпчелеге татар. Дөрес, татарлар урлашмый, алар кулга чиста, дигән даны бар. Иллә мәгәр бер-ике ел эшләүгә үк рус сәүдәгәренең үзен сатып җибәрерлек булып, русчага өйрәнәләр бит. Эштән куам, авылыңа кайтарып җибәрәм, дип өркетсәң, алар әти-әниләрен югалткандай үкереп-үкереп елый. Димәк, бу халык тәнендә аларны бер-берсеннән читләштергән яралы урыннары, тилгән урынына ташланып чукырдай йомшак яклары да бар бит.

Менә шушы ачышны сынап багу өчен Коркодинов ике-өч татар сәүдәгәрен чакыртты.

– Йә тиз арада чукынасыз, йә барча мөлкәтегезне талап алам! Үзегезне шәп-шәрә көенчә йә урамга, йә Себергә куам!

Сынды, валлаһидыр, сынды әлеге сәүдәгәрләр. Димәк, тел белән дин – җан азыгы гына, ә бәндә балаларын мәгыйшәттә мөлкәт, мул калҗалы табын, кәнәфи һәм нәфес яшәтә шул! Татар ирләренең бөтен Уфаны тирәләп алу нигезе дә – башкорт катламына язылган булып, күбрәк җир биләмәсе эләктереп калу һәм мул тормышта яшәү. Болар көмешкә суырудан һәм күршесенең тавыгын урлаудан, күршенең хатынын, анысы да эләкмәсә, балдызын кымтырыклаудан тәм табып, балчык белән сыланган алачыкта гомер кичерүгә риза түгел. Болар муллалары бакый дөньяда вәгъдә иткән җәннәтне фанилыкта кичереп калырга ашкына бит, и-и, хыялый җаннар!..

**2**

Коркодинов Ык ярында калыккан өр-яңа кирмәнне күреп алуга ук, зәхмәт суккан кешедәй, авызын ачты да хәрәкәтсез калды. Әттәгенәм! Теләкәй атлы сыңар морза да шушы кадәр дәһшәтле һәм кодрәтле агач кирмән калкытып куя алыр икән! Бүрәнәне бастырып тезгән биек стеналар, дүрт манара, ике асылма капка, ур, ерым, башларын очлап җиргә яртылаш күмелгән керпе-чытырманлык. Валлаһидыр, Уфадагы кирмән бер читтә торсын! Вәт менә бу морзаны чукындырып һәм ярдәмче итеп үзеңә алсаң икән!..

Кирмән әйләнәсе буйлап эчке яктан кútәртмә басма корганнардыр инде, сакчы ирләр манара һәм дивар түбәләре астына тезелешеп баскан. Диварга уелып ясалган тәрәзәләргә капланган һәм манараларда йөренгән шәүләләрен санасаң, сакчылар ике дистә ядрә очырту белән генә кырып салырлык дәрәҗәдә аз түгелдер, сафлары хәтәр генә саллы күренә. Ләкин алар рус полклары кебек кырым татарлары, төрек яисә ләһләр[13] белән яу кичергән, орыш кануннарын яттан үзләштергән көч түгел ләбаса. Менә, воевода галиҗәнаплары бер ыргылуда кирмән диварларыгыздан көл калдырып, үрнәк һөҗүм сабагы уздырачак әле!..

Коркодинов якындагы бер калкулык өстенә менеп басты. Моннан булачак яу кыры уч төбендәге кебек ачык тоемлана. Теләкәй кирмәне таба өстедәй тигез ялан-кырда алагаем зур чатыр яки эскерттәй олы кибән шикеллерәк калкып тора. Елга буенда да, ялан яклап та өстәмә чокырлар юк. Китче әле, «кил дә яула мине» дигәндәй, киң сәкегә туарылып яткан тол хатындай беркатлы, хәтта күндәм дә бу!..

– Дубина, Барятинский, Молоствов! – дип, воевода үз янына ярдәмчесен һәм Минзәлә каласыннан Мәскәү фәрманы буенча килеп җиткән кенәзләрне дәшеп алды. Түрәләр яшь-яшен, мәгәр олы корсаклылар, калкулык өстенә менгән арада өчесе дә тирләп-мышнап чыкты.

– Диспозиция мондый, – дип, сәрдәр кыяфәтенә кергән воевода дәвам итте: – Дмитрий Пантелееч, син бер полк белән әнә теге күл ягыннан ура. Кенәз Барятинский, Иван Фёдорович, син дә шулай ук аерым полк башында, елга ягындагы ике аралыкка бәреп керерсеңдер. Ә Дубина әфәндебез Уфа тирәсеннән тупланган ополчение һәм дә ике йөз стрелец белән әнә теге олы курган ягыннан һөҗүм ясар. Ләкин син ополчениегә, бигрәк тә мөселман җайдакларына күз-колак булырга онытма. Алай-болай татарлар

[13] Ләһ – поляк.

җебегәнлек күрсәтсә йә дала ягына кача башласа, стрелецлар ядрә һәм пулялар кызганып маташмасын.

Кенәзләр инде кире борылырга маташа башлаган бер мизгелдә Коркодинов янә өстәп куйды.

– Иң башта кирмәнне мортирачылар утка тотар, алар тынуга ук бердәм рәвештә һөҗүмгә ташланырсыз. Ходай безнең белән, алга, яуга, мөхтәрәм әфәнделәр!..

Берзаманны Ык ярында күк күкрәде сыман. Тупларның ярларга бәрелгән кайтавазы кирмән эченә бикләнгән бер йөз чамасы аргамакны чыгырыннан чыгарды, ахрысы, алар бәбәкләрен акайта-акайта, алгы аяклары белән күккә таба сикереп дуларга һәм иләмсез тавышлар чыгарып кешнәргә тотынды. Малкайларны бераздан гына көтүчеләр ипкә-сапка кертте.

Ядрәләр кирмән диварларына әлләни зур зыян китермәде. Дөрес, бераздан биш-алты урында бүрәнәләрнең чәрдәкләнеп, бер манараның яртылаш җимерелеп бетүе ачыкланды. Эчтә әзер бүрәнә өеме бар, җимерек җирләрне, агачларны салдагы шикелле бер-берсенә аркан белән бәйләп, өстәмә калканнар белән ямау авыр гамәл түгел. Иң яманы – һөҗүм, дошман белән йөзгә-йөз бәрелеш.

Минзәлә һәм Уфа укчылары озаклап өйрәтелгән, тәҗрибәле, каһәр! Әнә бит, алдан ук әзерләнгән озын баскычларын җиде-сигез ир култык астына кыстырып йөгерә. Унышар ир, тигез сафка тезелеп, фузей мөшкәләренә тутырылган ядрәләрне очырып, баскыч тотып килүчеләрне каплый. Бер саф икенчесен алыштыра, көпшәләреннән зәңгәр төтен бөркеп аткан гөрелте һич туктамый. Дәһшәт бөркегән залпларның хәвефле авазыннан диварга берегердәй булып сыену да коткарып кала алмый. Үлем белән качышлы уйнау, үлем туе бит бу!

Хәвеф аһәңе укчы солдатлар баскыч буйлап дивар өстенә үрмәли башлаган мизгелдә генә басылгандай булды. Нәкъ шулвакыт бүрәнә дивар уемтык-тәрәзәләрендә киң итәкле киез бүрек кигән башкорт егетләренең кара-кучкыл йөзе чагылып алды да аска таба дистәләгән ук яңгыры очты.

– А-а-ах! У-у-ух! – дип соңгы тапкыр аваз сала-сала, баскычлардан җир өстенә яраланган солдатлар тәгәрәде.

Ләкин солдатлар ныклап өйрәтелгән. Баскычтан аска тәгәрәгәннәрен, аннан ике-өч адым астарак ияреп менгәне алыштырды. Ул да түгел, югарырак менгән ирләр кирмән диварындагы бүрәнәләр очына ыргаклы бау ташлады, солдатларның алгы сафлары дивар эчендәге басмаларга да сикерешеп төште.

– Егетләр, чигенмәгез! – дип әмер бирә-бирә, ике яктан ике бертуган – Күчем белән Җәүдәт басма буйлап бер-берсенә каршы килә башлады, аларның юлына аркылы төшкән укчы солдатлар, тавык-үрдәк сыман канат җилпи-җилпи, дивар тышына очты...

Беренче һөҗүмнәрне җиңел, чамасыз кан түкмичә, кире кайтардылар. Аннары кирмән эченә дә җәядән очырылган уклар очып керә башлады. Менә монысын берәү дә күз алдына китермәгән иде.

– Башкорт мәргәннәре бит бу! Аларны кайсыдыр сатлыкҗан котыртып алып килгән! – дип, барыннан да элек Теләкәй морза дулады. Аннары ул кирмән эчендәге башкорт укчыларына борылып аваз салды.

– Киекбай, Кинҗә, Әлибай! Бояр Куркакдинга ияреп килгән сатлык борадәрләрегезгә аваз салмый булмас, аларны безнең тарафка чыгарырга кирәк!

Диварлар өстеннән урап, хәбәр кире кайтты:

– Һин борсылма, морза. Башкаса бедгә каршы ук осыру булмас!

Шул мизгелдә үк дивар өстендәге башкорт әле тилгән, әле ләкләк авазлары чыгарып хәбәр салды. Нинди тылсым, нинди галәмәттер, берзаманны Коркодинов әмеренә буйсынып килгән башкорт ирләре яны белән яткырып куйган арбалар ыстаны эченнән елан шикелле читкә шуышып китте дә күз ачып йомган арада иң якындагы күл буен уратып алган камышлар арасына кереп юкка чыкты.

Дивар өстендәге орыш-бәрелеш тавышлары кайсыдыр бер мәлдә тынган кебек булгач, Теләкәй морза янына биек басма буйлап качак Фёдор солдат йөгереп килеп җитте.

– Син кайчан миңа ганимәт тупларны сынап карарга форсат бирәсең соң? Мин аларның куәтен ачыклап карамасам, аннары йоклый алмыйм.

Теләкәй дә, якын-тирәдәге ирләр дә Фёдорның кыяфәтен күреп елмаймыйча булдыра алмады. Башында – татар бүреге, өстендә – татар җиләне, хәтта аякларында да татар читеге бит. Күзләре ут бөрки, яңак очлары алсуланып тора, валлаһидыр, бәйге сызыгына баскан ярсу чаптар кебек. Теләкәй башын чайкый-чайкый гына ризалыгын бирде:

– Әйдә-әйдә, сынап кара инде. Мәгәр бик сак кылан, үтә белеп көйлә. Безнең егетләргә зыян-зәүрәт килерлек булмасын.

Ике чыра янып бетәрлек тә ара узмагандыр, Ык буенда торган манара өстендә әүвәл бер көлтә ялкын һәм каз оясы кадәр төтен пәйда булды, аннары бар яланны дию пәрие үкергәндәй иләмсез аваз каплап алды. Коркодинов басып торган калкулык ягына борылып карасалар, воевода үзе ике як чигәсен кысып җиргә чүккән, ә аның алдында ике-өч офицер һәм җиде-сигез солдат гәүдәсе аунап ята иде.

– Машалла, Фёдор! Валлаһи, чын мәргән син!

– Гәрәй! Йәнәй! Ирәкте! Бүләр! – дип, бүрекләрен күккә чөя-чөя, дивар өстенә тезелешкән ирләр тантана итә һәм үз ыруларының рухларын шаһитлыкка чакыра башлады. Теләкәй генә тагын ни кылырга да белми каушап калды.

Воеводаның да хәле шәптән түгел, ахрысы. Ул ике уч төбе белән дә бер як ботына ябышкан, бармак очларыннан туктаусыз кан тама. Биш-алты стрелец аны кулларына күтәреп, көймәле арбасы ягына алып китте. Коркодинов карыша, тартыша, әмма аңа игътибар бирүче юк. Ахыр чиктә үзенең хәле белән ризалашты бугай, арбаның бер ягын каплап баскан солдатларга дәште:

– Иван Фёдорычны, Минзәлә воеводасын чакырыгыз! Моннан ары яу белән идарә итү аның өстендә. Мин аннан штурм, туктаусыз штурм гына таләп итәм!..

Стрелецларны җыеп, кабат тигез сафларга бастыру байтак вакыт алды. Юк, сынмаган да, шөбһәгә дә төшмәгән бу солдатлар. Сафлар алдында үзе йөгереп йөргән боярны күреп алуга ук, барча укчыларның йөзләре һәм

карашы кырысланды. Тыгыз сафлар диңгез дулкыныдай чайкала-чайкала кирмәнгә таба йөгерә башлагач, ялан өстен янә аҗаган уйнагандай тавыш каплап алды.

– Стрелец Савелий үлеме өчен үч алмый калмыйбыз!

– Порфирий, Сидор, Акинфий гомерләре өчен алга, алга, алга!..

Дивар өстенә менеп җиткән стрелецлар саны ике-өч йөз чигеннән дә арткач, Теләкәйнең яман тавышы янә күк йөзен ярды.

– Фёдор, Фёдор кайда?

Күз ачып йомган арада каршында качак кунак калкып чыккач, колагына иелеп пышылдады:

– Дары мичкәләре яшергән баз янына аттыр! Мин аерым хәбәр бирүгә үк, шнурларга ялкын элдерерсең.

Аннары Теләкәй якындагы бер башкорт яугиренә әмер бирде:

– Ук очыңа ут элдер дә Борындык күленә ат!..

Сагызлы сүс уралган ук һавада яшендәй эз калдырып күл өстенә төшеп чумуга ук куе имәнлек һәм әрәмәлек эченнән сөңге-чалгыларын урмандай уйнатып, җайдаклар алае өерелеп чыкты һәм кирмәнне тирәләп алган рус солдат вә офицерлары өстенә карчыга өере сыман очып кунды. Коркодинов кул астыннан качкан башкорт яугирләре дә шулар сафында икән, алар җәясеннән очкан уклар йомран сызгыргандай һаваны ярып барды һәм дистәләгән җайдакны иярләреннән умырып төшерде. Әмма бер-берсенә якынайгач, орышларда чыныккан стрелецларга каршы тору җиңел түгел икән, укчы солдатларның ыргаклы сөңгеләренә эләгеп, дистәләгән татар ирләре дә иярләреннән очып төште. Хәтта иярдән егылганнарны да исән калдырмыйлар, стрелецларның үткен шпагасы егетләрнең калын бишмәтләрен дә без урынына ертып кына керә.

Теләкәй янә бер башкорт яугирен үз янына чакырып китерде.

– Мөгаен, берзаманны миңа кансыз яисә җүнсез, дигән ат та тагарлар. Иллә мәгәр мин кабахәтлекне, үзенең әти-әнисен, ата-бабасын саткан сораннарны гафу итә алмыйм. Әнә, күрәсеңме, егет, каратлар арасына биләмә-байлык хакына ага-энеләрен дә, туган өммәтен дә кяфернекенә алыштырган сатлык борадәрләр кереп баскан. Дөресе – борадәрләр түгел, шул ук каратлар, үз мәнфәгатьләре хакына безне юк итәргә килүче кабих җаннар. Мин андыйларны гафу итә алмыйм. Безне әнә шул аумакайлык, җебегәнлек, таркаулык һәм дә ахыр чиктә дошман кавемне якын күрү, аның илә туганлашу җиңелү вә кол калу хәленә китерде. Менә шул сәбәпле без бүген бер кулыбыз илә дошманга, ә икенчесе илә алар арасына күчкән сатлыкҗан, соран вә җебегән җаннарга каршы орышырга мәҗбүр. Хәзер менә синең үзеңә һәм синең юлдашларыңа да боерам, ялварам, гозерлим. Дошман арасына басып, үз туганнарына каршы корал күтәргән, безгә үлем чәчүче татарларны чүкегез. Теләсә кайсы чирне, эт имчәгедәй иң яман чуанны да төбе-тамыры илә йолкып ату хәерле. Үлек барча тәнең буйлап таралса, аны инде коткарып булмаячак! Миңа җиңел түгел, ансат хөкем итмә. Ләкин мин бичара чигенмәскә мәҗбүр. Кабат гозерлим, барча сатлыкҗанны юк итегез! Ә гөнаһы, ярар, миңа, миңа булыр...

Берникадәр вакыт Теләкәй һөҗүм белән килүче дошман сафларын күзәтте. Һаваны яндырып, йомрандай сызгырып, дивар өстеннән зәһәр уклар оча. Әнә, дошман офицерының җилкәсе артына ышыкланып, ярымбөкрәеп атлаган бер татар сугышчысы җир өстенә ауды. Бишмәте чәшке тиресе белән каймаланган, йә старшина, яисә сәүдәгәрдер. Аннары, әнә, сәрпи бер ук сырган киемнәргә төренгән икенче татарның да бишмәтен ярып керде. Ук бичараның корсагына барып кадалгандыр, бишмәт ярыгыннан эчәгеләре суырылып чыкты, үзе капкынга эләккән бүредән дә яманрак улый. Күзәтеп тору да кызганыч, тик ни хәл итәсең: бу бит Аллаһы Тәгалә төшергән фәрман түгел, ә фәкать үзе сайлап алган тәкъдир, бик хурлыклы тәкъдир...

Дивар өстенә тагын ике йөзләп стрелец өстәлүен күргәч, кесәсеннән алып, Теләкәй ак яулык болгады. Стрелецлар моны бирелү, дип кабул итте, ахры, дивар өстендә кылычлар чыңлаган тавышлар сүлпәнәйде.

– Җиңелүен таный, каршы торырдай көче калмагандыр, – дип сөрән салган аваз күкрәп узды.

Теләкәй үзе дә ярсый башлады, Фёдор китеп югалган манара тарафыннан күз алмады, аннары түземлеге коргаксыды бугай, үз янында торган улы Җәүдәткә таба борылып дәште:

– Фёдор җепкә ут элдерә алмый интегә микән әллә? Җеп тирәндә, базның төбендә үк бит, бәлки, чиләнгәндер. Бар, ярдәмгә йөгер!

Теләкәй бу минутта үзенең нинди җинаять кылуын абайламыйча да калды бугай. Аның игътибары тик манарага юнәлгән, ул Фёдорны көтә, аңа өметләнә...

Ә Фёдор, чыннан да, бу минутта ике чакма ташны бер-берсенә сугып, һич кенә дә ап-ак җепкә очкын элә алмый җәфалана иде. Ниһаять, соңгы бер мизгелдә җеп очы ут алды, ялкын чебен безелдәгән тавыш чыгарып, астагы мичкәләр авызына таба төшеп китте. Артта мышнаган һәм дөбердәгән тавышлар ишетелде. Әйләнеп караса, морза улы Җәүдәт.

– Булды, булды, мин кабыздым, Җәүдәт! – дип тантаналы тавыш белән егетне кочагына алып та өлгермәде, түбәндә коточкыч шартлау авазы яңгырады, кибән кадәр ялкын манараның эчен чолгап алды...

Тыштагылар өчен дә кара мәхшәр. Мичкә-мичкә дары манараны гына түгел, диварларның яртысын әйләндереп атты. Йөзәрләгән татар яугирләре дә, рус стрелецлары да чәрдәкләнеп беткән бүрәнәләр астына күмелеп калды. Басмаларда орышып йөргән дошманнар – ике як та берьюлы тирән баз эченә йә җимерелгән дивар аръягына чәчрәп очты...

Теләкәйнең күкрәге һәм аягы яраланган, гәүдәсен кыймылдатырлык та җегәре юк иде. Томан эчендә калгандай, төрле яктан яңгыраган авазларны гына ишетеп ятты.

– Исән калган стрелецлар! Килгән юлга чыгып тезелегез!

– Яраланган офицерлар бардыр, берсен дә ташлап калдырмагыз! Ташлап китүегез соңыннан ачыкланса, строй алдына чыгарам да атам!..

Тагын тынлык, аннан тагын тавыш:

– Теләкәй морзаны Ык буена таба төшерегез! Анда көймә көтә.

– Шәһит киткән Җәүдәт белән Фёдор җәсәдләрен күпме эзләсәк тә, табып булмас инде...

**3**

Теләкәй ике тәүлектән соң гына һушына килә алды. Күзләрен ачып, карашын йөгертсә: үзенең газиз өе, янында хатыннары, имче карчык, ишек катындарак – кара көйгән Күчем. Теләкәйнең кымшануын шәйләп алуга ук, хатыннары аның өстенә иелә төшкән иде, хуҗа яргаланган иреннәрен ялап, бер генә сорау бирде:

– Җәүдәт, угылым Җәүдәт кайда?

Бер хатыны да җавап кайтармады. Күңелгә шом иңде. Теләкәй кырыс карашы белән Күчемгә текәлде. Ниһаять, мәгарә эчендәгедәй авыр тынлыкны өлкән улының аһәңе кылычтай ярып салды:

– Җәүдәт юк инде ул, әткәй... Энекәшнең җәсәден ике көн буе актаргач кына таптык... Сине көтеп булмый иде, ләхеткә иңдерергә дә өлгердек, ачуланма, әткәй...

Теләкәй күз кабакларын, йодрыкларын кысып, яман ыңгырашты. Иннә лилләһи вә Иннә иләйһи раҗигун! Ахмак син, җүләр вә тинтәк син, Теләкәй! Зиһене бар бәндә үз куллары белән газиз улын үлем авызына җибәрә, димени? Ләгънәт тиеш сиңа, ләгънәт, ләгънәт!..

## Тугызынчы бәйләм

**1**

Патшабикә Софья галиҗәнапларының иртән генә кәефе шәп иде.

Иртәнге каһвәсен дә эчәргә өлгермәде, сарай тупсасында шпагасын таш идәнгә бәргәләп ашыккан офицер пәйда булды. Үзенең күзләре каймак яларга дип, баз эченә төшкән мәченеке төсле ялтыр-йолтыр килә, төскә-биткә дә шактый чибәр, килешле.

Офицер патшабикәнең тагын да ачыбрак куйган күкрәкләренә, итәге «ялгыш кына» бер якка шуышып төшкәч ачылган таза, шома ботына да игътибар итми калмады, әлбәттә. Иллә мәгәр хезмәт бурычы һәм дә этикет дигәннәре дә бар бит, кадалгыры!

– Сезгә Уфа каласыннан ашыгыч пакет, галиҗәнапларыбыз. Бояр-воевода Коркодинов Андрей Михайлович галиҗәнаплары шәхсән сезнең изге вә нәфис кулларыгызга тапшырырга кушты.

– Син тумышың белән кай яклардан буласың, поручик әфәнде? Мәскәү каласында элек тә булганың бардыр бит, шәт? – дип кәнфитләнде азгын патшабикә.

– Мин Туладан, изге галиҗәнап. Мәркәзебез мин фәкыйрегезгә сабый чактан таныш.

– О-о, шулай укмыни? – дип Софья һаман кәнфитләнүен дәвам итте. – Әти-әниегезне озак күрми яшәү бик авырдыр?

Поручик та уенны бозарга базмады.

– Минем өчен Ватанга һәм гүзәл патшабикә галиҗәнапларына хезмәт итү барыннан да өстен.

– Рәхмәт, рәхмәт сезгә, поручик әфәнде. Алайса, сез бик еракка югалмагыз әле. Җавап хаты алып китәсегез булыр.

– Баш өсте, баш өсте, бөек патшабикәм...

Офицер күз алдыннан югалгач, патшабикә воевода җибәргән рапортны ахырына кадәр тыныч кына укып чыга алмады.

– «Без Уфа каласыннан меңьярымлы гаскәр белән ике йөз чакрым үткәч, Ык елгасы ярында каракларның хисапсыз өере белән бәрелешкә кердек. Казандагы бояр-воевода Барятинский Данила Афанасьевич ярдәм полкын бик соңарып һәм әле анда да мең кат ялварулар нәтиҗәсендә генә озатканга күрә, аның стрелецлары үз вакытында килеп ирешмәде һәм яу барышында үзем авыр яра алу сәбәпле, ахырда рекогносцировка кылырга һәм Уфага әйләнеп кайтырга мәҗбүр булдык». Вәт язып та торган бу карт алаша! Барятинский үз вакытында полк җибәрмәгән. Ул соңарган. Шәхсән Коркодинов үзе генә яуга кергән дә яраланган икән. Оят, хурлык! Нинди рекогносцировка дигән сүз ул? Нинди күзгә төтен җибәрү? Чигендем, качтым, йөгердем, диген, җебегән, карт алаша! Йа Хода! Җүнле, иңенә таянырдай төбәк башлыкларын каян табасы соң?!.

Софья шул рәвешле әле бик озак котырынды, шашынды, ахыр чиктә Коркодиновның җиңелү хурлыгын боярлар думасы утырышында күтәреп чыгарга, дигән карарга килде. Әйдә, Софья берүзе генә баш ватмасын, боярлар да, үзләре корып куйган системаның ни дәрәҗәдә череп, һичбер очракта да таяна алмас хәлгә килүен күреп, гыйбрәт алсын, ахыр чиктә патшабикә хәтле патшабикәгә акыл сатудан тыелсын, ул башлаган бөек гамәлләргә кысылмасын әле!

Дума утырышына Иван галиҗәнаплары ялгыз гына килгән. Пётр турындагы игълан һәммәсен диярлек аягыннан ега язды.

– Пётр Алексеевич галиҗәнаплары, әнисе Наталья Кирилловна белән бергә, әтисе Алексей Михайлович шәһәр читендә төзеп калдырган утарларына киткән. Яшүсмер Пётр галиҗәнапларының сәламәтлеген ныгыту таләп ителгәнгә күрә, әгәр боярлар думасы тарафыннан таләп булмаса, берничә ай буе Преображенский авылында гына гомер итәргә ниятлиләр икән.

Милославскийларга, ягъни Иван белән Софья яклыларга нәкъ шул гына кирәк, аларга бармак күрсәтсәң, беләгеңә кадәр әләктереп, тешләми каламы соң?!

– Ул борын асты да кипмәгән Пётр болай да Иван белән янәшәдә тәхеткә утыртып куюга лаек түгел иде. Пётр – сабый чагыннан бирле корых та корых килеп ютәлли, соңгы айларда бөтенләй яңагы-муены да, кул-аяклары да тартыша башлады. Кайбер чакларда егылып китеп, үз-үзен белештермичә, авызыннан селәгәй агызып, күзләрен акайтып, зәхмәт чире әләккәндәй тартыша. Алай, чире көчәеп, тәхеткә дә утыра алмый башлагач, аның үзенә дә, анасы Наталияга да тәхеттән бөтенләй баш тарту гаделрәк түгелме икән?..

Янә күкерт шикелле кабынып китәргә әзер талашны Софья-ирдәүкәнең мичкә төбеннән яңгырагандай усал тавышы өзде.

– Пётрның бары ни дә, югы ни. Сүз булмаганда, сүз булсын, ата казыгыз күкәй саламы? – дип, тиктомалдан гауга чыгармагыз әле. Җыелу сәбәбе үтә житди. Уфа воеводалыгында әнә татар белән башкорт баш күтәргән. Ул томана халык белән, билгеле ки, морзалар һәм муллалар җитәкчелек итә. Бер тилемсә мулла Көңгер төбәген хәтта Болгар әмирлеге, дип игълан итәргә дә маташа, ди.

– Татарлар Казан ханлыгы аударылганнан бирле артларыннан тын алып

кына яши иде бит әле. Мәчетләрен башыннан ахырына хәтле җимереп бетермәдек. Авыл-салалары исән-сау. Муллаларына тимибез, мәдрәсәләрен ябып куймадык. Ит изгелек, көт явызлык, дигәннәре шушылай була икән, – дип, Милославскийларның берсе бик тәфсилләп сөйли башлаган иде, Софья янә идарәне үз кулына алды.

– Уфа воеводасы Коркодинов махсус чапкын куган. Ул шактый олы гына гаскәр җыеп, фетнәчеләргә каршы чыккан булган. Мәгәр воевода гаскәрен Уфадан ике йөз чакрымда пыр туздырып ташлаганнар. Коркодинов үзе яраланган. Ул Казан воеводасы Барятинскийдан, ярдәмгә ике-өч полк стрелец бирмәүдән зарлана. Барятинскийны мин дә һич якламыйм. Падишаһлар иминлегенә куркыныч туган чакта үз кишәрлегенә генә бикләнеп яшәү хөкүмәт вәкиле итеп билгеләнгән, кул астына зур биләмә һәм мөмкинлекләр бирелгән түрәне һич акламый. Йә, әлеге хатаны ничек төзәтәбез?

Милославский яклылар тәкъдимнәрне су буедай тезде, язып кына өлгер.

– Стрелецларның өстәмә полкларын юлламасак, фетнәчеләрнең Көңгерне генә түгел, Уфаның үзен дә яулап алуы бар.

– Барятинскийларның Казанда утырганы да Смоленски яки Киевларны яулап, рус җирен киңәйткән һәм дәүләтне кинәндергән бик зур сәрдәр түгел. Әлләкем булып кылана икән, алырга да ыргытырга үзен!

– Аларның Барятинскийлары да, Коркодинов та җирле халыкны имеп, кесә калынайтып кына яткан түрәләрдер инде. Воеводаларны җавапка тарту да, җәза бирүләр дә онытылды бездә...

Тагын шактый озак тарткалашканнан соң гына Софья галиҗәнаплары үз фәрманын яңгыратырга батырчылык итте:

– Воевода Коркодиновны үз урыныннан алып ыргытырга! Кул астында булган барча полклары белән Казан воеводасы Барятинский Минзәлә кирмәненә күченсен һәм шуннан торып, ул төбәктә дөрләгән барча фетнә утын тар-мар итсен!

**2**

Минзәлә төбәгенең хуҗасы Иван Фёдорович йортында бүген бәйрәм. Билгеле, хуҗаның моны һичбер кешегә дә ычкындырганы юк, халык белеп алса, Иван Фёдоровичны Казанда утырган агасы Данила Афанасьевич кына воевода кәнәфиенә күтәргән, дип, дөньяны сасытачак. Ә Данила Афанасьевич белән алар, чыннан да, бер нәселдән – бабалары бер үк. Иван Фёдорович Данила агайга җигән[14] туры килә.

Өлкән Барятинский Казаннан йөзе кара көйгән рәвештә килеп төште. Серне дә теләр-теләмәс кенә ачып салды.

– Сазаган Софья үтә эреләнеп әмер салган, үзенең үгез күрми саргайган кысыр сыер хәленә төшүен исәпкә дә алмый, хөрәсән. Картлач Коркодиновның Ык буенда тар-мар ителүенә мин гаепле икән. Хәер, әлеге яуда син дә катнаштың бит әле, җигән, онытып җибәргәнмен. Менә шуның өчен Софья хәзер әтәч урынына миңа очып куна. «Казанда сак отряды гына калдыр да минем фәрманымны алуга ук барча полкларың белән Минзәләгә сыптыр! Элекке кебек, «атлар җитми, олау һәм туплар да аз», дип

[14] Җигән – русча: племянник.

сукрануыңны ишетәсе булмыйм. Үз кул астыңдагы полклар өчен гыйсъян халыктан атлар белән олаулар да талап алалмагач, нинди воевода син!» – дип, утлы таба өстендә биетмәкче була. Менә, олы башымны кече итеп, килеп җиттем инде. Тыңламый да булмый. Ул минем арттан күзәтергә дип, бик тә елгыр, селәүсендәй ут күзле бер поручикны юллаган. Тегесе: «Мин сине күрмим дә, белмим дә, воевода. Мин монда вакытлы гына, озакламый патшабикә мине мәркәзнең үзенә үк алдырачак», – дип юаткан була тагын. Яшьләргә җиңелрәк шул, алар итәк астына юлны бик тә җитез таба...

Иван Фёдорович әүвәл үз йортында бик тә затлы итеп табын оештырды. Поши, куян калҗалары көн дә эләгеп тормый, Минзәлә тамагыннан тотып китергән чуртан, кызылканат, табан балыклары да телеңне йотардай тәмле. Мәскәү әһелләрен эттән алып, эткә сала-сала, озак кәефләнеп утырдылар. Аннары хуҗа кеше Минзәлә бистәләрен урап кайтырга тәкъдим итте. Кунак кеше – хуҗаның ишәге бит, өлкән Барятинский да буйсынды. Нинди тәм тапкандыр, Иван Андреевич иң башта атларны кирмән эчендәге төрмә ихатасына алып керде. Монда бернинди дә яңалык юк, кул-аякларына чылбыр богаулар тагылган ун-унбишләп мәхбүс, зең-зең килеп, шалтыр-шолтыр килеп, юан-юан бүрәнәләрне ихатаның бер башыннан икенчесенә күчереп азаплана. Ризык дигән байлык яңгыр йә кар бөртекләре булып күктән яумый шул, мәхбүс ирләрнең тазалыгы көнләшерлек түгел.

– Монда синең өчен бер кызык та юк икәнен алдан ук чамалаган идем, гамуҗам[15]. Болар ише мәхбүсләр Казан зинданында да бардыр. Ә менә Минзәлә зинданында авыл башлыклары яисә старшиналар, алар өстенә морза балаларының аманат сыйфатында тотылуы турында ишеткәнең булдымы икән? – дип, Иван Фёдорович көтелмәгән яңалык ачып салгач, өлкән Барятинскийның да йөзе нык үзгәрде.

– Туктале, морза баласы – үзе дә морза бит ул. Нәкъ менә без – кенәз, без бояр баласы булган кебек. Без мәңгелеккә күчсәк тә, кенәз, бояр дәрәҗәсе балаларга да кала. Ә ата морзалар үз угылларын синең кулга ничек җиңел генә биреп җибәрде соң?

– Морзаларның, старшиналарның кайсысы угылларын үз ихтыяры белән безгә бирсен инде? Берсе дә бирми. Әмма ауга чыгу, ясак түләгәндә, күз-колак булырга дип, авыллар буенча әйләнеп кайту дигән йолалар да бар. Тагын-тагын, син үзең үк ишетеп беләсең, төрле вак-төяк бәрелеш, кайсыбер авылда канлы орышлар да булгалый. Менә шундый вакытларда беркатлы морза һәм старшиналар үзләренең угылларын печәнлеккә дә меңгереп яшерә алмый, базга да ябып куймый. Моны үз араларындагы очлы күзләрдән ишетеп алабыз да, тозакка эләктереп, Минзәлә зинданына кайтарабыз. Тиктомалдан бер генә мәхбүснең дә җанын кыйганыбыз юк. Ләкин моны иректәгеләр белми бит, һәрбер старшина үзенең улы исән-сау әйләнеп кайтса иде, дип кайгы йота. Морза балаларын аманатлыкта тотуның файдасы шул – әтиләре үзләрен фетнә уты белән таплаудан нык курка. Чөнки әтиләре берәр хөкүмәт вәкиленең гомеренә куркыныч тудырса йә ясак-салымнарын түләүдән баш тартса, улларына тәмуг.

Мондый хәл Казан воеводасында зур кызыксыну уятты, ахрысы, ул дәртләнеп дәште:

[15] Гамуҗа – ага, әтисенең туганы.

– Әйдә, морза угыллары тотылган зинданыңның берсен күрсәт әле.

Җир астындагы баздай бер бүлмәгә төшсәләр, рәшәткәләр артында сасып, башактай вакланып беткән салам өстенә егерме-утызлап мәхбүс сузылып яткан. Воевода хәтле воеводаларны шәйләп алгач, яртысыннан артыгы торып утыргандай итте, кайберләре аягына басты. Өсләрендәге кием карачкылары теткәләнеп, ерткаланып беткән. Балчыкка, тиргә баткан тәннәре еллар буе амбар-курада буталып йөргән киндер капчык төсендә. Кабыргалары чатыр эченә тарттырылган киргеләрдәй тырпаеп, бүртеп тора. Яңаклары эчкә суырылган, күзләре дә эчкә баткан сыман. Карашларында өмет нуры, яшәүгә омтылыш дигән хисләр соңгы тамчысына кадәр кипкән, юкка чыккан.

– Боларны тере мәет, дип атасаң да була бит. Алар җир йөзендәге тормыш белән алыш-бирешне күптән өзгән сыман. Тәннәре – монда, ә рухлары – үз хыялларындагы җәннәттәдер инде, – дип пышылдады Казан кунагы, тетрәнүен яшерә алмыйча.

– Мин дә чамалыйм, бу егетләр явыз җинаятьләр өчен мондагы зинданга китереп ябылмаган. Алар әтиләре куптарган фетнә, авыллары түләмәгән ясак-салым өчен рәшәткә артына эләккән. Дөресе – алар туганнары, авылдашларының җинаяте өчен газап чигә. Ләкин без гаеплемени? Мондый язмышка аларны әтиләре һәм шул ук старшиналары дучар итте ләбаса, гамуҗа абыкаем...

– Мондый әрвахларны якын-тирә авыллардан гына эләктереп кайттыгызмы? Ерак салаларга төбәлеп, гомерегезне пычак астына куярдай тәвәккәллек кылмагансыздыр, шәт?

– Төрлечә туры килде, өлкән воевода галиҗәнаплары. Әнә, сул яктарак җыелып баскан төркемне утыз чакрымдагы Күзкәй, Дәвек, Оргыды авылларыннан җыеп кайттык. Әнә теге, артта торган ирләрне алтмыш-җитмеш чакрымдагы Татар белән Мари Буләре, Әмәкәй, Байсар авылларыннан үзләре китереп бирде.

– Ничек инде үзләре? – дип акайган чагында Казан кунагының күзләре маңгаена менгән сыман булды.

– Без морзаларның балаларын гына алыштырып тору яклы түгел. Ә гади старшиналар, вакытлыча авыл башлыгы итеп сайлап куелганнар өчен бер йомшак бөке калдырдык. Андый авыллар мондагы аманатларны һәр ел саен алыштырып, яңартып тора ала. Ышанасыңмы-юкмы, гамуҗам, ни галәмәт, яңа аманатларны һәрбер көздә үзләре ихтыяри рәвештә китереп җиткерә. Яңа алмашны кирмән эченә кертеп япкач кына, искеләрен чыгарып җибәрәбез.

– Гаҗәп халык болар, – дип, Данила Афанасьевич янә баш чайкады. – Башка халык кирмәнгә һөҗүм ясап, төрмәдәге балаларын азат итү өчен башын салыр иде, ә болар, бер уйласаң, зынҗыр-богауларны үзләре кидереп һәм үзләре үк куалый-куалый китереп тә бирә. Коллыкка өйрәтелгән, коллыкка күнектерелгән атлар, этләр, ачуым килмәгәе, урамнарда чегәннәргә ияреп йөрүче һәм алар кушканда биюче аюлар сыман болар. Сәер, гаҗ-җәп!..

Түрәләрнең бер сорау да бирмичә борылып китәргә чамалавын сизеп алдылар бугай, зиндандагы өч-дүрт ир һәм егет рәшәткәләр тимеренә килеп

тотынды да, читлек эченнән җиһанга соңгы авазларын юлларга атлыккан шикелле, авыр гырлый-гырлый сөрән салды.

– Ичмаса, берәр телем, яртышар телем булса да икмәк бирегез безгә?

– Су, су, бер йотым су бирегез?

– Байлар авылыннан китерелгән Сәмигулла агай әнә шулай, бер йотым су илә бер кабым ипигә тилмереп, җан бирде. Җәсәден дә алып китмисез, ә аны Аллаһы Тәгаләбез фәрештәләре күтәп тора бит. Мәетне үз вакытында ләхеткә иңдерү фарыз...

Рәшәткә эченнән түрәләргә таба яп-ябык, нечкәреп калган кулларын тышкы якка сузган мәхбүсләрнең күзләренә төбәлү дә җаныңа утта кыздырылган пычак очы белән китереп кадаган сыман. Һәр караштa соңгы өмет, соңгы ялвару. Боларның күпчелеге, бәлки, асылда да якты җиһанга чыгып, әти-әнисе йортына, эне-сеңелләре янына әйләнеп кайту, кем тарафыннандыр сөелү һәм гыйшык дигән кадер-хөрмәтләрне күрүдән бөтенләй ваз кичкәндер. Адәм баласы чаптар ат ияренә сикереп менгән чакта гына гайрәтле һәм башбирмәс, ә кулларына зынҗыр кидердеңме – балта белән төбенә чабылган агач. Аны этеп аудару, таптап узу өчен бер кансыз адым да җитә...

### Унынчы бәйләм

### 1

Яз нык көттереп килде. Ә ялан-кырлар ерганак-күлләвекләрдән арынуга, Теләкәй иң әүвәл оныгы Акайны табып, аның шоп-шома итеп кырылган баш түбәсен кытыклаган булды.

– Йә, ташбаш, быел Сабан туе бәйрәмендә берәр чибәр кызга өйләнеп куясыңмы инде, юкмы? Алайса, синең туйны күрми калуым да бар бит.

Акай бик чамалый, шаяртa гына аның бабасы. Шулай тиктомалдан оныгына килеп бәйләнә торган гадәте бар аның.

– Миңа биш яшь кенә бит әле, ниткән кызлар, ниткән өйләнү ул, бабам? Аннары гомер буе карчыклар белән генә кичләр буе чәй чөмереп утырырга минем башыма тай типкәнме әллә?

Теләкәй ихахайлап көлде.

– Бер-ике карчык белән, дисеңме? Кич буе чәй чөмерәме бабаң белән карчыклар? Әһ, әйттең син!

Көлешеп туйгач, Теләкәй, Акайны җитәкләп, ат абзарларына таба атлап китте. Чаптарлар яравайлаучы Мөхәммәтша картка, Акай белән шаярган шул ук аһәң белән, авыз ерып әйтте.

– Кая, теге Ярканатны чыгар әле безгә, Мөхәммәтша агай. Бүген безгә Ярканаттан гайре ат ярамый. Уен-муен түгел, Акай батырга кәләш эзләргә дип юлга чыгабыз бит.

Мөхәммәтша карт шаяртуны ярты сүздән үк аңлап алды-алуын, аннары хуҗа каршында сынатырга да ярамый шул аңа.

– Бер ат кына килешеп бетмәс бит, морза, әллә булгач-булгач, аның янәшәсенә Карчыганы да җигеп чыкмыйсызмы? Сыңар атлы имче иргә нык бай мулла-мунтагай йә морзалар заты бик тәгәрәп төшмәс, хәтта капка төбеннән борып җибәрүләре дә ерак йөрмәс. Ә пар ат белән килеп, кыз дауласаң, бөтенләй бүтән бизмән.

– Әй, минем бабай шаярта гына лабаса ул, Мөхәммәтша бабай. Чәчү якынаеп килгәндә ниткән кыз эзләү ди?!

– Ә-ә, алай икән, алай, бәрәкалла! Язгы чәчү беткәч, дисең инде. Яшь кәләшне Сабан туенда апкайтабыз икән, алай булгач...

Кет-кет көлешеп алгач, күңелләре булды. Теләкәй белән Мөхәммәтша карт бергәләп, ат җиктеләр. Теләкәй никтер дилбегәне кабаттан утар ягына борды. Алдан ук сөйләшенгән, килешенгән булгандыр, ахрысы, мунча артыннан тыз-быз йөгереп кенә Теләкәйнең «төпчек» хатыны Гөлбикә йөгереп чыкты да иренең куна тактасыдай киң аркасы ышыгына кереп чумды. Акай күзгә чекрәеп кермичәрәк торса, ирennәрен турсайтып каршы алыр иде дә, хәзер ярамый шул...

Теләкәй атны Агыйдел буена таба алып китте. Берәр сәгать чамасы баргач, биек яр өстенә менеп тукталдылар. Моннан барча җиһан уч төбендә кебек. Елан сыман боргалана-боргалана, кайбер урыннарда кыяларның юлына терсәк куеп торуларына ярсый-ярсый, мәһабәт елга ага. Ярларының бер ягында йә куе әрәмәлек, йә үзара җитәкләшеп йөгерешкән каен, имән, усак, өрәңге, юкә, чыршы, нарат урманнары. Ул әрәмәлекләргә керсәң, һичбер шиксез, карагат, чия, гөлҗимеш, шомырт, камырлык, балан, миләш куакларына барып төртеләсең. Шул куаклар арасында урман тавыгы, көртлек, саескан, карга, песнәк, чыпчык ише кошлар – санап бетергесез. Урман эчләрендә төлке, селәүсен, куян, бүре, аюлар янәшәсендә поши, кабан дуңгызы, кыр кәҗәсе, җәйран да үзенә урын таба.

Икенче як яр буен күз күреме белән колачлап та бетерә алмаслык ялан биләп алган. Әбиләр вә өлкән хатын-кызлар һәрбер кыш башында каз өмәсе үткәргәннән соң ялан-кырга каурый һәм эре мамыклар чәчкән шикелле, Агыйделнең иңкүлек ягында да бер гаҗәеп пәһлеван әпен-төпен атлап узган да, әллә тылсымлы букчасыннан, әллә биек-биек агач кәүсәләреннән эләктереп, әле бер, әле икенче урында эре-ваклы күлләр, челтерәп тибә торган чишмәләр сибеп чыккан. Ул пәһлеван кайбер җирдә түмгәкләргә абынып, озаграк вакыт тукталып та торган бугай. Андый урыннарда хәтта сазлыклар да пәйда булган инде.

Менә бу иңкүле яр буе – барча тирә-як авыл ирләре вә яшь кыз-кыркын өчен җәй көне бер ай буе эшләп тә, күңел ачып та кинәнә торган сихри ялан. Сабан туе уздырып, бер-ике атна чамасы вакыт үтүгә үк әүвәл монда арбаларга төялеп, Чөгәнә, Такталачык, Уразай, Ямалы, Тыңламас, Аеш, Төкәй, Кәзкәй ирләре төшеп җитә. Алар каеннар шикелле тезелешеп, чалгылары артыннан пакус салырга тотынгач, әрсез кодачаныкыдай бүселгән йөз белән Шәбез, Әлем, Балтач, Кормаш, Җизмыек, Җияш, Богады ирләре дә килеп кушыла. Беренче көнне, гайбәт таратуга үпкәләп, яман бозылышкан яшь киленнәр шикелле, кич җиткәнче бер-берсенә юньләп сәлам дә бирешмиләр. Иллә мәгәр Агыйдел буеның иң рәнҗегән вә иң тешләк егет һәм кызларны да дуслаштыра торган тылсымы бар аның. Ул – кич, сихри вә мәхәббәтле тын кич!

Эңгер-меңгер төшеп, күз бәйләнә башлауга ук, бер-ике авылның елгыр егетләре әллә каян гына чыбык-чабык һәм корыган агач ботакларын тапмый калмый. Тынычрак бер урында әллә ничә учак тернәкләнә, зур-зур казаннар асыла. Оста ирләр ялт иткәнче сарык суеп өлгертә, кисәкләргә турый.

Аннары инде берсен-берсе әрепли-әрепли, өйрәтә-өйрәтә, казаннар янында иртәгә килен булып төшәсе яшь кызлар йөгерешә башлый. Егетләр менә шул чагында ук, күз салу гына түгел, җим дә ташлап ала.

– Әһ, кайсы авыл чибәре икән бу нечкә бил! Кулың аш-су эшенә бик килешеп тора!

– Әһ, менә мондый карачәч кулыннан аш ашау да тәмле буладыр ул!..

Көлсәләр-шаярсалар да, һәрберсе тәлинкәне төбенә кадәр ялтыратып куя. Ә аннары уен! Уртадагы бер учакны төн уртасына тикле сүндермиләр. Кызлар әллә каян гына калфак, алъяпкыч, читек табып кия, егетләр кушак бәйли, баш очына түбәтәй элеп куя. Татар, башкорт, мари, сигезле, капма-каршы килеп биюләр – берсе-бер калмый. Такмак әйтешәләр, «төлке-кыз» куалар, учларына төймә салышалар... Беренче кичтә барча кызлар, сүз беркеткән шикелле, авылдашлары корып куярга өлгергән чатырлар эченә кереп кача. Икенче-өченче кичләрдә учак түгәрәкләп утыручыларның сафлары сирәгәя, акрын-акрын гына чупылдашкан «сандугач» тавышлары әрәмәлек йә камышлык арасыннан ишетелә башлый... Аһ, ул сихерле вә гыйшык тулы кичләр! Аһ, син араннарга сыймас тай шикелле яшьлек!..

Теләкәй дә бүген яшьлегенә кире кайткан сыман. Ул Гөлбикәсен сыңар кулы белән күкрәгенә кочкан, икенче кулы белән йомшак кына итеп, аның йә чәчләрен, йә яңагын сыйпап ала. Акай оныгы кай арада Агыйдел буена төшеп җиткәндер, ыштан балакларын сызганып, яр читендә кызынып яткан маймычларны куып йөри. Тирә-юньдә гүзәл табигать, җан-җанашың янда, ир кешегә бәхетне тою өчен шул бик җиткән!

Дөрес, бу җиһанда әле адәм балаларына бәхет-шатлык өсти торган хәтер сандыгы да бар. Теләкәй өчен анысы да үкенечсез. Гөлбикәне ул урманнан тапты! Гаҗәп инде, гаҗәп!..

Теләкәй соңгы ун ел чамасында гел бер урман каравылчысы – Әхмәдулла янына барып йөрүгә нык күнеккән иде. Морза кешенең гозере дә юк-югын, ул үзенә яки авылга кирәкле агачны теләсә кайсы урманнан да кереп кисә ала. Теләкәй җиләк-җимешкә дә бик тәгәрәп төшми, хәтта үзен фидаи, җанатар сунарчы дип тә мактана алмый. Яшьлегендә чукмар белән бүреләр сугып алганы булды-булуын, мәгәр мондый мавыгу белән дә озак чирләмәде. Әмма адәм баласында барыбер үзе дә аңлап бетерә алмаган сихерле тарту көче, тыеп булмас гадәт туа икән. Әхмәдулладан аңа берни кирәк түгел, бик теләсә, Теләкәй үзе аңа сыерын-атын да, олау-олау печәнен дә илтеп бирә ала. Иллә мәгәр Сөн елгасы аръягындагы куе урман эчендә үзенә шәп кенә йорт салып куйган каравылчының хуҗалыгы да, аның тирәсендәге тынычлык-иминлек тә бик-бик тансык аңа. Әхмәдулланың мунчасы дуслар көнләшерлек, ул каен белән имән ботакларын аралаштырып, җайлы миллек ясый белә. Аның хәтта тын алырга чыккач эчерә торган әйрәненә, каен суына, әче балына тикле кабатланмас, үзгә. Теләкәй анда дөнья белән алыш-бирешен онытып, атналар буе кинәнеп яши ала.

Ачыгавыз, пошмас, түгел диген. Ничәмә-ничә тапкыр барып йөрде, шунда тукланды, йоклады, иллә мәгәр сыңар мәртәбә дә Әхмәдулланың үсеп килгән балаларына игътибар итмәде бит. Юк, ике малае һәм ике кызы барлыгын томанда адашып йөргәндәй шәйләде ул. Ләкин ятлап та, сүз катып

та түгел, фәкать җанлы шәүлә итеп кенә. Ул Әхмәдулла белән өстәл янына кайтып утыра, ә тегеләр, шулай тиеш сыман шундук юкка чыга. Әйдә,ауга чыгып керик, дип, ике өлкән ир җыена башласа, барысы да берникадәр ара аларга ярдәмләшеп йөри, әмма аякларына чаңгы-мазар киеп алдылармы, алар янә аймыл. Еллар үткән саен һаман шулай.

Бер ауга чыкканда, Исәммәт белән Торачы урманы эченә шактый тирән керелгән. Әүвәл ирләрнең икесе дә бер-берсенә торналар шикелле тагылып барган иде, бермәлне Әхмәдулла хәлиткеч сүз ташлады:

– Болай бозаулап барсак, бернинди дә кабан дуңгызы йә поши тоттырачак түгел, әйдә, икегә бүленәбез.

Хуҗа сүзе – канун. Җәя, пычак, ыргак һәм суларны бер кат барладылар да, бер аланлыкны ике яктан урап китте болар. Көрт бик калын ятмаган, әмма барган саен урман эче куера гына һаман. Япа-ялгыз көе тизлекне чамалау шактый катлаулы бит, Әхмәдулла Торачы ягындагы наратлыкка миннән дә тизрәк җитмәгәе, дип, үз-үзен каударлый-каударлый, Теләкәй адымын һаман кызулатты. Берзаманны агачлар арасында эңгер-меңгер куера башлады, ипләп кенә урман өстенә караңгылык ятты. «Шушында адашып калам бит, адәм тәганәсе!» – дип ярсый-ярсый, Теләкәй чаңгыларын тагын да тизрәк шудыра-шудыра, ниндидер ачыклык авызына да килеп чыкты. Әмма үз вакытында тыелып өлгермәде. Алда ниндидер яр икән, ул шуның өстеннән түбәнгә таба очты. Шуны гына көтеп торган сыман, Теләкәй өстенә бер ата кабан килеп ябырылды. Ике якка чыккан азау тешләре – үткен хәнҗәр сыман. Күзләрен кан баскан. Ике-өч адым гына артка чигенә дә, бер як хәнҗәрен тырпайтып, янә ташлана бу. Ләкин Теләкәйгә дә Әхмәдулла кабан дуңгызы тиресеннән тегелгән тун һәм киез итекләр кидергән иде. Ата кабан хәнҗәре киез итеккә килеп терәлсә дә, таеп китә, үз туганының тиресеннән тегелгән тунны да ертып керә алмый. Теләкәй инде үз балтырыннан зур пычак та алып өлгергән иде, ләкин ата кабан барыбер һөҗүм рәтен табып өлгерде бит, каһәр. Ул борыны белән Теләкәй өстендәге тунның итәкләрен кайтарып ташлый да, морзаның ботларын хәнҗәр очы белән телеп-телеп ала. Кайнар кан исен тоеп алгач, тәмам котырды бу, хәнҗәрен сөңге урынына төбәп, ерактан ук кадап юк итмәкче. Әмма Теләкәй кулларындагы ике зур пычакны абайлап өлгермәде. Томырылып килде дә, Теләкәйнең гәүдәсе өстендә мәңгелеккә дип күзләрен үк йомды...

– Теләкәй абый, Теләкәй абый, җаным! – дип ачыргаланып үз янына ташланган Гөлбикә тавышына аңга килде ул.

Күз кабакларын ачса – Әхмәдулла кызы. Элек килгән вакытларда ул өстәл тирәсендә табак-савыт ташып, әнисенә ярдәм итеп йөргән сабый иде, кай арада гына шулай үсеп җиткән?

– Теләкәй абый, син тоташ канга батып беткәнсең бит! Ничек болай булды? Нигә сиңа тагылып бармадым да, нигә сине аралап калалмадым, аһ син, җаныкаем?!

Теләкәйнең башы аңкы-миңке. Мизгел саен тәннән гайрәт, куәт китә сыман. Ул тоташ томан эчендә, зиһене нык чуалган. Шулай да, сирәк-мирәк булса да, күзләрен ачып ала, ә анда күз яшен тыя алмыйча елаган Гөлбикә сеңелкәш. Каян, ничек килгән?

– Мин сине үзебезгә чаклы алып кайтмый калмыйм, Теләкәй абыкаем! Тешләрем белән булса да тартырмын, Ходайга ялынырмын, иллә мәгәр кайтарып җиткерермен. Әгәр китеп барсаң, мин бичара синсез яши аламмыни? Сине ничә айлар буе яратып яшим бит мин, үзеңне бер күрү өчен дә ничә айлар буе тилмерәм, җаныкаем!..

Ничек итсә-итте, ләкин Гөлбикә аюдай ир гәүдәсен чаңгылары өстенә сузып сала алды бит. Аннары Теләкәйнең яралы ботлары өстенә ылыс ботаклары өеп чыкты да, каяндыр тартып чыгарган бер бау белән чаңгыларны алга сөйрәп китте.

– Алып кайтып җиткерәм, беркемгә дә бирмим, син минеке хәзер, җаныкаем! – дип өзгәләнә үзе...

Теләкәй урман каравылчысы йортында гына искә-ушка килде. Каршында аңа текәлеп утырган Гөлбикәне күргәч югалып та калды. Теләкәйнең барча чалбар-ыштаннары, күлмәге алышынган, монысы – кем эше?

Гөлбикә дә Теләкәйнең күз карашыннан ук аңлап алды бугай, читкә борылып кына, үзе дәште.

– Киемнәреңне мин алыштырдым, Теләкәй абый. Тәнеңнең барча җирен дә үзем юып чыктым.

Теләкәйнең «әһ» дип, читкә борылуы ошамады бугай, янә Гөлбикә дәвам итте.

– Оялма, оялма, Теләкәй абый. Минем гаебем юк. Безне Аллаһы Тәгалә үзе кавыштырды бугай. Әйе, мин яшермим, Ходайдан ялварып, һәрчак синең килүеңне көттем. Беләм, сиңа тиң дә түгелдермен, кирәгем дә юктыр. Чөнки синең, әнә, болай да ике хатының, җиткән улларың бар. Әмма мин нишләтим, хыялымда гел син. Сине күргәч кенә, миңа бәхет иңә. Мин синең кәнизәгең булырга да риза. Тик сине күреп яшәүдән, күз карашыңнан гына аерма мине берүк?

– Соң, мин иллегә җитеп киләм ләбаса инде, җаным, – дип, саксызрак сүз ычкындыруы булды, Гөлбикә Теләкәйне кочагына алды.

– Илле – синең кебек алтын ирләр өчен бернинди чик түгел. Мин синең янында бер ай, бер ел яшәүгә дә риза, үзеңнән генә калдырма. Калдырма берүк, җаным?!.

Теләкәй калганын Әхмәдулла белән хәл итеп бетерде. Унҗидедәге кызын утыз яшькә өлкәнрәк иргә өченче хатын итеп бирү мин-минлеген һәм җанын бик телсә дә, урман карвылчысы барыбер ризалашты. Ни әйтсәң дә, Теләкәй – морза кеше һәм чит-ят түгел. Үзенә генә алай әйтеп булмый, башка сүзен тапты.

– Урманда качып үскән кызымның бер ир-ат та күргәне булмады шул. Шуңа сиңа гашыйк булуы, суга баткан инсанның чыбыкка ябышуы сыманрак, бик нык гаҗәп түгел...

Урманда үскән, дигәннән, сәер чире булды яшь хатынның. Назланасы килсә, өй эчендә һәрчак каршы тора.

– Монда һава җитми миңа, түшәмнәр дә күкрәгемә баса. Әйдә, бик кирәк булса, йә яланга, йә урманга чыгыйк. Анда иркәләү-назымны да һич кызганмам, үзеңә дә мең кат рәхәтрәк булыр!

Сүзендә тора белде. Җир йөзендә Гөлбикәдән дә назлырак бер хатын юк! Шунысы гына яман – Гөлбикә-җаный һаман авырга уза алмый...

**2**

Теләкәй тагын берничә көннән соң Мөхәммәтша картка янә ат җиктерде. Ат караучы гына түгел инде ул хәзер, телгә оста.

– Әллә тагын никах яңартырга җыендыңмы, морза?

– Тфү! – дип сүгенде Теләкәй шулчак, үзе пешкән бәлеш өсте кебек кызарып та чыкты.

– Ярар, ярар, гөнаһы юк, савап, савап булыр, – дип, Мөхәммәтша һаман төрттерүен белде.

Ахыр чиктә Теләкәйгә кул селти-селти китеп барырга туры килде.

Бүген Теләкәй җиһанга ике өлкән хатыны – Саимә белән Җинанны алып чыга. Гел өй эченә бикләнеп яттылар, тузан кагу аларга да кирәк.

Саимә хәзер юантык, таза гәүдәле, Күчемне тапканнан соң шундый булып калды. Теләкәй үпкәләми, Ходайдан ни язган, шул ризыкның кадерен белү фарыз. Ә Җинан озынча һәм ябык, Җәүдәте дә нәкъ үзе булды. Җинан кайчагында кызып китә, аш-су бүлмәсе ягында тәлинкәләрне дә пешекчеләр өстенә очыргалый, диләр. Әмма Теләкәй янында сүзгә килгәне юк, кунакка барган чагында да гел елмаеп йөри. Хатын-кызны Адәм кабыргасыннан ясалган, дип сөйлиләр бит, бар, кайсы кабыргасыннан икәнен гөманлап, белеп кара. Иң мөһиме, ул бар нигъмәтне кысып-кымтып тота, менә шуның ярдәме беләндер, ястык-түшәкләргә тел тидерерлек түгел.

Саимәне Теләкәй эзләнеп-сайланып йөрмәде, ата тиешле Улакай күрше олыстагы Кыргыз авылыннан табып кайтты.

– Олыс хуҗасы Кодашның бик чибәр кызы үсеп җиткән. Минем ише, үзе олыс башлыгы булган кешегә арба тәгәрмәче йә кашуфка ясаучы Гайнан оста кызының кулын сорап бару килешеп бетмәс. Ит янына ит, бет өстенә бет өстәлеп тора, диләр бит, безнең ишеләргә кәләшне үзеңә тиң кетәклеккә кереп сайлау отышлырак. Дөньяныкын алдан белеп булмый, Алла сакласын, беркөнне йә абынып, йә бөлгенлеккә төшеп, көрчеккә килеп терәлүең дә бар. Менә шуңа сине Кодаш кордаш кызы илә кавыштырып кую бик мәслихәт булыр.

– Ярый, әткәй, – дип, ияк какты Теләкәй. – Арбаның алгы тәгәрмәче артыннан ияреп бармый булмас...

Ул чагында Саимә, чыннан да, чибәр иде, Теләкәйнең күңеленә шундук кереп ятты. Киңәшләшкән булып, болыт кадәр хыяллар кора-кора, тәүге атналарда төн буе сайраштылар. Аннары Саимә Күчемне тапты да кинәт кенә Теләкәйне этәрде дә куйды...

Икенче кәләш табуны Теләкәй инде әтисе Улакай иңенә тапшырмады. Кышкы бер айда Каракүл базарына чыгып киткән иде, шуның капкасы аша узганда әйләнеп караса, хәерче, кылка киемдәге бер агай тал чыбыгыдай зифа буйлы кызыйны җитәкләп, сәүдә рәтләренә кереп килә. Базарда тамга хакы алып торучы казый тиеш кеше сорагандыр инде, кылка киемле агай ярты мәйданга ишетелерлек итеп, ярып салды:

– Урлаган мал түгел, үз кызым. Дүрт санә буе салымым түләнмәгән, өй эчендә өстәлгә чыгарып куярлык бер кабым ипи дә юк. Кая барыйм? Менә, җиткән кызымны йә асраугa, йә кәләш итеп бирергә алып чыгам инде...

Теләкәй өстәмә сораулар биреп тә маташмады, хак турында тарткалашу да ваклану гына иде. Ул кесәсеннән бер уч көмеш акча чыгарып сузды да,

кызыкайны үзенең чанасы ягына сөйрәде дә китте. Җинан үз бәясен белә иде, ахры, бер үкереп елады да тынды. Кайту юлына чыккач, бер генә теләген кат-кат ялварды:

– Мине базардагы мал урынына сатып алганыңны берәүгә дә әйтмә...

Кайткач, Теләкәйнең күңелен күрү өчен тырышты ул. Төн буена йоклатмыйча чыккан чаклары да булды. Теләкәй бер чакта да тел күтәрмәде аңа, Саимәсеннән бер яман сүз әйттермәде. Ә тора-бара хатирәләр чуан төсле сытылып бетте, ахры, Җинанның да яратуы, иркә-назы чын күңелдән иде.

## 3

Күчем әтисен янә Агыйдел буендагы биек яр өстеннән эзләп тапты.

– Сорашкан булгансың икән, ә мин Минзәлә юлындагы күчмә сак егетләре яныннан урап кайттым.

– Әйе, сорашкан идем шул, – дип телгә килде Теләкәй, үзенең йөзе җитдиләнеп калды. – Никтер йөрәк яна әле, улым. Уйларымның очына чыга алмыйм, мием кайнап бетте. Без кайсыдыр тарафны эшләп җиткермибез. Без, дим, иллә мәгәр ул – син түгел, мин ялгызым инде.

– Аңлыйм, аңлыйм, яшермичә сөйлә, әйдә, әткәй.

– Без менә монда, гел үз казаныбыз тирәсендә генә әйләнәбез. Әллә нишләп, күз күргән, кул җиткән якын арада гына. Каядыр барып, аның иңсәсенә таянасы, аннан ярдәм вә күп киңәш сорашасы килә. Без шыр-ялгыз көенчә, урам уртасындагы, яландагы чыра йә учак урынына күз ачып йомганчы янып бетәбез бит. Каян гына аркадаш табасы да, ярдәм сорап, кемнәр алдына барып егыласы икән?

– Без алай кемнеңдер алдына барып тезләнердәй мескен хәлгә төшмәдек бит әле, син юкка көенәсең, – дип, Күчем, әлбәттә, каршы төшмичә калмады. – Коркодинов гаскәрен тар-мар иттек, аны воевода кетәклегеннән алып очырдылар, шул хәл начармыни?

– Бу бит бер генә җиңү әле, сыңар гына җиңү! – дип, Теләкәй чигенмәде.

– Бер генә түгел, әткәй! Без аңа кадәр үзебезнең авыл каршысында да җиңдек. Әле Тыңламас авылы каршында да, Пәнҗәр илә Бишбүкәндә дә патша стрелисларын пыр туздырып кайттык.

Теләкәй баш очындагы түбәтәен салып, аны йомарлап һәм һавада усал болгый-болгый сүгенүен белде.

– Ә ул кенәз Барятинскийлар дүрт-биш меңле гаскәр белән килсә? Мин иң ажгырып кузгалган чагында да шул Бикбау янындагы кирмәнгә нибары ике, ике мең ярым чамасы гына чирү җыя алдым. Ә кенәзләр хәтта өч мең солдат белән килгәндә дә, безне салам кибәне яки учак өстенә элengән казан урынына туздырып атачак бит!

Күчем инде тынычланды сыман, ул әле яңакларын, әле иягендәге сакалын кашый-кашый, ипле генә итеп сорап куйды:

– Ә син безне тагын дүрт мең, биш мең җайдакны бер чирү итеп җыя алмабыз, дип шөллисеңме?

– Ай-һай, улым, ай-һай! – дип, Теләкәй баш селтәде. – Безнең халык куркак. Без бит сый табыннарына, Сабан туйларына җыелгач кына, уртага чыгып «татарлар ил тоткан, татарлар бер миллион» дип бугаз киерергә генә

остабыз. Ә көндез чыра яндырып чүпли башладыкмы, кулына хөррият әләме йә ук-җәяләр күтәреп чыгардай батырларны ике-өч мең итеп җыя алмыйча да җык киләбез. Хәтта, син әйткәндәй, дүрт мең, биш мең итеп җыйсак та, алларында каратлар күренүгә, шуларның да яртысы дошман ягына качып китәчәк бит, эт еккыры! Аннары калдык, ярты чирүне дә урталай бүлүдән гайре чара таба алмыйсың. Чөнки безгә татарны кырырга дип килгән каратларга да каршы чыгарга, икенче яртысы белән сатлык җаннарның нәселен корыту өчен дә көрәшергә кирәк. Менә уйла инде, бербөтен итеп пешергән икмәктән дә чирегәр генә чирү торып кала. Ә ул чирек белән кемне генә, ничек итеп җиңик?

Теләкәй бер мәлгә тукталып, үз-үзен тынычландырган шикелле, уф-уф килеп тын алды. Аннары чигәләрен ике учына кысып, барыбер элеккечә сүгенүен белде.

– Менә, Мәскәүнекеләр безнең араны таркатып, бүлгәләп бетерү нияте белән яңа чир җибәрде. Морзалар ярты ел эчендә чукынып бетәргә тиеш, янәсе. Ә ул яман чир татар арасына инде әллә кайчан килеп кергән. Нарыкша, Ширәмәт йә Апракса дигән, Мишәринев, Урысов йә Тәтешев дигән кенәз аламалары болытлар өстеннән егылып төшмәде бит. Үзебезнең сатлыкҗаннар, байлыклары вә туймас бирәннәре хакына, ата-анасын да, милләтен дә сатты. Хәзер андыйларга каршы күтәрелеп, яу кылулар өчен кайдан гына чирү эзләп табыйк?

Күчем дә нәкъ әтисе кебек уйга чумды, бер сүз кыстырмады. Теләкәй дәвам итте:

– Үз туганыңны үз кулларың белән юк итеп йөрүләр дә һич тә савап түгел. Йөрәк бер генә бит, улкаем! Халык мине, мөгаен дә, теге чакта Ябалак сатлыгын каен агачына асып куйган өчен гел сүгәдер. Әле Бикбау янында башкортлардан чүкеткән сатлыкҗаннар өчен дә рәхмәт сүзе әйтүчеләр булмас. Ә бит барыбер көрәшергә кирәк. Гомер буе тезләнеп яшәгәнче, һич югы бер тапкыр биленңне турайтып, дошманга каршы кылычка-кылыч килеп, хөррият һавасын сулап калу күпкә кадерлерәк. Синең хакыңа, газиз Акай оланкаем хакына менә шулай кирәк.

Элеккечә уйга талган Күчем бераздан гына аваз бирде:

– Син Акайны үлеп яратасың, мин шаккатам, әткәй.

– Мөгаен, мин Акай йөзендә бик күп, бик күп татар оланнарын да яратамдыр. Аларның кол булып, җиргә чүгеп, заяга гомер уздыруын һич теләмим. Ә алар арасында иң якыны, әлбәттә, Акай булырга тиешледер инде.

– Тагын нинди чара гына бар соң, әткәй? Әләм күтәргән каһарманның күздән яшерелгән бизмәне булмый калмас.

Теләкәй байтак вакыт бер ноктага текәлеп торды да, авыр сулап, ниһаять, ярып салды.

– Башка кешегә тапшыра алмыйм, улым, ә сиңа гозерем бар. Син бер тәүлек эчендә җыен да Идел аръягына, Җигүле Ат таулары эргәсендә тереклек итүче калмыклар тарафына юнәл. Алар кайчандыр безнең бабакайлар белән бергә олуг Чыңгыз хан чирүендә яу йөргән. Аннары бабакайлар шулар белән үк бергә Алтын Урда каһанлыгын тоткан. Ошбу туганлык хисләрен чүплеккә чыгарып атулары бик икеле. Без менә

онытмыйбыз бит, аларның ирләре дә күңелләрендә әнә шул шанлы чорны йөртә. Мин шулай дип уйлыйм, шуңа нык ышанам.

Теләкәй янә улына күз йөгертте, тегенең һаман уйга батуын шәйләп, кабаттан үз эзенә кайтты.

– Калмыкларда хан урынына тайшә утырадыр. Ханны шулай, диләр. Мин хат язармын-язуын, әмма юлныкын белеп булмый, аның югалуы да мөмкин. Димәк, яттан сөйлә. Уфа, Сакмар яклап, падишаһларның бернинди дә гаярь чирүе юк, күчмә сак нөгәре булып йөргән ике йөз, өч йөз җайдакны гына кырып ташлау – аларга берни тормый. Агыйдел, Сөн, Ык, Чәрмәсән елгалары буйлап төшсәгез, сезгә каршылык күрсәтердәй чирү булмаячак. Әйдә, шул яклап бәреп керегез, юлда очраган кирмән вә урыс калалары да, ганимәт тә тик сезнеке генә, ә безгә хөррият өчен көрәштә ярдәмегез булыр, ди-ди өндә. Ишеткәнең бармы, «Чокырга егылып төшкән бүре кәҗәгә дә «җизнәкәй», дип ялынырга мәҗбүр», дигән гыйбарә сөйли иде ак сакаллы Мөхәммәтша бабай? Син дә ялын, телеңне кызганып маташма, улкаем. Әгәр үгетли алсаң, безгә дә бәхет кояшы әйләнеп кайтмасмы икән?

**Унберенче бәйләм**

**1**

Күчемне озаткач, бер ай буе имин яшәделәр, аннары хәбәр килде.

– Казан бояры булып утырган Барятинский Өфегә күченгән, моннан соң да Агыйдел, Сөн, Ык буйлары аның кул астына керә икән.

Керә икән, керә, шәрә арт сан күрсәттең ни дә, ялангач тәнеңә каеш кидердең ни, аннан ни үзгәрә? Ясак-салымнарны һаман элеккечә йә Уфа каласына, йә Минзәләгә илтеп түлисе бит. Ә кетәклектәге әтәчне алыштырудан гына салым кимеми шул.

Гәрәйлеләр Агыйдел буендагы тугайлыкка печән чабарга төшәбез, дип кымырҗып йөргән көннәрнең берсендә тагын хәбәр китереп җиткерделәр:

– Агай-энеле Барятинскийларның икесе дә Уфага чыгып киткән, Минзәләдәге стрелис алайларын үзләре илә алган...

Менә шул мизгелдә Теләкәйнең күз алдына кинәт Бикбау янында аның каршында башын иеп торган, үгез кадәр гәүдәле Шәрифҗан килеп басты.

– Минзәлә кирмәнендәге зинданда аманатлыкка алынган энем интегә бит, аны барып коткарасы иде?..

– Гомер ике килми, – дип, үзалдына пышылдады морза. – Үз кулыма бирелгән биләмә ирләрен дә яклый алмыйм икән, мин соң кемгә кирәк? Кара карга сыман тирес өеменнән – селәүчән, йә ат тизәгеннән бабасыр эләктереп кенә яшәп булмый лабаса!

Теләкәй барча тирә-як авылларга каудар чапкын куды.

– Иртәгә таңда ук һәр авылдан унар яугир ирне Минзәлә әтрафына озатыгыз! Җыелу урыны – Бикбау каршындагы җимерелгән кирмән эргәсендә!..

Теләкәй үзе таң атканда ук иргә сикереп менде. Юлда барган чакта, язгы ерганаклар шикелле, төрле яктан вак төркемнәр өстәлә генә барды.

– Без – әлемнекеләр!

– Без Җияштән! – дип, әле килеп җиткәнче үк сәлам бирешәләр.

Егетләр җор телле, нииндидер йөремсәк мәзәк сөйләп алу да аларга берни тормый.

– Күрше авылдагы Хаммат хәзрәтне, берәр мәрхүмне озатасы булса, ясин догасы укырга җыелышып җибәрәләр икән. Карт хатыны: «Хәзрәт, озак йөрмә», – дип әйтеп калса, яшь бичәсе: «Ашамыйча кайтма, бездән чыгым кимер», – дип әйтергә онытмый, ди. Мондый ике төрле караш тәмам аптыраткан. Бер китүендә үзенә ялланып, ихата себерүче Шакир атлы егетнең колагына болай пышылдаган: «Син күз-колак була күр, Шакир энем, яшь абыстай тегендә-монда чыгып, кети-мети уйнамасын берүк». Ә яшь абыстай нәкъ менә шул Шакир белән шаяра да икән. Бу юлы да бик тиз өлгергәннәр, ә хушлашкан чакта яшь абыстай ялчысына ялтырап торган бер тәңкә көмеш суза икән: «Беркемгә дә әйтмә, яңа форсат чыкса, тагын таммый калмас». Кайтып кергәч, мулла хәзрәтебез дә ялчы Шакирга шундый ук көмеш тәңкә чыгарып сузган бит, әй! Ялчы шуннан ары себеркесен менә болай җырлап болгый икән: «Теге якта да берни күрмим, бу якта исә бөтенләй истирәхәт».

– Әх-хә-хә-хә! – дип егетләр корсакларын уа-уа бер көлешеп ала. Сәфәр озын бит ул, алда яңа мәзәк-гыйбрәт сүзе яңгырамый калмый...

**2**

Теләкәй һөҗүмнәре бу кадәр дә шома килеп чыгар дип хыялланмаган да иде. Елга белән ике арада яткан чакыр-чокыр буенча кирмән диварларына килеп җиткәннәр иде, анда егерме-утыз солдаттан да ары һичбер сак юк. Стрелец дигән кавем көне-төне сак хезмәтен генә алып бармый, аларның кайсыберсе Минзәлә читендәге бистәдә үз йортын төзеп куймыйча калмый. Икенче төрлеләре бүрәнә юллап, йорт тергезеп тә интекми. Ел саен нииндидер орышта катнашып йөргән кирмән гарнизонында тол хатыннар булмый каламы соң! Елгыр стрелецлар нәкъ менә шул – корбан хезмәттәшенең көйләп куйган йортына яңа хуҗа булып кына килеп керә. «Йорт – байдан, хатын – Ходайдан» шул буладыр инде. Ә әзер йортлы һәм әзер хатынлы булып алгач, табынны хаклау өчен элекке йорт хуҗасының ихатасында һәм абзар-курасында да эшсез тору гөнаһ. Менә шуңа күрә гарнизонда дип исәпкә кергән ирләрнең дә яртысы йә печәндә, йә балыкта була.

Кирмәннең үз эчендә өчме-дүртме өлкән стрелецлар гына – башлык. Алар чаң кагарга да, оран салырга да өлгерә алмыйча калды. Теләкәйнең иравыл[16] егетләре диварлар өстенә ыргаклар ыргытып кына менделәр дә, манараларда йокымсырап торган биш-алты сакчыны буып ташлагач, кирмән капкаларын ачып җибәрделәр. Капкалардан җайдаклар ургылып керә башлады. Ләкин патша укчылары да әбисен күрүгә үк калтырап төшә торган булдыксыз кияү түгел. Күз ачып йомган арада кулларына фузейларын алып та, калын такталардан корылган калканнар артына качып та өлгерделәр. Берзаман усал залп авазы яңгырады, авыр ыңгырашып, берничә җайдак ауды. Түгәрәк ясап, кыршау урынына туктаусыз әйләнә-әйләнә, кылычлар белән тураклап бетергәнче әллә никадәр вакыт узып китте.

[16] Иравыл – алдан баручы разведка отряды.

Юлда очраган дүрт-бишләп сакчыны сөңге очына алып, зиндан авызына таба йөгерделәр. Баскыч буенча зинданга төшә башлаганда ук эчке яктан шашып кычкырышкан ирләр авазы яңгырап ишетелде.

– Без монда, без исән!

Теләкәйнекеләр инде канатланып, зиндан бүлмәләренең ишекләрен ачарга тотынды, кайдадыр тимер рәшәткәләрне дә җимереп аттылар бугай. Бер ишектән атылып чыккан мәхбүс-аманатлар туганнарын кочагына алды.

– Азат көнне дә күрәсе бар икән! Күпме көттек без бу мизгелне, күпме көттек!

Менә шул вакытта мәхбүсләрнең берсе зиндан түрендәге бүлмә каршына йөгереп барды да, каударланып, аның да ишеген каерып ачты. Ә эчкә сузылсалар – салам калдыклары өстендә кайсы пычак кадап, кайсы кылыч белән чабып үтерелгән егермеләп мәет аунап ята. Кайсыберләре соңгы көче белән сузылгандыр, аларының йодрыклары рәшәткә чыбыкларын учына ныклап кыскан. Һәр тарафта кан, кан исе...

– У-у-ух-х! – дип, бер янда үгез кебек таза Шәрифҗан ыңгырашып тезләренә чүкте. – Гарифҗаным, борадәрем минем! Сине коткару, алып кайткач башлы-күзле итү турында күпме хыялландым! Менә, күрешергә биш адым ара калгач, коткара алмадым шул! Мин гаепле, синең алдыңда мин языклы, туган!..

**3**

Игеннәрне җыюга төшәбез дип әзерләнеп йөргән чакта гына Сөн белән Ык елгалары уртасындагы яланлыклар буйлап, татар иленә калмык җайдаклары бәреп керде. Юлда очраган стрелец олауларын, сак нөгәрләрен ярсу үгез салам чүмәләләрен туздырып ташлаган шикелле генә сытып үттеләр дә җәя-сөңгеләрен болар да Минзәлә кирмәне тарафына юнәлттеләр. Анда каршылык күрсәтердәй көчне эзләп табарлык та түгел, шуңа күрә алар бистәләрне талап, кирмән диварларын нигезенә тикле яндырып күңел ачып алды. Шуннан ары гына җайдаклар ташкыны Өфе каласына таба эз саплады. Һичбер шик юк: елгыр Күчем – калмыкларның иравыл нөгәрендә, һәм этисе тарафына чапкын юлларга да онытмаган иде.

Теләкәй морза иравыл нөгәрен Сөн елгасы ярында эзләп тапты. Күчем белән кочаклашып күрештеләр. Ике-өч адым артка чигенгәч, Теләкәй хәтта улын берникадәр күзәтеп тә торды. Ялан-таулар буйлап туктаусыз чапкангадыр, ахры, Күчемнең йөзе-муены гына түгел, кул аркаларына тикле караланып чыккан. Йөзе тактадан юнып ясагандай кырыс. Чандыр, җыйнак буй-сынлы булып калса да, җилкәләр киң. Элек Акай, бабасына карап, «Син иңнәреңә әткәй белән әнкәйне дә берьюлы утыртып йөртә аласың», – дип шаярткан була иде, Күчем дә нәкъ шундый. Сөбханалла, берүк сөбханалла!..

– Мин ун мең җайдак алып кайттым, әткәй! – дип, Күчем аңа горурланып дәште. – Калмыкларның Сарытау эргәсендәге сараенда Әюкә тайшә үзе кабул итте. Син юллаган алтын-көмеш йөге шәп эретте бугай, бер дә сатулашмыйча, менә олы бер төмәнен аерып бирде.

Теләкәй асылда да гаҗәпләнеп һәм тетрәнеп калган иде, башын чайкый-чайкый, тик бер сүзне кабатлады:

– Сөбханалла, улым, сөбханалла!

– Әюкә тайшә үзе килә алмады, син аңлыйсың булыр, ул – урда хуҗасы бит, – дип һаман Күчем үзе бәйгегә ашкынган чаптар шикелле каударлануын белде. – Төмән башлыгы итеп, безгә үзенең энесе Зайсә тайшәне озатты. Мин аңа синең киләсеңне күптән әйттем инде. Көтә булыр, әйдә, янына барыйк.

Калмыкларга сәфәр чыгу бер йоладыр инде, Сөн буендагы яланлыкны дистәләгән чатыр сырып алган. Уртадагы, егерме киргәле чатыр башкаларыннан кияү каршыларга чыккан кәләш чәчендәге мәрҗән шикелле аерылып тора. Тирә-юньдә, сукмакларда сакчылары хәтсез, ләкин туктатып та, капшап та караучы табылмады.

Зайсә тайшә чатыр түрендәге аркалы, киң кәнәфи өстенә менеп утырган булып чыкты. Ишек төбендә генә ике сакчысы бар, ә болай берьялгызы. Теләкәйгә калмык йолалары ишетеп йә гөманлап булса да, берникадәр таныш, тайшә каршына килеп бил бөгүдән һәм тез чүгүдән дә тартынып маташмады. Теләкәйгә шәүлә шикелле бер җайдак ияреп килгән, чатыр алдында морза шуның кулыннан зур күн капчык алып калган иде. Шул капчыкны хәзер кәнәфи алдына кертеп салгач, тайшәнең йөзе яктырып китте сыман.

– Әссәламәгаләйкүм вә рәхмәтулла! – дип сәламләде морза.

– Вәгаләйкүмәссәлам! – дип, тайшә дә җавап бирде.

Дога кылгандай иткәч, тайшә сүз башлады.

– Олуг тайшә фәрманы илә мин сезләргә уң мең микъдарында җайдак илә килдем. Татар әһалисе безнем өчен бик тә кардәш кавем, сезләргә ярдәм кулы сузу, иңне кую безнем бурычымыздыр.

– Рәхмәт, рәхмәт, тәшәккүрләрем! – ди-ди, Теләкәй җавапсыз калмаска ашыкты. – Сезнең әтрафларга мин фәкыйрегез дә биш йөз җайдак ияртеп килергә батырчылык иттем. Кирәк санасагыз, без ки, татар угыллары, сезгә янә икеме-өчме яугир туплап кушылырга әзер.

Әллә, чыннан да, кирәксенмәде, әллә вакланасы килмәде, тайшә кулын селтәп, аны читкә этнәндәй итте.

– Юк-юк, кирәкмәстер, морза. Сездә урак өсте, халыкны эштән аермау отышлырак.

«Моның сиңа нинди отышы бардыр инде?» дип уйлап өлгерсә дә, Теләкәй уен тышка чыгарып селекмәде. Тагын берничә буп-буш җөмләләр алыштылар да Теләкәй, бил бөгә-бөгә, тайшәнең чатырын ташлап чыкты.

Ә калмык төмәненә барыбер иярделәр.

## Уникенче бәйләм

### 1

Мәскәү каласында янә зур гарасат. Икенче көн инде Кремль чолганышта. Кирпеч диварларны төрле яктан биш мең чамасы стрелецлар өере урап алган. Тимер капкаларны төяләр, дивар аша агач әрдәнәләре, эреле-ваклы таш, хәтта мәче үләксәләренә кадәр ыргыталар. Таләпләре сәгать саен күк күкрәгәндәй яңгырап ишетелә:

– Стрелецлар алдында Азов походы вакытында айлар буе җыелып килгән акчалата бурычларны соңгы тиененә тикле кайтарыгыз!

– Азгын Софьяның түшәк сакчысына әверелгән приказ башлыгы Шакловитыйны монда чыгарыгыз!

– Безне җәһәннәм читендәге Азов кирмәне өчен яуга шул туймас тамак Софья белән аның итәген ялаучы Шакловитый гына озатты. Меңәрләгән булып ятып калган стрелецлар өчен шулар җавап тотсын!..

Фетнәче стрелецлар үченнән өне алынган кенәз Шакловитый патшабикәнең йокы бүлмәсендәге почмакка кереп сеңгән. Ул сүз кушарга да шүрләп, мәче шикелле тын утыра. Софья гына дулаган ат шикелле бүлмә буйлап әрле-бирле йөри.

Аһ, ничек кенә Мәскәүнең үзеннән ун полк стрелецны, эрләнмәгән, сукмаган җеп шикелле, ике мең чакрымдагы Азов кирмәненә озатасы итте?! Пайтәхетнең үзендә буза куптарып ятмасыннар, яу походында акыл туплап һәм тузынуларын шунда ташлап кайтсыннар, имеш. Азов кирмәнен, диңгез буйларын кулга төшерсәләр, алар Софья итәгенә дә алтын-көмеш кайтарып тутырачак, янәсе. Тот капчыгыңны, әрсез патшабикә! Әнә, кирмән диварлары янына якын да килә алмыйча, әле далада ук татарлар аларны он-талкан иттереп, арт якларына тибеп кайтардымы? Җебегән Шакловитый котырта дип, нигә-нигә генә ун полк стрелецны да, сөекле җанашым Голицынны да шундый хурлыклы походка озатасы иттем?!.

Патшабикә бүлмәсенең ишеген дөбер-шатыр ачып, тупсада Милославскийларның берсе – Григорий Григорьевич пәйда булды. Йөзе корым яккандай караңгы, авызы иягенә салынган, куллары дер-дер килә.

– Тагын бәла бит, олы бәла, патшабикә галиҗәнаплары! Идел аша кичеп, Уфа белән Минзәлә воеводалыгы җирләренә Аюка тайшәнең калдык җайдаклары бәреп кергән! Инде Минзәлә кирмәнен яндырып ташлаганнар, хәзер түмәннәре Уфага юл алган, ди.

– Фәләненеңне себерим, әле шушы бәла генә җитмәгән иде безгә! – дип сүгенә-сүгенә, Софья киң караватөстенә җәелеп төште.

Шакловитый поскан почмагыннан күтәрелә төшеп, күз ташлады. Софьяны Нарышкинныкылар юкка гына «Сыер!» дип мыскыл итми шул, сазаган кызның имчәкләре таудай, ботлары нык картайган нарат кәүсәседәй юан, хәтта билен дә җайлы гына колачларлык түгел. Ни пычагыма дип шушы сыерга ябышып катты да, нишләп беренче айларда ук ташлап китмәде ул? Хәзер әнә стрелецлар ишек төбендә. Ә үзеңне эләктереп, дивар аша сөңгеләр очына болгап ыргытсалар?..

Ни әйтсәләр дә, Софья, чынлап та, шып-шыр ирдәүкә ул. Әнә, сикереп тә торды төрле якка агуын да чәчә башлады.

– Тәк, Григорий дәдәй, дума залына хәзер үк берничә боярны җый. Пётр-имгәк белән Наталияның һаман, кайтудан баш тартып, Преображенскоеда качып ятуын беләм, чапкын куып, вакыт әрәм итәсе юк. Пётр-имгәге көймәләргә җилкән тарттырып, аннары шуларны күлнең бер ягыннан икенче ягына куып җенләнә, ди. Әй, чукынып китсен!.. Кичә бугай, ахры, Кремль ихатасында Долгоруков белән Ромадановскийларның берсен күргән идем, менә шуларны чакыр. Иванны тинтерәтмә, барыбер файда булмас. Әйдә, җыеныйк та бер карарга килик...

Дума өстәле янында Долгоруков, Ромадановский, Милославский һәм... Софья үзе иде. Дөрес, ишек катында кулларына кәгазь-каләм йомарлап утыручы җиде-сигез ир бар.

– Бу Уфа воеводалыгында очы-кырые күренмәс фетнәләр үзәгемә үтте, – дип ярсый-ярсый, әлбәттә, Софья башлап үзе тезде. – Әле шул татар белән башкорт ук Коркодинов полкларын кырып салган, Минзәлә белән Көңгер кирмәненә дә хуҗа булган иде. Фетнәче каракларга каршы агалы-энеле Барятинскийларны юллап карадык, файдасы һич күренми. Инде ул гына җитмәгән, татар морзалары ганимәт, коллар, ат һәм барча кулга төшкән маллар белән алдап, Идел аръягыннан үз төбәкләренә калмык җайдакларын чакырып китергән. Алар Минзәлә кирмәнен нигезенә кадәр яндырып юк иткән, хәзер инде Уфага юнәлгәннәр. Ашыгыч рәвештә гаскәр юлламасак, ул калмыклар Уфаны гына түгел, әле Казанны да талап чыкмый калмас. Шушы хәвефне юк итү өчен каян гына полклар озатабыз да, сугышчан командирларны каян табабыз соң?.. Мин тәкъдимнәр көтәм...

Тынлык, тирән тынлык. Кәгазь кыштырдаган тавыш та ишетелми, боярлар хәтта сулышны да сузып кына ала. Һәммәсенең башы өстәл өстенә иелгән, бер-берсенең йөзенә күтәрелеп караучы юк...

– Кһм, кһм, – дип, тынлыкны барыбер дә арада иң өлкәне булган кенәз Милославский бозарга батырчылык итте. – Без әле күптән түгел генә Казанга Идел буеның баш воеводасы итеп, кенәз Шереметевны озаткан идек бит. Аның калмыклар һөҗүме турында сыңар гына да хәбәр җибәрмәве шактый сискәндерә. «Минем йортка ут капмаган бит», дип, читтә качып калырга теләсә, менә монысы начар. Шуңа күрә, иң беренче эш итеп, калмыкларга һәм, берочтан, фетнәчеләргә каршы яу оештыруны шушы Шереметевка йөкләп куйыйк әле.

– Бик хуп, бик хуп, – дип, ияк какты Софья, аннары ишек катындагы офицерларга әмер ташларга да онытмады: – Фәрман әзерләгез!

– Икенче төп бурыч – гаскәр җыю. Миңа калса, Түбән Новгород белән Әстерхан каласына тупланган стрелец полкларының биш-алтысын ашыгыч рәвештә Казан тарафына куу хәерлерәк. Ул калаларның берсендә – кенәз Урусов, икенчесендә кенәз Волконский комендантлар ролен үтәп тора бугай. Новгород белән Әстерханга һичнинди хәвеф янамый, әлеге кенәзләрне дә стрелец полклары белән бергә Казан каласына, Шереметев кул астына озатырга кирәк.

– Хуп, хуп, фәрман әзерләгез, – дип, мөһер сугып барды патшабикә.

Ахырда гына бояр Долгоруков торып басты. Үзе берәүнең дә күзенә карамый, ә тавышы еламсырап, үксеп чыга сыман.

– Теге чакта Иван белән Пётр падишаһларыбызга морзаларны ярты ел эчендә чукынырга мәҗбүр итә торган фәрманга кул куйдырып, нык ялгыштык без. Адәм баласының берсе дә хатадан хали түгел, иллә мәгәр дин вә иман алыштыру эше гаять тә ки авыр мәсьәлә шул. Дин бирмәк – җан бирмәк бит. Татар морзаларын да, башкортны да шул фәрман котыртты бугай. Илнең хәле болай да бик яман, әле Кырымнан, әле Азовтан борып кайтаралар. Мин элекке фәрманны тулысынча юкка чыгарыйк, димим, ә вакытлыча туктатып тору – безгә отышлырак.

– Ярый, монысын да кабул итәбез, бу хакта да фәрман әзерләгез, – дип җөпләде Софья. Аннары кенәзләрең күзләренә төбәлмичә генә, барыбер өстәп куйды: – Безгә кенәз Василий Голицынны да кабат приказ башлыгы итеп утыртмыйча, стрелецлар фетнәсе төгәлләнмәс сыман...

«Бүре дә тук, бәрәннәр дә исән» – шулай була икән...

**2**

Казанда кенәз Шереметев кылны кырыкка ярырдай булып бәргәләнә.

«Новгород белән Әстерханнан стрелецлар килеп өлгергәнче, ашыгыч рәвештә үзең дә ополчение тупла!» – дигән фәрман җибәргәннәр.

Ә ул җәһәннәмнән җыеп тупласынмы? Комендант аламаларына юри санаттырды, бистәләрен дә кушсаң, Казаннан биш мең дә биш йөз чамасы дворян белән рейтар[17] җыеп була. Мәгәр аларының да яртысы йә картлач, йә гарип бит. Аларга өләшерлек фузей, айбалта һәм кылычлар да җитми. Шулай икән, кайдан алып, ничек әзерләсен? Ә аннары, «син булдыксыз, син җебегән» дип, йөзгә корым ягарга да күп баш ватмаслар. Түбәндәге түрә өстәгеләр өчен һәрчак булдыксыз ул, аны кем генә белми?!

Фәрманны Мәскәүдән Степан Акинфов атлы дворян алып килгән. «Синең кул астыңдагы йомышчы булачакмын», – ди. Аһ, җүләргә саный, очсыз итә болар. Акинфовның баш воевода тырнак астыннан кер эзләү өчен озатылган шымчы икәнен дә төшенмәскә Шереметев беркатлы шалкан түгел ләбаса!..

Шереметев менә шулай божра эченә утыртылган тиен сыман бәргәләнә иде, Уфа каласыннан тагын яңа күсәк:

– Калмыклар белән татар-башкорт фетнәчеләре Бирск каласын яулап алган; талап чыкканнан соң кирмәнне тулысынча яндырып бетергәннәр!

– Йа Хода, коткар мине, коткар! – дип, күкләргә ялвармыйча, ничек түзәсең, ди!..

Ике көннән соң Новгородтан полклар килеп җитте. Шереметев үзе дә, якын-тирә рус авылларын урый-урый, мең кеше тирәсе чирү җыйган иде. Аннан-моннан коралландырып, олауларга тезеп, Минзәлә каласына озаттылар. Анда кирмәннең эзе дә калмаган, аның урынына яңасын кора торырлар, ичмаса, күз көеге булып, монда ятмасыннар!..

Алар урынына дигәндәй, баш воевода өстәле янына кенәзләрдән Волконский белән Урусов килеп төште. Полкларыннан аерым йөри болар, хәрби хезмәт бурычы, дигәнне өшкереп тә бирми. Шереметев Урусов белән ялгыз калган бер минутта юри сүз кузгатты, теге туган телен яхшы белә, каһәр!

– Ә мин татар җырларын моңы, көе өчен яратам, – дип теттереп кенә тора.

Вәт сиңа дин!..

Әстерхан полклары турыдан гына Минзәләгә юл тоткан, Казан каласына кереп тормаганнар. Шуны белеп алгач, кенәзләр дә бик тиз юлга чыкты. Көзнең иң шәп яңгырлары коеп торган чакта Минзәләгә җиттеләр. Кирмән диварлары ике яктан аякка баскан инде, ләкин манаралары, капка, зинданнары, воевода йорты һаман да юк. Монда алты-җиде мең кешелек

[17] Рейтар – сугышчы.

гаскәрне кундырырга йортлар саны да җитешми, аяк аслары туңдыра башлаганчы дип, Уфага ашыктылар.

Фетнәчеләр белән калмыклар да баш воевода кул астында килүче олы гаскәр турында ишетеп өлгергән, әлбәттә. Хөкүмәт полкларын Өфедән кул сузымындагы Бәрсуан елгасы ярында каршы алдылар. Күперләрне Шереметевныкылар килгәнче үк сүтеп бетергәннәр, полкларның берничәсен һичбер әзерлексез көе боздай салкын су эченә ташларга да туры килде. Ләкин фетнәче татар белән башкорт ирләре дә этәч сыман кунып, пырдымсыз ташланулардан җебеп төшә торган кавем түгел. Әллә кайдан гына туплар тапкан болар, аны кибән эвеннәре эченә яшереп, дарыны да дым һәм судан саклый белгәннәр. Өч туп залп бирүгә үк иллеләп стрелец елга төбенә китте. Калганнары бүре яки эт өркеткән каз көтүе шикелле кабат елганың кергән ярына ябырылган иде, ике яктан калмык җайдаклары атылып чыкты. Искә-аңга килгәнче, дистәләгән укчыларны турап ташладылар.

– Ойрот! Кыят! Сармат! – дип үкереп, үзләре ерак бабаларының рухын ярдәмгә чакыра, шул көч бирә бугай, тагын да гайрәтләнеп, шашып турыйлар шул...

Бәрсуан буендагы бәрелеш күзләр бәйләнә башлаганчы дәвам итте, бер як та җиңүгә ирешә алмыйча, кире чигенде. Теләкәйнең янә бер иңбашы яраланган иде, Күчем күбрәк аның янында бөтерелде. Яраны юып, әрекмән яфрагы бәйләп кую да ярдәм итмәде, Теләкәйнең тәне ут шикелле яна башлады, Күчем төн буе аның янында утырып чыгарга мәҗбүр булды.

Ә таң атуга, станга йөгереп кайткан бер яугирнең сөрән салгандай хәвефле тавышы һәммә кешене өнсез калдырды:

– Калмык җайдаклары барча чатыр-арбаларын җыеп качкан!

Ялгыш кына да ышана алмыйча, Күчем калмыклар корган стан урынына йөгерде, ә анда уткүз итеп озатылган бер татар егетен каен агачына бәйләп калдырганнар. Авызына тутырылган яулыкны тартып алгач кына, ул гарьләнә-гарьләнә ярып салды:

– Кичә кичтән Зайсә тайшә янына Әстерхан башлыгы юллаган елдам чапкын килгән. Воевода Зайсә тайшәгә бер олау тутырып, бүләк җибәргән, чапкын аны якындагы бер чокырга яшереп килгән икән. Үз чапкынын җибәреп ачыклагач, тайшә шундук кузгалып китәргә әмер бирде. Без ярык тагарак алдында утырып калдык бугай.

**3**

Теләкәй белән Күчем туган нигезләренә кайтып кергән чакта тирә-як яланнар өстен беренче кар пәрдәсе каплап алган иде инде. Теләкәйне саклык белән генә олаудан төшерделәр, әмма ул барыбер өй тупсасын үз аяклары белән атлап керә алды. Ике ягына да Җинан белән Гөлбикә килеп асылынмакчы иде, Теләкәйнең агарып һәм суырылып калган йөзен күргәч кенә тыелдылар.

– Йа рабби! Әй, бичарам, җаным!

Түшәккә кертеп салгач, билгеле ки, һәммәсе дә ухылдады, көйде, бөтерелде. Кечкенә Акай өчен дә бабасы бик кызганыч, кул аркасы белән күзен уа-уа, ул да мең кат аның янына килде.

– Син чирләмә инде, бабакаем. Аннары миңа Наянымны җигеп бирүче инсан табыламыни?

– Ә Мөхәммәтша карт?

– Һе, аның янына барып кына кара. Әй, аяк астында буталып йөрмәле, дип, шундук кире куа.

– Әһ, алайса, колагын борам икән!

– Борма инде, аның колаклары болай да ишетми бит...

Теләкәй ике атнадан соң аягына басты. Җинан белән Гөлбикә күпме балавыз сыкмасын, аларның кулыннан талап диярлек, киез итекләрен дә, туны белән бүреген дә киде. Тышка чыгып, як-ягына күз атса, Күчем улы Акайны җитәкләгән килеш Шәбез елгасы буендагы үзәнлеккә таба төшеп бара. Теләкәй куып җиткәч, оялып та тормыйлар, Күчем үз кулындагы зур балтаны суза.

– Менә, инәкәйләр елга уртасында бәке чабарга җибәрде. Мал эчәгеләрен юарга елга суы кирәк, диләр.

Теләкәйне шул чагында корт чаккандай булды. Балтаны талап диярлек үз кулына тартып алды да яр астына сузылган әрәмәлекләргә таба атлап китте. Бер урында тукталып, кат-кат таптангач һәм тирә-юньгә карап алгач кына, балта сабын янә Күчем кулына төртте.

– Менә бу урында элек чишмә тибә иде, егет чакта казып, суларын байтак эчтем. Ә аннары дөнья мәшәкате басты, чишмә онытылды. Бер чишмә дә корырга тиеш түгел, ул тач кеше җаны кебек. Менә шушы урында казы, чишмәне ач, улым...

Бер карыш тирәнлектә туңып өлгергән җирне балта белән чапкалый башлагач, ташлар арасыннан нәни ерганак сыман гына типкән сулы урын күренде.

– Улым, көрәк белән ыргаклар да алып төш, – дип, Күчемне янә ихатага кайтарып җибәргәч, Теләкәй үзе дә тирләп-мышнап, ике көрәк тирәнлеге җирне әйләндереп атты.

– Әткәй, син интекмә инде, яралы җиреңә зыян тидерерсең, – дигән тавыш ишеткәннән соң гына, күндәм кыяфәттә, улына урын бирде.

Учакта мул сулы казан кайнап чыгарлык ара буе Күчем җык чиккәннән соң, чишмәгә җан керде. Аның як-ягына, яр эченә кертеп, ике-өч рәшәткә кактылар. Су ярсыбрак ага башлагач, аның юлына улак та ясадылар. Кыш көне кар күммәсен дип, ниндидер түбә әтмәлләп кую да кирәк иде, аңа ярарлык такта-тимерләрне һаман да шул Күчем алып төште. Инде чишмә агышында нәзек кенә челтерәү авазы да пәйда булгач, Теләкәй аның каршына тезләнде, ике учына җыеп, суын татыды. Шул ук дәү учлары белән яңа суны Акайга да сузды.

– Әйдә, син дә татып кара, олан. Күрше-күлән сораштырса, бу чишмәне «бабайныкы», диярсең. Инде егет булгач, «әткәй чишмәсе», дип атасаң да ярый. Аннары үз угылларың да үсеп җиткәч, алар аны синең хакка «Акай чишмәсе», дип олылар. Менә шулай, адәм җаны, халык хәтере кебек әлеге чишмәне дә буыннан-буынга, елдан-елга сүндерми саклау кирәк. Кемдер бик яратыр аны, кемнәрдер үз итмәс. Теләкәй белән Күчем чишмәләре һәркем өчен дә татлы була алмас. Татлы булуы да кирәк түгел, ул мәңгелек булсын!..

## Унөченче бәйләм

### 1

Тыныч кына бер ай яшәргә дә ирек бирмәделәр. Өфе каласы учактагы казан урынына дөбердәп кайный иде, ахры, аннан байтак кына хәбәр бүлтәеп-тамып торды:

– Калмыклар качып киткәч, дуарәннәр язгы яланга чыккан колындай сикеренә. Шулар кул астындагы карат нөгәрләре Сөн елгасы буендагы Чакмак, Әмәкәй, Баек, Байсар авылларын талап узган. Кайсыннан – утыз, кайсыннан иллегә тикле атны талап алганнар, ди.

– Агыйдел ярында корылган станда стрелислар көн саен күнегү үткәрә, Казаннан килгән Ширәмәт-бояр тагын яңа мәсхәрә сәфәре әзерлидер инде...

Теләкәйгә китереп җиткерелгән соңгы хәбәрләрнең берсе аның бәгыренә, мөгаен, ук шикелле барып кадалгандыр.

– Кенәз Волконский үзенең стрелислары белән һөҗүм ясап, Көңгер кирмәненә бикләнгән Сәгыйт Җәгъфәр чирүен тар-мар иткән. Дүрт башкорт старшинасы шундук каратлар ягына чыгып, кенәзнең бишмәт чабуларын да үбә башлаган, ди. Мондый гамәлләрне баш воевода, кенәз Шереметев каршында да кылып, аннан гафу сорарга да онытмагыз дип, Волконский аларны Уфага юллаган...

– Ә Сәгыйт хәзрәт, Җәгъфәр хәзрәт үзе? – дип, тагын да түзә алмыйча, Теләкәй морза чапкынның йөгәненә ябышып сорау бирде.

– Әйе, әһ-һә, шамбы балыгыдай шома хәзрәт койрык тоттырды, ди! Ул үзенең капчык-сандыкларын инде кыш башында ук Тубыл ягына озаттырган иде. Каратлар кирмәнне һәр яктан бикләп куйгач, дүрт мөриде илә иң шәп атларда, яр аслары буйлап, янә Тубыл ягына чыгып ычкынды ул.

Нәтиҗәне күзаллаган икән, Теләкәй ярып салды:

– Мин тач шулай тәмамланыр, дип гөманлаган да идем...

Атна-ун көннән соң Бишбүкән-Андреевка ягыннан берьюлы өч-дүрт ир җыелып килде. Аңлашыла, бу төбәкләрнең дә итәгенә утлы күмер төшкән, хәзер бер иргә дә хатын түшәгендә генә яту булмас инде.

– Акинфа илә Урыс атлы ике дуарән Бөре юлы буйлап ике меңләп яугир алып килә. Җайдаклары биш йөз чамасыдыр, калганнары чаналарга төялгән, алар кәрван хәтле. Өфедәге озын колаклар хәбәр салуынча, каратларның бер кыйсеме Бөредә яңа кирмән күтәрергә дип тукталып калачак, икенче кыйсем Пәнҗәр илә Каенлы-Бириздәктәге чиркәүләргә нигез салачак, ди. Пәнҗәр тикле Пәнҗәргә төбәп чыккач, алар Бишбүкәнне дә урап үтә алмый. Анда яндырып юкка чыгарган чиркәү хакын, мөгаен, бездән түләтерләр. Шуны максат итсәләр, каратлар якындагы Ябалак, Кыргыз, Усаклы авылларын таламыйча калмас. Тагын йөзәрләгән атлар, сыер-сарык, хәтта өлгереп җиткән кызлар да таланачак. Халык түзәргә теләми, һәрбер авыл синнән ярдәм көтә...

«Ачы булса да аша, үз куагың җимеше, – дип, күңеленнән генә үзен сүкте морза. – Фетнәне син кузгаттың, ир вә егетләрне яуларга син иярттең, синең чакыру белән, аларның ничәмә-ничә йөзе син ятлаткан «хөррият» сүзләрен кабатлый-кабатлый, башын салып ауды. Учак өстенә казанны син элгәнсең икән, кайнап торган шулпасын йә суын да, әйдә, иң әүвәл үзең чөмер. Авызың пешәме-юкмы, кемнең ни эше бар?»

– Мин аңладым сезне, агай-эне. Иртәгә төш вакытында Бишбүкәндә булырмын...

Ялгыз калуга ук иң әүвәл ул Күчемгә дәште.

– Чаптарыңа атлан да Чулманның теге ягындагы Пәнҗәр авылына элдер. Юлда Барҗы, Ырыс салаларын узарсың, аннан берникадәр баргач, Салагыш, Тирсә, Уразай, Исәнбай авыллары тезелешеп тора. Һәрберсен дә кисәт. Өфе ягыннан каратларның зур чирүе килә. Барча авыллардан нөгәр тупласыннар. Мин дә юлга чыгам. Алла боерса, ике көннән соң Бишбүкән авылы тирәсендә бергә кушылырбыз.

Теләкәй яратып һәм зурлап, Күчемне күкрәгенә кысты, күзләренә төбәлеп карамады.

– Юлда уяу йөре, улым, тозаклардан саклан.

– Беренче тапкыр гына яуга чыкмыйбыз бит, мин чыныккан, әткәй, – дип, авызын ерып, елмайды да Күчем абзар ягына чыкты.

**2**

Бишбүкәнгә алып килүче юлның ике ягында да – куе урман. Теләкәй туплап килгән егермегә якын авыл ирләре күбесенчә мул ылыслы нарат агачлары артына яшеренеп ята. Күпчелек ирләр кулында болан мөгезләренә кылдан үреп тарттырылган тәтәле зур җәяләр, садакларда ярты чакрым буе сызгырып оча торган сәрпи уклар. Биредә нөгәрнең бер өлеше генә, ирләрнең күпчелеге урман эчендәге тирән ерым, үзәнлекләр эченә яшеренгән.

Баш очында гына эре суер сызгыргандай зәһәр тавыш ишетелде дә, нәкъ татар ирләре тезелеп яткан нарат агачларының берсенә ук килеп кадалды.

– Каратлар якыная! Яуга әзер торыгыз! – дип, Теләкәй якын-тирәдәге ирләр төркемен өстәмә рәвештә кисәтеп тә алды. Бу кисәтү чылбыр буенча ерактагыларга да тапшырылды.

Ниһаять, атлар пошкырган, мыр-мыр сөйләнеп барган ирләр тавышы да яңгырады. Шикләнерлек түгел, алда шыгырдаган өч-дүрт чанада күзәтчеләр һәм авылларга керүгә үк буш йортлар вә солы, сугым малы эзли башлаячак иравыллар гына. Теләкәй ике кулын ике якка җәеп, «кымшанмаска» дигән әмер бирде – болар узсын, аларга ук әрәм.

Ат тугарып җигәрлек ара үткәч, юл өстендә торналар кебек тезелешеп килгән олау да пәйда булды. Солдатларның бер өлеше үрәчәләр өстенә сузылып яткан, болары йокымсырый. Кайбер чаналарда изүләрен ачып, дөньясына төкереп баручы калай әтәчләр дә очрый, мондыйлары кичә көмешкәне лыкынганчы чөмергәндер инде. Офицерлар алдагы олауларда ике-өчләп кенә, алары да якалары эченә чумып, йокымсырап бара. Олаучылар кирәкме-кирәкмиме, ара-тирә дилбегәләрен селкеткәләп куя. Атлар риза түгел, пошкырып һәм башларын өскә чөеп алырга һич онытмый.

Олауның кыл уртасы Теләкәй яшеренгән карт нарат белән тигезләшүгә үк, һавада көртлек гөлдердәгәндәй тавыш ишетелде дә чаналар өстенә ук болыты очты. Сәрпи уклар яман сызгырып, дәһшәт бөркеп оча, шуннан өркеп, атлар камытларын өзәрдәй, тәртәләрен сындырырдай булып, өскә сикерә башлады. Солдатларның бер өлеше үрәчәләрендә яткан көе мәңгелеккә тынды, кайберләре юл читенә ауды. Яралылардан чәчрәгән кан дилбегә-чаналар, өнсез калган солдатлар өстенә сибелде.

– Караклар, карак фетнәчеләр һөҗүме бу!

– Чана үрәчәләре астына кереп яшеренегез!

– Беттек, туганнар, беттек! Ошбу кыргыйларны электән үк җәлләп тормый кырып бетерәсе калган!

Олаулар өстенә яңа ук яңгыры очты, янә дистәләгән стрелец көрт эченә чумды. Чаналардан сикереп төшкән солдатлар кая качарга белми, әрле-бирле йөгерә, һәр тарафта тәшвиш вә кычкырыш. Шулай да, офицерлар салкын канлы икән, яннары белән бастырып куйган чаналар уртасыннан аларның көр тавышлы әмере яңгырады.

– Бөтенегез дә көрт эченә сузылып ятыгыз! Фузейларны яуга! Караклар нарат агачлары артына яшеренгән, шулар арасына төбәп ут ачыгыз!

Мылтыклардан бердәм ут бөркелде, ату тавышыннан ылысларга сарган кар коелды. Татар яугирләре дә тик ятмый бит, солдатларны чүпли-чүпли, олаулар өстенә һаман уклар оча.

Теләкәй бөтенләй дә искәреп өлгермәгән, менә бу, каршыларындагы олау артыннан ярты чакрым ара калдырып, икенче олау да сөйрәлеп бара икән. Алда купкан мәхшәрне тоюга ук, икенче олау ирләре дә атларны кызулатты. Мондагы солдатлар мылтыкларын инде кулга тотып килә, беренче чана туктап калгач, юлның ике ягына да сузылып яттылар. Алар хәвефнең наратлар артыннан бөркелүен дә ачыклап өлгергән, татар яугирләрен дә, бал кортыдай безелдәп, дистәләгән ядрә чагып чыкты. Бөтен тирә-якта ыңгырашу, сүгенү һәм тәшвиш.

– Бу икенче олауны ничек сизмәгәнбез? Сакка җибәрелгән ирләр ни караган?

– Болар тупларын да көйләсә, тетеп сала безне!..

Чыннан да, икенче олаудагы офицерлар аңлап алды бугай, тар чаналарга бәйләп куелган олауларны борып куйдылар да, үз эшләрен яттан белгән тупчылар дарысын һәм ядрәләрен табып, тиз арада көпшәләр өстенә ут элдерделәр. Аннары ярты урман өстендәге кар тәлгәшләрен коеп, дию үкергәндәй зәһәр тавыш яңгырап ишетелде. Кайсыдыр ядрәләр нарат ботакларын умырып узды, әмма байтагы көрткә сеңгән фетнәчеләрне дә әйләндереп атты.

– Кәмингә, кәмингә[18] калдырылган яугирләрне чакырырга кирәк! Барысы да ут капкандай монда килеп җитсен! – дип, Теләкәй морза тезләренә күтәрелеп, арттагы ирләргә әмер ташлап өлгерде, ләкин икенче мизгелдә үк аның баш түбәсенә кемдер күсәк белән орды...

Берникадәр вакыттан соң ул үзен ниндидер гайрәтле кул сөйрәп баруын барыбер чамалады. Күз кабакларын ачарга, гайрәтле кул иясенә төбәлеп карарга теләде, көч тапмады. Аның чигәләре умарта оясыдай гөжли, баш түбәсен дә тәлгәш-тәлгәш булып тезелешкән кортлар талый сыман, яман сызлаулардан котылырлык түгел. Кайбер мизгелләрдә генә умарта кортлары тынып калгандай була, шул вакытта керфекләрен ачкан кебек тә, ләкин күз алдында куе-кара томан. Ул зиһененең кайсы төше беләндер үзен кемдер мышный-мышный көрт өстеннән сөйрәвен дә аңлый, кайбер чакта зур гәүдәле ирнең шәүләсе дә чагылгалап куя. Әмма кем ул, Теләкәй аны кай тарафта күрде? – Шуны аңлый алмый...

[18] Кәмин – засада.

## Ундүртенче бәйләм

### 1

Теләкәй, сызлана-сызлана күзләрен ачкан чакта, зур гына бер йортның идәнендә ята иде. Кул-аяклары арканга уралган, йорт түрендә – күркә төсле кабарынып баскан дворяннар. Димәк, морза – әсир, аны кайдадыр, ничектер кулга эләктергәннәр. Ә күркәләрнең бик ерактан, Мәскәү яисә Казаннан ук сикереп төшкән булулары мөмкин, болар җелегеңә үткәнче төпчеми калмаячак.

Теләкәйнең аңга килүен иң беренче җылы мичкә аркасын терәп утырган офицер шәйләде.

– Әһә, айныды безнең батыр. Йә, хәлең ничек, җаный? – дип каһкаһәле тавыш белән соравын да бирде.

Моңа җавап кайтарудан ни файда? Болар бит Теләкәйдәй асылкошны казык тешләреннән ычкындырачак түгел.

Күркә офицер Теләкәйнең уйларын үтәли күрәме соң, шундук ачып салды:

– Асыл кошның үзен капкынга эләктерү бәхете елмайды. Язмыш-кәнтәй безне үги итми. Шулаймы, кем, Пётр Гаврилович?

Ишек катындарак икенче офицер да утыра икән, Теләкәй аңа да беравык күз сирпеде. Озынча буйлы, ябык, киптерергә элгән балык кебек. Мәгәр үзен бик югары бәяли, ахры, киемнәре көяз, чәчләрен дә як-якка бөдрәләткән.

– Әйе, әйе, Сидор Матвееч, язмыш типкәләп йөртми, без шуңа да бик шат, – дип, «күркә»гә җавап бирергә ашыкты.

Һе-һе, ошбу «балык» ялагай һәм куркак та икән. Түрдәге офицер Сидор Матвеевич, димәк, ул өлкәнрәктер дә. Тагын ни сайрарлар?

– Без синең кем икәнеңне беләбез, шуңа күрә озак төпченмәбез, – дип, әлбәттә, «күркә» дәвам итте. – Ләкин безне бер сорау аптырата, син морза була торып, ун мең чамасы атка ия килеш, ни пычагыма дип фетнә кузгаттың да, ни кишеремә дип кулларыңа корал алып, яуга кердең икән? Сиңа ни җитмәде, морза, тагын ни кирәк булды? Әллә безнең кебек үк дворян булу, кенәз, бояр дәрәҗәләренә ирешү идеме синең исәп?

– Кирәк иде пычагыма, үзең әйтмешли, – дигән сүзләрне Теләкәй теш арасыннан сытып чыгарды, әмма шул чакта чамалап өлгерде – баш түбәсе, муены үтереп талый икән.

– Ни әйтте ул, ни әйтте? – дип «күркә» ишек катындагы «балык» тарафына якынайды. Тегесе татар телен ничек шулкадәр оста беләдер, «күркә»гә «ә» дигәнче тәрҗемә кылып бирде.

– Миңа берни дә кирәкми, ди. Аның безнең белән сөйләшергә исәбе дә юк, Сидор Матвееч.

– Оһо-оһо, герой инде, димәк! Мәгәр сөйләштерербез! Җәллад Степан, тире остасы кайда?

Ишектән аю кебек алпан-тилпән атлап әзмәвердәй таза, әмма бер күзенә ак сауган ир-ат килеп кергәч, «күркә» офицер эт чәңгелдәгән кебек өреп әмер бирде:

– Башта кулларыннан бәйләп, ыргакка ас моны, аннары йөзтүбән! Тегеләй дә, болай да егерме бишәр камчы!

– Түзәр микән? – дип, баш чайкады җәллад.

– Чамалабрак кыйна. Әле Шереметевтан нинди җавап килер? Уфага китер, дисә, сөйрәп йөрисе бар...

Степан бик үк котырып ярмаса да, очына тимерчыбык үрелгән чыбыркы Теләкәйнең тәнен ярып-телеп керде. Аеруча йөзтүбән асып куйгач, озак түзә алмады, биш-алты тапкыр сыдырып алуга ук аңын җуйды. Аннары меңнәр өстеннән башлык булып йөргән ирне сыер абзарына кертеп бикләделәр.

Икенче таңда аның эргәсенә шыпан-шыпан гына атлап, кичәге көяз «балык» – Пётр Гаврилович килеп керде. Үзе як-ягына карана, үзе артыннан эт куып килгәндәй кабалана.

– Сиңа дар агачыннан котылып калу өчен бер генә юл бар, морза. Өммәтеңнән баш тарт та, әйдә, чукын. Шуңа ризалык бирсәң, исән калачаксың. Әле малларыңа, байлыгыңа тимәүләре дә мөмкин. Хәтта Ширәмәт каршына кертеп бастырсалар да, мин чукынам, диген.

Теләкәй дию пәрие күргән сыман текәлде дә катты. Йа Хода, нинди бәндә, кайсы кавемнән бу? Саф татарча оста сөйләшергә аны кем өйрәткән?

– Син чукынган татар морзасымы әллә? – дип, ниһаять, телгә килә алды. Үзе һаман һич ышанмый, көтелмәгән кунакка текәлгән дә каткан.

– Әйе, морза мин, чукынган татар морзасы. Нижгар якларыннан. Нигә аптырыйсың? Җанны да, малны да саклап калу отышлырак иде, шуңа чукындым да. Берәүгә дә гомер ике килми. Яшәү кадерлерәк.

– Морза түгел, соран, сатлыкҗан син! – дип, Теләкәй ыңгыраша-ыңгыраша тезде: – Газиз әткәң вә бердәнбер әнкәңнән баш тартып, аларның йөзенә төкереп буламыни? Аныңише кабихлеккә барганчы, дар агачына менүең хәер. Күз алдымнан югал!

– Гомер, гомер, – дип, көяз «балык» янә нидер өстәмәкче иде дә, Теләкәй кырт кисте.

– Йә чыгып кит, йә кычкырам!..

Мондый хыянәткә өндәүче явызлар бер көяз «балык» кына булмаган икән шул. Көн яктысында өйгә сөйрәп керткәч, Теләкәй янына хөнҗү бер поп якынайды. Кулында олы тәре.

– Господи, упаси раба своего и поставь его на праведный путь! – дип укына-укына килеп, тәрене Теләкәйнең иреннәренә терәмәкче булды.

– Кит, анаңны эт еккыры! – дип үкереп, ничек попны тибеп очыруын Теләкәй үзе дә аңламый калды. Каян гына гайрәт табылган да, кайлардан көч алган?!

– Аһ, син әле һаман карак, һаман фетнәчеме? – дип чиный-чиный, «күркә» офицер, янә ишек тибеп, җәлладны чакырды. Теләкәйне янә ыргакка күтәрделәр, Степан бу юлы ярсый-ярсый ярды...

## 2

Теләкәй төн буена ыңгырашып-кызышып җәфаланды. Бөтен тәне пычак белән буй-буй итеп кискәләгән сыман. Бер яктан икенче якка да әйләнеп ята алмый, ничек кертеп ташлаган булсалар, шул көенчә – гел йөзтүбән аунады. Их, ул ниндидер тылсым белән өенә кайтса иде дә, газиз Гөлбикәсе аның аркасын хәтфә куллары, куян койрыгыдай нәфис бармаклары белән иркәләсә, бер сыйпаса иде! Юк шул, Теләкәй Гөлбикәнең йомшак кулларын бүтән татый алмас!..

Тышта буран үкерә, ә Теләкәйгә эссе. Тәне кызышудан кайчак йокыга да киткән сыман була. Күзләрен чытырдатып йомдымы, томаннар арасыннан һаман теге кара шәүлә калка. Зур гәүдәле, куллары имән тамыры яисә аркан кебек. Теләкәй аның күзләрен, йөз чалымнарын эзли, әмма Сабан туе батырыдай таза егетнең башына капчык яки битлек кидереп куйганнармыни! Сабан туе димәктән, ул аны берәр кайчан шундый бер бәйрәмдә очратмады микән? Әллә Минзәлә зинданыннан мәхбүсләрне азат иткән чакта бар идеме ул? Куллары, иңбашлары, куна тактасыдай киң җилкәләре – һәммәсе дә таныш, ә йөзен, кыяфәтен һич кенә дә күз алдына китерә алмый. Алай гөманлау, мөгаен, зур гөнаһтыр, кулыннан тотмадың бит. Иллә мәгәр шәүлә томан эчендә әвәрә килә дә, Сабан туе мәйданына сөлге тотып чыккан егет булып, әйләнә дә кайта. Явыз, явыз фараз!..

Ә Күчем, менә, төгәл күз алдында. Ярсу чаптарына сикереп атланган, кулында – шәп кылыч. Ул шул кылычын һавада яшен төсле ялт иттереп ялтыратып ала да аннары: «Күрдеңме, әткәй?» – дип җәелеп, авыз ера. Әгерҗе ягына да шул кыяфәттә чыгып киткән иде. Әле ярый, Теләкәй аңа ике тәүлек вакыт биргән булган, ә үзе ул бер тәүлек узуга ук яуга керде. Күчем әйләнеп кайткач та, аны эзләми калмас. Мәгәр тоткарланып калуы отышлырак. Әгәр ул да дошман кулына килеп эләккән булса? Юк, шайтаннар, сез Теләкәйне андый уйга кертеп маташмагыз! Ата кеше өчен үзенең газиз улын югалтудан да авыррак, газаплырак кайгы бармыни бу җиһанда?! Теләкәй Күчемне дошман кулына эләктермәс өчен йөз кат, мең кат җәзаланырга, ахыр чиктә аның урынына үзе үлем авызына атларга да риза! Тимә, тимә, үлем, минем газиз Күчемемә, йа Ходa, минем улкаемны исән көе сакла!

Әле, әле газиз Акай да бар бит. Әгәр кайтып керсәң, ул иреннәрен бүлтәйтеп, кат-кат сорар инде:

– Бабам, кайда йөрисең син? Карт әби, әнә, син кайтмый тордыңмы, «олагып йөри кайдадыр», дип сөйләнә. Син олагуны үзеңә ияртеп йөрмә, ялгызың гына ура да кайт, ура да кайт, яме?

Акай оланым – булган, үскән егет. Чишмәне генә, менә, юньле-башлы ачалмыйча киттем. Ул миңа түгел, Күчем улыма, Акай оланыма кадерлерәк. Чишмәне аларның берсе – «әткәм йөзе», икенчесе «бабам йөзе», дип саклар. Ә аннары чишмә Акай улына калыр. Буыннан-буынга чылбыр булып күчәр. Шулай сакласыннар. Хөррият суы һәр буынга, һәр татарга кирәк. Алар чишмә тибешен корытмаса иде!..

## 3

Кичә кичен ихатага чапкын кергән иде, ә иртәдә Теләкәйне авыл мәйданына сөйрәп чыгардылар. Теләкәй бер күз сирпеп алуга ук һәммәсен дә күрде. Әнә мәйдан уртасына киң күтәртмә төзеп куйганнар. Янында дар агачы. Ә мәйдан читенә татар, башкорт, чуваш, ар, чирмеш картларын, хатын-кызны, бала-чагаларны куып китергәннәр. Һәр тарафны стрелецлар чылбыры урап алган, лыгырдык офицер аламалары әйтмешли, сыңар тычкан чыгып кача алырлык та ара калмаган шул монда.

Беркөн абзарга качып-посып кына кергән көяз «балык», гәүдәсен шәмдәй төз тотып, янә аның янына килеп җитте.

– Әйдә, морза, күтәртмәгә атла!

Үзе әмерне яңгыратып бирә, ә Теләкәйнең йөзенә караудан шүрли. Морзага капылт кына кызык булып китте, ул авыз чите белән елмаеп мыгырдаудан да тартынып маташмады.

– Бүген мин бичарага тавык тәпиен үбеп карау бәхете дә эләкмәс микән инде? Теге хөнжү поп та каядыр юкка чыккан.

Көяз «балык» баш очындагы эшләпәсен төзәткән булып, ә асылда авызын каплап җавап кайтарырга мәҗбүр булды.

– Син соңардың, морза. Баш воевода Ширәмәттән әмер килеп төште. Менә шуны үтәргә ашыгабыз.

– Үтә очсызлыйсыз. Мине Өфе каласында, воевода күзәтүендә асып куярлар, дип хыялланган идем.

– Уфага ук илтергә куркалар шул, Күчемеңнең урлап китүе бар.

– Имәндә икән чикләвек...

Фәрман кәгазен Теләкәйне дар агачы астына бастырып куйгач, элмәкне муенына ташлаганнан соң гына күтәреп чыктылар. Ни галәмәт, фәрман гаҗәеп дәрәҗәдә кыска, саран яңгырады.

– Фетнәче караклар башлыгы Теләкәй морзаны айлар буе халыкны болгатып, рус дәүләтенең бөтенлегенә янап кылган җинаятьләре өчен Идел буеның баш воеводасы, окольничий, кенәз вә бояр Шереметев ... галиҗәнаплары фәрманы буенча, дар агачына асарга!

Мәйдан читендә унлап стрелец ду китергән дөмбак авазлары дөмбердәде, уртага җыелган йөзләрчә колның тәне чымырдады, арада бер генә кеше дә күз яшьләре сытып чыгармады.

Җәллад аяк астына куелган күтәртмә читенә китереп типкәнче, һавада Теләкәйнең бар мәйданны ярып кычкырган тавышы яңгырады:

– Хөррият чишмәсен, хөрриятнең җанын корытмагыз!..



Булат
Ибраһим

# ТАЙГАКЛАНГАН ДӨНЬЯ, ЮЛЛАР ТАЯ...

## Томан төшкән Казан каласына...

Томан төшкән Казан каласына,
Халык йөри томан арасында.
Томан арасында ни барын
Күрәсеңдер үзең, татарым?!

Тайгакланган дөнья, юллар тая.
Шофёр абзый, чабасың син кая?
Үзең генә түгел, карале,
Янәшәңдә халык бар әле.

Кул сузымы – күренерлек ара,
Ел артыннан еллар сала яра.
Томанлы көн, аңны томалап,
Мәңгелек кыш кора юмалап.

Ераккарак китеп баргачтын,
Иркенәеп һава алгачтын,
Дустым яза: «Бездә юк томан».
Бездә дә юк – бары күз тонган.

## Тоталар да Коръән яндыралар

Тоталар да Коръән яндыралар,
Утта янамыни тугры иман?
Бу Җир шары нигә шулкадәрле
Имансызлар белән шыплап тулган.

Барысын да бер арбага җыйнап,
Кара ягып нурсыз битләренә,
Дөнья буйлап куаларга иде,
Гыйбрәт булсын иблис этләренә.

---

Булат ИБРАҺИМ (1990) – *шагыйрь; «Йолдызлы билет» халыкара әдәби премиясе, Муса Җәлил исемендәге республика премиясе лауреаты. «Балык теле», «Безнең эзләр», «Шагыйрь» һ.б. шигырь җыентыклары авторы. Казанда яши.*

Кузгаталар халык күңелләрен,
Дәүләт белән дәүләт курчак уйный.
Коръән нурын кара төнгә төреп,
Җир шарында мәлгунь шайтан туйлый.

Тибрәтәләр иң нечкә кылларны,
Газаплатып ләззәт табучылар.
Туктатыгыз канлы шайтан туен,
Җанын сатып файда алучылар.

Тоталар да Коръән яндыралар,
Утта янамыни тугры иман?!
Бу Җир шары нигә шулкадәрле
Имансызлар белән шыплап тулган.

## Без – татар

Ватан дип ватылдык җирдә,
Ватан дип ярылдык без.
Өзелгән өмет эченнән
Яңадан табылдык без.

Безне үлмәс итә җирдә
Татар дигән атыбыз.
Гөнаһлы дип кыйсагыз да,
Тәмугтан да кайтырбыз.

Кылычлар кынында безнең,
Җәйләүдә атларыбыз.
Бабайлардан килгән нәзер –
Күңелдә антларыбыз.

Кылларыбыз нык әлегә,
Үсә кыз-улларыбыз.
Без – татар,
Безнең милләттән
Алыгыз кулларыгыз.

## Саңгырау тартыклар

Яңгырап чыга кайвакыт
Буш савыттан тавышлар.
Саңгырауга әйләнделәр
Соңгы елда танышлар.

Тарткан саен тартыла бит,
Сузган саен сузыла.
Саңгырауларга ияреп,
Тормыш юлы узыла.

Кемдер болай чарасыздан
Саңгырауга сабышты.
Кемдер, беләм, шул халәттә
Кәнәфигә ябышты.

Яңгырап тора иде бит,
Ялтырап тора иде.
Безнең алларда дошманнар
Калтырап тора иде.

Саңгырауга әйләнгәчтен,
Тарттыра зур тегермән.
Алпавыт абзый боерыгы:
Он ясарга диелгән.

Яңгырап чыга кайвакыт
Буш савыттан тавышлар.
Саңгырауларга әйләнмик,
Таныш түгел танышлар.

***

Үлем белән күзгә-күз –
Эчәр суларың бетмәсә,
Әле бетмәс сөйләр сүз.
Парә-парә булган йөрәк,
Сүнмә, сүнмә, бераз түз.

Язмышка язган сагыш –
Җир бездән туеп тетриме,
Җиргә сыймыймы каргыш?
Кояш чыкканын көтәме,
Калтыранып көнбатыш?

Үлем белән йөзгә-йөз.
Гомерең бетмәгән булса,
Әйдә, тормыш буйлап йөз.
Яз көткән күпме җаннарга
Көтмәгәндә килде көз.

Язмыштан бармы узмыш,
Кайларда сагалап тора
Безне соңгы тукталыш?
Тукта, өзелмә, өметем,
Ишетелә бер тавыш.

***

*Кеше өчен көлмәк ертма, дисең.*
Рәшит Ягъфәров

Яхшымы, яманмы илем,
Илемме бу, түгелме?
Бездән сорап та тормыйча,
Җиргә кайгы түгелде.

Ямалып беткән күңелләр
Гарипләтте йөрәкне.
Мәкергә төренгән дөнья
Ертмас итте күлмәкне.

Кеше өчен борчылмаска
Күрмәскә, ишетмәскә.
Болай да юк үз җылыңны
Дус белән бүлешмәскә.

Болай да суык кышларны
Суыклатып тагын да,
Бераз изгелек калдымы,
Кеше, синең җаныңда?

Калдымы күлмәк ертырлык
Намусы булган батыр?
Вөҗдансыз милләт тамгасын
Йөртәсе ничә гасыр?

Аналар күз яше булып,
Җиргә кайгы түгелде.
Яхшымы, яманмы илем,
Илемме бу, түгелме?

## Кәримнәр, Камиләләр...

Мин сезгә күпме дәшсәм дә,
Йөгереште тик күзләр.
Бер кәлимә сүз әйтмәде
Кәримнәр, Камиләләр.

Сездә бер тамчы гаеп юк,
Газиз асылташларым.
Кемнәр саранланды сезгә
Туган тел, җанашларым.

Йөрәгем әрни нигәдер,
Күңелне тырный яра.
Өзелгән чылбыр арасы
Һаман зураеп бара.

Кайчан өзелде бу чылбыр,
Ник кабат ялганмады?
Упкын үсә, тирәнәя,
Яралар ямалмады.

Минем дә гаеп бар монда,
Синдә дә гаеп, илем.
Кәримнәр һәм Камиләләр
Белмиләр туган телен.

## Бушкуыкларга

Күккә очарга талпына
Ясалма канатлары.
Чабам дип хыялланса да,
Бер урында тик чайкала,
Китми агач атлары.

Җил очырта әйткәннәрен,
Кайтмый кайтавазы да.
Еллар үтә бер-бер артлы,
Ышандырган назы да юк,
Ышандырган язы да.

***

Көн матур, дия алар,
Кояшлы җылы, дия.
Тәрәзсез булгач йортларың,
Кем генә нәрсә дисә дә,
Чынбарлык кебек гүя.

Бүген дә кояшлы, диләр
Бүген дә аяз икән,
Ишекнең аргы ягында
Җәйдән соң гел яз икән.
Тәрәзсез булгач йортларың
Дөньялар аяз икән.

Иртәгә дә болытсыз, ди
Үз иткән безне кояш.
Диварлар нидер пышылдый
Әллә бу яңгыр тавышы,
Әллә болыт арасыннан
Сулкылдап елый кояш.

## Балачак

Тузанга батып та,
Пычракта ятып та,
Пакь булып калган чак.
Авыртудан түгел,
Орышудан куркып,
Балавыз сыккан чак.
Балачак.

Тотмасын дип куркып
Ата каз һәм әтәч,
Чабулап качкан чак.
Иң зәһәр дошманың,
Кычыткан гаскәрен
Таяктан аткан чак.
Балачак.

Тез башы канап та,
Канамый ул диеп,
Елмаеп көлгән чак.
Уйнарга чыгарга
Яңгырның туктавын
Өзелеп көткән чак.
Балачак.

Урындык, мендәрдән
Тырышып-тырышып
Куышлар корган чак.
Әнинең кибеттән
Ни алып кайтасын
Сагалап көткән чак...
Балачак,
Бу – безнең балачак.

## Ястүен көтә мәчетләр

Ястүен көтә мәчетләр,
Ишек ачучыларын.
Ишекне ачып кирәргә
Көчен табучыларын.

Җәннәткә барыр юлларның
Тарая барулары,
Эх тормыш, тормыш туганым.
Мең дә бер сәбәпләр табып,
Еракка агуларым.

Бәхеткә кыска юл эзләп,
Тапталып калган башлар.

Ялгыштан сагышлар туган,
Ә сагыштан – каргышлар.

Җәһәннәм уты телләре
Кул сузым гына ара.
Яндырып ала да җанны,
Кабат суларга сала...

Кояш баткан, ай калыккан.
Казага калды ахшам.
Ястүен көтә мәчетләр
Бүген дә яңабаштан.

***

*Киң күңелле бул эчеңнән,*
*мыскыл ишетсәң, «вак» диген...*
Сәгыйть Сүнчәләй

Әй, күңлем, кальбем,
Җаным,
Тыныч бул.
Вак булма ваклар белән.
Баткакка кереп пычранма
Юылмас таплар белән.

Әй, күңлем, кальбем,
Җаным,
Боекма.
Баш булмасын зарларың.
Залимнәргә ярыйм диеп
Буталмасын ярларың.

Әй, күңлем, кальбем,
Җаным,
Кайгырма.

Сүнмәсен тугры иман.
Мизгеллек нәфес ләззәте
Бормасын туры юлдан.

***

Югалтырлык әйбер булган чакта,
Һәм югалтыр әйбер калмагач,
Шул чакларда куллар кылыч тота,
Сугыш ача хаклык тапмагач.

Шул чакларда кеше гөрзи ала,
Җәясен дә ала, угын да.
Гасыр буе йокымсырап яткан
Сихри бер көч таба рухында.

Ачу катыш рәнҗеш белән бергә
Арысландай күккә ыргыла.
Җанын-тәнен кызганмыйча бара,
Киек-җанвар кебек кырыла.

Шуннан менә җиргә хаклык кайта,
Бераз гына тузан тынганчы.
Җиңү бит ул рәсемнәрдә матур,
Җиңү җиңү бит ул җиңгәнче.

Ә аннары ул бары сүз генә
Хакын хаклау өчен хаксызның.
Ә аннары ул мәңгелек ялкын
Якыннарын җуйган ялгызның.

Ә аннары кайгылар да арта,
Ярлылар да арта шул сүздән.
Күпме нәфрәт, күпме үкенечләр
Күреп була сугыш кичкән күздән.

Җиңү белән сугыш бетми лә ул,
Тик кешеләр бетә җиңү диеп.
Югалтырлык әйберең калмагач,
Сугыш сиңа кылыч суза килеп.

Ә син аны зарыгып көткән кебек,
Артка юл юклыгын аңлагач,
Кабат-кабат кылыч аласың шул,
Бу дөньядан хаклык тапмагач.

Галимҗан
Гыйльманов

# ИБЛИС КОТКЫСЫ

КЫЙССА

**22**

Уразаның беренче көне җомгага туры килде. Бу мөселман дөньясында иң изге фалларның берсе булып санала.

Мәүлет җомга намазына иртәрәк барды. Ерак дип тормады, иң олы мәчетләрнең берсен сайлады. Бу Аллаһ йортын ул күптән үз итте, вакыты иркенрәк булса, иң элек шушында килергә тырыша. Монда иркенрәк кебек, нурлырак, кешеләр итагатьлерәк, иманлырак. Мәчет хәзрәтләре дә таный, Мәүлет белән кул биреп күрешәләр. Кайчакта Шәмси карт белән бергә баралар. Күчеп йөрисе юк – бер автобуска утырасың да барып җитәсең. Бу тәкъва карт әлеге мәчеткә ешрак та йөри, хәзрәтләр аны бик хөрмәт итәләр, ди, берничә тапкыр азан әйтергә дә дәшкәннәр.

Иртәрәк баруының сәбәбе аңлашыла – менә инде ике атна буе Мәүлет җанына тынгылык таба алмый йөди. Максаты: җанны бимазалап торган сорауларга җавап табу, күңелне кинәндерерлек догалар, дәлилләр ишетү. Бәлки, башта ук килергә кирәк булгандыр? Иң элек уңайсызланып бармады, аннары, көләрләр дип уйлады. «Үземә кушылган, үзем хәл итәм», дигән чаклары да булды. Хәлнең катлаулана, сорауларның күбәя баруын тойса да, имам хәзрәтләргә киңәшкә кермәде Мәүлет. Күрәсең, менә хәзер вакыты җиткәндер. Төштәге Хозыр Ильяс та аермачык әйтте бит: «Синең язмышыңа зур вазифа – Иблис ләгыйньне фаш итү бурычы йөкләнде, сиңа хәзер үк рухани вазифаларга якынаерга кирәк», – диде.

Түр бүлмәдә мәчетнең баш имамы үзе генә түгел иде. Түгәрәк өстәл артында өч кеше утыра. Баш имам Мөнир хәзрәт үзе, аның уң ягында әле күптән түгел генә сайлап куелган мөфти хәзрәтләре, аның янәшәсендә – мөфтинең шәригать буенча урынбасары Әюп хәзрәт. Нәрсә турындадыр кызып-кызып сөйләшәләр иде булса кирәк, Мәүлеткә кыен булып китте. Шартын китереп исәнләште дә, шундук борылып, ишек тоткасына үрелде. Авыз эченнән сүз боткасы да пешереп алды:

– Гафу итегез, борчыдым бугай.

– Юк-юк, борчымадың, түргә үт, Мәүлет туган. Әссәламәгаләйкүм вә рахматуллаһи вә бәрәкәтүһ! Бик вакытлы килдең. Нәкъ менә сине көтеп торабыз. Шәмси абзый кереп чыккан иде, сине килер кебек сөйләде. Бу

*Ахыры. Башы 8, 9 нчы саннарда.*

хакта ишетеп, мөфти хәзрәт тә килде. Шәригать белгече ни әйтер – аны да тыңлап карарбыз. Рәхим ит, утыр яныбызга, Мәүлет туган. Әле җомга вәгазенә бер сәгать вакыт бар, сөйләшеп, киңәшләшеп алыйк.

Мөфти, учларын җәеп, кулларын алга сузды:

– Дога кылыйк, җәмәгать, бик мөһим сүз башланырга тора, дога белән башлыйк, ниятләребезне Аллаһы Тәгалә ихтыярына тапшырып, аның пәйгамбәрләренә сыеныйк, Изге Китабыбыз булган Коръәнгә таяныйк, җәмәгать.

Мәүлет бу кадәресен үк көтмәгән иде. Мөфти хәзрәт үзе килгән бит! Киңәшмә җыеп, көтеп утырган! Шәмси картны әйт инде, яшертен генә эш йөртеп ята икән бит. Яшерен агент диярсең. Мәүлет кебек гади генә мунча кешесенә бу кадәр игътибар булыр дип кем әйтер?! Димәк, эшләр үтә дә мөһим, үтә дә җаваплы. Ай-һай, зурга киткән, ахры, эшләр!

Мәүлет үзенең дога гаменнән китеп барганын, ниндидер борчулы уйлар әсирлегенә төшә барганын аңлап-чамалап алды, мөфти әйткән доганы эченнән генә сүзгә-сүз кабатлап барырга тырышты. Ләкин кабатлап бара алмыйча, ялгышты, буталды, тагын шул баш катыргыч уйларга әйләнеп кайтты: «Бик җитди язмышка дучар булды лабаса ул. Ниләр көтә алда, ниләр көтә?..» Иблис коткысы белән бәйле шаукым аның үзен дә аптыратты инде, исәнгерәтте, бер миңгерәү мәхлукка, зомбига әверелдерде, ахры. Ярый ла бу мөхтәрәм хәзрәтләр аның болгавыр тормышын, хикмәтле язмышын туры юлга, хак юлга чыгарырга булышса.

– Сиңа бик тә хикмәтле төш кергән икән, Мәүлет диндәшебез. Сүз дә юк, андый төшнең һәрберебезгә кергән булуы бар. Шулай булгандыр да. Тик менә син генә аны күңелеңә якын алгансың, тормышыңны, язмышыңны шушы авыр мәсьәләне чишүгә, хәл итүгә көйләгәнсең. Бөтен хикмәт синдә булып чыга, Мәүлет туганыбыз. Аллаһы Тәгаләбез сине сайлаган, сиңа таянган булып чыга. Ә бит Иблис хакында андый хәбәрләр дөньялар кискен үзгәргән вакытта, иман, хакыйкать куркыныч астында калган чакта килә башлый. Кешеләр бер-берсен күралмый башлаган мәлдә, илләр бер-берсенә сугыш ачарга җыенган вакытта, бозыклык, әхлаксызлык тантана иткән тарихи дәвердә төшә безгә Иблис коткысы, шайтан шаукымы. «Алла сакласын» диярге генә кала.

– Шулайрак булды шул, хәзрәт. Бәлки, күңелгә, уйга, язмышка бу кадәр якын алырга да ярамагандыр бу төшне. Алдым шул. Шушы ике атнада гыйбрәтле дә, хикмәтле дә тормыш кичердем. Күп нәрсә белдем, күп нәрсә хакында белмәвемне, инде белә дә алмаячагымны аңладым. Иблис тарихына кагылмаска кирәк булгандыр, бәлки. Менә сез дә борчылгансыз.

– Мәүлет туганым, ул тарихка кагылмый мөмкин түгел. Борчылмый мөмкин түгел. Без, дин әһелләре, бу тарих белән көн саен, сәгать саен шөгыльләнәбез, догаларыбызда, гыйбадәтләребездә, вәгазьләребездә дә төп сүзебез шул хакта. Иблис һәм аның шайтаннары коткысы белән нәфес шаукымы – кешеләрне юлдан яздыручы төп сәбәпләр. Ләкин синең белән булган очрак тагын да мөһимрәк: син ул мәлгуньне табып, аны фаш итәргә тиеш буласың. Ә бу инде тагын да җитдирәк.

– Ләкин таба алмадым бит. Тапкан кебек буласың. Ә ул булмый, бөтенләй башка төрле гыйбрәткә очрыйсың. Ул әллә шулай юри алдап, буташтырып йөртә инде.

– Әлбәттә, шулай! Ләкин эзләү – үзе үк изге гамәл. Кешелек өчен, кеше

күңеле өчен, күңелләрнең чисталыгы өчен көрәш – үзе үк саваплы эш, Аллаһы тарафыннан мактала торган гамәл. Аллага шөкер, әле синең кебек мөселманнарыбыз бар.

– Мин бит диндар да, тәкъва да түгел. Догаларда да, гыйбадәтләрдә дә еш ялгышам, хәзрәт.

– Изге гамәл кылу өчен, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә һәм хөрмәтенә ирешү өчен тәкъва яисә рухани булу мәҗбүри түгел. Изге ниятең һәм изге гамәлләрең мөһимрәк. Әлбәттә, иман шартларын да үтәргә кирәк. Син бит аларны үтисең, шулаймы?

– Үтим, хәзрәт, үтим. Ләкин аларның төгәллеген бер Алла гына белә. Аннары Шәмси бабай беләдер, ул – минем остазым. Белмәгәнне аңардан сораштырам.

– Бүгенге көндә сине иң борчыганы нәрсә? Шул хакта сөйләшик әле. Мәсәлән, шул ук Иблис тарихында сине иң борчыган сорау нинди?

– Кемдер әйткән бит: «Мәсьәләне ачыклыйсың килсә, сәбәбен тап!» дигән. Минә шул: Газазил-Иблис белән Адәм галәйһис-сәлам арасындагы низагның сәбәбе нәрсәдә соң? Шуңа һаман төшенеп җитә алмыйм. Шуңа төшенсәм, Иблискә тизрәк барып җитеп булыр иде кебек.

Мөфти хәзрәт янында утырган хәзрәтләргә сынаулы караш ташлап алды. Аннары йомшак кына тамак кырып куйганнан соң, ниндидер шәкерт белән сөйләшкән кебек гади генә сүзләр белән, вәгазь телендә әңгәмәгә кереште:

– Мәүлет туганым, син дөрес аңлап алгансың: Җир тарихы, кешелек тарихы, кеше булып, мөселман булып яшәү өчен көрәш тарихы шушы Иблис белән бәйле гыйбрәтле хәлләргә барып тоташа. Һәм бу тарихны, бу хәлләрне Мөхәммәд галәйһис-сәлам теле белән Раббыбыз үзе безгә хәбәр итә. Иблис белән Адәм арасындагы киеренкелекнең кайчан, ничек килеп чыгуы – бер караганда, мавыктыргыч, икенче караганда, артык тәфсилләргә дә ярамаган тарих. Чөнки һәр илаһи тарихта без белмәгән, белә дә алмаган, бер Аллабызга гына мәгълүм әйберләр бар. Иблис белән бәйле тарих та – шундыйлардан. Ләкин төп нәрсә бик яхшы аңлашыла. Адәм атабызның җиргә иңдерелүенә иң элек Иблис коткысы сәбәпче.

– Анысын беләм, чамалыйм, хәзрәт. Тик минә ни өчен Иблис Адәм атабызга каныга соң, нигә юл куймый? Һәм бу әшәкелек ни өчен Җирдә дә дәвам итә? Моның өчен бик җитди сәбәп кирәк бит. Һәм моны тәкәбберлек белән генә аңлатып буламы?

Мөфти хәзрәт тел шартлатып куйды:

– Бу кадәр гыйлемең сокландыра, Мәүлет туганым. Мондый сорауларны гомер буе имам булып торган хәзрәтләр дә биреп бетерә алмый. Ә инде синең соравыңа җавап итеп, Әюп хәзрәт сиңа «Пәрдә» сүрәсеннән аятьләр укыр. Күреп торам: Коръәннең икенче сүрәсендәге Иблис тарихын син инде укыгансың, ә менә җиденче сүрәдәге аятьләргә барып җитә алмагансың. Йәле, Әюп хәзрәт, укып таныштыр бу гыйлем иясен шул аятьләр белән. – Мөфти шунда ук кабат Мәүлеткә таба борылды. – Күреп торасың, без әзерләнеп килдек. Белә идек: син бу илаһи тарих хакында җентекләп сорашырга тиеш.

Тиешле «Бисмилла» кәлимәсен әйтеп куйгач, Әюп хәзрәт, кулындагы тәфсир китабының кирәкле битен ачып, салмак кына укый башлады:

«Аллаһы Тәгаләбез инсаннарга мөрәҗәгать итеп әйтә: «Тәхкыйк Без

сезне Җир өстенә урнаштырдык, ничә тапкыр файдалану куәтен бирдек вә Җир өстендә тереклек итүегез өчен кирәк барлык нәрсәләрне бар иттек, ләкин шуңа да карамастан, бик аз вакытта шөкер итәсез.

Тәхкыйк төп атагыз булган Адәмне балчыктан халык кылдык, соңыннан күркәм сурәтле иттек, аннан соң фәрештәләргә әйттек: «Адәмгә карап сәҗдә кылыгыз!» – дидек. Фәрештәләр Адәмгә карап сәҗдә кылдылар, мәгәр Иблис сәҗдә кылмады, ул сәҗдә кылучылар арасында юк иде».

Аллаһы Тәгалә әйтте: «И Иблис! Мин сиңа Адәмгә сәҗдә кылырга әмер иткәч, сине сәҗдә кылудан ни нәрсә тыйды?» – диде. Иблис әйтте: «Мин аңардан артыграк, чөнки мине уттан яраттың, әмма Адәмне балчыктан яраттың», – диде.

Аллаһ әйтте: «Алай булса, җәннәттән чык! – диде. – Аллаһының әмеренә карышып, сиңа җәннәттә тәкәбберләнү һич дөрес булмас, чык аннан, хур вә рисвайлар җөмләсеннән икәнсең».

Иблис әйтте: «И Раббым, мине үтермә, кубарылачак көнгә кадәр дөньяда яшәргә миңа ирек бир», – диде.

Аллаһ әйтте: «Әлбәттә, мәгълүм вакыткача, ягъни кыяматкәчә, рөхсәт бирелә», – диде.

Иблис әйтте: «Адәмне өстен куеп, мине аздырганың өчен, әлбәттә, мин дә, бәндәләреңне алдап аздыру өчен Синең туры юлың өстендә утырачакмын, – диде. – Янә аларны аздырмак өчен алларыннан, артларыннан һәм уңнарыннан вә сулларыннан килермен. Шуннан соң аларның күбесен Үзеңә шөкер итүчеләр арасыннан тапмассың».

Аллаһы Тәгалә әйтте: «Бозылган вә җәннәттән сөрелгән хәлеңдә чык җәннәттән! Кешеләрнең сиңа ияргәннәре белән бергә һәммәгезне җәһәннәмгә салып тутырачакмын!» – диде.

Аллаһ тагын әйтте: «И Адәм, үзең вә хатының Һәуа җәннәттә торыгыз һәм теләгән урыннан ашагыз, әмма ошбу агачка якын бармагыз, әгәр якын барсагыз, залимнәрдән булырсыз», – диде.

Аларга Шайтан (Иблис) вәсвәсә кылды, Адәм белән Һәуаның күңеленә шик кертте. Аларның ябык (капланган) гаүрәтләрен ачмак өчен болай диде: «Аллаһ сезнең фәрештә булуыгызны һәм җәннәттә мәңге калуыгызны теләмәгәне өчен сезне ошбу агачтан тыйды», – диде.

Иблис тагын ант итеп әйтте: «Тәхкыйк мин сезгә яхшылык кына телим!» – диде.

Иблис аларны алдалап, агач янына алып килде. Адәм белән Һәуа агачтан үрелеп ашадылар, гаурәтләре ачылды вә алар шул гаурәт урыннарын җәннәт яфраклары белән капларга ашыктылар. Аларга Раббылары: «Әйә! Мин сезне шушы агачтан тыймадыммыни?! Вә: «Тәхкыйк Шайтан (Иблис) сезгә ачык дошман, сакланыгыз!» – дип әйтмәдеммени?!» – дип кычкырды.

Адәм вә Һәуа әйттеләр: «И Раббыбыз, үзебезгә золым кылдык, әгәр безне ярлыкамасаң, һәм рәхимлек кылмасаң, әлбәттә, бәхетсезләрдән булырбыз», – диделәр.

Аллаһ әйтте: « И Адәм белән Иблис! Бер-берегезгә дошман булганыгыз хәлдә Җиргә иңегез! Сезгә торачак урын һәм әҗәлегезгәчә файдаланылачак мөмкинлекләр Җирдә!» – диде.

Аллаһ тагын әйтте: «Җирдә тереклек итәрсез вә Җирдә үләрсез һәм Җирдән чыгарылырсыз», – диде.

Тагын әйтте: «И Адәм балалары! Без сезгә киемнәр яраттык, ул киемнәр гаурәтләрегезне каплар: янә мал яраттык һәм дә тәкъвалык киемен бирдек; ул тәкъвалык – саклану киеме – хәерледер; ошбу зекер ителгән нәрсәләр – Аллаһы Тәгаләнең галәмәтләре – кешеләргә вәгазь булып ирешер.

И Адәм балалары! Ата-анагызны җәннәттән чыгарган кеби, Шайтан (Иблис) сезне фетнәгә салмасын; ул бит аларның киемнәрен салдырып, гаурәтләрен үзләренә күрсәтер өчен, аларны алдады. Тәхкыйк Шайтан (Иблис) һәм, сез аларны күрмәсәгез дә, аның гаскәре сезне күрә; менә шул шайтаннарны кешеләр арасындагы ышанмаучыларга дус кылдык».

Әюп хәзрәт, төртелеп, тукталып калды, моннан соң килә торган аятьләргә күз йөгертеп алды, ләкин дәвам итүне кирәк тапмады, кулындагы китапны сак кына ябып куйды.

Бүлмәдә сәер тынлык урнашты. Гүя бу тынлыкны бозмау буенча ниндидер ярыш, бәйге игълан ителгән иде. Бераздан өчәүләп мөфти хәзрәткә дәррәү күтәрелеп бактылар.

Мөфти хәзрәт вәкарь белән генә сүз башлады:

– Бу илаһи тарихны гади генә дисәк, нык ялгышырбыз, җәмәгать. Адәм атабыз белән Һәуа анабызның уртак тормышлары авыр башлана, сүз дә юк. Аллаһы Тәгаләнең мәрхәмәте киң булуына сокланырга гына кала. Ул хәтта адәм балаларын һәм фәрештә кавемен Җиргә сөрүгә сәбәпче булган Иблис ләгыйньнең гомерен дә саклап кала, ул гына да түгел, кыямәт көнне бөтен бәндәләрнең җаннары алынып беткәч кенә, аның гомерен иң ахырдан кыячагын игълан итә. Әлбәттә, бу тарихта. Иблиснең Җиргә сөрелгәнчегә кадәрге, Газазил фәрештә – Аллаһы Тәгаләнең иң сөекле фәрештәсе чагындагы гомере бик әһәмиятле. Фәрештәләргә җәннәттә чакта ук өстенлек бирелгәнлеге аңлашыла: алар уттан яратылганнар, нурдан коелганнар, ә адәми затлар балчыктан яратылган. Әлбәттә, балчыктан яратылганда, Адәмнең тәненә сәмумнең утлы кызуы да бераз ягылып кала, шул ут аны шайтаннар коткысына бирелергә этәрә дә инде. Шуңа күрә Газазилнең – Иблис, ә фәрештә җеннәренең шайтан булып китүендә иң элек Адәм үзе гаепле. Аның табигатенә, холкына алдан ук алдану мөмкинлеге салынган була. Һәм бу алданудан, бозылудан, золымга тарудан аны тәкъва күлмәге, рухи, имани ныклыгы гына саклап калачак. Аллаһы Тәгалә үз бәндәләрен шулкадәр каты итеп сыный, ул хәтта аларны үзләренә дошман буларак, Җиргә иңдерелгән шайтаннарны күрү мөмкинлегеннән мәхрүм итә, ә Иблис өчен һәм аның гаскәре, иярченнәре, шайтаннар өчен бу мөмкинлекне калдыра. Менә шунда иманыңны саклап калып кара син!

– Димәк, хәзрәт, Адәм – Иблис тарихында иң элек Адәм үзе гаепле, ягъни без гаепле? Без бик тиз табигатьнең җенси хис-шаукымына бирелә без, шайтан коткысына эләгеп, нәфескә бирелеп, шунда ук тыелган җимешкә үреләбез – үзебезнең гаурәтләребезне ачып ташлап, бозыклык гамендә яши башлыйбыз, шулаймы? – Мәүлет үзе аңлаганча фикер йөртергә тырышты, ләкин фикеренең очына чыга алмыйча, мөфти хәзрәттән кайтарып сорарга мәҗбүр булды: – Алайса... без үзебез гаепле инде? Нигә «Иблис», «Иблис» дип, авыз суы корытабыз соң?! Аллаһ үзе шуңа юл куйгач...

Мөфти тыныч кына тыңлап торды да үрелеп, Әюп хәзрәт кулыннан тәфсир китабын алды.

– Мәүлет туганым, Әюп хәзрәт тагын берничә аять белән дәвам итәргә тиеш иде. Аларның мәгънәләрен үзем укыйм. Менә ул:

«Берәр вакыт фәхеш эшләр кылсалар: «Ата-бабаларыбызның бу эшне эшләгәннәрен күрдек һәм Аллаһ бу эшләрне кылырга әмер кылды», – диләр. Әйт аларга: «Аллаһ андый фәхеш эшләр эшләргә әмер кылмады һәм кылмаячак та, белмәгәнегезне Аллаһыга ифтира кылырга ничек оялмыйсыз?!» – дип...

Шулай ук әйт: «Раббым һәр囲 эштә гадел булырга өндәп әмер бирде вә һәр мәсҗидтә йөзләрегезне кыйблага юнәлдерегез вә динне Аллаһ ризалыгы өчен генә ихлас тотып, Аңа гына гыйбадәт кылыгыз! Әүвәлдә юктан бар булганыгыз кеби, үлгәннән соң терелеп, бар булырсыз», – дип.

Аллаһы Тәгалә бер фирканы туры юлга күндерде вә бер фирканы, рисвай итеп, аларга заләләт сабит булды, чөнки алар Аллаһыдан йөз чөереп, башка мәхлукларны, хайваннарны дус итеп алдылар, шулай булса да алар: «Без туры юлга күнгән кешеләр», – дип зан итәләр...

И Адәм балалары! Һәр сәҗдә кыла торган урында гаурәтләрегезне каплар өчен зиннәтле киемнәрегезне алып киегез, ашагыз вә эчегез, ләкин исраф кылмагыз, тәхкыйк Аллаһ исраф итүчеләрне сөйми.

Әйт: «Аллаһы Тәгалә бәндәләренә биргән зиннәтле киемнәрне кем харам кылды вә ризыктан пакь, ләззәтле булганнарын кем харам кылды?» Әйт: «Ул зиннәтле киемнәр вә хуш булган ризыклар дөньяда вакытта иман китергән мөэминнәргәдер, ә кыямәт көнендә кайбер мөэминнәргә, кяферләргә мәхрүмдер». Әнә шулай аятьләребезне Хакны белгән кешеләр өчен ачык аңлатабыз...»

Менә шул, Мәүлет туганым, Аллаһ сыный безне, һәрдаим, һәр гамәлдә сыный. Иблис коткысы да – иң элек сынау, кешелек өчен, иман китергән мөэмин-мөселманнар өчен авыр сынау. Бу хакта тәфсир-аңлатманы Коръәннән табарга мөмкин. «Маидә» (Ашъяулык) сүрәсенең 48нче аятендә Аллаһы Тәгалә Мөхәммәд галәйһис-сәлам гә болай ди, игътибар белән тыңла:

«...Әгәр Раббыңнан килгән Коръәндәге гадел хөкемнәрне артыңа куеп, Коръән хөкемнәрен белмәгән надан кешеләргә, аларның батыл (мәҗүси) гадәтләренә иярә күрмәгез! Сезләрдән һәрбер җәмәгать өчен шәригать төзедек һәм диндә ачык юллар күрсәттек. Әгәр Аллаһ теләгән булса, әлбәттә, бөтен дөнья кешеләрен бер диндә, бер юлда һәммәсен бер җәмәгать кылыр иде, ләкин сезгә биргән нигъмәтләре һәм иңдергән Коръән хөкемнәре белән Аллаһ сезне сынап карарга теләде. Шулай булгач, гөнаһлардан саклануда алданмагыз һәм савапны кәсеп итүдә ярышыгыз, һәм ярышта алга чыгыгыз! Кайта торган җаегыз Аллаһ хозурында бит, анда Аллаһ сезгә дөньяда вакытларыгызда хөкемнәренә ихтилаф кылуыгыз турында хәбәр бирер. Ягъни ачыклар: Коръән хөкемнәрен үтәргә тырыштыгызмы? Әллә Шайтан (Иблис) гамәле булган бидгать гамәлләрне үтәргә тырыштыгызмы? Хөкем каты булыр.» Һәм, ниһаять, «Хатыннар» сүрәсеннән бер мисал. «Шайтанга ияргән кешеләрнең урыны – җәһәннәм, алар аннан котылырга һич юл тапмаслар», – диелгән бу сүрәдә.

Бүлмәдә тагын тынлык урнашты.

Мәүлет шунда күбрәк белгән саен күбрәк аңламый барганына төшенде. Бу ике атнада ду кубып, Иблис эзләп йөрү кирәк тә булмаган лабаса! Сынау

артында һәрвакыт Аллаһы Тәгалә игелеге, аның шәфкате-миһербанлыгы була икән бит! Сынау, димәк ки, сынау гына, ә бернинди афәт тә, фетнә дә түгел. Аннары, ничек кенә яшәсәң дә, хөкем бары тик Кыямәт көнендә генә төшәчәк, шулай булып чыга. Ә анда кем бар да, кем юк.

– Син хаклы түгел, Мәүлет туган. Ахырзаманнан, Кыямәттән ягъни Аллаһы Тәгалә каршына барудан куркырга, дөресрәге, Аллаһ каршына баруга әзерләнергә тиеш булсак та, без бүген иң элек үзебез өчен, гаиләләребез, балаларыбыз, оныкларыбыз өчен яшибез. Иманлы яисә имансыз булуыбыздан да тора аларның язмышы. Мин шулай уйлыйм.

Мәүлет шаккатты: мөфти хәзрәт аның уйларын укып бара икән бит. Ләкин сер бирмәде. Күңеленә авыр гамь булып төшкән шул бер сорауны бирде:

– Шулай да әйтегез әле, мөхтәрәм хәзрәтләр: Шайтан, Иблис бармы соң ул? Булса, кайда ул? Миңа бит шул хакта әмер килгән иде. Төштәге Хозыр-Ильяс, аны табып, фашларга кушкан иде. Сезне тыңлагач, бөтенләй аптырадым әле: андый ук куркыныч түгел кебек тоела башлады бу Иблис дигәннәре. Иң мөһиме ул да түгел әле. Иң мөһиме – сынау булып чыга. Ә бит, белүемчә, кешеләргә килгән авырлык – сынау гына түгел, ә кылган гөнаһлары өчен җәза да. Менә шуннан сорау туа инде: Иблис җәза бупарак килә аламы?

– Юктыр. – Әңгәмәгә мөфтинең шәригать буенча урынбасары кушылып китте. – Җәза алу өчен үзең шайтан кылган галәмәтләрне кылырга, золымнар эшләргә, Иблис коткысына бирелеп, башкаларга яшәү авырлыгы яисә кара кайгы китерергә кирәктер. Җәза өчен гөнаһ кына җитми, җәза алу өчен имани һәм гамәли җинаять эшләү зарур, җәмәгать.

Башкалар аның бу сүзләрен хупламадылар да, кире дә какмадылар, баш чайкап кына утырдылар.

Шунда әңгәмәгә мәчетнең баш имамы кушылып китте һәм сүзне бик тиз генә төгәлләп тә куйды:

– Чынлыкта, җәмәгать, Иблис үзе түгел, аның иярченнәре – кяферләр, мөнафыйклар, мөшрикләр, мөртәтләр, фәсыйклар куркынычрак, чөнки аларны тиз генә танып булмаска мөмкин. Килешәсезме? Безнең бөтен бурыч, вазифа: шул кяферләрне һәм ялган мөселманнарны табып фашлау, аларны мөмкин кадәр иманга кайтарырга тырышу. Аларын тапсак, алар янында койрыгын болгап йөргән шайтаннарны, Иблиснең үзен бик тиз чамалап алырбыз. Шулаймы, хәзрәтләр? Җомга намазына керергә вакыт җитте. Кузгалыйк. Вәгазьне үзегез сөйлисезме, мөфти хәзрәт?

– Үзем сөйләрмен, мәүзугы да әзер. Иблис коткысы турында күптән сүз катканыбыз юк иде. Ә кирәк, бик кирәк. Аллаһы Тәгалә ихтыяры һәм ярдәме белән, шулай ук Мәүлет кардәшебезнең җан тынгысызлыгы сәбәпле, менә бүген җай да чыгып тора.

**23**

Мөфти хәзрәтләрнең вәгазен Мәүлет кызыксынып тыңлады. Аеруча ике нәрсә аның күңеленә нык тәэсир итте. Беренчесе: Иблис, кеше тормышына, кеше язмышына һәм кеше күңеленә йогынты ясаганда, Адәм бабабыз табигатенә башта ук салынган ике сыйфатка таяна – минминлеккә (эгоизмга) һәм нәфес шаукымына. Иблис дигәннәре, кешедәге менә шул сыйфатларны белеп-чамалап ала да үзенең кара эшенә керешә,

имеш: алдый-ялганлый башлый, кызыктыра, хэйләләп, мактаган булып кылана, бетмәс-төкәнмәс ләззәт, байлык, ризык-нигъмәтләр вәгъдә итә. Икенчедән, зиһене сай, ярлы, күңеле һәм рухы йомшак яисә зәгыйфь кеше Иблис ихтыярына тиз бирешә. Андыйларны шайтани затлар тиз күреп алалар, чөнки бу бәндәләр, гадәттә, томан исә рәшә эчендә гомер кичерәләр, алардан бертуктаусыз илаһи көч, энергия сарыф ителеп, тышка чыгып тора. Шул ачык каналлар аша кереп, аларны кулга төшерү бик җиңел, ди.

Мөфти, вәгазен бүлеп, кайсыдыр гарәп илендә булган Ислам дине галимнәренең халыкара конгрессы, аның нәтиҗәләре хакында сөйләп алды. Соңгы мәгълүматларга караганда, соңгы биш ел эчендә саф мөэмин-мөселманнар арасында югалтулар катастрофик дәрәҗәдә күп икән. Иблис бертуктаусыз чүпләп, үз ягына аударып тора икән мөэмин-мөселман бәндәләрне. Бу, иң элек, дөньяда барган үзара сугышлар, кан коешлар белән, шулай ук соңгы елларда көчәя төшкән фәкыйрьлек, мохтаҗлык һәм әхлаксызлык белән бәйле, ди. Гаиләләрнең кыска гомерле булуы, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең алыш-бирешкә корылуы да Иблис тегермәненә су коя. Иблисне фаш итәчәк кешеләр дә билгеләнгән инде. Алар үзләре дә моны белә.

(Боларны ишеткәч, Мәүлет үзалдына елмаеп куйды. Як-ягына каранды. Ләкин кешеләрнең аңарда кайгылары юк иде. Барысы да йотлыгып, мөфти хәзрәтләрен тыңлый.)

Бөтен кыенлык шунда: Иблис мәлгунь ерак атабыз Адәмнән, димәк ки, аның балаларыннан, оныкларыннан күп яклары белән өстен. Әйтик, кешеләрне күрсә дә, ул үзе күренми, ә манипуляция өчен бу бик җайлы, ул шулай ук көчле ышандыру шаукымына ия, җитмәсә, ялкынлы трибун-оратор да, күңеленә еландай кереп оялый торган көчле психолог та. Һәм ул Адәм галәйһис-сәлам балалары каршына төрле образ-сурәтләргә кереп тә килә ала.

Кеше күзенә күренмичә яши торган җеннәр дә бар, әлбәттә. Алар арасында кешеләр яклы булган, кешеләргә миһербанлы җеннәр күбрәк тә әле. Шайтан армиясен фашлаганда, бу җеннәр ярдәмгә килә алмыймыни?! Ләкин Иблис коткысына каршы торган мәлендә бәндәчелек, шушы изге, ак җеннәргә генә ышанып, аларга гына таяна алмый, чөнки бу җеннәр кешенең табигате, холкы һәм язмышы өчен тулысынча җавап бирә алмыйлар. Ни өченме? Чөнки шулай куелган: алар һич кенә дә Аллаһы Тәгалә өлешенә керергә тиеш түгелләр. Аннары, аларның үз мәшәкатьләре дә җитәрлек. Чөнки җеннәрнең үз шайтаннары бар. Һәм алар бертуктаусыз каршылыкта, киеренкелектә яшиләр. Еш кына бу җеннәрдә кешеләр кайгысы да булмый.

Ә менә адәми шайтаннар белән җенле шайтаннар берләшеп алсалармы! Пәйгамбәрләр вакытында ук алар, берләшеп, кешеләргә хәтәр золымнар китерәләр. Бу хакта «Терлек» сүрәсендә аермачык әйтелә. Мәүлет, вәгазь тыңлый-тыңлый, җен шайтаннары, адәм шайтаннары хакындагы аятьләрне исенә төшерергә тырышты. Ничек диелә әле? Әһә... «Коръән белән гамәл кылучыларның дошманнары булган кеби, әүвәлге пәйгамбәрләрнең дә яки аларның өммәтләренең дә дошманнары булды. Без (Аллаһ) аларга җени һәм адәми шайтаннарны дошман кылдык, ул шайтаннар алдана торган зарарлы сүзләрне файдаланып, бер-берсен вәсвәсә кылырлар. Әгәр Раббың, җени вә

адәми шайтаннарның вәсвәсә кылмауларын һәм кешеләрне аздырмауларын теләсә иде, әлбәттә, вәсвәсә вә аздырмас иделәр, ул шайтаннардан һәм аларның Аллаһка ифтира кылган ялган сүзләреннән кисел! Җени вә адәми шайтаннар, ахирәт көненә ышанмаган кешеләрнең күңелләрен үзләре ягына аудару өчен аларга төрле ялган сүзләрне вәсвәсә кылырлар, аларның бу эшләре башка кешеләрнең дә үзләре кебек үк шайтан булуларын теләгәннәре өчен...»

Мәүлет мөфти хәзрәт вәгазеннән тагын шуны аңлап калды: тормышны, яшәешне, кешене һәм аның әхлагын, яшәү рәвешен үзгәртергә, яхшыртырга була, әмма бер мәлдә төрле кыяфәткә кереп яши алган, әле күренеп, әле күренмичә кешене дивана итә торган Иблисне җиңү мөмкин түгел, ул кешеләр, бәндәләр белән янәшә Кыямәт көненә кадәр яшәячәк һәм иң соңгы булып кубарылачак, ягъни Аллаһ каршына басачак...

Җомга намазы һәрвакыттагыча тантаналы төстә, бәйрәмчә узды. Мондый көнне намаз ияләре затлырак киенгән булалар, йөзләре дә яктырак, нурлырак кебек. Алар бу көнне итагатьлерәк тә: шундук урын бирәләр, терсәкләре тиеп китсә дә, баш иеп, түбәнчелек белән гафу үтенәләр, дога пышылдыйлар. Шулай да, Мәүлет өчен бүгенге намаз гадәти булмады. Бәйрәмчә дә булмады. Нидер (хисме, тойгымы, уймы?) аның күңелен шомландырып, бимазалап торган кебек иде. Беренче рәкәгатьтән соң аеруча йөрәге ярсынды. Шундый тойгы: кемнеңдер үткен карашы аның әнә шул йөрәген каезлапмы-каезлый, чукыпмы-чукый иде.

Әмма намазда күңелне догадан аерып алырга ярамый. Чит-ят карашларга баш борырга, күңел иләсләндереп, төрле хиссияткә бирелергә тиеш түгел мөселман кешесе.

Мәүлетне икенче рәкәгать башындагы догалар коткарды. Мөфти хәзрәт артыннан ул бу юлы өч дога пышылдады һәм, сәҗдәгә киткәндә, баягы бимаза хакында онытып өлгергән иде.

Мәүлет мәчеттән каршылыклы хисләр белән чыкты. Бу араларда күңеленә җыелган төрледән-төрле уй-фикерләрнең, хис-тойгыларның бик күбесен югалтып, шактый бушанып, җиңеләеп чыкты ул. Шул ук вакытта катгый гына бер карарга да килде: моннан соң Иблис артыннан кумаска, дөнья бетереп эзләмәскә, бу очракта Иблис аны үзе килеп табачак. Мөгаен, шулай дөресрәк булыр. Ә хәзер дингә керешергә, мунчада эшләп йөргән килеш мәдрәсәгә укырга керергә, аннары, Аллаһы Тәгалә насыйп итеп, руханилыкка чыгарга.

Урамда аны Шәмси карт көтеп тора иде. Күрәсең, ул арткырак рәтләрдә урнашкан булгандыр: бик тиз ак киенеп алган. Кәефе ярыйсы күренә, Мәүлетне һәрвакыт көр тавыш белән ерактан ук эндәшеп каршы алды:

– Нихәл, Мәүлет балакай? Күңелең тынычланып, урынына утырып җиттеме? Хәзрәтләр белән эчке бүлмәдән чыкканда, бик акыллы, зиһенле кешегә охшап тора идең. Узып киткәндә, мине дә күрерлек түгел идең хәтта.

– Ай, ачуланма инде, Шәмси бабай. Чынлап та, зиһеннең бик каты чуалган чагы булгандыр. Кичерә күр, зинһар.

– Юк-юк, болай гына әйтүем. Хәзрәтләр белән очрашып сөйләшүең кирәк иде анысы.

– Бу очрашуны оештыруда синең дә өлеш булды бугай, Шәмси бабай?

– Булды, нишләп булмасын?! Соңгы көннәрдә йөзеңә карарлык түгел иде бит. Сине борчыган сорауларга нинди дер ачыклык кертсә дә, хәзрәтләр генә

кертә ала иде. Шуңа күрә дә, мәчет әһелләре белән килештереп, мөфтинең үзенә үк хәбәр иттердем. Иң кызыгы, Иблиснең кешеләргә кабат якынаюы хакында алар белә булып чыкты.

– Ярый, Шәмси бабай, булган хәл булган инде. Әйдә, кайтабызмы? Моннан соң ныклап уйларга туры килер инде. Хәзрәтләр белән сөйләшкәннән соң, мин ниндидер бүтән бер дөнья ачкан кебек булдым. Таныш түгел бүлмәгә барып керәсең бит, нәкъ шулай булды. – Бераз уйланып торганнан соң, Мәүлет авыр сулагандай итте дә өстәде: – Киләчәктә миңа да хәзрәтләр арасына керергә туры килер, мөгаен.

– Бик хуп, Мәүлет балам. Белгәнеңне миңа да өйрәтеп торырсың. Миңа эләкмәде инде ул уку дигәннәре. Их, эләкмәде.

Урамга чыктылар. Ишек төбендәге текә баскычтан төшеп, урам капкасына юнәлделәр. Шунда Мәүлеткә әллә нәрсә булды. Ул, үзе дә сизмәстән, ялт итеп артына борылып карады. Баягы, ике рәкәгать арасындагы тоем: гүя кемдер үзәкләргә үтәрлек итеп карап тора.

Бу кадәр халык арасыннан ничек табасың инде ул карашны?! Кем соң ул – танышымы, дус-дошманымы, әллә гомер буе саклап килгән җан сакчыларымы, фәрештәләре яисә җеннәреме? Бәлки, шайтаннарыдыр? Шулвакыт, келт итеп, Мәүлет каршына көтмәгәндә килеп күренә торган котсыз шайтан сурәте килеп басты. Чәч тарап утырган Саниясе янында, көзгедә пәйда булган Шайтан-Иблис сурәте, чынлап та, аның күңеленә, хәтеренә мәңгелеккә уелып калды. Шул сурәткә охшатып эзләп карарргамы?

Күп эзләргә туры килмәде.

Әнә ул! Мәчетнең уң як почмагы артында, башын бу якка сузыбрак, карап тора. Мәүлетләрне күзәтә. Тач шул сурәт. Шул йөз, шул күз һәм шул шаукымлы караш. Эчкә баткан төртке күзләр күмер кебек яна, борыны алга чыгып, кәкрәеп тора, колаклары, очлаеп, өскә тырпайган. Башына, эссе җәй булуга да карамастан, кәпәч-бүрек кигән, аның читеннән куе камыл чәчләр, мыек-сакаллар тырпаеп чыгып тора. Шайтан да шайтан, бу да шайтан! Әллә?.. Әллә Иблиснең үзе үкме? Юри генә уйлап куйса да, шайтан турындагы фаразыннан куркып, йөрәгенә шом йөгерде. Чынлап та, Шайтан яисә Иблис булса? Юкка күренмидер Мәүлетнең күзенә. Нидер әйтергә теләп яки өмет итеп үреләдер. Өченче күренүе бит инде. Туктале, нишләп өченче? Икенче генә! Шулай да өченче кебек. Берсе онытылган гына, ахры.

Мәүлет Шәмси картны чабуыннан тартып туктатты. Күзләрен баягы сәер кешедән алмыйча гына, картның колагына үрелде:

– Шәмси бабай, әнә теге кешене беләсеңме? Ә-әнә теге уң почмак буенда бу якка карап тора. Кискен кыланма, яме, сизә күрмәсен.

Йөзәрләгән пар күз арасыннан кирәкле күзләрне табу Шәмси карт өчен уңайсызрак булды. Шулай да, күзләрен кыскалап, борынын җыерып эзләнә торгач тапты ул аны.

– Теге җөнтәс, кәкре борынлы кешене әйтәсезме?

– Әйе, нәкъ шул шайтан кебек кешене.

– Беләм мин аны. Бидгать дигән кырым татары. Әллә Кавказданмы? Балкарлымы шунда... Милләтен белмим, безнеңчә сукалый сукалавын... Бик сәер кеше. Дәшми-сөйләшми, астыртын карап тик йөри. Йөрми дә, бер урында карап тик тора. Әйдә, киттек тизрәк, зәхмәте төшмәсен!

– Мәчеттә нинди зәхмәт булсын инде?! Изге урын бит бу, догалы урын.

– Алай димәле, Мәүлет балакай. Аллаһ йорты дисәк тә, аның эчендә кем булганын беркем дә әйтә алмый. Бу кеше хакында да төрле хәбәрләр йөри. Ике атна элек кенә күренә башласа да, аның хакында сүзләр күп чыкты инде. Үзе бик сөйләшми, ахры, кем беләндер сөйләшеп, аралашып йөргәнен күргәнем юк. Әмма сак булырга кирәк. Мәчет ул догалы, тәкъва кешеләр йөри торган урын гына түгел, анда коткы таратырга теләп кергән залим бәндәләр дә, хәтта кара сихердән яралган рухи затлар да очрап куя. Мин моны төгәл беләм. Кайчакта андый затларны үтәли чыгып-кереп йөрисең, ыһ та итмиләр.

– Бәй, Иблис тә керә ала инде, алайса?

– Чынлап та, син эзләгән мәлгунь зат булуы да бар. Ул бит мәчеткә рәхәтләнеп керә ала. Алуын ала, ләкин ул монда коткы тарата алмый. Чөнки бу – Аллаһ йорты. Иблис дисәң дә, ул мондый изге йортта Аллаһ кануннары буенча яши башлый, юкса, җәһәннәм уты обеспечен. Ул бит җәннәттә иң акыллы фәрештәләрдән саналган, шуңа күрә Аллаһ куйган тәртипләрне генә белә булыр. Монда ул иң элек – Газазил, шуңа да койрыгын бот арасына кысып кына йөридер әле! Кара син аны, мәчеттә йөреп ята диген, ә! Элгәреге картлар шулай сөйлиләр иде.

Мәүлет тагын бер тапкыр теге кеше торган якка күтәрелеп карады. Почмак буш иде. Шулай тоела: ул тирәгә кешеләр якын бармаска тырышалар, әнә бит – уратып-уратып узалар. Кара син аны! Бая гына күзләрен чекерәйтеп карап тора иде, кай арада җилләр искән үзеннән! Бидгать дисәң дә, димәсәң дә, чын бидгать, сихер инде бу!

Шуның белән шул булды. Озакламый бу очрашу да онытыла башлады. Тик ара-тирә генә өйдә Сания: «Мәчеттә очраган теге сәер карт бүтән күзеңә чалынмадымы?» – дип сорап куя. Яисә Шәмси бабайның: «Мин төгәл беләм, кара сихердән туган затлар алар. Ыһ та итмиләр түлке», – дигән шомлы сүзләре исенә төшә дә, күңеле ялкынсына башлый...

**24**

Беркөнне Мәүлет белән Сания тормышында берьюлы ике вакыйга булды. Алар «Сабыйлар йорты»ннан Мөхәммәд белән Гайшәне алып кайттылар. Шатлыкларын уртаклашырга Шәмси карт керде. Ул балаларга багышлап, догалар укыды, азан әйтте. Соңыннан балаларның уллыкка, кызлыкка алынуы хакындагы документларны ашыкмыйча гына, иҗекләп укып чыкты. Тагын догалар пышылдады, тагын азан әйтте. Бу юлы ул аны яшьләрнең шушы араларда күчәчәк яңа фатирларын котлап яңгыратты.

Мәүлет бик бәхетле иде бу кичтә. Кичтә, чөнки аларның бу бәйрәме уразаның авыз ачу мәленә – кояш баеган изге сәгатьләргә туры килде. Гаилә башлыгы, кичәнең дога өлеше тәмамланып, аш өстәле әзерләнгән арада, балаларны аерым-аерым да, икесен берьюлы да кулларына алып, күтәреп йөрде, үчтеки итеп сөйде, чөйде, әллә ниләр эшләтте. Ә менә Саниянең кәефе бик үк шәптән түгел иде, ахры. Сорасалар: «Үзем дә белмим, нигәдер күңелем шомланып тора: нәкъ шушы минутларда нәрсәдер булыр кебек. Күңелемнең бу кадәр җилкенгәне юк иде. Юньлегә генә булса ярар иде дә...»

Тәмледән тәмле ризык-нигъмәт тулы өстәл янына урнашып алгач кына ишек катындагы кыңгырау шалтырады. Бер-берсенә карашып, тынып калдылар.

Һәрберсенең карашында «Кем булыр бу?» дигән сорау иде. «Менә килде ул мәл, хәерлегә генә булсын иде!» – дип, ишеккә таба беренче булып Сания кузгалды. Аның артыннан Мәүлет торып басты. Үзенең тоныклана башлаган күз карашлары белән Шәмси карт та диваннан күтәрелергә тырышып карады, ләкин күтәрелеп җитә алмады, кабат йомшак диван кочагына чумды.

Ишек артында Миндияр белән аның йөргән кызы басып тора иде. Мәүлет белән Сания, кулына чәчәк бәйләме тоткан Миндиярга игътибар да итмичә, аның кечкенә буйлы, җирән чәчле, почык борынлы, бөтен йөз-бите сипкелгә баткан сөйгәненә төбәлделәр. Кыз үзенә төбәлеп карап торган ике пар күзне кыю кабул итте, әмма эчке дулкынлануын яшереп бетерә алмады. Күренеп тора: ул әлегә бу өй хуҗаларының, аның кем, каян, нинди булуын алдан белеп торуын күңеленә дә алмый, шуның белән ул алардан бәхетлерәк иде.

Мәүлет белән Сания Миндиярның яңа кызы хакында шактый беләләр иде инде. Очрашканда, Миндияр үзе дә, яшермичә-нитмичә, ничек бар, шулай хәбәр итеп торды: мари ягыннан икән, тегүчелеккә укыган, фабрикада эшли, дини түгел, күбрәк мәҗүси, ташлар, төймәләр, җепләр, энәләр белән эш итә, ди. Гомумән, авыллары белән тегүчеләр икән анда. Гомер-гомергә тегүчелек белән шөгыльләнәләр. Төп кәсепләре – курчаклар тегеп, шуларны сатып көн күрү. Табынганнары да шул курчак икән. Авыл читендәге урманда «курчак аланы» бар, ди, менә шунда төрледән-төрле курчакларга табынырга йөриләр, ди. Иң урта бер җирдә патша курчак утыра, ди. Аның хәтта йорты да бар, ди. Ул йортның манарасы да бар, ди. Исеме бик сәер – Әйбәлис. Очлы борынлы, очлаеп, өскә тырпаеп торган колаклы, йөнтәс йөзле, озын койрыклы бер котсыз курчак икән ул. Безнең шайтаннарны хәтерләтә, ди. Ә менә аның тирәсендәге курчаклар берсеннән-берсе матурлар, купшылар, ди. Барысының да исеме бар, ди. Бик матур исемнәр, ди: Гүзәл, Сылу, Чәчәк, Гөлкәй, Айсылу, Айгөл, Айнур... Атнаның һәр шимбәсендә авыл карт-карчыклары, шул аланга барып, әлеге курчаклар белән аралашып, көн үткәреп кайталар икән. Аларга ризык-нигъмәтләр илтәләр, табын әзерләп, ашаталар, эчертәләр, күңелләрен күрәләр – шул курчаклар алдында җырлар җырлап, биюләр биеп, уеннар уйнап, хәтта курчакларның туйларын туйлап кайталар, ди. Шулай иткәч, тегеләр дә мәрхәмәтлелек, игелеклелек белән җавап бирәләр, ди: илгә кызулык килгәндә, яңгыр җибәрәләр, бакча-басулардагы уңышны арттыралар, малларны афәттән саклыйлар, кешеләрне парлы, имин һәм бәхетле итәләр, ди, дөрес булса.

Ләкин хәзер яшьләр авылдагы бу сәер йолаларга сак карый башлаганнар. Күбесе бөтенләй дә читләшкән. Әмма Әйбәлис культы һаман яшәп килә, ди, бу авылда. Хәзер аны карт-коры күбрәк сихерләү йолаларында яисә, киресенчә, сихер кайтаруда кулланалар, ди. Яшьләрне әнә шул кара сихер галәмәтләре куркыта да инде. Шуңа күрә тизрәк читкә китү ягын карыйлар, ди. Халык телендә курчаклар патшасының исеме дә хәзер башкача әйтелә икән, – аны Иблис дип кенә җибәрәләр, ди, хак булса. Иблис, мәлгунь, бөтен явызлык, золым һәм нәфеснең башында торган зат буларак, бу кечкенә татар авылында мәркәзен булдырып, кешеләрнең аң-зиһеннәренә үтеп кереп, кеше сихерләү, кеше аздыру, кеше котырту белән шөгыльләнеп ята, имеш. Ул хәзер кеше теле белән сөйләшә дә башлаган, имеш. Әмер биреп,

коткы таратып ята, ди. Соңгы ике атнада бөтен тирә-як авыллар баштан-аяк сихергә һәм аракы сөременә чумган. Илгә ураза ае кергәч кенә кара хорафат басылгандай булган.

Айя (кызның исеме шулай икән) өй хуҗаларында әйбәт тәэсир калдырды. Тыйнак, ачык йөзле, итагатьле. Йөзендәге сипкелләре баштарак аның якты йөзен ямьсезләп торган кебек иде, бераздан бу нурлы чырайны нәкъ менә шул сипкелләрнең нурландырып, балкытып торуы ачыкланды.

Кунак кызы балалар янына бармады. «Бүген генә авылдан килдем, анда хорафат җитәрлек, берәр шаукым ияреп килүе бар, балаларга якын бармыйм, ерактан гына сокланып карап торам», – дип, күңелдәгесен әйтте дә салды. Балалар белән күбрәк Миндияр шаярды, уйнады. Тиздән аларның уенына Мәүлет килеп кушылды. Шәмси карт бер читтә елмаеп утыра бирде. Ара-тирә генә «Сөбеханалла», «Сөбеханалла», – дип пышылдый яисә «Алла сакласын!» «Алла сакласын!» – дип, бөтен җаны-тәне белән ухылдап куя. Ул бөтен җаны-тәне белән канәгатьлек тоеп, рәхәтлек кичереп утыра, гүя моңа кадәр җанын борчып торган бер авыр мәсьәлә хәл ителгән, һич югы хәл ителеп килә.

Өстәл янында икесе генә торып калган Сания белән Айяга шул гына кирәк иде, алар, чынаякларын тотып, бүлмәнең кухня дип йөртелгән почмагына барып урнаштылар. Йөзгә йөз куеп, үзләре генә аңлаган телдә бик мөһим сүзгә керештеләр.

Сүзне Сания башлады. Ярымпышылдап әйтелгән һәр сүзендә ниндидер сер, хикмәт бар кебек:

– Каян бу хәлгә төштең, Ая акыллым? Син бит үз иркең белән йөрмисең безнең тирәдә. Нинди уй алып килде сине Миндияр янына, аннары безнең янга? Кем җибәрде?

– Мин үз хәлемне үзем генә беләм, Сания апа. Һәм сез беләсез. Мин бит сезнең кем икәнегезне шундук чамаладым. Шуңа да ачылырга булдым. Монда килергә дә Миндиярдан үзем сорадым. Без аның белән аңлаштык инде. Мәүлеткә якынаю өчен генә аның белән танышуымны да әйттем. Башта бик нык үпкәләштек, аннары дуслаштык. Ничек кенә танышсам да, мин аны ярата башлаганмын икән, Сания апа. Ул да шулай, ди. «Яратып өлгердем шул инде, аерыла алмыйм», ди. Менә шундый хәлләр бездә.

– Хәзер бөртекләп сөйлә, акыллым: ни өчен кирәк булды сиңа Мәүлет?

– Бервакыт авылга кайтканда, Әйбәлиснең әмерен җиткерделәр. Китапча әйтсәк, Иблис инде ул. Менә шул Иблис әйткән: «Бик каты мине эзлиләр икән, шул кешеләрне табып, исләрен алырга кирәк», – дигән. Шулай дигән, имеш, безнең авыл карыена. Әйбәлис белән сөйләшеп торучы, аның телен белүче, шаман кебек кешене, «карый» диләр бездә. Карыйлар нәселе бар авылда. Дөресен генә әйткәндә, мин үзем дә шул нәселдән, кечкенәдән сихер, шаукым серләренә өйрәнеп үстем. Ләкин мин бу шөгыльне яратмыйм. Шуңа да шәһәргә чыгып киттем. Тик кайтмыйча да булмый – әтием белән әнием шунда. Бер кайтканда, карый бабай мине чакыртып алды да: «Иблисне фаш итәргә йөрүче Мәүлет дигән кешене табарга кирәк», – диде. Төпченеп сорашмадым. Бездә сорашырга, төпченергә ярамый. Әйтелгән икән – үтәргә кирәк. Үтәмәсәң, зәхмәт белән җәзалыйлар: йә кул-аягың тартыша башлый, йә зиһенеңә зыян килә. Шәһәрдә беләләр икән

инде бу хакта. Урам сукбайлары Мәүлеткә төртеп күрсәттеләр. Әмма, ничек кенә тырышсам да, әле алдына, әле артына чыксам да, ул мине күрмәде, хәтта тоймады, сизмәде дә. Шуннан соң мин Миндиярга күчтем. Ә ул мине бер генә күрде. Күрде дә үзеннән бер адым да читкә җибәрмәде. Миндияр аша Мәүлет белән таныштым. Бөтен тарих шул, Сания апа.

– Шуннан, таптыңмы соң эзләгәнеңне?

– Таптым.

– Бу хакта карый бабаңа әйттеңме?

– Юк, әйтмәдем, әйтәсем дә килми. Чөнки бу эшнең әйбәтлек белән бетмәячәген беләм. Ә мин Миндиярны яратам. Сания апа, нишләргә миңа? Килүем дә сездән киңәш сорарга иде. Миндияр ышанмый. Мәүлеткә зыян салыр өчен генә сорыйсың, ди. Ә мин чын күңелем белән сорыйм.

– Нәрсә эшләргә җыена соң ул Мәүлеткә каршы?

– Мәүлетнең курчагын ясап, шуны яндырырга телиләр, ахры. Һәрхәлдә, шулай эшлиләр иде элгәре. Соңгы елларда күргәнем юк. Әйтәм бит, бик кайтып йөрмим, дип.

– Синнән ни кирәк соң? Ясасыннар да яндырсыннар. Мәүлет үзе нигә кирәк, дим?

– И-и, Сания апа, әйтмәдеммени әле? – Безнең йолаларда яндыру гына җитми шул. Шул кеше белән аралашып, яндырыла торган курчагына әлеге кешенең сиңа ияреп кайткан тән аурасын һәм җан сулышын өрергә кирәк. Шулай булганда гына курчак иясе золым күрә.

– Димәк, сиңа, Мәүлетне күреп, аның белән аралашу да җитә?

– Әйе, бик җиңел. Юк-юк, уйламагыз да, мин моны эшләргә җыенмыйм. Мин, гомумән, кабат шаукымга, сихер дөньясына кайтырга теләмим. Без Миндияр белән гаилә булып яшәргә җыенабыз, Сания апа.

– Ашыкмыйсызмы? Сихер тирәсендә яшәп, бәхетле гаилә корырга мөмкинме соң, Ая акыллым?! Менә Мәүлет белән дә шик-шөбһәләрдән, шаукымнан арынып бетә алганыбыз юк. Беләсеңме, ул әлегә кадәр миңа ышанып җитми, шикләнә. Хәтта «Иблистер бу» дип уйлаган чаклары да еш була. Мин моны тоеп, юк-юк, төгәл белеп торам!

– Алай икән... Нишләргә соң миңа?

– Йөрәгең нәрсә ди, ни эшләргә куша соң?

– Йөрәгем бүген телсез, сукыр, саңгырау. Мондый хәл миндә беренче мәртәбә.

– Әйе... Мин сиңа Мәүлетне бирмәячәкмен, чөнки мин синнән көчлерәк. Шуңа күрә Иблискә кайтып әйтә аласың: «Мәүлетне кулга төшереп булмаячак», – диярсең. Төшенәсеңме эшнең кая табан барганын?

– Төшенәм дә, юк та. Чөнки, мин авылга бүтән кайтмаячакмын, Сания апа. Туйдым сихерләреннән!

– Сания апа да, Сания апа, дисең. Ташла әле шул төчеләнүеңне! Сания дип кенә әйт! Әйтелгән икән – үтәргә тиешсең. Кайтабыз, ник кайтмаска?! Барысын да ачыклап, һәр нәрсәне үз урынына куеп киләбез. Юк, мине сезнең Иблис кызыксындырмый. Мине әнә шул «Әйбәлис сектасы»ның башлыгы – Иблис белән «сөйләшеп йөрүче» карыегыз кызыксындыра. Бөтен хикмәт тә аңарда. Бик серле ул кешегез. Яңа Алла, яңа дин уйлап чыгарган, имеш. Ә үзе халыктан акча җыеп, зур йорт салып куйган. Карама миңа аптыраулы караш белән. Аны гына беләм мин. Минем үз җеннәрем шул хакта хәбәр итте.

– Аңлыйм, Сания апа. Ай, Сания. Шуңа күрә дә аптырап карыйм. Нинди көчле сезнең тоемыгыз, никадәр ерактан күрә күңел күзләрегез!

– Күрәм, барысын да күрәм. Бүген бигрәк тә күрәм. Чөнки Мәүлеткә кагыла бу тарих. Андый чакта минем күңел аеруча сизгер.

– Ни күрәсез, Сания апа?

– Ташла, дидем бит шул апа дигәнеңне!

– Ни күрәсең, Са... Сания?

Башын артка ташлап, күзләрен йомып, тирән уйга чумып утырган Саниягә ирләр дә игътибар иттеләр, бер-бер артлы Сания белән Айя утырган кухня өстәленә таба күченеп утырдылар. Баштарак бу гайре табигый хәлдән үзара көлешеп, елмаешып алдылар, бераздан ирен читләренә, күз төпләренә сизелер-сизелмәс кенә сызыла башлаган җыерчыклар тартылып киткәндәй булды, йөзләре, карашлары җитдиләнде.

Аларның күз алдында Сания шаукымлы халәтенә кереп бара иде. Сөйләгән сүзләре генә шушы дөньяныкы.

– Күрәм. Ләкин үзен түгел, атасын да түгел, бабасын күрәм. Бөтен нәрсә бабасыннан башланган. Бабасы оештырган нәрсә бу. Иблисне дә алар уйлап тапкан. Дөрес, курчакларга табыну күптән булган бу авылда. Ләкин беренче булып бабагыз сөйләшә башлаган. Кулларында таягы да бар, шуның очы белән җиргә суккалап йөри. Сукыр булмагандыр бит?..

– Әйе-әйе, «Сукыр бабай» дип йөртәләр иде аны!

– Дәшмә... Үзем дә күреп торам. Әнә шул сукыр бабаңда бөтен хикмәт. Сукыр кешеләргә Аллаһ тарафыннан бер җен бирелә. Әнә шул җен сукыр адәмнәрне карап-тәрбияләп, саклап йөртә. Ләкин ул җеннәр адәми затлардан өстен булырга тиеш түгел. Өстен булсалар, кеше аларга коллыкка төшә, алар нәрсә әйтә, шуны эшли, алар ничек тели – шулай яши башлый. Кеше бу җенгә нык ияләшә, хәтта аны күрергә, тотып, сыйпап карарга тели. Ә бит җеннәрне тотып, капшап карап булмый. Шуңа күрә дә теге җен кисәге сукыр картка үзенең курчак-сурәтен эшләп бирә. Күрәм, күрәм. Барысын да күрәм. Әнә ничек астыртын елмая. Тукта-тукта. Бу бит шайтани зат! Иблис токымы! Менә кайда икән хикмәт! Шушы токымның җен-шайтаннары авыл кешеләрен күпме вакыт үз карамагында, үз шаукымында тоткан. Кайтып килергә, дөньяны чистартып, аруландырып килергә кирәк.

Ниһаять, Мәүлет түзмәде, Сания алдына килеп басты.

– Нәрсә бара монда, нинди сихер сеансы бу? Нәрсә эшләгәнеңне аңлыйсыңмы-юкмы, Сания? Бу сихерле, шаукымлы дөньяга кермәскә бер сүз биргән идең бит инде, ә?! Сания! Сания, дим!..

Сания ирен ишетерлек тә, аңларлык та хәлдә түгел иде. Сихерле шаукым экстазына бирелеп, бер гасыр элек яшәгән бәндәләрнең рухлары, әрвахлары белән аралашырга, үзара аңлашырга тырыша иде.

**25**

Саниянең шаукымлы сеансында ни булганын беркем дә белми калды. Бу хакта турыдан-туры сорашучы да булмады. Мәгәр анда хәлләр бар иде! Сания шайтан коткысы дигән шаукымның нәкъ авызына барып керде. Нindидер төссез, кыяфәтсез, чынлыкта, күләгә, шәүлә кебек котсыз, хәшәрәт затлар бер сукыр малайны сырып алганнар да, колагына тукыпмы тукыйлар:

– Менә сиңа курчак!
– Менә сиңа курчак!
– Ә син – безнең курчак!
– Ә син – безнең курчак!

Аеруча бер хәсис шайтан әлеге ялгызак һәм бичара малайның куенына ук бөтерелеп, боргаланып керә, үрелеп, аның муеннарыннан кочып ала, яңакларыннан сыйпап назлый, иркәли. Хикмәти Хода: малай һич карышмый, каккан казык кебек кымшанмый да утыра бирә. Менә аны ниндидер күкзәңгәрсу рәшә болыты сырып ала, нечкә, озын муены тирәсендә боргаланып уйный һәм кысып буарга керешә. Малай чак-чак тын алып тора да, башын аска ташлап, тынып кала. Аннары тагын башын калкыта, гүя ул шушы бер мизгел эчендә үлеп терелә. Ләкин инде ул башка кеше, кеше дә түгел, күбрәк курчакны хәтерләтә. Бу юлы инде аның күзләрендә нур юк, йөзендә яшәү гаме, яшәү дәрте сүнгән. Хәрәкәтләре салмак, хәтта бераз картларча. Әнә ул торып басты да әллә каян гына кулына килеп кергән, үзе чаклы котсыз курчакны тирбәтергә, ярсып-ярсып сыйпарга, назларга кереште: «И-и, и-и... И-и, и-и...» Шулай кочаклашып, назлашып, алар томан эченә кереп югалдылар, алар артыннан гасырларның ухылдап ыңгырашуы гына ишетелеп куйгандай булды.

Миндиярның яраткан кызы сабыйларча ихлас, хәтта самими булып чыкты. Әллә шулай тоелды гынамы? Баштарак җавап бирмичәрәк торса да, Айя Мәүлет белән Саниягә ияреп, авылга кайтырга риза булды. Шулай да «Миндияр да кайтсын иде» дигән шартын тәгаенләп өлгерде. Миндиярның кайтачагын белеп, Мәүлет шатланды гына. Аның белән югалмыйсың, бер мәртәбә генә сыналган фал түгел. Шаукым-сихергә дә артык аптырап китми. Әнә бит, Сания белән Айяның шаукымлы сеансыннан соң да, Мәүлетнең кулбашыннан кага-кага:

– Ну, эләктек без синең белән, әзи. Чистый сихерче кызларга килеп юлыктык, парин. Хәерлегә булсын! – диде дә борчулы уй-хисләрен шундук төенләп тә куйды, йөз-чыраеның барлык җыерчыкларын кузгатып, чын мишәрчә итеп, ихлас елмаеп җибәрде.

Шулай килештеләр. Дүртәүләп кайтырга булдылар. Айя үзе алданрак кайтып китә. Калганнар, очраклы рәвештә генә кайтып төшкән кебек кинәт авыл җирлегендә пәйда булалар. Шуннан ниләр эшләсен күз күрер. Ничек кенә булса да, урман тупыйгында урнашкан бу ерак авылдагы Иблис төенен чишәргә кирәк. Шунсыз Мәүлетнең дә, Саниянең дә күңелләре тынычлана алмаячак. Бу аларның бурычы кебек хәтта.

Сания үзенең магик мөмкинлекләренә ышанды. Шуңа күрә дә күңеле тыныч иде.

Ләкин шаукым шуңа күрә дә шаукым инде: аны беркем дә алдан тоеп, белеп, аңлап, иң мөһиме, аңардан сакланып бетә алмый. Хәтта көчле шаукым, магия ияләре дә.

Урман эчендә еландай бормаланып, дөресрәге, боргаланып яткан юл өстендәге ул авылга, ерак юл үтеп, кичкырын гына кайтып төштеләр. Авыл дисәң инде... Урман эчендә җәйрәп яткан тигез кыр-басу уртасында берберсенә сыенышып утырган, ун-унбиш йорттан торган бер урам икән ул. Авылның ике башыннан да урманга юллар кереп китә. Әле алардан башка

да шактый сукмак чыга. Ә кыр үзе төрле төстәге таҗлары белән балкып утырган чәчәкне хәтерләтә: бер өлешендә бодай, арпа игененең гәрәбәдәй нурланышы күзләрнең явын алып тора, икенче бер җирдә куе яшел төскә чумып утырган бәрәңге, чөгендер басулары, кукуруз кырлары шәйләнә.

Басу-кырлары матур булса да, авыл үзе шыксыз, караңгы. Зур, мәһабәт йортларның ишекләре тәбәнәк, тәрәзәләре кечкенә, түбәләре җәлпәк. Йортларга тамчы да буяу кермәгән, татар авыллары өчен хас купшылык, нәзакәтлек тә юк ишек-тәрәзә башларында. Капка-коймалары да тәбәнәк, буялмаган, күп җирдә читән генә тотылган. Әһә, күзгә беренче җан ияләре чалынды, – авыл белән басу арасындагы чирәмлектә берничә мал чемченеп йөри. «Хәтта атлары, сыерлары да тәбәнәк, ахры, бу авылда», – дип уйлап куйды Мәүлет. Чынлап та, ниндидер кәрләләр авылы бу. Айя үзе дә кечкенә ләбаса! Тукта, кайда соң әле ул үзе? «Карабрак торырмын, каршы алырмын», – дигән иде бит.

Авыл башына машиналарын туктатып, бераз таптанып тордылар да урам буйлап кузгалдылар. Ләкин ике-өч адым да атлый алмадылар, аларны, җир астыннан иңрәп чыккан шикелле, җаннарны шомландырып, тонык бер тавыш куып җитте:

– Белеп керәсезме? Сез кирәкме бу авылга?

Яшьләр шым булдылар. Бер мәл артларына барылып карарга куркып тордылар. Әлеге дә баягы, Миндияр барысына караганда да тизрәк айныды, җир астыннан ишетелгән тонык тавыш иясен дә беренче ул эзләп тапты. Әлеге тавыш һич кенә дә җир астыннан килми икән. Якындагы кукуруз басуы читеннән ишетелә икән ул. Өлгереп килгән кукуруз үсентеләреннән чак кына калку кеше гәүдәсен тиз генә күреп тә, шәйләп тә алу мөмкин түгел икән. Ул әнә ничек күзгә бәрелеп тора бит! Салам эшләпәсе өскә таба очлаеп күренә. Җыйнак кына татар сакалы. Кашлары куе. Чал чәчләре, бөдрәләнеп, эшләпә читеннән бүлтәеп чыккан. Күзләре – төртке күзләр, алар шулкадәр эчкә батканнар, карашларының нәрсә белдергәнен тиз генә аңлау да кыен. Ә болай... Җыйнак, пөхтә, хәтта мөлаем гына бер карт.

– Сез кирәкме соң бу авылга? Бу хакта уйладыгызмы? – Карт кабатлап сорады, шулай итеп сорады ки, бу сорауга җавап бирми калу һич кенә дә ярамый иде.

Барысына караганда да ушлырак Миндияр, бөтен мөлаемлыгын эшкә җигеп, картка таба китте.

– Нихәлләр, бабай! Без эзләгән авыл шушы буламы инде?

– Шушылыкка шушы да, тик ни калган сезгә бу авылда?

– Монда минем яраткан кызым яши.

– Айяны беләм. Шуннан?

– Нәрсә – шуннан? Ә сез аны каян беләсез? Ягъни мин белгәнне каян беләсез?

Шулчак Миндияр янында Сания пәйда булды. Ул башта Миндиярның колагына: «Юк белән башыңны катырма, күрмисеңмени – юри сөйләшә бит, хәзер дилбегәне миңа бир. Ә үзең шым бул!» – диде дә кукурузлар янында торган картка карап кычкырды:

– Бабай, без Айялар авылына килдек. Сүзебез, ниятебез бик җитди. Нигә тел яшереп торырга?! Турыдан-туры сөйләшик тә шушында ук эшне бетерик!

Карт кискен генә башын күтәрде, күзләрен кысып, бермәл сынап карап торды. Аннары басуыннан аерылып, яшьләргә таба килә башлады. Сания, Мәүлет белән Миндиярга үз урыннарында калырга кушып, картка каршы китте. Карт килә-килешкә сорашуында булды:

– Сез Әйбәлис янына килдегез, шулаймы?

– Шулай, нәкъ шулай, бабай, син үзең безнең килүне теләдең бит. Менә, Мәүлет дигән кешене алып килдек. Әйе, без Иблисне эзлибез, ә аңа Иблисне табу, фашлау бурычы йөкләнгән, ә сез, ягъни мәсәлән, сез – Иблис ихтыярын үтәп йөрүчеләр – безне эзлисез. Безнең – үз максатыбыз, сезнең – үз максатыгыз. Башта ук әйтеп куям: мин рухлар, әрвахлар телен беләм. Шуңа күрә сез ни уйлаганны белеп торам...

– Миңа болар билгеле. Сөйләп тормасагыз да була.

– Каян, кемнән? Әлбәттә инде, Әй...Әй... Бә... Бә...

– Әйбәлистән. Монда бөтен нәрсә аның ихтыярына буйсынган.

– Безнеңчә Иблис инде ул.

– Анысын белмим. Ул безнең өчен Әйбәлис! Борынгыдан шулай килә. Бездәге халык аның сүзе, аның дине буенча яши. Ә бу диннең беренче шарты: «Авылга чит-ят кеше керергә тиеш түгел, авылдан сер дә чыгарга тиеш түгел». Шулай булгач, сезгә бу урам ябык.

Ул арада тагын Миндияр чәчрәп, алга чыкты:

– Тукта! Бу урында мин сорарга тиеш: керергә ярамагач, мин үз кәләшем янына ничек итеп килеп йөрергә тиеш инде, ә?

Сания аны тагын читкә этәрде. Ишарәләп, Мәүлет янына барып басарга кушты. Үзе Миндиярның әйткәнен эләктереп алды:

– Чынлап та, кайда безнең Айя? Нигә ул каршы алырга чыкмады?

– Ул сезнеке түгел, Майя – безнеке. Безнеке генә!

– Безнеке дигәнең – Әй-бә-лиснеке буламы инде?

– Әйе, Әйбәлиснеке.

– Һәм сезнекеме? Сез – шушы авылның карые, шулай бит?

– Әйе, мин – карый. Айя – минеке дә. Әйбәлис үз әмерен минем аша җиткерә икән, ызначит, мин пәйгамбәр кебегрәк кеше булам, Мөхәммәд кебек.

– Айя сезнеке булса, Мәүлет – минеке. Шуннан, нишлибез инде?

– Килешәбез: сезгә Айяны бирәбез, ә сез безгә – Мәүлетне.

– Сез мине аңламадыгыз. Мәүлет – минеке, дим. Ахыр чиктә. Айя да безнеке инде. Әнә иреннәрен чәйнәп торамы бер егет? Йөрәге шартлар дәрәҗәгә җиткән. Мишәр егете ул. Дуамал холыклы, кызу канлы. Аның ачуын китерергә ярамый. Айя – шул усал егетнең кәләше. Алар өйләнешергә сүз куешканнар. Шулай булгач, барысы да – безнекеләр. Шуңа күрә көч тә, хаклык та безнең якта булып чыга.

Карт уйланыбрак торды. Аннары, тавышын күтәрә төшеп:

– Бездә алай гына авылдан чыгып китеп булмый. Алай гына өйләнешеп тә булмый. Әле сезнең үзегезнең чыгып китүегез дә икеле, – диде.

Сания, киресенчә, тынычланып калды.

– Аңлашылды, абзый кеше. Хикмәт Әйбәлистә дә, Иблистә дә түгел, бөтен хикмәт, дөресрәге, бөтен бәла сездә икән! Бернинди Иблис тә, аның коткысы да юк, ә менә ничә буыннар бөтен авылны үз сихер шаукымы

белән, кара хорафат белән куркытып торган карыйлар нәселе, сезнең нәсел бар. Сез үзегез – Иблис. Сез үзегез халыкка золым таратып, аны куркытып, талап, рухи яктан зәгыйфьләндереп, имгәтеп яшисез. Тоям, хәтта беләм, күреп торам: сездә сихер шаукымына сәләт бар, юрау, имләү, арбау сәләте дә бар. Ләкин бу сәләтләрегез, бернинди каршылык күрмичә, гасырлар буе кешеләрне изүгә, аларның кешелеген, рухиятен, уй-фикерен, күңел көрлеген басуга хезмәт иткәннәр. Һәм, көрәш рухыннан мәхрүм булып, үзләренең магик көчләрен югалтканнар. Хәзер ул шайтани көчегез безгә куркыныч түгел, кем, карый абзый. Аннары, мәгълүм бит: ураза аенда шайтаннарның егәрлеге бетә, ә сез шайтаннар кавеменә күченеп өлгергәнсез, шуңа да көчсез калгансыз. Яхшылык белән сорыйм: юл өстендә тормагыз, безне авылга җибәрегез, анда нишләргә икәнен без үзебез карарбыз. Авыл халкын җыеп, кешеләрне чын асылларына кайтару ураза аенда изге гамәлләрдән саналыр. Кешеләрне теге Әйбәлис-Иблис курчагыннан азат итәрбез. Кем белә, бәлки, Мәүлеткә, башка бәндәләргә җибәрелгән, шайтанлык коткысы таратырга Җиргә төшкән Иблис хакындагы илаһи төшләр, шушы бер изге-саваплы гамәлне кылып, җирдәге гөнаһлы тормышны аз гына булса да, чистарту, игелеккә, миһербанлыкка, шәфкатьлелеккә, гомумән, имани, рәббани тәгълиматыбызга, хакыйкатькә якынайту өчен җибәрелгәндер дә. Аллаһыбыз барысын да күреп, белеп тора. Тәкъдиребезне Аңа тапшырдык.

Ләкин карый чигенергә җыенмады. Уң кулын югары күтәреп, бармакларын таҗландырып тырпайтты, сул кулын асылындырып, учларын шулай ук «таҗландырып» җәеп, сихерчеләр телендә «казык» дип йөртелгән хәтәр йоласын башкарырга җыенды. Сания моны шундук аңлап алды, карый ягыннан йөзенә салкын җил исә башлау белән каршы тору әмәленә керешге: ике кулын як-якка җәеп җибәрде дә аякларын аерып басып, башын кискен рәвештә аска иде, шул рәвешле йөзен салкын җил агымыннан яшерде. Ләкин бу әле саклану чарасы гына иде. Бераз вакыт чәчләрен җилдә тузгытып торгач, Сания чын сихер йоласына кереште: менә ул киерелеп ачылган бармакларын бер йодрыкка җыя башлады, чәнти бармакларын гына калдырып җыеп бетерде, аннары, шулай басып торган килеш, уң якка таба әйләнергә керешге. Башта салмак кына әйләнде, аннары кызурак хәрәкәтләнергә керешге. Берничә минут шулай үз күчәрендә әйләнгәләп торганнан соң, кинәт туктап калды, бармакларын кабат тырпайтып, кулучларын кискен генә алга ташлады да, авыз эченнән генә нидер укына-укына, башын өскә чөйде, йөзен күтәрде, утлы карашлары белән каршысында һаман әле мәҗүси иләслектән котыла алмый торган карт карыйга укталды.

Карый чарасыз бер кыяфәттә баскан урынында басып, дөресрәге, тораташ кебек катып калды, яшьләр авылга табан кузгалды. Артына карана-карана барган Миндияр сорамый булдыра алмады:

– Шулай һәйкәл кебек торачакмы инде ул?

Сания бу сорауны көткән икән. Уйлап та тормыйча:

– Без авылдан чыгып киткәнче шулай торачак.

Миндиярда тагын бер борчу бар икән:

– Ничек тә Айяны табарга иде, ә, Сания?

– Шуның өчен килдек бит инде, Миндияр. Чак кына сабыр ит, барысы да әйбәт булыр, җайланыр...

Ниһаять, күптәннән дәшмичә йөргән Мәүлетнең дә «теле ачылды»:

– Сания, ә, Сания, дим.

– Нәрсә, Мәүлет? «Ачуланышсак, мине дә таш һәйкәл кебек катырып калдырмассыңмы?» дип сорамакчы идең, шулаймы?

– Әйе, Сания, каян белдең?

– Белдем инде... Кем белән яшәгәнеңне онытасың бугай, Мәүлет. Әйттем бит мин сиңа: тормышың тынгысыз һәм башкатыргыч булачак, дип.

– Авыр булачак, дип тә әйткән идең...

– Юк, авыр булмаячак.

– Нигә алай дисең?

– Чөнки без бервакытта да ачуланышмаячакбыз, Мәүлет. Шуны колагыңа киртләп куй, яме...

Ир белән хатын әңгәмәсен башын чайкый-чайкый тыңлап барган Миндияр әйтеп куя:

– Кая килеп эләктем мин, җәмәгать, ә?! Һич баш эшләми, чеметегез әле берәрегез...

Ул арада тәбәнәк коймалар артында башлары гына калкып-күренеп торган кешеләр очрый башлады. Яшьләрнең исәнләшүенә алар берничек тә җавап бирмәделәр. Акбур кебек ак чырайлы, рәсемдәге кебек нурсыз, төссез катып калган йөзле бәндәләрдә җан әсәре юк кебек тоелды Мәүлеткә. Әйе, нәкъ шушындый котсыз бер урында яшәп ятарга мөмкин Иблис дигәннәре. Алай дисәң инде... Әнә бит нәрсә сөйли Сания. «Иблис үзе юк, ә Иблис исеменнән сөйләүчеләр, имеш, аның ихтыяры, әмере буенча кара золым кылучылар гына бар», – ди. Ю-у-к, бар ул Иблис, бар. Аны уйлап чыгаручылар гына бу кадәр әшәкелекне эшләп бетерә алмаслар иде. Кеше җаны, адәм баласының йөрәге бу кадәр явызлыкны, ялганны, хөсетлекне, кан коешны, сихер шаукымын күтәрә алмас иде. Бер килеп ярылыр иде, шартлар иде, билләһи!

Бервакыт капкалар ачыла башлады. Ярымачык капкаларда башлар күренде: хатын-кызларның барысы да шәльяулык япкан, ир-атлар исә бүрек кигән иде. Ләкин бу башларның гамендә әле генә авылга килеп кергән өч чит-ят кеше түгел, ә урамның аргы башыннан йөгереп килүче кыз бала иде. Бөтен көченә иңрәп-кычкырып килүче бу баланың тавышына авыл этләре дә өрүләреннән тукталып калдылар, кайберләре шыңшый-шыңшый, ояларына кереп посты.

– Айя апам, Айя апам! Коткарыгыз! Айя апамны коткарыгыз!

Урамга, үз капка төпләренә каккан казык кебек чыгып баскан халык кызның ачыргаланып кычкыруын әллә ишетә, әллә юк. Аларның карашы кабат Сания-Мәүлет-Миндияр ягында. Авыл кунаклары исә, киресенчә, бөтен игътибарларын сөрән салып, дөнья куптарып килүче 5-6 яшьлек кыз балага юнәлткәннәр.

– Коткарыгыз! Апамны коткарыгыз!..

Мәүлет беренче булып кызга каршы йөгерде. Аның артыннан Сания белән Миндияр да адымнарын тизләттеләр.

– Нәрсә булды? Кемне коткарырга? Кемнән? Әйдә, хәзер барысын да тыныч кына аңлат, акыллым.

– Нәрсәсен аңлатып торасың инде аның! – дип, куып җиткән Миндияр да кыз алдына килеп чүгәләде. – Күрмисеңмени – тач апасы бит. Айя! Нәрсә

булды? Апаңа нәрсә булды? Ник дәшмисең? Акыллым, сөйлә инде: кайда ул? Кем нәрсә эшләтте аны?

Күп йөгерүдәнме, елауданмы, чит-ят кешеләргә юлыгып, каушап калуданмы, кечкенә Айя, чынлап та, телсез калган иде. Бераздан соң гына, янына килеп җиткән Сания апасы, иелеп, җилдә тузгып-таралып, йөзен каплый башлаган чәчләрен бармаклары белән тарап, сыйпап, рәткә китерә башлагач кына җавап бирерлек хәлгә килде кыз.

– Апа... Айя апа... Анда... Урманда... Сазлыкта... Бата...

Кыз авыл урамының аргы башыннан шомланып күренеп торган биек кара урманга төртеп күрсәтте.

Бу юлы беренче булып Миндияр торып чапты. Аннары гына – Мәүлет, Аннары – Сания белән теге нәни кызчык.

Ләкин Миндияр ерак китә алмады. Авылны чыгуга, кая барырга белмичә, каушап, туктап калды. Урман дигәннәре авылдан шактый ерак булып чыкты. Аңа кадәр әле диңгез кебек җәйрәп яткан бодай басуын үтәсе бар иде. Авылны чыгуга, иген басуын төгәл кисәкләргә телеп, өч якка өч басу юлы кереп китә. Иң арттан килүче Сания белән нәни кыз урта юлдан киттеләр. Шуны гына көтеп торган кебек, Миндияр аларны тиз генә куып җитте дә узып китте. Мәүлет аның артыннан йөгерде. Кечкенә кызның тәмам хәле беткән иде, Сания аны күтәреп алды. Үзе бертуктаусыз сорашты:

– Нәрсә булды апаң белән? Кайда бата ул? Ни өчен?

Кыз инде тынычланган, сөйләшерлек хәлгә килгән:

– Карый бабай аны Әйбә... ә-әлис урманындагы яланда бер агачка бәйләп куйган. Мин аны шунда таптым. Бауны чишкәч, апам авылга йөгерде. Тик ике арадагы сазлыкка кереп батты. Ул хәзер анда батып ята. Безнең сазлык бик яман, әллә ничә кешене алды инде. Тизрәк барыйк, ул инде муеннан баткан иде. Мине җиргә төшер, әйдә йөгерик.

– Миндияр абыең белән Мәүлет абыең шунда инде, алар коткарыр.

– Юк, алар коткара алмаячак апамны.

– Нигә алай дисең?

– Алар үзләре батачак анда. Әйдәгез инде, тизрәк барыйк, барысын да коткарыйк.

Менә алар, кулга-кул тотынышып, йөгерә башладылар. Озак барасы булмады, урманны кара тасма кебек уратып алган сазлыкны шундук чамалап алды Сания. Менә нидә икән хикмәт! Урманга тиз генә кереп китеп булмый икән әле! Зәхмәтле сазлык аерып тора икән аны кешеләр тормышыннан. Якында гына нindидер тавышлар ишетелеп калды. Сазлык эченә чәчелгән куаклыкларның кайсыдыр җанланып китте, чайкалып куйгандай булды. Кеше башлары күренде. Сания Мәүлетне шундук танып алды.

– Мәүлет!..

– Сания. Без баттык... Без батып барабыз, әнә Айяны коткарыгыз, аның бугазына җиткән инде.

Бер-бер артлы батып баручы өч кешене коткарырга шактый вакыт китте. Сания якыннан гына агач ботаклары җыеп килде. Шуларга баса-баса кереп, шактый хәлсезләнгән, бер сүз әйтерлек тә егәре калмаган Айяны тартып чыгарды. Аннары егетләрне коткарырга тотынды.

Якындагы чишмә янына барып, юынып, чистарынып алганчы шактый

вакыт узды. Көн кичкә авышты. Сәхәрдән соң авызларына бер тамчы су капмаган ураза егетләре тәмам хәлсезләнделәр. Ә Саниягә берни булмаган шикелле – үзенең хәлсез юлдашлары тирәсендә бөтерелепме бөтерелә! Айя исә чишмә суыннан соң бик тиз аякка басты.

Иң төп сорауны да Айя бирде:

– Әйбәлисне күрәсегез киләме?

Мәүлет тә, Миндияр да Саниягә күтәрелеп карадылар. Җавапны Сания бирергә тиеш иде, ахры...

– Күрәсебез килә, шулай бит, кадерлем?

Мәүлет хатынының соравын җавапсыз калдырды. Болай да бөтенесе аңлашыла бит инде. Сүзгә Миндияр кушылып, ир белән хатын арасында барлыкка килгән киеренкелекне бушатып җибәрде:

– Күрмәгәннең күрәсе килә, күргәннең качасы килә...

Барысы берьюлы елмаеп җибәрделәр.

Ерак барасы түгел икән. Утыз-кырык адымнар үткәч тә, күзләренә бер утар чалынды. Биеклеге билдән узмаган койма артында бер кечкенә йорт шәйләнде. Буяп, бизәп эшләнгән бу йорт эт оясыннан зуррак булып, авыл ихаталарындагы келәтләрдән кечерәк иде. Алдында болдыр кебек, ярымачык корылма да бар. Анда зур кәнәфи. Тәхет! Әйе, Иблис-Әйбәлис тәхете. Әнә ул үзе! Шул тәхеттә башын артка ташлап, оеп утыра. Кул арасына керә башлаган балалар зурлыгындагы бу курчак, чынлап та, гайрәтне чигерерлек дәрәҗәдә котсыз, килбәтсез иде. Мәүлетнең күз алдына шундук кайчандыр Сания чәч тарап утырганда, көзгедә күренеп алган шайтан сурәте килеп басты. Бу ике хәшәрәт зат, чынлап та, бик охшашлар иде. Бигрәк тә очлаеп киткән колак яфраклары, тирәнгә баткан, пыску торган күмер төсендәге төртке күзләр, кашсыз, сакал-мыексыз, әмма кара тәкләр белән чуарланган, ара-тирә йон баскан чандыр йөз. Ничек кенә шулкадәр дә бөртекләп, җентекләп эшли алдылар икән бу курчак зәхмәтен?! Мәүлет чын-чынлап тел шартлатып куйды. Шушы җансыз, аңсыз чүпрәк галәмәте бөтен тирә-якны куркытып, өркетеп торсын инде, ә!

Ул арада Айя койма кебек үк тәбәнәк капкага барып тотынды.

– Менә ул... Килгәч, аны сәламләргә кирәк. – Кыз, үзе дә сизмәстән, ике учын да алга җәеп, күкрәк турысына күтәрде: –

> Әйбәлис, Әйбәлис!
> Әйбәлиснең исеме бер!
> Сиңа килгән бәндәләрнең
> Асылы бер дә, нәселе бер...
> Бу нигезгә килгән җаннар
> Синең белән көчледер...
> Әйбәлис, Әйбәлис!
> Әйбәлиснең исеме бер!

Шунда әллә нәрсә булды. Көтмәгәндә, аланлыкта салкын җил өермәсе уйнап алды. Җил теге зәхмәти курчак ягыннан исә иде. Койма башларына тотынып, тораташтай басып торган яшьләр төркеме, үзләрен үзләре белештермичә, җиргә бөгелеп-сыгылып төшә башладылар. Сания генә койма башына таянып өлгерде, әләгеп калды һәм бөтен көченә җилкапканы ачып җибәрде. Шул ярсуы белән эчкә үтеп, абына-сөртенә, Әйбәлискә табан китте. Менә ул шайтан

кыяфәтле хәшәрәт курчак каршында пәйда булды. Бермәл тын калып, медер-медер килеп, үзе генә белгән әфсен-догаларны укыганнан соң, нindидер бер үҗәтлек һәм усаллык белән курчакны тәхетеннән йолкып алды да бар булган көченә кизәнеп, сазлыкка таба ыргытты.

Шуннан соң гына үзенә дә, койма буена чүккән юлдашларына да хәл керде. Алар, ихата уртасына җыелып, тәэсирләре белән уртаклаша башладылар. Барысының да йөзе җитди иде. Бераздан Миндиярның сүзләре барысын да елмайтып җибәрде:

– Кичә үлгән булсам, шундый кызыктан мәхрүм кала идем, билләһи! – Үзе Айяны кочагына алган да, башларына төшкән сихердән азат итәргә теләгәндәй, йә аның чәчләреннән сыйпап куя, йә бит очларыннан үбеп ала.

Мәүлет тагын җитдиләнде:

– Моннан тизрәк котылырга кирәк, җәмәгать.

Саниядә борчу тагын да күбрәк. Чөнки ул әле генә күз алдында булган хәлләр хакында күбрәк белә. Менә ул үзалдына сөйләнгән кебек кенә әйтеп куйды:

– Ә бит курчак белән булган хәлләр моның белән генә бетмәде әле. Карый да вакытлыча гына чигенде. Сак булыйк, теге Әйбәлисне табып, тиз генә юк итик. Шунсыз мондагы кара шаукымнан котыла алмаячакбыз. Күңелем сизә: карый үз көчен башкаларга биреп калдырырга тели. Авыл өстендәге җил-гарасат шул хакта сөйли. Әйдәгез, тизрәк табыйк теге нәмәрсәкәйне.

Ул арада Саниянең уйларын сизгән шикелле бая Әйбәлис курчагы атылып-бәрелеп барып төшкән якта тагын җил бөтерелеп алды, күңелгә шом салып, агачлар шаулашты. Аннары нindидер шәүлә күзгә чалынып китте. Бераздан урманны үлем тынлыгы басты.

Таралышып, Әйбәлис-курчакны эзләргә керештеләр. Ләкин ул бер җирдә дә күренмәде. Шунда Сания иң шомлы сүзне әйтте:

– Моннан тизрәк чыгарга кирәк, сихерле урын бу. Эш Иблистә түгел. Менә шушы урында – аста борынгы каберлек бар, һәм андагы кешеләр үз үлемнәре белән үлмәгәннәр. Кайберәүләр табигатькә сыенып, җир белән күк арасында бәргәләнгән рух-әрвахларның шаукымлы көчләрен үз файдаларына кулланганнар. Халыкка коткы таратып, үз тормыш-язмышларын көйләгәннәр. Шул. Әйдәгез, тизрәк кузгалыйк, юкса...

– Нәрсә юкса? Сания, аңлатып сөйлә инде, зинһар. – Гомердә булмаганча, Мәүлет тынгысызлана башлады.

Ләкин Сания җавап бирмәде. Мәүлеткә җитди генә карап куйды да сазлык аша авылга алып чыга торган сукмакка кереп китте.

Ниһаять, Айяның «теле ачылды»:

– Сания апа, мин башта ук әйтеп, кисәтеп бетермәгәнмен. Карыйның малае да сихер белән шөгыльләнә. Хәтта оныгы да. Үләр алдыннан һәр карый үзенең шаукымлы көчен улына тапшырырга тиеш. Карыйның малае – Бәхрәм абзый капка башыннан карап калган иде. Юньлегә түгел бу, Сания апа. Әнә бит нинди җил-давыл кубарга тора.

Сания бу юлы дәшмәде. Җавап итеп, адымнарын гына кызулатты. Ул, ныклы бер карарга килеп, авылның сихерче карты – карый басып калган урам чатына таба ашыга иде.

Карый басып калган урам чатына шактый халык җыелып өлгергән.

Кемдер аны урынынннан кубарып алмакчы була, кемдер, килеп, артына тибеп китә, бертуктаусыз: «Шул кирәк сиңа, мәлгунь, шайтан сыңары!» – дип сөйләнә. Карый һаман шул басып калган урынында тора. Хәлсезлеге йөзенә чыкса да, күңеле тыныч, көр иде аның. Чынлап та, котылып өлгергән, ахры, ул Әйбәлис шаукымыннан, дөресрәге, аны кемгәдер тапшырырга өлгергән, ахры. Саниянең борчулы уйларын белгән шикелле Айя шундук, үрелеп, аның колагына пышылдады:

– Кешеләр әйтә: без урманда чакта карый бабай улына тапшырган үзенең сәләтен, хәзер авылда аның улы карый булачак, ди. Әйбәлисне дә безнең яннан ул алып киткән булырга тиеш...

Сания бер кул ишарәсе белән үк элеккеге карыйны газаплы тормышыннан азат итте. Карт шундук, аяк буыннары йомшап, алга сөртенеп китте. Җиргә сыгылып төшкән картны янәшәдә басып торган берничә кеше күтәреп алды да култыклап, өенә алып китте. Аның урынын Сания алды. Җыелган халык кузгалышып, үзара сөйләшеп, шаулашып алды. Ара-тирә «Сихерче», «Имче-томчы», «Шаукым иясе» дигән сүзләр ишетелеп калды... Сания аларга игътибар итмәде, салмак, хәтта сабыр, йомшак тавыш белән сүз башлады:

– Бернинди Әйбәлис тә, Иблис тә юк, җәмәгать. Аның әмерләрен үтәп, башыгызны катырып, күңелегезне борчып яшәмәгез. Урмандагы шаукымлы урыннар бүтән сезне саташтырмасын. Анда кермәсәгез, тагын да яхшырак булыр. Үз авылыгызда тыныч кына яшәгез: балалар үрчетегез, иген игегез, йортлар җиткерегез, туйлар ясагыз, бәхетле булыгыз! Ә карыйлар нәселеннән читләшегез. Алар үзләренчә яшәсен, аларда шаукым галәмәте бар-барын, ләкин, үзегез теләмәсәгез, алар сезне көчләп үз секталарына алып керә алмаячак. Хәл-әхвәлләрегезне Айя аша белешеп торырмын. Онытмагыз: һәр кешедә шаукымга каршы торырлык кына көч, тылсым-магия бар, иманыгыз нык булса, бабаларыгызның нәсел көче җитәрлек булса, сезнең авылга да җанлы тормыш кайтыр. Шайтан, Иблис коткысына бирешмәссез, иншалла. Исән-имин яшәгез, бәхетле булыгыз, туганнарым!

**26**

Казанга кайтканчы сөйләшмәделәр. Миндиярга аеруча ямансу иде. Чөнки Айясы авылда калды. Шулай кирәк булды. Ул анда хәзер авыл советы да, мөгаллим дә, имам да. Кара хорафат аңкып торган шомлы хәятта үз эчләренә йомылып беткән авыл кешеләре арасында аңлату эшләре алып барырга тиеш.

Миндияр да калырга теләгән иде. Сания кырт кисте:

– Синең белән үз миссиясен башкара алмаячак ул. Игътибары читкә китәчәк, күңеле таркалачак. Рөхсәт юк. Халык белән үзе аңлашып бетерсен әле башта. Яңа карый белән дә уртак тел тапсын. Ничек кенә булса да, бер нәсел кешеләре бит. Ләкин халыкны бу Әйбәлис-Иблис сазлыгыннан алып чыгарга тиеш ул! Ә без кайтып торырбыз, булышырбыз. Мәүлет, сиңа зур эш бар: бу авыл хакында район хакимиятенә хәбәр итәргә кирәк, бәлки әле таныш депутатларың аша эш йөртерсең. Болай булмый бит инде. 90нчы еллардагы башбаштаклыклардан соң да шактый вакыт үтеп бара. Инде иң кара авылларда да мәктәпләр торгызылды, авыл советлары эшли башлады, ә монда һаман Иблис коткысына тиң зәхмәтле шаукымнар хөкем сөрә.

Шулай килештеләр. Айя еламсырап торып калды, калганнар өч чакрым читтәрәк урнашкан олы юлга юнәлделәр. Гел уңайга килеп торды: трассага килеп чыгу белән, яннарына галәмәт зур автобус килеп туктады. Хикмәти Хода, автобус салоны буш иде. «Мондый ыгы-зыгы вакытында олы юлда буш автобуслар да йөрер икән», дип уйлап алды Мәүлет, үзе, җавап эзләгәндәй, машина йөртүченең баш очындагы көзгегә күтәрелеп карады. Шофёр таныш кебек тоелды Мәүлеткә. Каян таныш булсын ди?! Әллә кайдагы юл чатында иң беренче очраган лабаса ул!

Егетләргә тик утырырга кушып, Сания акча түләп килде. Көлеп-елмаеп киткән хатын шактый уйчанланып, хәтта нидәндер шөбһәләнеп, шомланып килде. Ләкин авыз ачып, бер сүз әйтмәде, машина тәрәзәсе аша офыктагы нindидер билгесез бер ноктага төбәлеп утыруында булды.

Казанга килеп кергәч, автобус иң беренче урам чатында ук туктап калды. Урта ишек ачылды. Берәм-берәм җиргә сикерделәр. Иң ахырдан кузгалган Мәүлет, төшәр алдыннан, машина йөртүче кабинасына үрелеп карады. Менә хикмәт: анда беркем дә юк иде. Мәүлетнең йөрәге жу итеп китте, җаны табанына төшеп ятты. Нинди галәмәт бу – автобус шофёрсыз гына кайткан лабаса! Ә бит анда кеше бар иде. Һәм ул кемгәдер бик охшаган да иде! Ыспай гына киенгән, күзләренә алтын кысалы күзлек элгән, кара чәчле, кара мыеклы чибәр ирне тагын кайда күргәне булды соң? Ә! Иң элек мунчада күрде ул аны, аннары Балалар йортында Санияне көткәндә. Әле аңа кадәр банкта очраган иде, кибеттә, базарда. Хәтта әчкечеләр яныннан кайтканда, автобуста аның өчен билет алган иде! У-һу, Мәүлет булган бар җирдә дә очрап торган лабаса бу бәндә! Урам буйлап барганда, Мәүлет үз шик-шөбһәләре хакында Саниягә дә әйтте. Хатын бер көлде, бер кара янды:

– Автобусның шофёры, чынлап та, безнең таныш булып чыкты бит. Безне алып кайтырга махсус килгән, диярсең. Сине белә, әмма бу хакта сиңа әйтергә кушмады. Билет алганда сөйләшеп алган иде. Бик сәер бу, бик сәер. Шундый тойгы: ул бар да, юк та. Рухлар белән, җеннәр белән шулай була, аннары...

– Нәрсә, аннары, Сания?

– Аннары, шайтаннар белән... – Сания әйтте исә кайтты, теманы тиз генә алыштырырга булды: – Безне өйдә сагынганнардыр инде, тизрәк кайтырга иде. Трамвайлары да сирәк йөри, ичмасам.

Сания шайтаннар хакындагы сүзне озайтып тормаса да, Мәүлетнең күңеленә олы бер шик кереп оялаган иде инде. Ул баягы сорауны бирми кала алмады:

– Син ничек уйлыйсың – автобус шофёрдан башка гына йөри аламы?

– Син ни сөйлисең, Мәүлет! Автобус ничек инде йөртүчесез генә йөри алсын?!

– Кайда иде соң ул? Безнең машинада шофёр урыны буп-буш иде бит.

– Без чыгарга кузгалганчы ук сикереп төшеп, тәгәрмәчләрен типкәләп йөрде ул. Мәүлет, их сине! Чын шофёрлар шулай эшлиләр: ерак юлдан кайтсалар, тәгәрмәчләрен карап йөри башлыйлар, берәр нәрсә булмаганмы, янәсе.

Шунда гына Мәүлет бик арыганын тойды. Тәне белән дә, зиһене белән дә нык талчыкты ул. Ураза вакытында көннәр буе бер тәгам ризыксыз, бер йотым сусыз йөрүнең никадәр кыен булуын белсә дә, ул бүген изге йоладан

баш тартмаска булды шул. Әле авыз ачарга да хәтсез вакыт бар. Миндиярга нәрсә! Ул бүген, ерак юлга сылтау итеп, уразага кермәде, әнә, автобустан төшкәч тә, чат саен очрап торган киосклардан инде берничә мәртәбә су эчеп килде. Сания уразага кермәсә дә, түзде, Мәүлетне үртәмим диптер инде, авызына тамчы су да капмый йөрде.

Хәлсезлектән, талчыгудан котылырга теләп, Мәүлет тагын теге таныш та, таныш түгел дә кеше турында уйларга кереште. Кем соң ул – Мәүлетнең юлында очрап, ярдәм итәргә әзер булып торучы изге кеше? Беренче тапкыр кайда күрде соң ул аны? Ә менә нәкъ шул көнне Мәүлет төгәл хәтерли: теге хикмәтле төшен күреп, Шәмси карттан шул төш хакында сорашырга урамга чыккач күрде ул бу күзлекле, димәк ки, зыялы бәндәне. Әйе шул, Шәмси карт белән сөйләшеп тора иде ул. Берәр танышы булды микәнни? Ишектән атылып диярлек килеп чыккан Мәүлетне күргәч, ул итагатьле генә саубуллаша башлады. Менә ул, Шәмси картка йомшак кына кул биреп, тизрәк китү ягын карады. Шуннан соң бу сәер кеше гел күренеп торды аның тормышында. Бәлки, ул үзен шулай махсус күрсәтеп торгандыр. Юк ла, җаны-тәне ураза сынавында булып, хәлсезлектән газапланса да, әллә нинди саташулы әкиятләр уйлап чыгарырлак дәрәҗәдә түгелдер бит инде?! Нигә булмасын?! Әнә бит: өч акыллы зат, дөнья мәшәкатьләре хакында да онытып, хәтта үз сабыйларын ташлап, Иблис курчагы артыннан ярты дөньяны гизеп кайтып баралар. Дөнья шулайрак икән шул: анда әкият белән чынбарлык укмашып, керешеп беткән, хәтта кайсы чын, кайсы уйдырма, миф икәнен дә төгәл генә белүе, чамалавы кыен. Бигрәк тә теге хикмәтле төштән соң зиһене буталды, уйлары чуалды Мәүлетнең. Ничек кенә яңадан рәткә салып, тәртипкә китереп бетерергәдер бу зиһен шүрлеген?!

Балаларга Шәмси картның карчыгы Зөлләә әби күз-колак булып торырга тиеш иде. Бу кечкенә дә төш кенә әбекәй бик бала җанлы карчык булып чыкты. Көне буе балаларны өф итеп кенә тоткан. Рәхәтләренә түнеп, изрәп йоклап ятучы балаларына карап, Сания белән Мәүлет сөенечләреннән ике яклап килеп кочаклап алдылар Зөлләә карчыкны.

– Сез карап торган өчен без күпме тиеш? – дип сорады Мәүлет, учларын түш кесәсенә таба шудыра башлап.

– Һи-и, нинди түләү ди?! Мин үзем акча бирер идем әле шундый да сылу, инсафлы сабыйлар белән берникадәр вакыт яшәү мөмкинлеге биргән өчен. Үзебезгә балалар, оныклар үстерергә насыйп булмады шул. Булмады!.. – Яулык чите белән күзләрен сөртергә керешкән карчыкны яшьләр тынычландырырга ашыктылар. Мөмкинлек чыккан саен аны балалар янына чакырырга сүз бирделәр.

Зөлләә карчык чыгып киткәч, икесе дә дәррәү балалар йоклап яткан түшәк янына килделәр, бер-берсенә сыенышып, бик озак аларның тигез сулыш алуларына, ара-тирә генә сискәнеп, дертләп куюларына, аннары алсу йөзләрен киң җәеп, елмаеп җибәрүләренә карап тордылар. Ниндидер, әлегә бик үк таныш түгел бәхетле мизгел иде бу. Бәхетнең яңа хисе, тоемы, юк-юк, бәхетнең үзе иде бу!

Сания, иелеп, балалар өстендәге япманы рәтләп куйды да күтәрелеп, Мәүлеткә карады. Аның карашларында баягы бәхет чаткылары чагыла иде. Юк, ул гына да түгел, тагын нидер бар бу карашларда, серле мәгънә бар.

Аның артында шом тора, әмма ул шомлылык кына баягы бәхет хисен баса алмый, чөнки бу хис, бу тоем зуррак һәм мөһимрәк. Ләкин ул шом-шөбһәдә, кинаяле сагаю бар бит! Ничек кенә күрмәмешкә тырышсаң да, бар!

Мәүлет Саниянең карашларына үзенең җылы, мәхәббәтле карашлары белән җавап бирде, хатынының күңелен борчып торган кинаяне, шик-шөбһәне юып ташларга теләде. Ләкин Саниясенең карашлары көчлерәк иде. Мәүлет моңа аптырамый да. Үзе сайлаган язмыш лабаса: ул бит үзе теләп шаукым белән эш итүче кызга өйләнде. Һәм үкенми дә, чөнки белә: Сания үзенең сихри көчен бервакытта да Мәүлеткә зыян китерерлек итеп кулланмаячак.

Менә бу юлы да беренче булып Мәүлет биреште. Саниясенең якты, әмма шактый гына авыр карашыннан күзләрен читкә алды, ләкин икенче мизгелдә үк кабат хатынының күзләренә күтәрелеп бакты:

– Сания, кадерлем, нәрсә булды бүген?

Сания тиз генә җавап бирмәде. Керфекләрен дә кузгатмыйча, һаман Мәүлетнең мөлдерәмә күзләренә карап торуында булды. Ләкин бу тынлык озакка бармады, шулай тутырып карап торган килеш, Сания үзалдына гына, хәтта ярымпышылдап әйтеп куйды:

– Бүген без Иблисне күрдек, Мәүлет.

Хатынының әйткәннәре Мәүлеткә берничек тә тәэсир итмәде. Ну, күргәннәр, ди. Шуннан? Ләкин бит ул Әйбәлис чын Иблис түгел! Әлбәттә, шаукым галәмәте, әмма Иблис үзе түгел! Бу бит инде ачыкланды. Нигә авыз суы корытып сөйләп торырга?!

Мәүлетнең уйларын бүлеп, һаман әле бер ноктага төбәлеп карап торучы Сания тагын кабатлады:

– Әйе, Мәүлет, без Иблиснең үзен күрдек.

Бу юлы инде Мәүлет сүзнең Әйбәлис курчак хакында гына бармаганлыгын аңлап алды. Анысын аңлады аңлавын. Тик менә нәрсә хакында сүз барганына төшенеп бетә алмады.

– Сания аңлатып сөйлә әле, үзең дә Әйбәлис шаукымы ияртеп кайтмагансыңдыр бит? Күзләрең дә башкача карый, уйларың да сәер... Ташлале шул сихер-михереңне! Әйдә сабыйларыбыз белән матур гына яшәп китик...

– Син дә күрдең аны, Мәүлет...

– Кемне, нәрсәне?

– Иблисне.

– Ә? Иблисне? Син чынмы? Мин бит сине шаяртасың дип торам.

– Син дә күрдең, Миндияр да, барыбыз да күрдек. Аны элек тә күрә идек, бу юлы чынлап төшендем: шул – Иблис!

Мәүлет нидер аңлый башлады. Күңелләренә кара шом иңдерерлек кемне күрделәр алар бүген? Кемне? Бүген күргәннәре Мәүлетнең күз алдыннан яшен тизлегендә үтеп китте. Әйбәлис авылындагы хәлләр, карыйлар нәселе язмышы, юлдагы хәлләр. Машина йөртүченең кинәт кенә юкка чыгуы. Әһә! Менә шушы урыннан җентекләбрәк карыйк әле бу «кино»ны! Сәерлеге бар, әлбәттә! Элек тә күргән кебек. Ләкин, барыбер, күңел ышанмый, очраклы гына килеп чыккан автобус шофёры ничек Иблис тикле Иблис булсын инде?!

Сания аның уйларын укып бара иде.

– Бу очраклы хәл булмады, Мәүлет, аның безне шәһәргә алып кайтуы махсус оештырылган иде. Аңлыйсыңмы – мах-сус!

Яңа, көтелмәгән ачышларыннан, авыр уйларыннан аяк буыннары йомшап, икесе дә өстәл янына чүктеләр. Ләкин бер-берсеннән карашларын алмадылар. Мәүлет төгәл белә иде: әгәр карашын хатынының күзләреннән алса, ул шундук акылыннан язачак. Алла сакласын!

Бераз тын калып утырдылар. Тынлыкны тагын Мәүлет бозды:

– Бер дә ышанасы килми бит, Сания, Ул шундый ярдәмчел, зыялы, чыпчын интеллигент инде менә! Йөзен кара инде, киемнәрен, үзен тотышын. Үз итми, яратмый мөмкин түгел андый кешене!

– Шуңа күрә Иблис бит инде ул. Йөз-кыяфәтен, хәтта холык-фигылен бер мизгелдә мең мәртәбә үзгәртә ала. Шулай да, син хаклы, ниндидер сәерлек, серлелек бар бу бәндәдә. Ләкин минем эчке тоемым, дөресрәге, Ходай тарафыннан бирелгән сәләтем бер әйбер хакында төгәл хәбәр итә: безне бүген Иблис алып кайтты. Мин хәтта шул хакта да кистереп әйтә алам: кая гына барсак та, бигрәк тә син кайда гына булсаң да, ни генә эшләсәң дә, ул сине күз уңыннан ычкындырмаган, шуңа да ул сиңа таныш, чөнки гел күз алдыңда булган. Минемчә, ул моны махсус шулай эшләгән һәм хәзер дә шулай эшли. Ни өчен – әлегә әйтә алмыйм. Монда ниндидер сер бар. Нәкъ менә шушы урында зур сер бар. Чынлап та, ни өчен ул үзенең барлыгын, хәтта үзенең яман нияттә булмавын гел искәртеп тора? Әллә шулкадәр дә хәйләкәрме ул? Безнең алда күз буямакчы буламы? Ышанычыбызны яулап, рухыбызны, язмышыбызны агуламакчымы? Тагын берәр коткы ниятлиме?

Бу сөйләшүнең очы-кырые булмавын, һаман катлаулана баруын аңлап, Сания чәй өстәле әзерләргә кереште, Мәүлет тәһарәт алырга юыну бүлмәсенә кереп китте. Юынган вакытта намаз алдыннан укыла торган догаларын яңартты. Әйе шул, бүгенге сәфәрдә җан-йөрәкләренә төяп алып кайткан авырлыктан, коткарса да, Коръән кәлимәләре, якты дога гына коткарып калыр кебек иде.

**27**

Моннан соң Мәүлет, кая гына барса да, ни генә эшләсә дә, һушын җыебрак, тирә-ягына караныбрак йөри башлады. Тагын очрамасмы теге күзлекле кеше? Аллаһы Тәгалә тарафыннан Җир өстенә кешеләрне сынау өченме, аларның рухын сындыру, имгәтү өченме җибәрелгән бу фәрештәдән башка ул инде үз тормышын, хәтта язмышын да күз алдына китерә алмый иде. Сания аңа якын барырга кушмаса да, шушы бер ай эчендә күңелен биләп алган «Иблис тойгысы» аның төп күңел халәтенә, Коръән битләрендә каргалган шушы рухани зат белән очрашу, аңлашу аның яшәү максатына әверелгән иде.

Шул бәхәссез: Мәүлет эзләп таба алмаса да, теге күзлекле кеше кыяфәтендә йөрүче Иблис мәлгунь бервакыт үзе аңа ишарә бирәчәк. Шунсыз булмый. Мәүлет-Иблис тарихы уйлап чыгарылган икән инде, аларның язмышлары һәрвакыт янәшә һәм тәңгәл барырга тиеш. Ә янәшә тәңгәл барган юллар барыбер бер очраша, кисешә ул!

Шулай булды да. Әйбәлис сәфәреннән соң бер атна уздымы-юкмы,

көтмәгәндә каршысына килеп чыкты ул Мәүлетнең. Мунчадагы сменасыннан чыгып, якындагы кибеткә кереп чыгарга уйлаган иде, урамның каршында такси машинасы туктады, аннан теге икейөзле Иблис чыкты. Дөрес, бу очракта да ул зыялы, тәрбияле, пөхтә һәм заманча киенгән чибәр ир-егет кыяфәтендә иде. Күзлеге дә үз урынында. Менә ул машина йөртүчегә тиешле акчасын түләде дә йомшак кына ишекне япты һәм, башын күтәреп, нәкъ менә Мәүлет басып торган якка күз сирпеп алды. Кыска гына бер мәлдә аларның хәтта карашлары очрашкан кебек булды. Аннары, берни булмагандай, башын барасы юл ягына борып, ашыкмыйча гына китеп барды. Мәүлет, бертуктаусыз машиналар тыз-быз килеп торган юл аркылы чыга алмыйча, баскан урынында таптанып калды.

Соңыннан светофор аша чыгарга рөхсәт биргәч, шактый урап йөрде ул Иблис кереп киткән урамны. Ләкин бу көнне аларның юллары бүтән кисешмәде. Аның каравы, берничә көннән колхоз базарында очратты ул аны. Иблис диясе дә килми, якыннан тагын да чибәррәк һәм мөлаемрак ир булып чыкты ул. Мәүлет зур капка-ишектән килеп кергәндә, аны гына көткән кебек, залның аргы башында төбәлеп карап тора иде. Базар кайгысын да онытып, Мәүлет аңа таба китте. Ләкин, барып җиттем дигәндә генә, аны кемнәрдер сырып алды. Аларның җанлы әңгәмәсен бүләсе килмичә, Мәүлет бер читкә барып басты. Аның каравы, туган кебек якынаеп киткән бу кешене өйрәнергә җай чыкты. Менә шунда аның иң соңгы, беленер-беленмәс кенә торган йөз чалымнарына кадәр өйрәнде дә инде Мәүлет. Чибәр, пөхтә, хәтта артык пөхтә, аеруча костюмы-галстугы бик килешеп тора үзенә, кулындагы кечкенә сумкасы аны зыялы гына түгел, шактый эшлекле итеп күрсәтә. Йөзе яшь, чәчләренә аз гына чал куна башлаган, күзләре күк төсендә, кашлары... Ә менә кашлары сыек, әллә инде бөтенләй дә юкмы? Күзлеге дә булмаса, кашсыз, аның йөзе шактый сәер күренер иде.

Үзе кем беләндер сөйләшә, үзе Мәүлет ягына карап-карап ала. Аның да, тизрәк әңгәмәсен өзеп, Мәүлет белән күрешергә, сөйләшергә, аңлашырга теләве әллә каян күренеп тора.

Шунда кемдер Мәүлеттән вакытның күпме булуын сорады. Мәүлет, сәгатенә карап, минутына кадәр төгәл итеп җавап бирде һәм тагын күзлекле кеше ягына күтәрелеп карады. Күзлекле кеше дә, аны уратып-сырып алган базар әһелләре дә урыннарында юк иде инде. Мәүлет анда омтылды, монда эзләнде, әмма теләгән кешесен таба алмады.

Иблис булырга мөмкин күзлекле кеше хакында кайтып әйткәч, Сания, бер дә исе китмичә генә:

– Бер дә борчылма, ул сине үзе эзләп табачак. Димәк, сәгате сукмаган булган. Ә бит һәр очрашуның вакыты була. Гомерең озын булыр, син моңа мең мәртәбә инанырсың әле, – диде.

Чынлап та, эзләп тапты ул аны. Көтмәгәндә. Искәрмәгәндә.

Кайсыдар тукталышта автобус көтә иде Мәүлет. Тик утырганчы дип, кесәсеннән алып, көз көне укырга барачак мәдрәсәнең имтиханнар программасын карый башлады. Автобус һаман килмәде. Кеше шактый җыелып өлгерде. Яшьләр. Бу тирәдә институтлар күп. Укырга керү, имтихан бирү мәшәкатьләре белән йөриләрдер, мөгаен. Мәүлет тукталыштагы

кешеләрне җентекләбрәк өйрәнергә кереште. Соңгы вакытта бу аның гадәтенә кереп китте. Теге күзлекле кеше килеп чыкмасмы, күренмәсме? Ул зыялы бәндәне Иблис дип әйтергә дә тел әйләнми. Күзлеклеләр бар. Хәтта аңа охшаган ир-атлар да бар. Әмма ул юк. Бүген дә күренми...

– Син мине эзлисеңме?

Мәүлет сискәнеп китте, як-ягына каранды. Әмма янәшәсендә беркемне дә күрмәде. Ике якта да урыннар буш иде...

– Кем... Кем дәште миңа? Кем син? Син кайда?..

– Мин... Мин яныңда утырам.

Мәүлет арырак йокымсырап утырган карчыкка үрелеп карады. Юк, ике дөнья чигендә яшәп ятучы әби тавышы түгел бу. Икенче ягында да күренмәде тавыш иясе, анда бер кыз белән егет кызып-кызып ничек имтихан бирүләре хакында сөйләшәләр иде. Ә менә черем итеп утыручы әби белән икесе арасында урын буш, тавыш шуннан килә дә.

– Син кем? Шаярма, дим.

– Ә хәзер күрәсеңме?

Буш урында Мәүлетнең эзләгән кешесе – күзлекле ир-ат пәйда булды. Елмаеп торган була бит әле. Үзе елмая, әмма йөзе, күзләре елмаймый. Кешечә түгел бу. Кеше түгелдер бу... Каян кеше булсын! Сания аның Иблис икәнлеген күптән фаш итте бит.

– Күрәм. Алайса, син – мин эзләгән кеше инде? Кеше дип...

– Әйе, син эзләгән кеше. Кеше дип... Кем булуымны беләсең. Ләкин мине мәлгунь итеп таныткан исемне генә атама. Иблис димә. Мин фәрештә булып яралдым һәм минем үз исемем бар. Әйдә таныш булыйк: Газазил.

Телсез калып, зиһенен чак җыеп торган Мәүлеткә, җавап итеп, кул сузарга гына калды:

– Мәү-лет.

– Менә таныштык та. Хәзер безгә сөйләшергә кирәк. Бу – сөйләшү урыны түгел. Әйдә әнә теге бакча буена. Анда, аулакта, эскәмияләр күп. Беркем дә комачауламас. Курыкма, мин сиңа бармак очы белән дә кагылмам. Вәгъдә – иман!

– Иман? Син ничек ул сүзне әйтә аласың?

– Борчылма, Мәүлет. Хәзер шул хакта сөйләшәбез. Әйдә киттек. Мине әнә шул бакча почмагында барып табарсың.

Теге бәндә ничек пәйда булса, шулай ук юкка да чыкты. Мәүлет исә тиз генә кузгалып китә алмады, бу көтелмәгән очрашу тәэсиреннән аңа һушын җыярга кирәк иде. Уен эшмени – Иблиснең, әй лә, Газазилның үзен тапты бит ул, дөресрәге, Газазил үзе аны тапты. Бәлки әле, ул – бу ләгыйнь зат белән очрашкан беренче кешедер? Менә бит нинди тарихи очрашу! Хәерлегә генә булсын иде! Иблис тикле Иблис белән очрашу алдыннан ниндидер дога да укырга кирәктер инде...

Күзлекле ир-ат аулак урындагы бер эскәмиядә аны көтеп утыра иде инде. Ул Мәүлетне аягүрә басып каршы алды.

– Кайткач, әле генә укыган догаңны тагын бер тапкыр кабатлап, өйрәнеп чык. Гарәп телендә бер хәрефнең нечкә йә калын әйтелүе дә мәгънәне капма-каршы якка үзгәртергә мөмкин. Син аны үзең дә беләсең.

– Син мине дога өйрәтү өчен чакырмагансыңдыр бит?

– Сабыр бул, Мәүлет, башкалар әйткәнне кабул итәргә өйрән. Хәтта ул әйткән кеше Иблис булса да.

– Кабул иттем, кем... Газазил.

– Дөрес эндәштең. Менә хәзер сөйләшергә дә була.

– Йә, тыңлыйм. – Мәүлетнең әле һаман сер бирәсе килми иде бу җәһәннәм кисәвенә. – Сүзең нәрсә хакында?

– Әйтик... синең хакта.

– Минем хакта?

– Әйе, иң элек синең хакта. Әлбәттә, минем хакта да. Аннары дөнья барышы, яшәештәге вазгыять хакында.

– Сүзең бик зурдан икән.

– Зурдан. Тыңла. Сиңа минем хакта төшеңдә хәбәр иттеләр, шулаймы? Хозыр бабай үз эшен төгәл башкарды. Ул – ике дөньяда да, ягъни фанилыкта да, бакыйлыкта да яши ала торган, бер дөньядан икенчесенә кереп-чыгып йөри ала торган бердәнбер илаһи зат. Раббыбыз аңа шундый мөмкинлек биргән. Ә ике дөнья арасында күпер бар. Ул – төш. Менә шул төш аша кешелек дөньясында бик күп хәерле гамәлләр кылына. Хозыр-Ильяс кылган гамәлләр – иң изгеләрдән санала. Сез, кешеләр, аны юл хуҗасы буларак та хөрмәт итәсез. Юл – шул ук төш инде ул. Фанилык белән бакыйлык арасындагы юл. Шул төш аша сиңа да, миңа да хәбәр килеп ирешәте. Шулай итеп, минем хакта Җиргә хәбәр җибәрелде. Бу хәбәр меңләгән кеше төшендә игълан ителгән булса да, бер син генә аны күңелеңә алдың, мине эзләп, дөньяга чыгып киттең. Шул минутта мин сине эзләп таптым һәм күз уңыннан ычкындырмадым. Төш юраган вакытта Саниягә дә мин көч биреп тордым.

Ә хәзер сүз минем хакта. Ни өчен минем хактагы хәбәр Җиргә шулай ашыгыч рәвештә игълан ителде соң? Җавап бирәм: Раббыбызның ихтыяры шундый иде. Шулай кирәк иде. Дөнья киңлекләрен фетнә һәм афәт рухияте, Җир өстен гөнаһ шомлыгы баскан бер мәлдә, хәятебездә шәфкатьсезлек, бозыклык, хөсетлек, ялган, нәфрәт көчәйгәндә, һәрвакыт минем хакта хәбәр игълан ителә. Мең ел элек тә шулай булган, йөз ел элек тә, хәзер дә бөтен кара эшләр миңа сылтана. Юк, моңа минем тамчы да ачуым килми. Чөнки бу – минем язмыш. Минем бурыч, минем миссия! Мин булмасам, бу урында башка бер фәрештә булыр иде. Кемдер кешеләр игътибарын изгелек белән явызлык арасындагы каршылыкка, көрәшкә җәлеп итәргә тиеш бит инде! Раббыбыз миңа бу язмышны, миссияне Адәм белән Һәуа балаларын сынау өчен махсус тапшырды. Чынлыкта, инсаннарны Кыямәт көнендә оҗмахка яисә тәмугка билгеләү өчен Иблис коткысы кирәк булды. Кем шул сынауларны үтә – оҗмахка элә, кем үтә алмый – тәмуг утында яна! Мин, ГАЗАЗИЛ – Аллаһның иң гайрәтле, укымышлы һәм талантлы фәрештәсе — Раббыбыз кушуы буенча төшеп, шаукымлы коткымны таратып, Җир тормышына мәгънә бирдем, яшәү мәгънәсе! Ә яшәү ул – көрәш, оҗмахка эләгү өчен көрәш, һич тә булмаса – тәмугка эләкмәү өчен көрәш! Мин кешеләргә кеше булып калырга, үзләренең чын, ихлас, иманлы кеше булуларын дәлилләргә мөмкинлек бирәм. Аңлыйсыңмы шуны, Мәүлет хәзрәт?!

Мәүлет бу күзлекле ир-ат сөйләгәннәрдән берни дә аңламады. Әмма бар зиһен байлыгы һәм йөрәк ярсуы белән тойды: эшләр монда бик җитдигә

китеп бара икән бит! Кешелек язмышы, конкрет кешеләрнең фанилыктагы һәм бакыйлыктагы язмышлары хакында сүз бара лабаса!

– Аңладым, әмма уйлап бетерәсе бар.

Ә күзлекле кеше (аны һаман әле Иблис дияргә дә, Газазил дияргә дә тел бармый) Мәүлетнең ярымпышылдап әйткән сүзләренә игътибар да итмәде, үз фәлсәфәсен дәвам итте:

– Менә мине кем дип уйлыйсың? Иблис дипме? Газазил дипме? Дөресен генә әйткәндә, мин үзем дә төгәл генә белмим: күбрәк мин кем – Иблисме, Газазил фәрештәме? Ә бит мин, чынлыкта, Газазил булып, күктә – Аллаһ катында яшим, ә Иблис булып Җирдә гомер сөрәм. Шулай да мин үземне күбрәк Газазил итеп хис итәм. Мин бит башта ук фәрештә итеп яратылган. Газраил, Җәбраил, Микаилләр белән бер уттан яратылган. Балчыктан әвәләнгән Адәм хәзрәтләре һәм аның җариясе Һәуа белән килеп чыккан аңлашылмаучылык – кешелекне тудыруга, аны Җиргә иңдереп яшәтүгә, язмышлы итүгә кирәкле мөһим этәргеч, сылтама, дәлил генә. Чынлыкта, мин – кешелектән башка беркем түгел, ә кешеләр миннән башка яши алмыйлар. Башта ук шулай уйланылган. Сезнең заман теле белән әйтсәк: шундый илаһи проект бу! – Күзлекле кеше бераз тын калып торды. Авыр сулап куйды да сүзен дәвам итте: – Бер проект та камил түгел. Һәм безнең илаһи проект та кимчелекле булып чыкты. Беренчедән, кешеләргә золым, яманлык, бозыклык ныграк ошый икән. Мин көрәш рухы булсын дип кенә җибәргән коткыларны алар тормыш девизы, яшәү кредосы итеп алдылар, байрак итеп күтәрделәр. Яшәү, тәрбия, әхлак тәгълиматларын шул мин иңдергән, бер-береңне күралмауга, хөсетлеккә корылган коткы фәлсәфәсенә көйләделәр. Аерым дәверләрдә явызлыкның өскә калкып чыгуы, тормышның асылын, мәгънәсен билгели башлавы нәкъ шул хакта сөйли. Сезнең чор белән дә шулай килеп чыкты: күз алдыгызда илләр таркалды, тигезлеккә, хаклыкка, иминлеккә корылган идеяләр җимерелде, фетнәләр күбәйде, кайдадыр сугыш уты кабынып китте, йөзәрләгән, меңәрләгән корбаннар җиргә түшәлде. Иң мөһиме, кеше кешелек асылын югалта башлады. Бер кеше – икенчесеннән, бер халык – икенчесеннән үзен өстен куйды. Һәм менә шул мәлдә мин үземнең миссиямне игълан иттем, кайчандыр үзем үк Җиргә иңдергән коткы тарафдарлары белән көрәшкә чыктым һәм менә сине дә үземә ярдәмгә чакырдым.

Шулай итеп, яңадан Җир йөзендә пәйда булдым. Үзем дә аптырадым: мин юкта монда шайтаннар армиясе шулкадәр үрчегән, һәм, иң кызыгы: аларның инде миңа бер катнашы да юк. Әйе-әйе, кайчандыр мин коткы салып калдырган шайтаннарның эзе дә юк, бүгенге шайтаннар – шул ук кешеләрнең, шул ук җеннәрнең бозык иярченнәре генә. Монысы да Раббыбызның ихтыяры: мин, Иблис мәлгунь була торып, кабат үземнең илаһи асылыма кайттым, шушы үзем тудырган, тәрбияләгән шайтаннарның бозык иярченнәренә каршы көрәшергә тиеш булдым! Көлке түгелмени?! Көлке түгел, чөнки кешелек бик зур ике афәт алдында тора: аларның берсе – ата-аналы, бала-чагалы гаиләә мохитенә каршы килә торган әхлак һәм атом-төш сугышына әверелеп, Җирдәге бар тереклекне юкка чыгарачак Бөтендөнья сугышы. Шуңа да мин монда. Шуңа да син монда.

– Ә ни өчен – мин? Мин бит – иң гадәти банщик. Һич аңламыйм...

– Син – Раббыбыз каршында илаһи сынауны үткән бердәнбер кеше. Син дөньяга яный торган афәтләргә битараф калмадың. Яманлыкны фаш итәргә алындың, явызлыкка каршы күтәрелдең.

– Анысын арттырасың инде, кем... Иблис агай... әй лә, Газазил. Нинди көрәш инде ул?! Кая гына барсам да, анда йөрәк асларында Иблис коткысын йөртүчеләрне табармын, Иблисне, аның иярченнәрен фаш итәрмен, шуның белән аларны җиңәрмен кебек иде. Юк шул, алай ук гади түгел икән дөнья. Мин яманлык юрап барган урыннарда чын, ихлас, хәтта изге затлар табып, шаклар катып йөрдем. Хәтта мәңге айнымый торган исерекләр арасында да, зиначылар, алдакчы сатучылар, иләс-миләс шагыйрьләр, фәкыйрьләр, сугыш чукмарлары, халык тарафыннан мең мәртәбә каргалган чиновниклар, депутатлар арасында да шайтанның үзен очрата алмадым мин. Ә инде юраучы-имче кыз минем сөйгәнемә, хатыныма ук әверелде.

– Беләсеңме – ни өчен шулай?

– Юк. Белсәң – әйт. Ни өчен?

– Чөнки Иблисне дә, шайтанны да, җенне, албастыны да син кешеләр арасында таба алмаячаксың. Аллаһыбыз аларны кеше күзеннән яшергән, ә менә аларның сыйфатларын үз рухларына һәм табигатьләренә ягарга, димәк ки, язмышларына алырга, шуның белән үзара көрәш һәм сынау вазгыяте тудырырга мөмкинлек биргән. Бу вазгыятьтә Аллаһы Тәгалә кеше кешелеккә һәм иманга кайтсын өчен бөтен шартларын тудыра, бөтен юлларын һәм догаларын ача. Син яманатлары чыккан кешеләр янына әнә шул сынау вакытларында баргансың, бәхетеңә, аларның күбесе синең алда акланган, ул сынауны үтә алган.

– Туктале, син татарча каян беләсең соң? Гомумән дә, бу мөһим проектыгызда нигә татарларны сайладыгыз? Мине, мәсәлән?

– Әйттем бит инде – сез аны үзегез сайладыгыз. Син үзең сайладың. Димәк, сезнең халыкта эчке рухи көч-егәрлек, дөньяви гакыл һәм имани акыл бик көчле. Ә бу гакыл һәм акыл зур сынаулар үтеп кенә, язмышка тиң югалтулардан, җиңелүләрдән һәм данлы җиңүләрдән соң гына барлыкка килә ала. Үз дәүләтен югалтып та, дөнья тота алган халыклар икәү генә иде Җир йөзендә. Аларның берсе кабат үз дәүләтләрен төзи алды, ә сезгә әле бу максат куелган гына. Бәлки, шуңа күрә дә сезне сайлаганбыздыр? Шуңа күрә дә бүген мин синең белән сөйләшеп утырамдыр? Ә сөйләшүебезнең теленә килгәндә, бу бик гади: фәрештәләр кем белән аралашалар – шуның телендә сөйләшәләр. Бу – безнең имани тәгълиматыбызның олы сере.

Ә хәзер мин китәргә тиеш. Мин үз эшемне эшләдем, ә калганы – синең эш. Сиңа инде мәчет әһелләре күп нәрсәне аңлаттылар, яныңдагы хәләлең дә – Аллаһ бәндәсе, гади кеше күзенә күренми, гади кеше аңына барып ирешми торган күп нәрсә аңа ачык, димәк, Аллаһы Тәгаләбез бу яклап та ярдәменнән ташламаган. Хәзер инде сиңа үз тәкъдиреңне булдырып яшисе генә калды.

– Шулай да, иң элек нидән башларга?

– Менә хәзер кайт та намазга бас. Соңгы рәкәгатьнең сәҗдәсеннән соң укыла торган Әттәхият белән Салаватны әйткәндә, сиңа дога мәкаме белән хәбәр килеп ирешер. Шул хәбәрдә әйтелгәннәр – намаздан соң кылынырга тиешле иң беренче гамәлең булыр.

Мәүлет «ә» дип тә, «җә» дип тә әйтә алмый калды, күзлекле кеше урыныннан торды, кулындагы җыйнак кына сумкасын култык астына алып, саубуллашырга кулларын бирде.

– Йә, хуш, хәзрәт. Миңа китәргә вакыт җитте. Соңгы сүзем калган икән әле: балаларыгызга матур, изге исемнәр кушкансыз. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салаллаһу галәйһиссәламнең рухы бик шат булды. Ул миннән шул шатлыгын җиткерүемне үтенде.

Иблис кузгалырга торганда, ниһаять, Мәүлеткә дә җан керде.

– Син китәсеңдәмени инде, Иблис?.. Газазил... Ә миңа нишләргә соң, сине ничек табарга, күрергә?

– Барысы да Сания абыстай кулында. Мин аны күп сынадым: өшкереп-куркытып та, юхаланып-юмалап та... Ул – безнең кеше. Аның йөрәгендә илаһи очкын ята. Фәрештәләр яралганда төшеп калган ут чаткысы. Ләкин сак бул: ул утта үзең янып көймә. Бар, хәзер үк кайт, сине газизләрең көтә.

– Тукта, тукта, Иблис... Газазил... Иң мөһиме калды әле: син мине үзеңнең фәрештә булуыңа ышандырмадың. Сүз генә, дога гына җитми. Бер могҗиза күрсәт, зинһар, илаһилыгыңа, руханилыгыңа, тылсым көчеңә, илаһи шаукымыңа ышандыр, инандыр, үтенеп сорыйм. Алайса, күңелдә вәсвәсә кала, шик-шөбһә кала. Зинһар...

Ул арада берничә адым читкә китеп өлгергән күзлекле бәндә якындагы тоташ көзгедән торган колонна артына кереп югалды. Менә ул бераздан, Мәүлет аңын-зиһенен җыеп өлгергәнче, үтә дә ямьсез, котсыз бер хәшәрәт рәвешендә, киноларда гына була торган, кылыч борынлы, эчкә баткан күмер күзле, очлаеп киткән яфраклары өскә тырпаеп торган колаклы, алга таба кәкрәеп чыккан очлы аякле йөнтәс бер җен-шайтан кыяфәтендә килеп чыкты! Үзенең хәйләкәр, хәтта мәкерле елмаюы белән җаннарны өркетерлек, зиһеннәрне ялгыштырырлык иде бу Иблис мәлгунь. Бертуктаусыз янып-сүнеп, пыскып-җемелдәп торган күзләре генә ни тора! Менә аны көзгеле колонна тагын үзенә йотты, бер мизгелдән колоннаның икенче ягында баягы мөлаем ир кеше кабат пәйда булды.

Мәүлет, үзе дә сизмәстән, саубуллашырга кулын күтәрде. Күзлекле ир аңа шундый ук кул ишарәсе белән җавап бирде һәм көзгеле колонна артына кереп юк булды. Мәүлеткә ул шул көзгеләр эченә үк кереп киткән сыман тоелды.

**28**

Өйдә Сания аны сорау белән каршы алды:

– Күрдеңме?

– Кемне күрдеңме?

– Иблисне күрдеңме, дим.

Мәүлет «күрдем» дип тә, «күрмәдем» дип тә әйтмәде, бары тик:

– Син аның Иблис булуына ышанасыңмы? – дип, сорауга сорау белән җавап кайтарды. Аннары кискен генә сорап куйды: – Ә син каян беләсең, Сания?

Хатын дәшмәде. Нигә дәшәргә? Болай да аңлашыла бит! Белә ул, барысын да белә. Юк, имче, сихерче буларак кына түгел, хатын-кыз буларак

белә! Бәхетенә ымсынган, юк-юк, бәхетен табып, сихри һәм илаһи тою сәләтенә ирешкән хатын-кыз буларак белә!

– Безнең бу тарих шуның белән тәмамланырмы, Сания?

Саниянең акыллы хатын булуын белә иде Мәүлет. Бу юлы да шуңа инанды. Хатынының әйткәннәре аны тынычландыргандай булды:

– Иблис тарихы беркайчан да тәмамланмаячак, Мәүлет. Кешеләр яшәгәндә, Иблис токымы да, шайтан гаскәре дә яшәячәк. Аллаһы Тәгалә шулай куйган, шулай теләгән. Моннан соң да адәм затының бөтен яшәеше, тормышы сынауларга корылган булачак, аны һәр адымда нәфес, мәкруг, вәсвәсәләр сагалап торачак, кеше исә, кайчакта җиңел генә, кайчакта зур югалтулар белән шушы сынауны үтәчәк, шулай Кыяматкәчә дәвам итәчәк... Гөнаһ белән тәүбә аның төп күңел гаме булачак. Иң мөһиме, һәр сынаудан кеше чистарынып, кара уйлардан арынып чыгачак, үзенең бәхетенә якынаячак. Аллаһы Тәгаләгә ныграк сыеначак, Коръән сүрәләренә, дога кәлимәләренә ныграк төшенәчәк. Борынгылыктан килүче им-томны, ырымнарны, табигать һәм халык йолаларын да ата-бабалар кулланганча кулланачак. Минем моңа иманым камил, Мәүлет.

Мәүлет Сания янына килде дә аны кысып кочаклап алды.

– Ә бит мин шушы ике атналык Иблис тарихыннан сине табып чыктым, Сания, гаиләле булдым. Бу – иң мөһиме! Тормышым бөтенәйде, язмышым ипләнде, чынлыкта, беркем юньләп белмәгән, иң гади, гадәти мунча кешесеннән зыялы, күренекле затлар арасында сүзе үтә торган бер татар иренә әверелдем. Тагын, тагын... Руханилыкка юл ачылды, дога, Коръән сүзе яшәү ихтыяҗына әверелде. Менә бит ничек үзгәрдем мин, Сания, менә ничек минем тормышым үзгәрде!

Ул арада үз караватларында йоклап яткан сабыйлар бер-бер артлы шыңшып уяна башладылар. Сания, йөгереп барып, башта Мөхәммәдне алып килде, аны, үчтеки итеп сөя-сөя, Мәүлетнең күкрәгенә куйды. Үзе тагын ятагында ялгыз калганын сизенеп елап җибәргән Гайшәне алырга китте. Бала янына барышлый, үзе дә сизмәстән, стенадагы көзгегә кискен генә борылып карады. Аннан, хәйләкәр елмаеп, затлы кыяфәттә, ап-ак мөлаем йөзле, җыйнак кына сакал-мыек җибәргән, алтын кысалы күзлек киеп алган бер ир карап тора иде! Хикмәт шунда ки, ныклап карасаң, бу гөнаһсыз йөздә, урам себерүче Шәмси карт чалымнарын да, Мәүлетнең җан дустына әверелгән мишәр татары Миндияр чалымнарын да, сәрхуш җаннар башлыгы Мәйрух белән халык депутаты Юпитер Марсович чалымнарын да, Иблис тарихына катнашы булган башка бик күпләрнең йөз чалымнарын да табарга, чамаларга була иде.

Сания бу мөлаем йөзгә шундый ук мөлаемлык белән җавап бирде дә, Гайшәне алып, кабат ире янына ашыкты. Ул хәтта аның артыннан көзгедәге ир сурәтенең ничек итеп йөнтәс тәнле, өскә очлаеп тырпайган колаклы, шундый ук очлы, аска кәкрәеп төшкән борынлы, эчкә баткан күмер күзле, котсыз кыяфәтле бер хәшәрәт затка әверелүен дә сизмәде.



Илһам
Ногман

# КАН ХӘТЕРЕ ҖАННЫ БИМАЗАЛАР...

## Изге китап

Тәүге Китап ул Күкләрдән иңгән Җиргә, бәхәссез.
Аллаһ сүзе гомер бакый булган бөек, бәһасез.

Бихисап хикмәт тупланган бу мөкатдәс Китапка.
Һәр тәкъва җан мөкиббәндер чын, илаһи хитапка[1].

Могҗизага тиңдер аның һәрбер сүрә, аяте.
Чагылган монда җиһанның бар мәхлукат хәяте.

Иманлы инсаннарның ул бер төшмәгән кулыннан.
Бары Китап яздырмаган бәндәне хак юлыннан.

Күңелгә илһам биргән ул төшенкелек басканда,
Тәүбә кылырга күндергән гөнаһларга батканда.

Изге Китап булгангадыр – урыны түрдә һәрчак.
Шуннан да асыл хәзинә дөньяда булмаячак!

Илаһи нур бөрки аннан Җир йөзенә, Галәмгә.
Рәхмәт безнең күзне ачкан бу кодрәтле Кәлямгә[2]!

## Дала хатирәсе

Үткәннәрдән тик курганнар калган
Һәйкәл булып бөек бабамнарга.
Каракошлар бары шомландырып
Килеп куна сынташ-балбалларга...

[1] Хитап – мөрәҗәгать, эндәшү. Аллаһның кешегә мөрәҗәгате дә «хитап» дип атала.
[2] Кәлям, кәлямулла – Аллаһ сүзе, Коръән китабы күздә тотыла.

Илһам НОГМАН (1963) – *шагыйрь, мөхәррир. «Хыялыма килә җитәсем», «Үзәгем өзелгәндә» исемле китаплар, күпсанлы җырлар авторы. Казанда яши.*

Козгын, карчыгалар хаким монда,
Алар биләмәсе бу мазарлар.
Күргән саен шушы курганнарны,
Кан хәтере җанны бимазалар...

Ерак тарихларга алып китә
Уйлар, сискәндереп, искәрмәстән...
Курганнарның эргәсенә ятып,
Җилләр елый, гүя исәрләнгән...

## Таулар

*Көрднең иң якын дусты бер генә:*
*ул – таулар.*
Көрд халык мәкале

Җил-давылдан ышыклар гел алар,
Иңен куеп, авыр чагында,
Мәгъруру таулар калкан булып басар,
Һәрчак торыр синең сагыңда.

Таулар, таулар... Горур бөркетләрнең
Туган җире, кунар кыясы.
Бу дөньяда, әйе, һәркемнең дә
Гел бертөрле булмый оясы...

Таулар иле нинди сокландыргыч! –
Биеклеккә күңел омтыла...
Монда хөрлек, монда бу дөньяның
Барлык ваклыклары онытыла!

## Аяныч хәл

*Татарлыктан татар һич гарь итәрме,*
*Кеше үз исемен инкяр итәрме?*
Дәрдемәнд

Кая китте мәгънәле һәм матур
Исемнәрең синең, татарым?
Күңелеңә якынмыни шундый
Нам-атлары җиде ятларның?

Элеккеге горурлыгың, халкым,
Әллә инде тәмам җуйдыңмы?
Нинди генә исем кушмыйсың син,
Асыл атларыңнан туйдыңмы?..

Газиз баласына элгәргеләр
Мондый исемнәр бит кушмаган.
Татармы син, әллә маңкорт мөртәт
Милләтсез бер затка охшаган...

Иллария, Арианналарны
Ничек татар диеп атарга?..
Реваль, Робсон, Марлен, Изиллар соң
Нигә кирәк безнең татарга?!

Гөлҗамаллар, Рәйхан, Сәрбиназлар,
Йосыф, Ибраһимнар кайда соң?
Өмет итеп буламыни инде
Бу исемнәр кире кайтасын?..

Һич тә күргәнем юк башкаларның
Үз исемен инкяр иткәнен.
Аяныч хәл, исемен дә җуйгач,
Онытадыр кеше үткәнен...

## Фәкыйрьлек

*Иң зур фәкыйрьлек –*
*ул күңел фәкыйрьлеге.*
Тереза Ана

Матди байлыгым юк минем бер дә,
Шөкер, фәкыйрь түгел йөрәгем.
Ходаемны һәрчак зекер кылам,
Биргән өчен иң-иң кирәген.

Күпме изге ният күңелемдә,
Мәрхәмәтлек, шәфкать, игелек...
Тик хөсетлек, көнчелек юк миндә,
Ник яшәргә җаның игелеп?!

Җир һәм Күкләр – бөтен җиһан сыйган
Йөрәгемә шушы кечкенә.
Ләкин анда хәрәм, явызлыкка
Урын булмас, булмас һич кенә!

Мал табам дип дөнья кумадым мин,
Рухи байлык булды җыйганым.
Күңел фәкыйрьлеген күтәралмам –
Шул булмасын иде җуйганым!

## Ил фәрештәсе[3]

*Мөгаллимә Ләйсән Фәрит кызы*
*Гәрәевага багышлыйм*

Халык сезне олы хөрмәт белән
«Ил фәрештәсе» дип атаган.
Зыялысы булган милләт кенә
Заман белән бергә атлаган.

Фәрештәгә тиңләгәннәр сезне,
Изге булган чөнки эшегез.
Һәр заманда дәрәҗәгез олы,
Хөрмәт-мәртәбәле кеше сез!

Элек-электән үк татар халкы
Гыйлем-мәгърифәткә омтылган.
Рухи азык булгач тормышының
Бөтен михнәтләре онытылган...

Бүген дә сез алгы сызыкларда
Тел-әхлакны саклап торасыз,
Ил вә милләт тәрәккые өчен
Җаныгызны фида кыласыз.

Бик җаваплы, авыр хезмәтегез,
Күпме бурыч сезгә йөкләнгән!
Башкарасыз эшегезне, шөкер,
Уңышлырак хәтта көткәннән.

Мөгаллимә булу мәртәбә ул,
Лаектыр тик моңа сирәкләр.
Алар кебек фидакярләр бүген
Бу дөньяда бигрәк кирәк лә.

Укучысы һәрчак күңелендә,
Уйламый ул үзе турында...
Аның өчен шәхес тәрбияләү
Тора әүвәл, алгы урында.

Йөрәген дә балаларга бирер,
Икеләнми хәтта бер генә.
Мөгаллимә! Тиңли алмыйм сине
Фәрештәдән башка беркемгә!

## Татар халык ашлары

*Наилә Якуп кызы*
*Гарәфетдиновага багышлыйм*

Табын корып кунак җыяр өчен
Аш-суларың кирәк куярлык.
Татар өстәлендә ризык-нигъмәт
Булган һәрчак телең йотарлык.

Сый-хөрмәте белән халкым минем
Бар дөньяга шөһрәт казанган.
Татар ашын татыр өчен хәтта
Килгән кайчак кунак Казанга.

Нинди генә ашлары юк аның:
Каклаган каз, казы, тутырма,
Гөбәдия, өчпочмак, корт, чәкчәк,
Бәлеш, өлеш, азу, бастырма...

Бу кадәрле сый-нигъмәтне аңа
Хак Тәгалә үзе биргәндер.
Уңган-булган татарларның моңа
Лаек икәнлеген белгәндер.

Бармы икән башка милләтләрдә
Моннан артык нигъмәт тагын да?!
Мин халкымның бөеклеген күрәм
Хәтта менә шушы табында!

## Миләүшәләр

Тәрәз төбебездә миләүшәләр –
Синең иң яраткан гөлләрең.
Серләшәсең алар белән кайчак,
Беләсеңме әллә телләрен?

[3] Ил фәрештәсе – илгә изгелек китерүче кыз. Революциягә кадәр хатын-кыз мәктәп укытучыларын – мөгаллимәләрне шулай атаганнар.

Ямь өстиләр алар өебезгә,
Күтәрәләр һәрчак күңелне.
Шуңа безнең өйдә һәрвакыт җәй,
Шуңадыр да бездә күңелле.

Миләүшәләр, безне сөендереп,
Ел буена чәчәк аталар.
Өебезгә күзләр кермәсен дип,
Тырышалар бугай бит алар...

* * *

Күзләреңнән синең яшьлегемне эзлим,
Бер үбәсем килә, ничекләр соң түзим?!

Очрашмасак кабат, искә алмас идем,
Кичерә күр мине, әллә ничек сөйдем...

Күпме еллар үткән сизелми дә, иркәм,
Ул чакларга кабат, их, кайталсак икән!..

Башларымны янә син уйларга салдың,
Бу гыйшыктан, белсәң, күпме сабак алдым.

Берни кылып булмый, бар да инде үткән,
Сиңа диеп өзгән гөлләр күптән кипкән...

## Яратасы килә көздә дә

*(Җыр)*

Яшьлек үтеп киткән
Сизелми дә күптән.
Күңел генә бер дә картаймый.
Яратасы килә,
Шашып елый-көлә,
Чәчләр агарганга карамый.

Бер сүрелми икән
Бу хис сөю дигән,
Картаясың һич тә килмәсә;
Язлар үткәненә,
Көзләр җиткәненә
Күңелләрең әгәр күнмәсә.

Гомер буе сөеп,
Яшик янып-көеп,
Тормышның бер ямен җуймыйча.
Яшьлектәге төсле,
Типсен йөрәк көчле,
Сөеп-сөелепләр туймыйча!



Айгөл
Әхмәтгалиева

# КҮЗ НУРЛАРЫМ

ДРАМАТИК ХИКӘЯ

Катнашалар:
Х а т ы н
И р
А н а
К ы з
Е г е т
Д у с
Х а н ы м

*Сәхнә идәне шахмат тактасын хәтерләтә. Вакыйга шушында, бер генә урында бара. Катнашучылар – әйтерсең лә шахмат фигуралары, алар тамаша дәвамында кереп-чыгып йөрмиләр, һәрчак сәхнәдә, «тактада». Арткы планда ярым түгәрәк рәвешендә капма-каршы куелган ике караваt, ул урталай киселгән алма рәвешендә. Пәрдә ачылганда, үзәкләрне өзеп бишек җыры ишетелә, ул җанны иркәли, колакны иркәли. Бераздан аны күмәргә теләгәндәй, еpактан заманча, дөбер-шатырга корылган музыка кушыла. Ул көчәйгәннән-көчәя, бермәлне бишек җырын бөтенләй күмеп китә.*

*Алгы планда* е г е т *планшетта уйнап утыра,* к ы з*ның колагында колакчыннар, ул җыр тыңлый. Музыка тавышы тына.*

Х а т ы н *(караватта яткан җиреннән башын күтәреп).* Су... Бирәрегез су гына бирсә...

*Җавап кайтаручы юк. Хәлсезләнеп, кире ята. Бераздан көч-хәл белән торырга маташа. Егет аны күреп ала.*

---

Айгөл ӘХМӘТГАЛИЕВА (1973) *– язучы; М.Кашгарый исемендәге халыкара премия лауреаты. «Синең өчен яшим», «Баланнарда бал тәме», «Таллыкүлдә былбыл бар» һ.б. китаплар авторы. Чаллыда яши.*

Е г е т *(канәгатьсез генә)*. Нәрсә?

Х а т ы н . Су... Тамагым яна...

Е г е т *(Кызның колагындагы колакчынын йолкып ала)*. Бар әле, су алып чык.

К ы з . Нигә мин? Сиңа әйткән бит.

Е г е т . Кулың каламыни инде? Уйнап бетерәсе иде.

К ы з . Күреп торасың бит, мин җыр тыңлыйм.

Е г е т . Синең шул булыр. *(Тавышын йомшартып, ясалмалык белән)* Бар инде.

К ы з . Үзеңә кирәктә нинди тон белән эндәшәсең, ә?

Е г е т . Дура.

*Кулын селтәп, караватбашындагы стаканга үрелмәкче була. Хатын инде торып чыгып киткән. Егет ишеккә барып карый да кире утыра. Х а т ы н көч-хәл белән чыгып, урынга ятмакчы була, кулындагы стаканы төшеп ватыла.*

Е г е т . Үзем алып чыга идем бит инде. Ну вот... *(Кызның колагындагы колакчынын йолкып ала)*.

К ы з . Нишлисең соң син? Па гына кайтсын, яме?

Е г е т . Себереп ал. Минем уен бетә...

К ы з *(чыраен сытып)*. Ма, ну кайчан тереләсең инде син? Туйдырды инде. Чәйне мин яса, өстәлне мин җыештыр.

Е г е т . Син кыз кеше, эшең шул.

К ы з . Егет кешегә идән себерергә ярамыймы әллә?

Е г е т . Кыенмыни инде? Себерке, соскы аласың да...

К ы з . Менә, менә, бер кыенлыгы да юк. Үзең дә себерке, соскы аласың да...

*Әйләнеп карыйлар. Х а т ы н көч-хәл белән идәндәге стакан ватыкларын соскыга җыя.*

К ы з . Үзем түгәрмен, шунда торып торсын.

Е г е т . Да, тагын берәр атнадан.

К ы з . Бәйләнмә әле. Кая соң бу әти? Таң ата бит инде.

*И р алгы планга уза.*

К ы з . Чё шулай озак?

И р . Эшләр, кызым, эшләр.

Е г е т *(мыскыллы елмаеп)*. Иртәнге өчкә хәтлеме?

*И р хатын яткан якка текәлеп карый.*

И р . Дару эчтеме?

*К ы з белән е г е т иңсәләрен җыералар.*

К ы з . Эчкәндер.

Егет. Бездән сорамады.

И р . Нигә йокламыйсыз?

К ы з . Ә минем йокы килми.

Е г е т . Канишны. Көндез бердә тор да.

К ы з . Үзеңне бел. Миннән ун минутка алдан торган икән берәү.

*И р карап-карап тора да кәчтүмен салып киерелә, йокларга җыена.*

К ы з . Па, акча калдыр әле.

*И р кесәсеннән шактый акча чыгарып, к ы зга суза.*

Е г е т . Ә миңа?

И р . Син кая барасың?

Е г е т . Курыкма. Анда йөрмим. Беләсең, завязал...

И р *(акча биреп)*. Сез анда чамалап... Тәртип булсын, яме?

К ы з , Е г е т. Все о’кей, па!

*Караңгылана. Ут яктысы х а т ы нга төшә. Ул көчкә торып, сөялеп утыра.*

Х а т ы н . Нишләп шулкадәр салкын? Тышта яз. Җылыткандыр бит инде.

*Тормакчы була. Урындык аркасына тотына, урындык авып китә. Тавышка и р торып утыра.*

И р . Нәрсә, су кирәкме?

Х а т ы н . Юк. Салкын.

И р . Соң, юрганыңны бөркән.

Х а т ы н . Җылы керми. Дөньясы салкын.

И р . Тагын башлана инде... Мә, җәймәне бирәм.

Х а т ы н . Кирәкми. Шкафтан мамык шәлне генә табып бирсәң.

И р . Төн уртасында шәл эзлимме инде?

Х а т ы н . Өске киштәдә. Уң як почмакта.

И р *(кулында шәл. Эченнән тәмәкеләр төшә)*. Монысы нәрсә тагын?

Х а т ы н . Тәмәке. Көя төшмәскә.

И р . Болай да кортлап беткән иске шәл түгелме соң?

Х а т ы н . Иске түгел. Әнкәйдән калган.

И р . Моның ни җылысы булсын.

Х а т ы н . Бар. Әнкәй шәле ул.

И р . Бүтән кирәк нәрсә юкмы? Бер торганда әйтеп кал да...

Х а т ы н . Тынычлап йокла. Берни дә кирәкми.

И р . Тынычлап, имеш. Йокларсың...

*Ята, җәймәсен башыннан бөркәнә.*

Х а т ы н *(шәлне кулында таратып)*. Кәҗә мамыгыннан. Әнкәй үзе бәйләгән иде. Бакчы, күзе киткән. Югыйсә, элегрәк күргән идем бит, шунда эләктереп кенә куясы бит. Бу кадәр үк сүтелмәгән дә булыр иде. Юк инде, башында ук кул җитмәгәч... Сүтелә-сүтелә кая кадәр җиткән диген. Башында ук кул җитмәгәч, вакытында текмәгәч... Исеңдәме, теге чакны әйтәм. Син институттан каникулга кайткан идең. Әкәмәт салкын иде ул кыш. Әнкәйдән кич чыгыйм әле дип сорыйсы килә – әткәйнең талканы коры, аннан куркам. Шушы шәлне башыма урадым да, олы ападан печенье табасы алып кайтам дип чыгып киттем. Коймак пешергән идем ул көнне. «Камыры калды, шуннан печенье пешерәм әле», дигән булдым. Коймак камырыннан кем печенье пешерсен инде, йә? Әнкәй сизенгәндер, аягыңа киез итек ки, катасың бит, дип кычкырып калды.

*И р урынында бөтерелеп, борылып ята.*

Х а т ы н . Табага чынлап та бардым. Шуны күтәреп, олы апалардан чыгып килгәндә, пәлтә җиңеннән эләктереп алдың, исеңдәме?

*Х а т ы н шәлне башына урап, алгы планга килә. Аның яшь чагы.*
*И р урыныннан тора. Аның да е г е т чагы.*
*Шул чорлардан үзәк өзгеч дәрәҗәдә һәркемгә таныш көй ишетелә...*

Х а т ы н . Әлләй, котымны алдың бит!

И р . Чү-чү, башымны яра күрмә. Мине эзләп чыктыңмы?

Х а т ы н . Кайтканыңны да ишетмәгән идем.

И р . Шулайдыр. Әйтәм җирле

бер алдыңа, биш артыңа карый-карый йөгердең.

Хатын. Әллә артымнан күзәтеп килгән инде?

Ир. Эндәшми түздем. Атлауларыңа тиклем сагынган идем, рәхәтләнеп күзәттем.

Хатын *(бәхетле елмаеп, аңа сыена)*. Ә мин сине сагынырга өлгермәдем.

Ир. Юкмы? Мин синеме, мин сине....

Хатын. Күтәрмә, төшер, кеше күрсә...

Ир. Синнән коймак исе килә.

Хатын. Шәлгә сеңгәндер. Төшер инде.

Ир. Төшермим әле. Шулкадәр сагындым, саташырлык булып сагындым үзеңне.

Хатын. Мин дә... Үзем сагынам, үзем әнкәйләр күрмәгәндә елыйм. Шәһәргә киткәч, мине оныткансыңдыр, әллә нинди фыртавай кызлар очраткансыңдыр дип уйлап, хыялланып беттем.

Ир. Фыртавай кызлар?

Хатын. Алардан коймак исе дә килмидер.

Ир. Кәнишне. Алар коймак пешерә беләдисеңме әллә?

Хатын. И, көлә бирәү... Озакка кайттыңмы?

Ир. Әллә куасың да инде?

Хатын. Сакалың бар бугай, битемне кытыклый.

Ир. Кулларың боз булган. Туңдыңмы әллә?

Хатын. Юк ла, җылы бит.

Ир. Җылы? Әйе шул, утыз градус кына дигәннәр иде бүген.

Хатын. Ә миңа салкын түгел.

Ир. Мин яныңда булганга ул, беләсеңме?

Хатын. И, телгә остарган бирәү. Шәһәрдә ярты ел укыдым дигәч тә.

Ир *(пышылдый)*. Шулкадәр сагындым. Күзгә син дә укырга килсәң, мин сине бер минутка да үземнән калдырмыйм, белеп тор.

Хатын. Ярар. Култык астыңа кыстырырсың да гел үзең белән йөртерсең.

Ир. Син минем күлмәк кесәсенә дә сыясың. Йә куенымда, җылыда гына йөрерсең. Менә бүгенге кебек.

Хатын. Кызык булыр иде, әйеме, күз нурым. Бар дөньясы салкыннан калтырап торганда, мин синең куеныңнан башымны чыгарыр идем дә, «миңа җылы, миңа рәхәт» дип кычкырыр идем.

Ир. Ә нигә көләсең? Чынлап та, мин сине беркайчан да туңдырмам, сылуым. Ышанасыңмы?

Хатын. Ышанам. Мин сиңа ышанам, күз нурым.

*Ут хатынга төшә. Ул артка чигенә, шәлне сала, сабый бала кебек тотып, кулында тирбәтә.*

Хатын. Улыбызны алып кайткан көнне онытмагансыңдыр. Дөньясында бер бәхетле идек, әйеме? Тулай торак бүлмәсендә торабыз, дөньябыз шып-шыр. Өстәл, ике урындык, караватыбыз бар. Әллә ниткән еллар булды бит ул. Әткәйләр ел буе хезмәт хакы күрми эшләде. Безгә тигән стипендия өч-дүрт көн тамак ялгарга җиткәндер. Әйтергә оят, кашык-чәнечкене дә аскы каттагы ашханәдән кыстырып мендек бит, адәм көлкесе. Ә пычакны үзебез сатып алдык! Каршы яктагы «Хозмаг»тан. Исеңдәме? Бәбәй алып кайттык – бишек тә, коляска да юк. Әнкәй кунакка килгән иде, җәллләгәндер инде – башына бәйләгән шәлен калдырып китте.

*Ана алгы планга уза. Шәлне иңбашына сала. Урындыкта утырган егетнең башыннан сыйпап сөя.*

А н а . Бәхеткәйләре булсын берүк. Ата-аналы, алтын канатлы, бәхетле, тәүфыйклы булсын!

Х а т ы н . Әнкәй, карый белерменме икән?

А н а . Башыңа төшсә, башмакчы буласың, диләр, кызым. Карамый ни... Хатын-кызның төп эше шул инде ул – бала карау, аны тәрбияләү.

Х а т ы н . Син безнең бишебезне ничекләр үстергәнсеңдер, хәзер генә шаккатам, әнкәй! Бер төндә кырык уяныргa кирәк бит.

А н а . И балам... Төнлә уянулары гына ни аның?! Бала тездә чакта сөйдерә, менә тездән төшкәч көйдерә шул ул... *(Түшәмгә текәлеп тора)*. Таш калада бишек асарга да җай юк, әй. Аста да таш, өстә дә таш дигәндәй.

И р . Әби, хәзер бишек модада түгел. Киләсе атнада коляска алып кайтам.

Х а т ы н . Бишектә рәхәтрәктер кебек.

И р . Урамга чыгам дисәң, барыбер коляска кирәк.

А н а *(иңбашындагы шәлен сүтеп, шуңа бала төргәндәй итә)*. Бала алдында дилбегәне берегез уңга, икенчегез сулга тартмагыз берүк.

И р . Безнең әби әллә нинди галимнәрне бәреп ега, әйеме, сылуым?

Х а т ы н . Әнкәйнең тел сандыгын актарсаңмы...

А н а . Сандык дип... *(Көлә)*. Сөйләнелә инде, балалар, тел сөяксез бит.

Х а т ы н . Шәлеңне нишләтүең, әнкәй?

А н а . Бәләкәй чакта сине гел шуңа төреп үстердем. Ябыграк идең бит, җил тимәсен, туңмасын ди торган идем. Ике башын төйнәп бәйли идем дә, шулай үземчә бишек ясап, үзем белән бер тотам калдырмый йөртә идем.

И р . Әби, кызың хәзер дә шулай иркә, җылы куенда гына яши.

Х а т ы н . Әнкәй алдында... Мине оятка калдырып тагын...

А н а . Бәхетегезгә күз тимәсен берүк, балалар. Икегез бер сүздә булсагыз, арагызга сүз дә, күз дә кермәс, иншалла!

*А н а арткы планга уза.*
*И р белән х а т ы н бер-берсенә сыенып торалар. Шәлнең ике башын төйнәп, бишек рәвешенә китерәләр.*

Х а т ы н . Бу катыргысы нигә инде?

И р . Аркасы бөкрәймәсен дим. Болай җайлырак бит.

Х а т ы н . Каты булмасмы?

И р . Бала-чаганы бәләкәйдән үк катыга күнектерергә кирәк аны.

Х а т ы н . Ул шундый нәни, шундый йомшак! Кул аркаларын кара әле, пешкән кабартма кебек, әйеме, күз нурым?

И р . Коймак кебек диген, сылуым. Син бит коймак яратасың.

Х а т ы н . Сиңа көләргә генә булсын.

И р . Бәхетемнән көләм. Янымда – син, алдымда – баһадирдай улым. Тагын ни кирәк?

Х а т ы н . Кирәктән күп әйбер юк анысы.

И р . Киләсе атнада зарплата булырга тиеш, вәгъдә иттеләр.

Х а т ы н *(авыр сулап)*. Инде өченче ай вәгъдә итәләр.

И р . Авыл булганда, ач утырмыйбыз анысы.

Х а т ы н . Әйтмә дә. Әле дә ярый ике яклап әткәй-әнкәйләр булыша. Ите, бәрәңгесе, оны дигәндәй... Мес-мес килеп йоклый, әллә елмая да инде?

И р . Төш күрәдер. Елмаюы синекенә охшаган.

Х а т ы н . Борыны тач синеке.

И р . Кашларын кара әле, алары – синеке.

Х а т ы н . Колаклары – синеке.

И р . Ә син – минеке.

Х а т ы н *(ирнең кочагына сыенып)*. Бәхет шушыдыр инде ул, әйеме, күз нурым?

И р *(хатынны кулларына күтәреп)*. Улыбыз янына кап-кара күзле бер кыз да алып кайтсак, бәхетебез дә түп-түгәрәк булачак, сылуым!

Х а т ы н . Бар почмак та түгәрәкләнсә, берәр җире кителә генә башламасын дип куркам, күз нурым!

*Х а т ы н арткы планга уза. Кулында – бала биләве итеп тоткан шәле.*

Х а т ы н . И, бәхетле чак булган да инде, әйеме? Малыбыз юк иде – җан җылысы бар иде...

*Д у с һәм х а н ым алга узалар. Икесе дә затлы киенгәннәр.*

Д у с . Шушындый дырада яшәп ятасыңмыни? Кем уйлаган... Безнең группада иң башлы егет идең түгелме? Кызыл диплом һәм эт оясы чаклы бүлмә.

И р . Олырагы да булыр. Эшләп торам бит.

Д у с . Эшләп? Ха-ха-ха... Заводта инженер булыпмы?

Х а т ы н . Әйдәгез, утырыгыз, урнашыгыз әле. Монда бераз кысанрак инде, гаеп итмәссез.

Х а н ы м . Да-а... Шушында ике бала үстерәсезме?

Х а т ы н *(бәхетле елмаеп)*. Тәгәрәп үсеп киләләр күз нурларым.

Х а н ы м . Без бала дип ашыкмадык. Үзең өчен яшәп калырга кирәк.

Х а т ы н . Шулар белән әвәрә килә-килә яшибез, зарланмыйбыз.

Д у с . Кичә сине очраткач, кызык булып китте. Укып бетергәнгә ничә, биш ел үттеме? Дөресен әйткәндә, беркемне күргәнем, сөйләшкәнем юк. Вакыт җитми, дөнья куабыз. Бүген җай чыкты. Тукта, мин әйтәм, килеп күреп китим, рәхәтләнеп бер сөйләшеп утырырбыз дим *(як-ягына карана)*.

И р . Күңел киң булса, сыябыз, борчылма. Безнең үзебезчә, барысы да бик гади инде...

Х а н ы м . Минеке өйдә сирәк була. Кайчак атналар буе күрмим үзен.

Х а т ы н . Читкә йөреп эшлимени?

Х а н ы м *(ирен чите белән ачы елмаеп)*. Кайсы читтә йөргәнен этем белсен... Үзенең салоннарына баш-аягы белән чумган.

Х а т ы н *(төшенеп җитмәсә дә)*. Ә-ә-ә...

Х а н ы м . Ярар, акчаны учы-учы белән кайтарып бирә, минем нишләгәнемә, нәрсә алганыма кысылмый – шунысына рәхмәт.

Д у с . Шуңа аптырыйм: нинди шәп момент булды, кем күпме каера алды – чумырды гына. Син нишләп болай йоклап калдың ул, ә?

И р . Нишләргә тиеш идем соң мин?

Д у с . Нишләргә, нишләргә... Бераз гына мозгаларыңны селкетергә кирәк иде. Акча алышынган моментта мин никадәр кредит алдым, күпме техника, фатир эләктереп калдым. Бер төн эчендә ул кредитым тиеннәргә әйләнде дә куйды. Айн момент илтеп түләдем ул копейкаларны. Шул чакта милеккә әйләндереп калмаган булсам, мин дә бүген синең шикелле шымытыр кочаклап утырыр идем.

И р . Бөтен кешегә андый сәләт бирелмәгән шул....

Д у с . Минем кебекләр әле ул балыкның эресе түгел. Менә андыйлар йотты инде, акулалар, китлар... Завод-фабрикаларны тиеннәргә эләктереп калдылар. Завод нәрсә, олы бер илне кабып йоттылар, ха-ха-ха... Ярар, безгә эләккәне дә җитә, зарланмыйбыз...

Х а т ы н . Минем юньләп эшкә дә чыга алганым юк әле. Малай да, кыз да бер-бер артлы тудылар да... Бакча да алып булмый үзләренә, урын юк, диләр.

Х а н ы м . Төртә белмәгәнсеңдер....

Х а т ы н . Нәрсәне?

Х а н ы м . Нәрсәне булсын? Майларга, берәрсен җайларга диюем...

Х а т ы н . Бүтәннәрне майлау түгел, үз балаларыма ак май ашатырга да җай чыкмый кайчак. Әй, ирем исән булсын (*ире ягына җылы караш ташлый. Ир дә аңа текәлә. Елмаеп, бер-берсенә күз кысалар)*. Барысы да рәтләнер.

Х а н ы м . Һавага карап, булыр дип авыз ачып көтеп утырсаңмы? Беркем дә болай гына китереп тоттырмый, матурым.

Х а т ы н . Түшәмеңнән биегрәк сикереп булмый инде.

Х а н ы м *(иргә текәлеп карап тора)*. Иреңнең куллары көчле күренә... Дәртледер, назлыдыр... *(Үз иренә карап ала).*

И р . Дөньясы гел болай болганып тормас әле. Бер рәтләнер.

Д у с . Син кайсы илдә яшәгәнеңне белмәгән кеше шикелле сөйлисең. Болганудан туктаса, хәзер таяк тыгучысы табыла аның.

И р . Шулай. Мәңгелек кризис иле диген.

Х а н ы м . Минем дә назда коенып яшисем килә. Янып, кайнарланып! Көчле кулларда тибрәлеп.

*Х а т ы н аптырап, д у с ягына ымлый.*

Х а н ы м . Аның тормышы үз эзендә – эш, акча, дуслар, сауналар, кызлар... Әй, чукынып кына китсен лә. Күнектем инде. Кесәсендәге акча янчыгы, счёт номерлары, машина ачкычы, хатын – һәр ир кешедә булырга тиешле нәрсәләр барысы да бармы – бар. Аңа шул җитә. Минем тормышыма тыкшынмаса – миңа шул җитә. Ул үзенчә, мин үземчә дөньяның артына типтереп яшибез, ха-ха-ха...

*Алгы планда д у с, х а н ы м.*

Х а н ы м . Тыңлале...

Д у с *(кесәсенә тыгылып)*. Күпме кирәк?

Х а н ы м . Акча түгел. Рәтлерәк эшкә урнаштыр шушыларны. Балалары жалко.

Д у с . Ха! Тапмасыннар иде. Минем проблема түгел.

Х а н ы м . Бергә укыган, дус дисең бит.

Д у с . Безнең группада егерме дүрт кеше укыды. Мин аларның барысын да кайгыртырга тиешме?

Х а н ы м . Барысын да димим. Менә боларны.

Д у с *(кыланып)*. Әллә берәр хәйрия фонды ачып җибәрәсеңме? Сиңа килешә икән бит.

Х а н ы м . Маймылланма. Аны гына эшли аласың бит.

Д у с . Мин барысын да эшли алам. Тик үз теләгем белән генә. Яки... алдыма ялынып килсәләр... Ха-ха-ха.

Х а н ы м . Килмәячәк. Андый сорттан түгеллеге йөзенә чыккан.

Д у с . Тә-ә-к... Хәзер турысын әйт: сиңа балалар жалкомы, әллә аларның аталарымы?

Х а н ы м . Турысын әйтергә? Мин үземне кызганам.

Д у с . Кы-зык... Нигә алай булды әле ул?

Х а н ы м . Син бит мин барында да үзеңнең пычрак уйларыңнан арына алмыйсың, шулай бит?

*Д у с дәшми.*

Х а н ы м *(елмаеп)*. Башыңны җүләргә салма. Ул хатынны күзең белән ничә чишендердең, ә? Хыялыңда син инде аның белән...

Д у с . О-о! Ир затыннан булсаң, синнән менә дигән Отелло чыгар иде.

Х а н ы м . Тик бу хатын – каты чикләвек. Хәтта синең дә тешең үтмәячәк.

Д у с *(елмаеп)*. Мине бөтенләй бетереп ташлавыңмы?

Х а н ы м . Булыш син аларга. Үз эшләрен ачалармы, башкасымы. Ә мин сиңа булышырмын.

Д у с . Аптыратыйммы-тинтерәтимме уйныйсың, ә?

Х а н ы м . Син ул чикләвекне ватарсың. Ә мин сиңа булышырмын.

*Ут сүнә. Яктыра. К ы з һәм е г е тнең балачаклары. Чүпрәк сумкага уенчыкларын җыялар.*

К ы з . Әнием, курчагымны алсам ярыймы?

Е г е т . Әнием, ә мин машинаны алам.

Х а т ы н . Алыгыз, ал, күз нурларым. Болай сөйләшәбез: еламыйсыз, сугышмыйсыз, тәрбияче апаларны тыңлыйсыз.

Е г е т . Ә сез безне кайчан килеп аласыз?

И р . Атналык бакча дип аңлаттым бит, улым. Атна азагында.

К ы з . Әтием, ә атна нәрсә ул, күпме?

Х а т ы н *(елмаеп)*. Менә, бармакларыңны кара әле. Атнада җиде көн. Ә сезне биш көннән соң ялларга алып кайтабыз, яме.

Е г е т . Нигә шулай озак?

И р . Кем шыңшый анда безнең? Олы егетебезме, оялмыйчамы?

К ы з . Ә мин шыңшымыйм. Минем анда курчакларым кү-үп булачак, әйеме, әнием? Уйныйм да уйныйм, уйныйм да уйныйм...

Х а т ы н . Без әтиең белән эшләребезне җайга салгач, сезне бүтән бакчага күчерербез, яме. Иртән илтеп куярбыз, кич өйгә алып кайтырбыз. Бераз гына түзегез инде, күз нурларым. Ә монысы нигә?

К ы з . Курчагымны төрәм. Өшемәсен өчен.

Х а т ы н . Әбиеңнең иске шәле бит бу, кызым. Калдыр *(алып читкә ыргытмакчы була. Шәлне сүтә)*. Күр әле, бер элмәге ычкынган, күзе киткән. Ярар, бер җай белән әләктереп куярмын *(караватка ыргыта)*.

Е г е т . Әнием, минем өйдә каласым килә!

К ы з *(абыйсына карап торгач)*. Минем дә, минем дә! Минем сезнең янда буласым килә, әнием! Бакчага барасым килми минем!

И р . Тавышны бетердек. Киттекме?

*Ут сүнә. Яктыра. Алгы планда ак яулыклы, озын ак күлмәкле а н а. Х а т ы н башын күтәрми генә акча санап, калькуляторда чутлап, кәгазьгә нидер язып утыра. И р киемнәрен сумкага җыя.*

А н а . Иртән чабасыз, кич чабасыз. Нәрсә инде бу, кызым?

Х а т ы н . Тагын бер кибет ачтык, әни. Чапмый нишлисең.

А н а . Авылга да юлыгыз сирәгәйде. Балаларны да юньләп күргән юк.

Ир. Аларны атналык лицейга урнаштырдык бит, әби, үзебез дә сагынып кына күрешәбез.

Ана. Башта атналык детсад дидегез, хәзер атналык мәктәп... Хәерле булсын. Хөкүмәт тәрбияли хәзер балаларны, ата-ана түгел.

Ир. Эш бит, әби, эш. Әз генә тукталдыңмы, башкалар таптап китә дә бара. Тәк, мин дә киттем. Берсекөнгә кайтам.

Хатын. Берсекөнгә?

Ир. Мәскәүгә очам. Сәгать өчтә самолёт.

*Ир чыгып китә.*

Ана. Ала-ай.. Иреңнең кая барганын чыгып китәр минутында гына беләсең түгелме, балам?

Хатын. Бер-береңә хисап биреп торыр чакмы, әнкәй? Башта дустына булган бурычларын түләп бетерик дип чаптык – эш башлаганда ул ярдәм итте бит, хәзер үзебез өчен... Борчылма, күнектек инде. Тормышыбыз бөтен булсын дип тырышабыз. Балалар үсеп килә. Бүтәннәрдән ким булмасыннар, дибез.

Ана. Фатирыгыз болын кебек. Бер-береңне эзләп тапмалы түгел. Ишек төбегездә ике машина.

Хатын. Шәһәр читендә йорт җиткереп киләбез, әнкәй. Осталар икенче ай эшли инде. Анысы хан сарае кебек булачак!

Ана. Хәерле булсын, балам, хәерле булсын!

Хатын. Әллә сөенмисең дә инде, әнкәй?

Ана. Балаң өчен ничек сөенмисең. Ата-ананың бөтен куанычы – балалар бәхете бит инде ул, кызым... Күгәрчен тавында җиләк өлгергән. Син тәгәри-тәгәри, ята-ята җыя торган идең.

Хатын. Нинди җиләк, әнкәй? Бер генә минут та буш вакыт юк, үзең күрәсең. Җиләк... Күктәге кояшны да күргәнем юк минем хәзер, әнкәй! Товар алып кайтабыз, товар сатабыз, тагын товарга китәбез...

Ана. Авылга кайткач, кич мунчадан чыгып, йолдызларга карап тора торган идең...

Хатын. Мондагы сауналарның үз йолдызы, әнкәй.

Ана. Балаларыңның теле катыланган. Бәләкәй чакларында әтием, әнием дип өзелеп торалар иде, хәзер «па» белән «ма»га әйләнгәнсез икән... Татарча әйткәнне аңлап та бетермиләр.

Хатын. Аңлавын аңлыйлар, рәтләп сөйләшмиләр генә.

Ана. Бая кызыңа «күз нурым» дигән идем, кашын җыера. «Нәрсә дигән сүз ул?» – ди. Глазаның лучы дигәч, көләрме дисәм, тагын кашын җыерды.

Хатын. Сораган бар нәрсәләре алларында. Әтиләренең акчадан өзгәне юк. Киемнәре – энә-җептән чыккан.

Ана. Хәерле булсын, балам. Талны яшь чагында бөгеп калсаң гына...

Хатын. Аларны күрергә вакыт та юк, әнкәй. Менә эшләрне җайлап бетерсәк...

Ана. Ай-һай, балам... Дөньяның койрыгын тота алырсыз микән? Барыбыз да шулай дигән булабыз: менә моны бетерсәк, тегене бетерсәк... Яши башларбыз кебек. Керфегеңне күтәреп карасаң, аһ итәсең. Шәм кебек сызыла да төшә шул гомеркәйләр, сизми дә каласың.

Хатын *(елмаеп)*. Ә безнең барысы да алда әле, әнкәй.

Ана. Мин исән чагында сүземә колак салам димисең...

Хатын. Әнкәй, алай димә, сиңа яшәргә дә яшәргә.

Ана. Әнкәйләр мәңгелек түгел, балам...

*Ут сүнә. Яктыра. Алгы планда и р һәм х а н ы м. Ханым матур нәзек эчке күлмәктән.*

И р . Син унсигез яшьлек кызлар кебек!

Х а н ы м *(мут елмаеп)*. Син дә егетләрдән ким түгел!.. Бу юлы нәрсә уйлап чыгардың?

И р . Мин Мәскәүдә. Берсекөнгә генә кайтам.

Х а н ы м . Ә мин хатыныңа шалтыратсам? Ирең минем янда, борын төбеңдә генә дип әйтеп ташласам?

И р . Өлгермәячәксең. Син шалтыратканчы, мин сине тотып ашап бетерәм. Менә болай...

Х а н ы м . Кулларың көчле. Дәртле син, артык кайнар. Мин моны беренче күрүдә үк аңладым. Хатының бәхетле.

И р . Сине дә бәхетле итеп кенә торам түгелме?

Х а н ы м . Чөнки мин шулай теләдем. Беләсең: мин буйсындырырга яратам.

И р . Беләм. Мине дә туры юлдан син генә тайпылдырдың.

Х а н ы м . Үрнәк ир. Тәртипле ата. Әүлиядай гаилә башлыгы... идең.

И р . Бер күз сирпүең җитте.

Х а н ы м . Бер түгел, алдашма. Бирешмичә байтак түздең.

И р . Сезгә баргач, үзең өскә ташландың бит.

Х а н ы м . Ә нишләргә кушасың? Минеке атна ярым югалып йөрде, ләх булып кайтып егылды. Нәкъ шул чагында килеп кермәсәң.

И р . Ә син үтә күренмәле эчке күлмәктән муеныма сарылмасаң...

Х а н ы м . Каным кайный минем, аңлыйсыңмы, каным кайный!

И р . Хәзер суытабыз аны!

*Ут сүнә. Яктыра. Алгы планда х а т ы н һәм д у с.*

Д у с . Эшләр гөрлиме?

Х а т ы н . Зарланмыйбыз.

Д у с . Хуҗа күренмиме әллә?

Х а т ы н . Ул Мәскәүдә, берсекөнгә генә кайта.

Д у с . Мәскәүдә? Һы... Шушындый сылу хатынын ялгыз калдырыпмы?

Х а т ы н . Кирәкми. Кырык кат әйттем. Миңа бәйләнергә кирәкми.

Д у с . Аптырыйм мин сиңа. Укаң коеламы инде, йә? Бер генә булса да яратасым килә үзеңне.

Х а т ы н . Меңенче тапкыр кабатлыйсың бугай. Телеңне юкка әрәм итәсең.

Д у с . Да-а... Эт симерсә, хуҗасын тешли, ди.

Х а т ы н . Мине эткә, үзеңне хуҗага тиңләвеңме бу?

Д у с . Юк. Просто шулкадәр яхшылыкларымнан соң бер генә тапкыр булса да якты чырайга лаектыр бит инде мин?

Х а т ы н . Үз вакытында булыштың, рәхмәт. Синең ярдәм белән аякка бастык. Бурычларыбызны акчалата гына түләп бетерү җитмәдеме, инде мин дә кирәкме?

Д у с . Ачы телле син. Турыдан ярып сөйләшәсең. Шуңа күрә ошыйсың да.

Х а т ы н . Кызларны пирчәткә урынына алыштырып торырга мөмкинлегең бар.

Д у с . Бар. Алыштырам да.

Х а т ы н . Шулай булгач? Мин нәрсәгә кирәк сиңа?

Д у с . Бәлки, кызык өчендер. Моңарчы үземне кире какканнарын күргәнем булмады бит.

Х а т ы н . Минем ирем сине үзенең дусты дип саный.

Д у с . Санасын. Дөрес эшли.

Х а т ы н . Ә бит син җирәнгеч кеше.

Д у с . Ир-атлар барысы да шулай.

Син әллә үз иреңне башка камырдан әвәләнгән дип санныйсыңмы?

Хатын. Ул хамелеон түгел.

Дус. Их, бу хатын-кыз. Чәче озын, акылы кыска... Син аны бу минутта чыннан да Мәскәүдә дип уйлыйсыңмы?

Хатын. Ул Мәскәүдә.

Дус. Әгәр мин сиңа ул Мәскәүнең шәһәрнең теге очындагы өч бүлмәле фатирда икәнен расласам? Кем белән икәнен дә әйтеп бирсәм?

*Хатын дәшми.*

Дус. Беләсеңме, син ике гасыр арасында адашыбрак калгансың бугай. Берьюлы ак та, кара да булырга исәп, ә? Юк инде, жаныңны акчага саткансың икән, синең табынганың, сәждә кылганың – бары тик акча, акча, акча гына була ала, җанкисәгем. Ә акча ул – сине кол итә, үз кубызына теләгән көенә биетә. Аh, ничек дәртле, ничек сихерле аның көе?! Елан кебек, телләреңне асылындыра-асылындыра биисең. Хәлең бетеп туктарга уйласаң да, ул көй сине мәрткә киткән җиреңнән кабат торгызып биетә. Ач күзеңне, дөнья бу, җанкисәгем!

Хатын. Миңа салкын. Мин туңам. Миңа шулкадәр салкын.

*Артка барып, мамык шәлне ала. Аны тарата. Бая аз гына булып күзе киткән өлеш шактый зурайган. Алгы планда кыз. Колагында колакчыннар. Шул көйгә селкенә.*

Кыз. Ма, син чё? Елыйсың штоли?

Хатын *(аңа текәлеп карап тора)*. Син кайда булдың?

Кыз. Что за вопрос? Кайда булсам да, барыбер түгелмени?

Хатын. Мин сиңа сорау бирдем: син кичәдән бирле кайда йөрдең?

Кыз. Мин җавап бирдем. Кайда йөрсәм дә, какая разница? Синең ни эшең бар?

*Хатын кисәк кенә Кызның яңагына сугып җибәрә. Үзе дә куркып китә. Кыз аңа акаеп карый.*

Кыз. Одурела штоли? Мин бөтенесен пага сөйлим!

Хатын. Гафу ит. Үзем дә сизми калдым.

Кыз. Минем юклыкны әле генә күрдеңмени? Ә бит мин бөтенләй юк, мин, чыннан да, юк бит, юк!

Хатын. Кызым, тыңла әле...

Кыз. Син миңа «кызым» дидең? Ма, ты чё? Каян килгән сентиментальлек?

Хатын. Мин – синең әниең. Бераз булса да тоныңны үзгәрт.

Кыз. Мин нормальный тон белән сөйләшәм. Һәрвакыт шушы тонда.

Хатын *(кызына бик озак текәлеп тора)*. Синең берәрсенә гашыйк булганың бармы?

Кыз. Мин синең алдыңда отчитываться должна, да?

Хатын *(кычкыра)*. Кызым, мин – синең әниең...

Кыз. Ә мин белми идем. Хаха-ха...

Егет. Чё это с ней?

Хатын. Кемнәр белән, кайларда йөри синең сеңлең?

Егет. Мин каян белим.

Хатын. Син – аның абыйсы. Яклаучысы, саклаучысы. Син дә белмәгәч.

Егет. Ма, ә син үзең безнең турыда берәр нәрсә беләсеңме соң?

*Хатын хәлсезләнеп, караватка утыра.*

Х а т ы н . Синең берәрсенә гашыйк булганың бармы?

Е г е т. Ты чё, ма, мин синең алда отчитываться должен, да?

Х а т ы н . Улым, мин – синең әниең...

Е г е т. Ә мин белми идем. Ха-ха-ха...

*Х а т ы н шәлне иңбашына яба. Йөрәген тотып, авыр итеп тын ала. Ут х а т ы нга төшә.*

Х а т ы н . Йоклыйсыңдыр инде. Тагын арып кайткансыңдыр. Мин дә ялкытканмындыр. Шактыйдан урын өстендә ауныйм. Ни алга, ни артка дигәндәй. Кыз да сорый, кайчан терeләсең инде, ди... Яшь бит әле мин, гомернең яртысы да яшәлмәгән кебек. Кем ышансын... Шундый матур яшәп киткән идек, әй. Кай мәлдә тормыш арбасын салуландырып җибәрдек? И, хаталарның җеп очын табып, киреләр сүтеп җыясыңмыни... Бернәрсәбез дә юк чагында бездән дә бай кеше булмаган лабаса... Хәзер бар нәрсәбез дә бар һәм берниебез дә юк... Гомернең узганын да, киләсен дә акчага сатып алып булмый икән бит...

*Ут сүнә. Яктыра. Алгы планда и р һәм х а т ы н. Ир бая алып киткән сумкасы белән.*

Х а т ы н . Юлларың уңдымы? *(Иренә текәлеп карый.)*

И р . Барысы да нормально. Арытты гына.

Х а т ы н . Шулайдыр. Самолёт белән дисәң дә, ерак юл. Арыгансыңдыр. Киемнәреңне машинага салыйм.

И р . Алар пычрак түгел, борчылма.

Х а т ы н . Алайса, үзең юын. Коенып чык.

И р . Менә анысы комачауламас.

*Х а т ы н үз-үзен кочаклап, башын ия.*

Е г е т. Па, акча кирәк иде.

И р *(кесәсенә тыгылып)*. Соңгы арада күпкә китмәдеме? Көн саен акча, акча...

Е г е т. Хәзерге заманда акчасыз бер адым да атлый алмыйсың.

И р . Синең кебекләр үзләре теттереп дөнья көтә. Ә син һаман әзергә бәзер.

Е г е т. Па, чё, үз улыңа акча жалко штоли? Хәер биргән кебек саранланасың.

И р . Саранланмыйм. Әзрәк чаманы бел диюем.

Е г е т. Па, барыбер бирәсең бит инде. Давай сүзгә вакыт әрәм итмә.

К ы з . Па, миңа тоже акча кирәк!

И р . Да-а, кесәң генә чыдасын... *(Акча бирә.)*

К ы з *(алга килә. Әрнүле пышылдап, кулындагы акчаларга карап, үзалдына)*. Па, а чё син сорамыйсың, ул акчалар нигә кирәк, ничек туздырасың, нишлисең, ничек көн үткәрәсең дип нигә сорамыйсың, па?

*Ут сүнә. Алгы планда и р һәм д у с.*

Д у с . Эреләнү җитте синең. Соңгы арада күзгә-башка күренмисең.

И р . Үзең беләсең, әле монда, әле тегендә йөгерәм.

Д у с . Әле тегендә йөгерәм диген... Йә, ярый. Малаең белән сөйләштеңме?

И р . Хы. Нәрсә турында сөйләшергә тиеш идем?

Д у с . Ничек, ул сиңа бернәрсә дә әйтмәдемени?

И р . Давай, боргаланып-сыргаланып тормыйча гына, яме. Ни турыда әйтергә тиеш иде ул миңа?

Д у с . Минем салонда күпме акча оттырып, сине ялангач калдырырга җыенуы турында.

И р . Ничек салонда? Каян барып кергән ул анда?

Д у с . Җиргә төш, дустым. Син нәрсә, әллә уен салоннарына, казиноларга дүрт аяклы, алты куллы кешеләр йөри дип беләсеңме? Нәкъ синең-минем кебек гадәти җан ияләре килә анда.

И р . Минем малай... Син шуны белә торып, аны упкынга этеп төшердеңме? Миңа берни дә әйтмәдеңме?

Д у с . Ә синең сораганың булдымы? Миннән түгел, улыңның үзеннән. Нишли ул, син биргән акчаларны нәрсәгә туздыра? Ха-ха-ха... Инде икенче елын безнең даими кунагыбыз ул, ата кеше!

И р . Күпме?..

Д у с . Ярыйсы *(кәгазь суза)*.

И р *(башын тотып)*. Үтерәм!

Д у с . Синең белән дуслык хакына бер атна вакыт бирдем мин аңа. Өч көне үтте. *(Сарказм белән)*. Син Мәскәүдә чагында...

И р . Башым эшләми. Бу хәтлене табарга... Банктагылар гына җитми дә җитми.

Д у с . Күчемсез милкең бар. Кибетләрең, фатирларың, хан сарае кебек төзеткән коттеджың, машиналарың...

И р . Син нәрсә, безне чыннан да ялангач калдырырга җыенасыңмы әллә?

Д у с . Ә нигә? Кеше туганда да шыр ялангач туа, үлгәндә дә норковый тун кидереп күммиләр...

И р . Туктале, уйларга бир..

Д у с . Уйларга? Ха-ха-ха...

*Алгы планда и р һәм х а н ы м.*

И р . Синең ирең мине пычаксыз суярга җыена. Башны элмәккә генә тыгасы калды бугай.

Х а н ы м . Бердәнбер акыллы юл шул дисеңме?

И р . Тагын нишләп була?

Х а н ы м . Эзләсәң табыла ул.

И р *(җанланып китә)*. Әллә башыңа берәр акыллы фикер килдеме?

Х а н ы м . Син нәрсә, моңынчы мине тилегә саный идеңме әллә?

И р . Юк инде. Син дә һәр сүзгә бәйләнергә торма әле.

Х а н ы м . «Син дә...» Тагын кем бәйләнә инде синең һәр сүзеңә? Хатыныңмы?

И р . Юк. Аның миннән соңгы арада берни сорашканы да юк. *(Сискәнеп китә)*. Тукта, безнең сөйләшкәнебез дә юк бугай бит... Минем аны юньләп күргәнем дә юк шикелле. Бүлнискә барам диде. Кайтты. Тагын китте. Кичә өйдә иде. Шайтан алгыры...

Х а н ы м . Сүзне башкага бордың...

И р . Ә-ә... Йә, нинди вариант тәкъдим итмәкче буласың?

Х а н ы м . Хатыныңны бир бер төнгә... минекенә.

И р . Нәрсә-ә? Син нәрсә, ычкындыңмы әллә?

Х а н ы м . Нигә кычкырасың? Бүре дә тук, сарык та исән.

И р . Авызыңны яп! Ни сөйләгәнеңне колагың ишетми.

Х а н ы м . Минеке инде ничә ел сыр тирәсендәге төлке кебек әйләнеп йөри. Хатыныңны алай ук каты чикләвек дип уйламаган идек. Хәтта синең минем янда кунып йөргәнеңне белгәннән соң да ярылып төшмәде.

И р . Син... Сез... *(Ярсый, кизәнә, кулын кире төшерә.)*

Х а н ы м *(бик тыныч)*. Нигә гаҗәпләнәсең? Әйе, ул барысын да белә. Синең әледән-әле нинди Мәскәүдә, кем белән булуыңны да...

И р *(башын тотып)*. Аның бит берни дә сиздергәне юк.

Х а н ы м . Син шулай уйлыйсың. Күзләренә күтәрелеп караганың бармы соң?

И р . Нигә, ни өчен?

Х а н ы м . Ни өченме? Дөресен әйтимме? Нигә әле мин, шушы кадәр матурлыгым, шушы кадәр байлыгым белән зар елап яшәргә тиеш идем? Мин дә бит хатын-кыз бәхетенә өметләнеп, иремә ярատып чыктым. Ә ул... Бар җылысын акчага һәм сөяркәләренә таратып бетерә иде. Ана булу бәхетеннән дә ул мәхрүм итте мине. Өйләнешеп, авырга узгач, «үзебез өчен яшәп калыйк» дип, баламны төшерттерде. Шуннан соң инде башка бик теләсәк тә... Акчаның күлләрендә йөзеп яшим, баштарак, ай, ничек рәхәт иде. Тик соңыннан эчтән нидер кимерә башлады. Аннан сезне күрдем. Сез... шыр ялангач өйдә, иске шәлгә төренгән балаларыгызны үчтекиләп, бер-берегезнең күзенә генә карап, бәхет күлендә коенып яшәп ята идегез...

И р . Адәм кыяфәтендәге иблис син...

Х а н ы м . Бәлки шулайдыр да.

И р . Ирең синең чын йөзеңне белсә, үз куллары белән буып үтерер иде, мөгаен.

Х а т ы н . Ул барысын да белә.

*И р дәшми.*

Х а т ы н . Син минем янда беренче һәм соңгы ир дә түгел, анысын да белә. Хатыныңны ризалат, бер төннән укасы коелмас.

И р *(башын тотып)*. Монысы сиңа нигә кирәк, аңламыйм?

Х а н ы м . Шушы пычрак дөньяда нишләп әле ул гына чиста калырга тиеш ди?

*Алгы планда и р һәм х а т ы н.*

И р . Больницага барам дигән идең.

Х а т ы н . Бардым. Соңгы арада әллә нишләп гел хәлем бетә.

И р . Нәрсә диделәр?

Х а т ы н . Әдәп өчен генә сорыйсыңмы?

И р . Нишләп инде? Син бит – минем хатыным.

Х а т ы н . Шулай бит әле.

И р . Дарулар кирәк булса, акча җәлләмә.

Х а т ы н . Акча... Бер кочак дару алдым. Үтәр әле.

И р . Син давай, чирләмә...

Х а т ы н . Үзеңнең дә йөзең качкан...

И р . Качар да...

*Алгы планда к ы з, е г е т. Һәрберсе үзалдына сөйләнәләр.*

К ы з . Гашыйк булу, имеш... Җир йөзендә йөргән тере мәетләргәме?

Е г е т . Кесә тулы акчаң булса, мәхәббәт аңлатып үзләре арттан йөгерәләр. Ха-ха-ха...

К ы з . Мин кешеләрне күралмыйм. Аеруча шат күңелле, елмаеп яшәгәннәрне. Кесәләрендә җил уйный – ә алар елмаялар. Бер-берсенә карап елмаялар! Ненавижу! Ни өчен мин елмая белмим? Ни өчен?

Е г е т . Бу дөньяның патшасы да, Алласы да – акча, акча, акча.

К ы з . Минем ярты гәүдәм ут-ялкында яна, яртысы туңып калтырана кебек. Елмая белгәннәрне күреп дөрләп янам. Ни өчен мин генә күңелемнән еларга тиеш әле, ни өчен башкалар шушы пычрак дөньяда елмаеп яшәргә тиеш?

Е г е т . Миңа срочно акча кирәк! Пага ничек әйтергә?

*Алгы планда ха т ы н һәм д у с.*

Д у с . Йә, нәрсә, җанкисәгем, барысын да тыныч юл белән хәл итәбезме?

Х а т ы н . Нәрсәне инде ул? *(Хәлсез генә елмаеп.)* Тагын һаман шул ук балык башымы?

Д у с . Шул ук балык башы. Миңа син кирәк.

Х а т ы н . Минем башкалардан бер артык җирем дә, ким җирем дә юк.

Д у с . Бәлки. Тик миңа син кирәк.

Х а т ы н . Китим әле мин.

Д у с . Син миңа бер төнеңне бүләк итәсең, ә мин шуның өчен улыңның бар бурычын сызып атам.

Х а т ы н . Улымның? Нинди бурычын?

Д у с . Ничек, ирең сиңа бернәрсә дә әйтмәдемени?

Х а т ы н . Юк. Юк. Мин берни белмим.

Д у с . Ну и семейка... Улың минем салонда, беләсеңме, күпме акча оттырды? *(Колагына иелеп пышылдый.)*

Х а т ы н *(йөзе агарынып китә, чайкалып куя)*. Йа Хода!

Д у с . Кызык, әйеме? Башына бәла-каза килсә, кеше Ходайны исенә төшерә. Аңынчы ни уйлыйдыр...

Х а т ы н . Син моны барысын да алдан уйлап эшләдең бит, шулаймы?

Д у с . Бәлки. Мин артка чигенергә өйрәнмәгән шул.

Х а т ы н . Ал. Бар акчабызны, мөлкәтебезне ал. Ә мине тынычлыкта калдыр.

Д у с . Аңламыйм, ничек шулкадәр кире булырга мөмкин, ә? Мин сораган акчаларны китереп биргәч, сез дүртегез дә эшләпә тотып хәер теләнергә чыгып китәчәксез бит, ха-ха-ха...

Х а т ы н . Шулай да булсын. Мал дип, син миңа тәнемне генә түгел, җанымны сатарга кушасың. Ә минем җаным да, тәнем дә берәүгә генә никах белән бирелгән... Беләм, мин аның турында барысын да беләм. Артык сүз кирәкми *(хәлсезләнеп тын ала).*

Д у с . Нинди хатын син, ә? Шундый диагноз куелганын белгәннән соң да...

Х а т ы н *(ярсып)*. Кабахәт син! Минем һәр адымымны күзәтеп йөрисеңме? Аны берәү дә белергә тиеш түгел, аңлыйсыңмы, берәү дә! Балаларым да, ирем дә!

Д у с *(тыныч кыяфәттә)*. Борчылма. Миннән чыкмас. Шуны гына әйт: берәр ничек ярдәм итә аламмы?..

Х а т ы н . Аласың. Мине тынычлыкта калдыр.

Д у с . Гаҗәп кеше син. Беләсеңме, мин сезгә беренче килгән көнне үк җаныңны үтәли күргәндәй булдым. Мин кайнаган дөньяда бер генә чиста кеше дә юк иде, ә монда – шулкадәр җылы, шулкадәр саф, бәллүр савыт кебек үтә күренмәле бер садә җан утыра. Иреңнән көнләштем. Аның бәхетеннән көнләштем.

Х а т ы н . Һәм безнең тормышыбызга кеше кыяфәтендәге иблис булып үтеп кердең, шулаймы?

Д у с . Шулай. Башта азарт биләп алды, тора-бара мин сине үлеп яратуымны аңладым.

Х а т ы н *(хәлсез елмаеп)*. Синең кебекләр ярата белми, үзеңне алдама.

Д у с . Нәрсә, әллә минем эчемдә җаным юк дисеңме? Сине үземнеке итә алмаудан үз-үземне күралмас дәрәҗәгә җитеп, ай, ничек бәргәләндем мин. Әгәр бер генә тапкыр булса да минем кочагыма керсәң, син дә нәкъ башкалар кебеккә әйләнер идең

дә мин синең дә калганнар кебек үк гап-гадәти икәнеңне аңлап, чиркаlisted ныр, күңел түремнән чыгарып атар идем...

Х а т ы н . Матур сөйлисең...

Д у с . Чынын сөйлим. Синең хәлеңне беләм. Врачың янында булдым.

Х а т ы н . Хәзер минем көчсезлегемнән файдаланмакчы буласыңмы? *(Елмая).*

Д у с . Сиңа елмаю шундый килешә, сылуландыра...

Х а т ы н . Ул да кайчандыр миңа сылуым дип эндәшә иде. Күптән инде, бик күптән...

Д у с . Мин сине яратам. Кичер мине. Курыкма, бу яратуыма алмашка берни сорамыйм.

*Ут сүнә. Яктыра. Х а т ы н урын өстендә ята. И р аңа иелеп карый.*

И р . Озакка китте түгелме? Врач ни ди?

Х а т ы н . Үтәр, ди. Бераз аунап ят, ди.

И р . Алай булса, ярый. Мин ни, киттем. Даруларыңны эчәргә онытма.

Х а т ы н . Онытмыйм. Эчәм. Балаларны хәтергә ал әле.

И р . Тагын проблема тудырып кына карасыннар! *(Хатынга текәлә.)*

Х а т ы н . Тагын нәрсә?

И р . Юк. Берни дә юк. Барысы да хәл и-тел-де.

*И р аңа карап-карап тора да артка чигенә.*

Д у с . Кузгалма, торма. Хәлеңне белергә генә сугылдым.

Х а т ы н *(башын читкә бора).* Нинди кеше соң син?

Д у с . Гап-гади. Мин сине киләсе атнада Израильгә алып китәм. Барысы да сөйләшенгән.

Х а т ы н . Мин беркая да бармыйм.

Д у с . Барасың. Яшисең килсә, барасың.

Х а т ы н . Ә син каян беләсең, бәлки минем яшисем килмидер? Мин барысын да югалттым. Үземне дә, балаларымны да, иремне дә. Кай арада – шунысын гына сизми калдым.

Д у с . Арттырасың. Алар барысы да синең янда.

Х а т ы н . Улымның оттырган бөтен акчасын кичергәнсең. Ирем мине синең белән төн үткәргән дип уйлый.

Д у с . Үзе шулай дидеме?

Х а т ы н . Әйтмәде. Мин аны күзләреннән укыдым.

Д у с . Каян килгән укымышлы кеше...

Х а т ы н . Ни өчен? Югыйсә мин сиңа аңлаешлы итеп әйттем.

Д у с . Беләм. Ә болай гына бер генә гамәл дә кылырга ярамыймы? Яратырга, кичерергә... Алмашка берни дә сорамыйча гына?

Х а т ы н . Гафу ит. Синең кебекләр, болай гынамы?

Д у с . Минем кебекләр... Кызык әйттең.

Х а т ы н . Аңлаешсыз кеше син. Тышкы кабыгың белән эчке дөньяң ярашмый димме?

Д у с . Ә без бөтенебез дә битлек киеп яшибез. Без бөтенебез дә – артист-лар!

Х а т ы н . Ә мин тормышта уйнарга җыенмаган идем. Тормышыбызны түгәрәкләп бетерербез дә, рәхәтләнеп яши башларбыз дип кенә өметләнгән идем. Шул ялган өмет белән үз-үземне алдап, чын тормышның янәшәдән узып барганын гына сизми калганмын.

Д у с . Кыскасы, шул: киләсе атнада юлга. Билетлар алынган.

Х а т ы н . Мин беркая да бармыйм. Күрәчәктән җир читенә китеп тә котыла алмыйсың. Ул гомерне бер елга озынайттың ни, бер көнгә ни... Иртәме-соңмы, барыбызның да юл ахыры бер нокта.

Д у с . Син болай тиз бирешергә тиеш түгел. Син көчле кеше, аңлыйсыңмы, көчле кеше! Күргәнең бардыр: инде бер генә өмете калмаган дигәннәр дә ил буйлап садака җыя, каядыр чит илдә дәва табарына, терелеренә ышана. Ә син?

Х а т ы н . Кулыңнан килсә, авыру балаларга булыш. Хаталы булса да, яшәлде бит инде, миңа шунысы да җитәр. Дөньяның матурлыгын күрергә дә өлгермәгән авыру сабыйлар кызганыч. Нинди олы дәүләттә шуларга таяныч табылмасын инде. Үз башыңа төшкәч кенә уйлана башлыйсың икән ул.

Д у с . Син яшәячәксең. Мин сине кулларымда күтәреп булса да алып китәчәкмен, менә күрерсең!

Х а т ы н *(хәлсез генә елмая)*. Мине кире дисең. Үзең миннән дә кирерәк.

*Ут сүнә. Яктыра. Баягы вакыйга кабатлана. Е г е т планшетта уйнап утыра. К ы зның колагында наушник.*

Х а т ы н *(башын күтәреп)*. Су... Берәрегез су гына бирсә...

*Җавап кайтаручы юк. Хәлсезләнеп кире ята. Бераздан көч-хәл белән торырга маташа. Егет аны күреп ала.*

Е г е т *(канәгатьсез генә)*. Нәрсә?

Х а т ы н . Су... Тамагым яна...

Е г е т *(Кызның колагындагы наушнигын йолкып ала)*. Бар әле, су апчык.

К ы з . Нигә мин? Сиңа әйткән бит.

Е г е т . Кулың каламыни инде? Уйнап бетерәсе иде.

К ы з . Күреп торасың бит, мин җыр тыңлыйм.

Е г е т . Синең шул булыр. Бар инде.

К ы з . Үзеңә кирәктә нинди тон белән эндәшәсең, ә?

Е г е т . Дура.

*Кулын селтәп, караватт башындагы стаканны алмакчы булып үрелә. Хатын инде торып чыгып киткән. Е г е т ишеккә барып карый да кире утыра. Х а т ы н көч-хәл белән чыгып урынга ятмакчы була. Кулындагы стаканы төшеп ватыла.*

Е г е т . Үзем алып чыга идем бит инде. Ну вот... *(Кызның колагындагы наушнигын йолкып ала.)*

К ы з . Нишлисең соң син? Па гына кайтсын, яме?

Е г е т . Себереп ал. Минем уен бетә...

К ы з *(чыраен сытып)*. Ма, ну кайчан тереләсең инде син? Туйдырды инде. Чәйне мин яса, өстәлне мин җыештыр.

Е г е т . Син – кыз кеше, эшең шул.

К ы з . Егет кешегә идән себерергә ярамыймы әллә?

Е г е т . Кыенмыни инде? Себерке, соскы аласың да...

К ы з . Менә, менә, бер кыенлыгы да юк. Үзең дә себерке, соскы аласың да...

*Әйләнеп карыйлар. Х а т ы н көч-хәл белән идәндәге стакан ватыкларын соскыга җыя.*

Кыз. Үзем түгәрмен, шунда торып торсын.

Егет. Да, тагын берәр атнадан.

Кыз. Бәйләнмә әле. Кая соң бу әти? Таң ата бит инде.

*Ир алга үтә.*

Кыз. Чё шулай озак?

Ир. Эшләр, кызым, эшләр.

Егет *(мыскыллы елмаеп)*. Иртәнге өчкә хәтлеме?

*Ир хатын яткан якка текәлеп карый.*

Ир. Дару эчтеме?

*Кыз белән малай иңсәләрен җыералар.*

Кыз. Эчкәндер.

Егет Бездән сорамады.

Ир. Нигә йокламыйсыз?

Кыз. Ә минем йокы килми.

Егет Канишны. Көндез бердә тор да.

Кыз. Үзеңне бел. Миннән ун минутка алдан торган икән берәү.

*Ир карап-карап тора да кәчтүмен салып киерелә, йокларга җыена.*

Кыз. Па, акча калдыр әле.

*Ир кесәсеннән шактый акча чыгарып, Кызга суза.*

Егет Ә миңа?

Ир. Син кая барасың?

Егет. Курыкма. Анда йөрмим. Беләсең, завязал...

Ир *(акча биреп)*. Сез анда чамалап... Тәртип булсын, яме?

Кыз, Егет. Всё о'кей, па!

*Караңгылана. Ут яктысы хатынга төшә. Ул көчкә торып, сөялеп утыра.*

Хатын. Нишләп шулкадәр салкын? Тышта яз. Җылыткандыр бит инде.

*Тормакчы була, урындык аркасына тотына, урындык авып китә. Тавышка Ир торып утыра.*

Ир. Нәрсә, су кирәкме?

Хатын. Юк. Салкын.

Ир. Соң, юрганыңны бөркән.

Хатын. Җылы керми. Дөньясы салкын.

Ир. Тагын башлана инде... Мә, җәймәне бирәм.

Хатын. Кирәкми. Шкафтан мамык шәлне генә табып бирсәң.

Ир. Төн уртасында шәл эзлимме инде?

Хатын. Өске киштәдә. Уң як почмакта.

Ир *(шәлне ала. Эченнән тәмәкеләр төшә)*. Монысы нәрсә тагын?

Хатын. Тәмәке. Көя төшмәскә.

Ир. Болай да кортлап беткән иске шәл түгелме соң?

Хатын. Иске түгел. Әнкәйдән калган.

Ир. Моның ни җылысы булсын.

Хатын. Бар. Әнкәй шәле ул.

Ир. Бүтән кирәк нәрсә юкмы? Бер торганда әйтеп кал да...

Хатын. Тынычлап йокла. Берни дә кирәкми.

Ир. Тынычлап, имеш. Йокларсың...

*Ята. Җәймәсен башыннан бөркәнә. Хатын шәлне сүтә. Сөйләнә.*

Хатын. Бигрәк тиз үтә икән шул кеше гомере. Ә менә шәл булып шәл ничә буынга чыдасын әле. Тик күзе киткән. Шуны башта ук эләкте-

реп куйган булсам инде... Ничек чыгарып атмаганмын әле үзен... Безнең оныкларны моңа төреп тирбәтүче булмас шул. Иске, диярләр, кортлап беткән дип көләрләр. И-и, нинди шәл... Туу белән кулына телефон тоттырып куярлар. Заманасы шул. Дөньясы шул.

А н а *(арткы планнан тавышы килә)*. Замананы гына гаепләү дөрес микән, балам? Дөнья пычрак түгел, бәндәләрнең күңеле керле. Нәфес каралта йөрәкләрне, нәфес. Матурлык күрергә яратылган күзләрне дә, Ходайдан иңгән сүзләрне ишетергә дип бирелгән колакларны да, иман белән мөлдерәмә булырга тиешле күңелләрне дә шул мәлгунь каплап тора.

Х а т ы н *(хәлсез тавыш белән үзалдына көйли)*.

Аһ, әгәр дә мин гөл булсам,
Ак чәчкә атар идем.
Атлап түгел, яшьлегемә
Йөгереп кайтыр идем...

Бу синең җыруың иде бит, әнкәй!

А н а . Кайтулар юк, балам, бер киткәч, үткәннәргә кайту юк. Юллар ябык, капкалар бикле.

Х а т ы н . Кичер мине, әнкәй!

А н а . Син мине кичер, балам. Күңел күзләреңне ачарга житешмәдем.

Х а т ы н . Миңа салкын. Миңа синең җылың кирәк, әнкәй! Ташлама зинһар, калдырма ялгызымны!

А н а . Ашыктың, балам, һай, ашыктың. Ашыгуың белән соңга калдың...

Х а т ы н *(җан ачысы белән кычкыра)*. Әнкәй!

*Алгы планда д у с һәм х а н ы м.*

Х а н ы м . Саунагамы?

Д у с *(бераз дәшми тора)*. Мәчеткә барып кайтам.

Х а н ы м . Ка-а-ая?

Д у с . Ишеттең бит.

Х а н ы м *(мыскыллы елмаеп)*. Гөнаһларыңны юдыртмакчы буласыңмы әллә?

Д у с *(үзалдына сөйләнгәндәй)*. Нәрсәдер дөрес түгел, дөрес түгел...

Х а н ы м . Синең башың дөрес түгел бугай. Кичә, гадәттәгечә, артыграк җибәргәнсеңдер. Мәчет имеш...

Д у с *(хатынына текәлеп тора)*. Синең кайчан да булса уйлап куйганың бармы: кем син, нигә яшисең, җирдән киткәч, нәрсә көтә?

Х а н ы м . Алай-болай берәр секта каптырып алмагандыр бит үзеңне?

Д у с . Моңа хәтле минем өчен яшәүнең бөтен мәгънәсе – бүгенге тормыш иде.

Х а н ы м . Ни үзгәрде?

Д у с . Яшәү мәгънәсе – үлем икән ләбаса. Теләсә кайсы мизгелдә якаңнан тотып алырга әзер Әҗәл агай икән. Дөнья белән акча түгел, Аллаһ идарә итә?!

Х а н ы м *(куркынып)*. Син саташып сөйләнмисеңме ул?

Д у с . Курыкма, саташмыйм. Нәрсә диде әле ул: барыбызның да юл ахыры бер нокта, дидеме?

Х а н ы м . Кем әйтте? Точно әләктергәннәр икән үзеңне!

Д у с *(үзалдына уйлангандай)*. Гаҗәп. Шул бер ноктаны да атлап үтә алмагач, минем банк-банк долларларымның кодрәте дә шулкадәр генә, димәк?

Х а н ы м . Шоколад төсенә кереп, кызынып кайтасым килә. Киттем әле мин.

Д у с *(кулын селти)*. Таш бәгырь син. Синең җаның юк кебек... *(чыгып китә)*.

*Х а н ы м, әле генә кызулап атлап чыгарга барган җиреннән,*

*кисәк туктала, бик озаклап һәм бик дикъкать белән ире артыннан сүзсез карап тора. Куллары белән кисәк кенә изүен йомарлап тота. Үзалдына пышылдап, җан әрнүе белән сөйләнә.*

Х а н ы м . Бәгырь, имеш. Җан, имеш... *(Ире киткән якка борылып, кычкырып ала.)* Ә син каян беләсең? Берәр тапкыр минем җаным белән кызыксынганың булдымы? *(Тагын әрнүле пышылдый.)* Ул бәгырьнең ни сәбәпле таштан да катыракка әверелүен аңлыйсыңмыни син... Дөньяга туганчы ук бәгырьсезләрдән ярал да... Минем бит үз гомеремдә бер генә кешегә дә, бер генә тапкыр да әни дип эндәшеп караганым юк! Кем ул мине тудырган кеше, ни җаны белән үз сабыен язмыш кочагына ташлап калдырган? Нинди була ул әни төсе, әни исе, әни пешергән аш тәме – мин бит боларның барысыннан да мәхрүм идем... Шулай да мин әни дигән кешене кайчагында төшемдә күрәм. Чынлап. *(Хыялый тавыш һәм мәҗүси елмаю белән.)* Өнемдә йөз-кыяфәтен бер генә тапкыр да күрмәсәм дә, төшемдә барысы да аермачык кебек. Имеш, минем нарасый чагым. Әнкәемә сарылганмын да, алсу иреннәремне чупырдатып, шундый тәмләп күкрәк сөте имәм! Ул мизгелләрнең татлылыгы!... Ә бит минем бер генә тамчы да күкрәк сөте авыз иткәнем булмады! Мин дөньядагы иң олы бәхеттән мәхрүм үстем! *(Истерикага бирелеп кычкырып ала).* Ишетәсеңме, мин әни җылысыннан мәхрүм идем! *(Тагын әрнүле пышылдый).* Үзем дә әни була алмадым... Минем үземә дә беркем дә, беркайчан да, бер генә тапкыр да әни дип дәшмәячәк... Ә син җан дисең, бәгырь дисең... *(Башын иеп тын кала.)*

*Алгы планда к ы з. Колагындагы наушнигын муенына төшергән.*

К ы з . Мин үз атамның акчаларын талыйм *(зәһәр елмая)*. Аның бер генә тапкыр да ул акчаларны кая куясың дип сораганы юк... Ә мин бүген тагын балалар йортында булдым. Пустышкалар, пелёнкалар, гөлҗимеш сироплары, памперслар илттем. Әти акчасына! *(Тагын зәһәр елмая)*. Андагы балалар да минем кебек – алар да елмая-көлә белми *(башын ия)*. Алар дөньяда әти һәм әни дигән затларның барлыгын да белми. Ә минем бит әтием дә, әнием дә бар!

*Наушниктан х а т ы н тавышы ишетелә.*

Х а т ы н . Бу шәлне сиңа бирәм, кызым. Иске дип чыгарып ташлама берүк. Әбиеңнең дә, әзме-күпме минем дә җан җылысы сеңгән аңа. Син инде җиткән кыз, беркөн килеп үзең дә әни булырсың. Почык борынлы нарасыеңны шушы шәлгә төреп тирбәткәндә, бернәрсәне гомерлеккә күңелеңә салып куйсаң икән, кызым: бу дөньяда ана җылысыннан да кайнаррак берни юк. Шул җылы җитмәгәндә балалар каты бәгырьлегә, җансызга әйләнә икән. Балалар гына түгел, бар дөньясы бозга әверелә икән... Кызганыч, мин үзем моны соңга калып аңладым. Бик соңга. Рәнҗемәгез миңа, күз нурларым...

К ы з *(нәрсәнедер хәтерләргә тырышкандай)*. Күз нурларым? Минем бит бу сүзне кайчандыр ишеткәнем бар!

Е г е т *(планшетта уйнаган җиреннән башын күтәреп)*. Миңа акча кирәк. Күп акча кирәк! Акча кирәк! Кичә безнең шофёрдан

сорап торгач, ул мине өенә чакырды. Эт оясы чаклы бәләкәй генә өйләрендә шундый тәмле ис килә иде. Мин ул исне әле генә искә төшердем: коймак исе ул, без бәләкәй чакта әни пешерә торган коймак исе иде!

*Планшетта х а т ы н тавышы.*

Х а т ы н . Мин бүген синең күзләреңнең төсе үзгәргәнен күрдем. Бәләкәй чагында пешеп җитмәгән карлыган кебегрәк иде алар, ә бүген шомырт каралыгы сеңгән диярсең. Кичер, улым, мин ул төсне бүген генә күрдем. Бәләкәй чагыңда, түшәмгә чөя-чөя сөйгәндә, чырык-чырык килүеңне, аяк табаннарыңны кытыклый-кытыклый мендәр өстендә уйнатканда елмаюдан бит очыңдагы чокырларның батып-батып китүен аермачык хәтерлим. Шуннан соңгы гомер кишәрлеге күзне бәйләп узылган диярсең... Рәнҗемәгез миңа, күз нурларым...

Е г е т *(нәрсәнедер хәтерләргә тырышкандай)*. Күз нурларым? Минем бит бу сүзне кайчандыр ишеткәнем бар!


*Ирнең колагына х а т ы н тавышы ишетелә.*

Х а т ы н . Без бит шундый бәхетле идек. Хәтерлисеңме? Алтынкөмешләрем дә, затлы киемнәрем дә юк иде. Шушы иске шәлне башыма ябынып, аягыма киез итек киеп, капка төбенә чыга идем. Шәлеңнән коймак исе килә дип көлә идең, әйеме? Коймак исе... Соңгы тапкыр кайчан коймак пешереп ашаттым икән? Балаларымның да тел очында коймакның тәме сакланмагандыр инде... Гел әзер пицца, роллар, суши китертеп ашыйлар лабаса... Шәлне ташлаттырма, яме, күз нурым... Ул минем төсем булыр. Безнең саф яшьлегебез төсе булыр... Күзе киткән, ертылып ук киткән... Үзем гаепле, вакытында кулым җитмәгән... Эләктереп куючы булырмы – белмим...

И р . Күз нурым? Минем бит бу сүзне кайчандыр ишеткәнем бар! *(Ике куллап башын тота.)*

*К ы з да, е г е т тә, и р дә өчәүләп х а т ы н яткан караватянына киләләр. Караватпөхтәләп җыештырып куелган, анда иске шәл генә ята. Хатын анда юк...*

Пәрдә.



Зөфәр
Дәүләтов

# ЭРЕТЕР СЫМАН ЙӨРӘГЕМ КОТЫПНЫҢ КАРЫН...

## Сөю түгелме?

Сөю булмыйча, бу нәрсә икән?
Тыя алмыймын нигә үземне?
Йөрәк талпына гел синең янга,
Язмыш дигәнем ул – син түгелме?!

Язгы кояштай карашың назлы,
Иркәли һәркөн гашыйк күңелне.
Күгем бизәгән, җаным җылыткан
Җирдәге кояш – ул син түгелме?!

Челтер чишмәгә куйган чиләгем
Мөлдерәсә дә, тулып түгелми!
Сихәтлек биргән зәм-зәм суыдай
Җаныма дәва – ул син түгелме?!

Сиңа карыйм да күзем чагыла,
Әйталмый йөдим әйтер сүземне.
Яратканымны белми йөрисең,
Шушы газаплар – сөю түгелме?!

## Бер кызга

Белгәннән бирле дөньяда
Син сылуымның барын,
Эретер сыман йөрәгем
Бөтен котыпның карын.

Күңелемә яз китердең,
Тының белән җылытып.

---

Зөфәр ДӘҮЛӘТОВ (1953) – *шагыйрь, прозаик; Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, Р.Төхфәтуллин исемендәге әдәби премия лауреаты. «Тормыш дигән язмыш», «Төзәлмәс яра», «Яшәү яме» һ.б. китаплар авторы. Әлмәттә яши.*

Яратырга тели күңел,
Бар дөньяны онытып.

Йөрәгемә тию белән,
Җаным нурга төрелде.
Син – сусаган күңелемнең
Эзләгәне түгелме?

Үләненә су сибимме
Сиңа илткән сукмакның?
Дөньяда бәхет бар икән –
Җанга рәхәт шулчаклы!

## Син бәхетле миннән башка да

Тормышыңа мин кирәкми инде,
Син бәхетле миннән башка да.
Ятларныкы итте язмыш сине,
Йөрәккәең хәзер башкада.

Үкенечләр өчен калдың мәллә,
Күңел түрләремә кердең дә?
Акылымнан язып сөяр булам,
Синдәй якын түгел беркем дә!

Уйларымнан чыгып кит, дисәм дә,
Йөрәк һаман сиңа ашкына.
Хыялымда гына йөрсәң дә,
Тынар сыман түгел ташкыны.

Синнән башка яшәү – яшәү түгел,
Син бердәнбер мине җилкеткән.
Сине уйлап гомер кичәм менә,
Син бәхетле булсаң – шул җиткән.

## Бәхетле бул

Җиде җил кебек бу сагыш,
Бәгырьне кисә-кисә,
Бәхетсез итәр микәнни?
Яратам да югыйсә.

Син дип саташуларымны
Белми дә йөрисеңдер.
Кояш чәчкәседәй янам –
Юри дә күрмисеңдер.

Бер карашың әсир итте,
Ут кабызды йөрәктә.
Гомер буе янар булам,
Ә югалткач – бигрәк тә.

Бергә чакның һәр минуты
Күңелемнең түрендә.
Оныттырдым дия күрмә –
Син бердәнбер бүген дә.

## Күңел ишегеңне бикләмә!

Сагышым да, юанычым да син,
Син булганга яшим дөньяда.
Син булганга хисем чишмәләре
Әверелде ташкын-дәрьяга.

Чарасыздан хыяллана күңел,
Озатып куя көн дә өеңә.
Сыңар канат белән кагынамын,
Бусагаңа баскан көемә.

Синең уйлар йөзә миннән башка,
Син бәхетне күктән көтәсең.
Ул, булса да, җирдә генә була,
Белсәң иде минсез килмәсен.

Бикләмәче күңел ишегеңне,
Элеп куйма әле келәсен!
«Сөям!» диеп сиңа киләсем бар,
Йөрәгеңә барып керәсем.

Рәхмәт яусын өзгәләгән өчен,
Ике күзем карый мөлдерәп.
Син дип янсын иде моннан соң да
Ялкын камап алган бу йөрәк!

## Син гел йөрәктә

*А.га*

Син – озак эзләп табылган
Язмышым бүләгедер.
Күземә төбәп карама,
Өзәсең үзәгемне.

Синең турыда уйласам,
Ут каба йөрәгемә.
Чын мәхәббәт шушы булса –
Ирештем теләгемә.

Ялгызлыгымны белгәнсең –
Туры килдең юлыма.
Кутәреп йөртәсем килә
Китап язган кулыма.

Минем өчен тугансың да,
Минем өчен үскәнсең.
Сөбханалла сылулыгың,
Әллә күктән төшкәнсең.

Нигә газапладың шулай,
Иртәрәк табылмадың,
Теләмәгән идең мәллә
Мәхәббәт кагылганын?

Бер карашың җитә калды,
Йөрәкне алдың телеп.
Күңелгә саркып кердең бит,
Яратканымны белеп.



Илгиз
Зәйниев

ХИКӘЯЛӘР

# БӘХЕТ

Хатыны башта бик озак кыбырсып ятты, аннан кинәт йокыга китте дә гырлый да башлады. Әнсарның хатыны эре сөякле, түм-түгәрәк, ире әйтмешли, «колачлап алмаслык Россия сыман». Әнсар үзе янәшәдә йокыга китә алмый ята бирде. Ул күптән түгел генә иярченле антенна куйдыртты, шуңа телевизорында каналлар күп. Пульт төймәсенә бер бармак белән генә басып, ул дөнья буйлап сәяхәт итә иде. Бер-бер артлы каналдан-каналга сикереп, берсендә дә озаклап тоткарлана алмады. Башта ул «хәзер карарлык бернәрсә юк» дип уйлады. Элеккечә өч канал булган заманалар узды инде. Хәер, алар ул вакытларда да хатыны белән телевизор бүлешә алмыйлар иде. Ләкин бу зәвык һәм кызыксыну бәрелеше иде. Бу каршылыкны алар аш бүлмәсенә икенче телевизор куеп хәл иттеләр. Ә хәзер исә карарлык канал юк.

Әнсар телевизорын сүндереп куйды. Аяк очындагы таза мәче мырлавы белән хатынының гырлавы рифма хасил итә дә үзенә бер көй чыга, ул шул көйгә изрәп, кешелек турында уйлап ятты. Күз алдына бер-бер артлы телевизорда күргән сурәтләр килде, гүя телевизор аның миенә кереп утырган иде. Сурәтләр әкренләп, бер картинага җыелды. Пазл тәмам җыелып беткәч, Әнсар «кешелек – бәхетсез» дигән нәтиҗәгә килде. Шул фикер белән бергә ул йокысы бөтенләй качканын аңлады. Ул бүген тәгаен йоклап китә алмаячак.

Әнсар урыныннан торып, тәрәзә янына килде. Урамда яңгыр сибәли иде. Ул бүлмә буйлап арлы-бирле йөренә башлады, аның һәрбер адымыннан идән такталары сыкранып, сызланып куя иде сыман. Баскыч төбенә чыгып, тәмәкесен көйрәтеп җибәрде. Ашыкмыйча, сирәк кенә суырып тартты – уйлана иде. Йокы белән тынычлыгы да качты. Әнсар өйгә кереп, өстенә фуфайкасын элде, козырёгы сынган «Аксубаевский район – 80 лет!» дигән язулы бейсболкасын, аннан, исенә төшеп, чалбарын киде дә тагын чыгып китте.

«Кешелек дөньясы, чыннан да, бәхетсез бит. Ник? Нигә кешеләр бәхетсез? Нәрсә булды соң бу дөньяга?» дигән уйлар белән ул урам буйлап китте. Авылда бөтенләй телевизор булмаган вакытларны исенә төшерде. Әле кайчан гына иде бит. Клуб бар иде, анда кино алып киләләр иде.

Илгиз ЗӘЙНИЕВ (1987) – *драматург, режиссёр. М.Җәлил исемендәге премия лауреаты, ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе. «Бәби» исемле китап авторы. Казанда яши.*

Бөтен авыл шунда бергәләшеп, кино карарга җыела иде. Аннан беренче телевизорлар кайтты. Һәм бөтен авыл шул тылсымлы тартмалы йортка җыела башлады. Телевизор карыйлар, аралашалар.

Ул төнге караңгылыктагы йортларның шәүләләренә карады. Аның бөтен гомере шушы авылда үтте. Һәр йортның тарихын, һәр гаиләнең серләренә кадәр белә – авылда сер саклап булмый. Менә монда Маһруй апа яши. Ул кияүдә булмаган, балалары юк, аны һаман саф кыз дип сөйлиләр, һәм бу гайбәт түгел, хакыйкатькә күбрәк охшаган. Кара әле, аның Маһруй апа авызыннан «мин бәхетсез» дигән сүзне бер дә ишеткәне юк икән ләбаса!

Биредә Миңнулла белән хатыны Хәят яшиләр. Миңнулла хатынын еш кыйный. Яшь чакларда ул аны идән астына ябып тота, дилбегә белән яра иде, берничә мәртәбә тәрәзәдән урамга атканы да булды. Хәят үзе дә җебеп тормый. Миңнулланың лаякыл исереп, ишегалдына кайтып ауганын көтеп кенә тора, шундук аны бауда эленеп торган кер, тирескә катып беткән абзар чиләге белән, йә булмаса кармак сабы сынганчы кыйный да, аннан өйгә сөйрәп кертеп, чишендереп, урын-җиргә яткыра, үзе янәшә менеп ята иде. Ә кышын алар кара бияне чанага җигеп, бояр белән бояр хатыны сыман толыпларга төренеп, күрше авылга Хәятнең әниләренә кунакка китеп барганда, аларны кем дә булса бәхетсез дия ала идеме соң?

Бу йортта Габдулла абзый яши. Ул – сугыш ветераны. Сугышта сул күзен югалткан, контузия алган. Авылга кайткан да мулла булып киткән. Инде яше туксанда булуга карамастан, ул әле дә сарык асрый, җәен шул сарыкларына печәнне үзе хәстәрли. Нургаян апа белән алар өч малай үстергәннәр. Балалары шәһәрдә яшиләр. Кайткан саен аларны шәһәргә алып китмәкче булалар, ләкин картлар һаман күнмиләр. Уллары аталарын сарык асрап интекмәскә үгетләп карыйлар, ләкин Габдулла абзый аларны малай-шалайларны сүккән сыман пыр туздырып ата.

Менә кем-кем, ә Ризван белән Айгөл – тәгаен бәхетлеләр. Балаларының бик озак телләре ачылмый торды, ә күптән түгел ниндидер авазлар чыгара башлаган, хәтта «әннә» дигән.

Шамилнең яшьлеге бик дуамал үтте. Кушып санаганда, ул барысы унсигез ел төрмәдә утырды. Инде иллегә җиткәндә, соңгы мәртәбә утырып кайтты да атасыннан калган йортта яши башлады. Тол хатынга өйләнде. Хәзер инде, картлык көне җитеп килә дигәндә, кызчык үстереп ята. Кышын кочегаркада эшли, җәен калымга чыгып китә.

Әнсар зиратка кадәр барып җитте. Зират авылның кыл уртасында. Зиратта биек-биек агачлар үсә. Тыныч. Яңгыр тамчылары гына көзге яфракларга бәрелеп чәлпәрәмә килә, сирәк кенә ярканатлар кычкырып куя иде. Бу инде күптәнге зират. Авыл халкы, ким дигәндә, йөз ел мәрхүмнәрне бирегә озатадыр. Якында гына балалар бакчасы, мәктәп. Әнсар әле балалар бакчасына, әле зиратка, кабат балалар бакчасына һәм янә зиратка карап басып торды. Барысы да янәшә генә, дип уйлап куйды ул.

«Ә телевизорда бар да – бәхетсез. Нигә?» дип, уйларын дәвам итте Әнсар. Ул телевизордан сөйләнгән сүзләрне искә төшерде, фикерләрне җентекләп барлап чыкты. Башында телевизордан ишетеп тә мәгънәсенә төшенә алмаган бәхәсләр өермә булып әйләнде. Һәм шул башында гүләгән бөтен телевизор сүзләре арасында ул кинәт бер сүзгә төртелде – прогресс. Әнсар бу сүзне

алга китеш, үсеш итеп аңлый иде. Димәк, нәрсәдер булган һәм ул тагы да яхшырган, дип уйлый иде ул үзенчә. Димәк, кешелекнең төп теләге һәм омтылышы – шул прогресс дип, бик интегеп, ми сырларын селкетте ул. Ул үзенең белемсез булуына пошына, мин берәр нәрсәне аңлап бетермимдер инде, дип уйлый. Ул бит телевизордагылар сыман гыйлемле түгел, әллә ни китап та укыганы юк. Ләкин шулай да Әнсар, үзенең миендәге дөрес бураздага төшкәнен, хакыйкатькә бик якын килүен һәм тиздән кешелекнең бәхетсезлек сәбәбен ачыклаячагын тоя иде. Һәм нәкъ шулай булды да. Кешелекнең бәхетсезлеге – прогресстан. Әнсар шуны аңлады.

Шуннан мантыйк буенча икенче сорау туды: ә нәрсәгә кирәк соң ул прогресс?

Әнсарның бу сорауга җавабы бер генә иде: кешелек дөньясын яхшыртыр, кешене бәхетле итәр өчен. Әмма кешеләр инде мең еллар прогресска омтыла, ә ул кешене бәхетлерәк итәме соң? Әйе, трактор белән җир сөрү ансатрак дип уйлады ул. Ләкин танк белән үтерү, бәхетсезләрне арттыру тагын да җиңелрәк. Кая чаба соң бу кеше? Бар да янәшә генә бит. Бу прогресс дигәннәре кешене кая алып барып җиткерергә тиеш соң? Кайчан соң без прогрессның чигенә килеп җитәрбез? Һәр эшнең дә азагы була. Чәчү дә бер көн тәмамлана, урак өсте дә.

Ә прогрессның азагы кайда? Ияләнмәгән уй хезмәтеннән аның башы авыртырга тотынды. Ул уйлый һәм үзе уйлап чыгарган нәрсәләрдән курка башлады. Хәтта тәмәке кабызып җибәрде. Әгәр дә прогресс бәхетсезлеккә генә илтә икән, димәк, ул җир йөзендә бер бәхетле кеше калмагач кына тәмамланачак. Яки прогресс кешелек дөньясын үтергәч кенә. Әнсар аяк очында ятарга яраткан мәчесен исенә төшереп куйды. Мәчегә прогресс кирәкми. Ул болай да бәхетле. Мәчеләр беркайчан аны белмәгән, бер генә буын мәчесе дә. Алар гомердә дә тычканны ниндидер яңа технология буенча тотарга омтылмаганнар, өсләрендә дә һаман шул бер тун булган. Мәчеләр беркая чапмый, ләкин алар үз тормышларыннан канәгать. Әлбәттә, ул үзенең мәче түгеллеген аңлый. Ләкин аның мәчесе чит ил машинасы алмаганнан тилмергән кешеләрдән бәхетлерәк.

Манарадан иртәнге намазга чакырып, азан яңгырагач кына, ул төне буе авыл буйлап йөргәнен, өшеп, арып беткәнен аңлады. Эре-эре атлап, өенә юнәлде. Ә үзе туктаусыз уйлый иде: «Барына да шул прогресс гаепле. Прогресс кешелек дөньясын үтерәчәк. Иртәгә үк шул антеннаны йолкып атам, шайтаныма олаксын!»

Әнсар йокы бүлмәсенә керде. Мәче белән хатын әле дә шул килеш яталар иде. Аларга күз салды да: «Менә бит ул – бәхет!» дип уйлап куйды. Чишенеп, урынына ятты да колачлап ала алмаслык хатынын кочаклады. Мәче – аяк очында, хатын – куенда. Аларның җылысыннан җылынып, Әнсар бик тиз изрәп йокыга китте. Төшендә гел бер сүзне мыгырдады: «Менә бит бәхет... Бәхет...»

# ҖӘННӘТКӘ КАДӘР ЯРАТУ

Мәрхүмә хатыны мәете өстендә хәзрәт ясин чыга башлагач, аның күңеленә мәхәббәт ишелеп төште. Ул чит кеше сыман бер кырыйдарак тора иде, соңгы юлга озату йолаларын белми, хәзрәтнең нәрсә укыганын аңламый. Комачауламады. Барын да хатынның туганнары башлап йөрде. Халык күп түгел иде.

Хатынының каберенә шундый оста итеп, җайлап кына туфрак ташлавыннан аның алтын куллы кеше икәне күренеп тора иде. Читтән карап торучы кеше хәтта: «Бу хатынын карт тупыл астына ике метрлы дымлы чокырга күмеп куярга гына хыялланып яшәгән икән», дигән фикерләр дә туарга мөмкин иде.

Буш өйдә аны мәхәббәт көтеп тора иде. Аш бүлмәсендә аның авырлыгыннан артсыз урындык сыкранып куеп, карашы чынаяктагы әле кичә генә хатыны пешергән чәйгә төшкәч, аны кинәт кайгы басты. Ул бик тыныч иде сыман, әмма күз яшьләре туктаусыз ага бирде. Һәм ул, әлегә кадәр мондый хисләр тойганы булмаса да, шундук таныды – бу мәхәббәт иде. Ул моңа аз гына да шикләнмәде. Күкрәгендә бердәнбер теләк кабынды: хатыны белән булу теләге.

Ул хисләрен хәзрәткә сөйләде.

– Китап болай ди: бакый дөньяда барлык туганнар бергә җыелыр, – дип, хәзрәт аны юатырга тырышты.

Күпчелек кешеләр кебек үк ул да дин турында сирәк-саяк ишеткәннәрдән генә белә иде. Әти-әниләре дә берни өйрәтмәделәр, чөнки үзләре дә Аллага ышанудан һәм ашаганнан соң укылырга тиешле догадан артыгын белмиләр иде. Ләкин ул җәннәт белән җәһәннәм бар икәнен аңлый иде. Аның чамалавы буенча хатыны һичшиксез җәннәткә эләгергә тиеш иде, чөнки ул фани дөньяда да фәрештәгә тиң яшәде. Әле җитмәсә, күп кайгы-хәсрәт күргән фәрештә сыман. Ә иң мөһиме, ире тарафыннан күп кайгы хәсрәт күргән фәрештә сыман. Үз-үзенә хөкемне ул шикләнми чыгарды: аның бүгенгәчә булган биографиясе белән җәннәт ишекләрен ачып керү һич мөмкин түгел. Аның үз гомерендә берәүгә дә яхшылык эшләгәне булмады. Беркайчан. Беркемгә. Бу аның кагыйдәләренә сыймый иде. Начарлыкны, күп кылмаса да, кылгалады һәм бер дә тәүбәгә килмәде. Аның бер дусты да юк иде, алай гына да түгел, кем белән булса да дуслашырга дигән уй аның башына да килмәде.

Күз яшьләре һаман туктаусыз ага бирде. Өендә ялгызы калуга аны мәхәббәт буа иде. Аңа бер генә теләк тынгылык бирмәде – хатыны белән буласы килү теләге.

Ул җәннәт һәм анда эләгү шартлары турында өйрәнә башлады! Хатыны аны шунда көтә, ул моны тәгаен белә. Һәм шулай ук ул кан тамырларыннан мәхәббәт акканын белә, тоя иде. Хатыны белән буласы килү теләге аны мәңгегә басып алды. Бу аның яшәвенең максатына әверелде.

***

Мөселманнар өчен изге Рамазан ае иде. Карт тәравих намазыннан кайтып килә. Кинәт тигез җирдә абынып, узып барган автомобиль астына егылды.

Карт әкренләп, җаны чыкканны сизеп ята иде. Тирәсендә чабышып йөргән кешеләрне ул күрми. Бер мизгелгә генә күңелендә шик туды: машина астына үзем ятмадыммы мин? Ләкин аннары абынганын ап-ачык итеп исенә төшерде. Шуннан күңеленә тагын шом керде, үлемгә юри бирешеп ятмыймы соң ул? Бу да гөнаһ булыр иде. Ул тормакчы булып карады, яшәмәкче булып тырышты, әмма үлем юрганы акрынлап, өстенә ябылганын тәгаен тойды. Күзләреннән мәхәббәт тама иде. Йөзе елмаюда катып калды. Хәзер инде ул тәненнән аерылган аң гына иде. Хатыны белән буласы килү теләге гомер булмаганча көчәйде.

Карт изге Рамазан аенда үлгәненә Аллаһы Тәгаләгә рәхмәтләр укып ята иде. Мөселманнар өчен бу айда үлү – җәннәткә керү дигәнне аңлатканны ул белә иде.

Аны олы хөрмәт белән җирләделәр. Бөтен ишегалды бер-берсен күрмәгән-белмәгән, таныш булмаган кешеләр белән тулды. Әмма һәркайсының йөзеннән картны шәхсән белүе һәм үлемен зур югалту итеп кабул итүен аңларга мөмкин иде.

Аны хатынының сул ягына куйдылар. Кырык ел эчендә кабер ташы тоныкланган, ә биек тупылдан черек төп кенә калган иде.

## РАННУР

Мәдәният йортыннан эштән куып чыгарылганнан соң, Раннурның яшәү мәгънәсе калмады.

Раннур унсигез яшеннән сәнгать җитәкчесе булып хезмәт итте. Баянда уйный, спектакльләр куя, бәйрәм концертлары оештыра, ә иң мөһиме, җырлый иде! Ул сәгатьләр буе җырлый ала. Бернинди һөнәри белеме юк, әмма һәрбер халык җырындагы борманы белә, тавышын бөдрәләтеп, чигү чиккән сыман җырлый иде. Озын җырларны сузып җибәрсә, залдагы бөтен әбиләр яшьләрен тыя алмыйча, күзләрен сөрткәлиләр иде. Раннур аларның елаганнарын белеп, күңелләренә тагы да тирәнрәк үтеп керер өчен пышылдап диярлек җырлый башлый иде. Җырның аеруча хисле җирләре шулай иткәндә отышлырак яңгырый дип саный иде ул. Әмма аның тавышы көр. Шуңа ул нечкә пышылдауны көчле яңгыраш белән чиратлаштырып барды – бертөрлелектән качып, тамашачыга йоклап китәргә сәбәп бирми иде. Шаян җырларны да ул бик оста башкарды. Андый җырларны башкарганда, ул бик оста итеп кашларын сикерткәли, мут кына күз кыса һәм шундый самими чырай ясый иде, моны күргән һәрбер авыл хатын-кызы аңа һичшиксез гашыйк була. Кыскасы, сәхнәгә Раннур хуҗа иде.

Аны эштән куганнан соң ул сәхнәдән җиргә төште дә өенә кайтып китте.

Беркем белән бер сүз сөйләшмәде – бер атна ябылып эчте. Мунчада. Каршына баянын куеп. Ничек кенә уйныйсы килсә дә, ул кулына баянын алырга кыймады. Кырык сигез яшендә аны маңкасы да кипмәгән бер малай-шалайга алыштырырлар дип уйлый ала идеме соң ул? Ул малайның кулындагы кәгазь кисәге (диплом) аңарда булмаганга гына, Раннур кадәр Раннурның профессионал түгеллеген күз алдына китерү мөмкинме?!

Бер атнадан мәдәният йортында концерт булачагы турында игълан чыгарып элделәр. Раннур ахыргача карышты, чөнки мәдәният йортына ике аягымның берсен дә атламаячакмын дип әйтеп ташлаган иде.

Әлбәттә, ул концертка барды. Иң соңгы булып килде. Соңгы рәткә кереп утырды да утыргычына сеңде. Утыз елга беренче тапкыр ул биредә тамашачы ролендә иде. Тамашачының колакларын ярырлык итеп музыканы кычкыртып куюларын, аны кисәк өзүләрен, атлаган саен микрофон чинавын күзәтеп, ул үлә язды. Яңа гына табадан төшкән дипломлы «профессионал»ның фонограммага бик зәвыксыз итеп җырлавы соңгы тамчы булды. Моны күзәткәндә, Раннурның йөрәге җилдә бәргәләнгән

күзге яфрак хәлендә иде. Менә өзеләм, менә өзеләм дип типте аның йөрәге. Ул сөйрәлеп кенә, өенә кайтып китте һәм кабат бер атна тоташтан эчте. Мунчасына бикләнеп эчте һәм җырлады. Әби-карчыклар мунча артындагы эскәмиягә җыелып, Раннурның күкрәген чәрдәкләгән моңнан күз яшьләренә буылып, көнбагыш чиртә-чиртә, аның җырлавын тыңладылар.

Ә төн белән таң арасында, җирдән куе томан күтәрелгәндә, ул авыл урамнарын урап йөри, тәрәзәләргә озаклап карап тора башлады. Һәрбер тәрәзә артында ким дигәндә ике-өч кеше – Раннур аларга шундый матур итеп җырлый алган булыр иде. Бары бер тәрәзәдә генә ут эленгән, ул да булса мәчет иде. Ул һәр иртәне мәчет каршына басып, мәзиннең азан әйткәнен көтә башлады. Мәчеттә бик әйбәт тавыш аппаратурасы. Иганәчеләр бүләк иткән иде. Раннур әле ул чакларда шундый әйбәт аппаратураны аңа клубка түгел, мәчеткә бүләк иткәнгә рәнҗеп йөрде.

Шундый иртәләрнең берсендә азан әйткәнне көтеп торган Раннур каршына мәзин карт килеп басты. Ике кулын сузып күреште. Күзләренә карап торды да:

– Иртәгә кил. Аек булсаң, азан әйтерсең, – диде.

– Хәзер менә... – дип уйлап куйды да, кабаланып, өенә атлады Раннур. Ә аны куып барган сыман аркасына таушалган картның яхшы аппаратурадан яңгыраган азаны бәрелә иде.

Раннур мәчеткә барырга җыенмаса да, иртәгесе көнне тамчы да эчмәде. Эчү дә туйдырды дип уйлады ул.

Көн бик озын, киче чиксез, ә төн – мәңгелек булып тоелды.

Ә таң беленер алдыннан ул, әлбәттә, авылны урап кайтырга чыкты. Аяклары аны үзләреннән-үзләре мәчет каршысына китереп бастырдылар. Мәзин карт гаҗәпләнү сиздермәде, аның артыннан барырга кушып, мәчеткә кереп китте, Раннур аның артыннан иярде.

Озак еллар дәвамында авыл мәзин картның азанына изрәп йоклый бирә иде. Бу иртәне исә авылдашлар урыннарында кыбырсыды, кайберәүләр исә, үзләре дә аңышмыйча, гадәттән тыш иртә уяндылар.

Манарага беркетелгән репродуктордан Раннур башкаруында азан яңгырый иде. Моны беренче ишеткән кешеләр Раннур азанының сәер яңгырашын аңламый тордылар. Ә очлы колаклылары исә, бу азанда «Әллүки» көен ишетеп алдылар. Шул көннән башлап, тәүлегенә биш мәртәбә Раннур әйтүендә «Рамай», «Шахта», «Галиябану», «Иске Кара урман», «Тәфтиләү», «Сибелә чәчәк» көйләрен хәтерләткән азан яңгырый башлады. Раннур азан сүзләрен бик оста итеп халык көйләренең бормаларына салып әйтә иде. Ул бик тырышып, бөтен авыл тыңлаганын аңлап башкара иде бу эшне. Әйбәт микрофон, яхшы тавыш аппаратурасы аңа җан рәхәте бирә иде.

Шулай ярты ел үтеп китте. Раннурның җырга булган мәхәббәте аны Аллаһы Тәгаләгә якынайта, аның белән бәйләп тота кебек тоела башлады. Ул намаз тәртипләрен өйрәнергә тотынды. Һәм шуннан соң гына чын күңелдән Аллага ышана башлады!

*Маралтай Раймбәк улы Ыбыраев (1969) – Казакъстанның Җамбул өлкәсе Сарысу районы Игилек авылында туган. 2010 елда Әхмәт Ясәви исемендәге университетны тәмамлый. Төрле елларда «Кентавр» газетасының баш мөхәррире, Казакъстан телерадиокомпаниясе мөхәррире, Казакъстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары булып эшли. Шигырьләр яза. «Тарпаң», «Асау», «Каратау газәлләре» һәм башка китаплар авторы. 2016 елда аның Казанда «Алатау» дигән китабы татар телендә басылып чыкты.*



Маралтай
Ыбыраев

# БЕР УЛЫҢМЫН, И КАДЕРЛЕ ВАТАНЫМ!

## Кызгыш*

*Ватаным, сиңа әйтәм!*

Мукагали

Үлсәм – синең бусагаңда үләмен,
Акыннарын олылаган бөек илем.
Иясе бар этләр талап ятса да,
Беркемгә дә зарланмаган бүре идем.

Тузан баскан тарихымны туздырмый,
Чалам корбан ниятемнән узмаска.
Ул итәмен дисәң – синең колыңмын,
Кол итәмен дисәң әгәр... сүз башка!

Беркайчан да корган капкын булмадым,
Дошманга да мин башлап ук атмадым.
Нинди афәтләр төшсә дә башыма,
Хаин булып, Ватанымны сатмадым.

Ханның кече баласыдай ул идем,
Сызлап, әрнеп күп авыртты йөрәгем.
Башкалада, йортсыз торган Касыймдай,
Каңгырып күп булды минем йөргәнем.

Чебен җаным безелдидер чебендәй,
Моңнар булмас җирдә минем моңымдай.
Сиңа карап чуар җаным уйнаклый,
Кашка аттан туган җирән колындай.

* Кызгыш – тәкәрлек

## Натюрморт

Каләм калган өстәленең өстендә,
Кәгазь калган өстәленең өстендә.
Кабызмаган чыраг тора тагын да.
Менә Коръән, Коръән ята янында!
Инде кабат батмастай карый кояш,
Батса, кабат атмастай... карый кояш.

Янә дә бер матур сары гөл ята.
Баштук әйтү кирәккәндер ул хакта.
Кинәсе ни кәгазь белән каләмнең –
Тузанына батып чиксез галәмнең.
Әверелгән мәлдә гөл очар кошка,
Коръән булса, мизгеле тиң сәгатькә.

## Мөхәммәтне раслау

Фани дөнья,
Кояш белән батам да,
Антым булып таң атканда атамын.
Бар галәмне тезләндерер алдыңа
Бер улыңмын, и кадерле Ватаным!

Афәт килсә казакъ дигән халыкка,
Каләмемне алыштырып кылычка,
Синең каның минем каным булган күк,
Иң беренче мин керермен орышка!

Мин туганмын –
Ир-Мөхәммәт үлгән көн.
Мин булмасам,
йөрәгеңне имләр кем?!
Хак-Мөхәммәт әйтеп киткән кешегә:
Килер, дигән...
Килгән акын,
ул – Минмен!

## Эңгер

Төн карасын төнлеккә
Юлдаш итеп буйлаган.
Безнең газиз йөрәккә
Йолдыз чөеп уйнаган.

Чал дөнья калган өнсез,
Күккә дәшеп күңелне.
Теләгенә ашмаган
Саным санга бүленде.

Бер кошчыкның чырлавы
Борчу сала күңелгә.
Каеннарның кайгысы
Йөрәгемә түгелә.

Без чишмәгән хатаның
Җавабын соң кем табар?
Үткән гомер ишеген,
Йә, кайсыгыз, кем кагар?!

## Йөрәк

«Туктыйммы соң?» – диде миңа йөрәгем
(Ул туктаса ни буласын беләмен).
Сылу кызның йөзе кебек дөнья,
Мин киткәч бит гүзәллеген ул җуяр?..

Син туктарсың, сүндергәндәй утны су,
Син туктарсың,

Тормыш ләкин туктамас.
Син вакытны бакыйлыктан эзләрсең,
Бакыйлык бит фанилыкка охшамас.

«Туктыйммы соң?» дигән сүзең тәкъдирме?!
Күз алдыма килде шунда чал таулар.
Искә төште күктә йөзгән болытлар,
Ярга тулып ярсып аккан елгалар.

## Оптимизм

Бүгенге төн – минем өчен соңгы төн.
Гомеремнең әҗәлгә атын бордым.
Мең омтылып Аллага телем җитми,
Мәгълүм булды шайтанга якынлыгым.

Бар да мине алдыйлар, алданам мин,
Аллам минем, әманәт сиңа җырым.
Йөрәгемнән йөз ботак үрләп чыгып,
Әверелсәм иде талга, эһ тәкъдирем.

Бүгенге төн минем өчен авыр шундый,
Җаным калкып бара бер кавырсындай.
Бергә йөргән дусларым (бармы алар?)
Гүремне киң алсайде, авырсынмый.

Җаен табып туры бүген килә алган
Әҗәлем – ак, ышанам, сатмас мине.
Ел кошыдай әйләнеп кире кайтмас
(Ышанмасаң ышан) адәм үлә диме!

Хәсрәтле бүгенге төн минем өчен,
Хәсрәте җанымны яшен итте.
Син исән бул, кара җырым, бәгырем,
Күп дигәндә, бер картның башы китте.

## Намус

Тавык намусы булыр тарыда,
Чәчелсә тары – ул да чәчелер.
Аккош намусы булыр парында
(Парына гына бары баш орыр).

Ишәк намусы тапмас һич парын,
Уенда аның – тутыру карынын.
Тулпарны сүгеп, үч алам, димә,
Тулпар намусы – узу бәйгедә.

Бөркет намусы үткер күзендә,
Кояшка да ул карар күз кысып.
Кемдә дә түгел, калсын бергә-бер
Үз-үзе белән карга намусы.

Галәм намусы кояштан нурлы,
Кояшсыз булмас дөньяның яме.
Даланың яме гөл белән серле,
Гөлсез дә дала барыбер ямьле.

Яналмый пыскып ялгышып йөрер,
Гайбәт һәм хурлык булып соңында, –
Акын намусын Алласы белер,
Синең намусың тик үз кулыңда!

*Казакъ теленнән* **Рафис КОРБАН** *тәрҗемәләре.*



Наил
Шәрифуллин

# «ШАГАЛИЕВ ШӘҮЛӘСЕ»

хикәя

Тәнәфес беткәнен хәбәр итеп, кыңгырау чылтырады. Без инде өлкән классларда – шуңа да тәртипсез булмасак та, кыю, үз-үзебезгә ышанган. Элекке еллардагы кебек кабаланып, класс бүлмәсенә атылып кереп, парта арасына утырырга ашыкмыйбыз. Шаяру-сөйләшү, төрткәләшүләр, кызларны үртәү әле дәвам итә. Ун минутлык кыска гына тәнәфесне шулай кыланып озынайтырга тырышабыз. Әмма дә ки, бер күзебез барыбер класс ишегенә таба караштыргалый. Әле тагын икенче күз дә бар бит. Анысы гел башка якны – озын коридорның «Учительская» дип язылган бүлмәгә борылып кереп китә торган башын күзәтә. Һәм нәкъ шул мизгелләрдә бездән ике-өч яшькә кечерәк ыбыр-чыбыр – дүртенче, бишенче класслар (сигезенчедә генә булсак та, үзебезне инде хәйран зурга – әллә кемгә санныйбыз) әле генә тузан туздырып чапкан су буе коридорның башында чираттагы дәресне үткәрергә дип, үзләре утыра торган бүлмәдән чыккан укытучылар күренә башлый. Араларында мәһабәт гәүдәле, уклау йоткандай төз буй-сынлы, салмак адымнары әллә тагын метрдан арткан илле яшьләр тирәсендәге чибәр ир – хәзер безгә сабак бирәчәк тарих укытучысы Шагалиев абый да бар. Аның бүген дә барысы да үзенчә – Шагалиевча. Сажинлы адымнар, озын буй, без күптән белгән сурәтле галстук кына җитмәгән, бу юлы да култык астына дәреслекләр, класс журналы кыстырган. Шулар янәшәсенә бер өем күргәзмә әсбаплар да сыйган. Саналганнарның бөтенесе янына бүтән бер укытучыда да булмаган, буялган, бизәкләр төшерелеп, лакка катырылган, такта янында җавап биргәндә, безнең кулга да килеп эләгә торган, буе ярты метрдан арткан затлы күрсәткеч таяк – указка сыешкан.

Бөтен мәктәп белә: башка бер генә укытучыда да андый указка юк. Ул гынамы? Башка бер укытучыда да ЛЭТИ аппараты (ул хәрефләрнең нәрсә аңлатканын белмәсәм дә, исеме бүгенгәчә хәтергә уелып калган) дип аталган «кино» күрсәткеч тә юк. Ким дигәндә, ике-өч дәреснең берсендә без шул аппарат ярдәмендә үзебез үткән тарихи темалар буенча диафильмнар карыйбыз. Безнең өчен андый хәл – вакыйга. Кәҗәсеннән бигрәк мәзәге, дигәндәй, диафильмнан бигрәк аппаратка ушыбыз китә. Гади «кино» күрсәткеч кенә түгел ул. Аның төп хикмәте – кадрларны

күчерү, ягъни плёнканы алга, артка әйләндерү өчен 3-4 метр озынлыктагы электр шнурының башына урнашкан пульттагы төймәләргә генә басасы. Басуга гөжләп, мотор эшли башлый, экрандагы сурәт алышынып та куя. Аппаратны кабызу, сүндерү дә шул пульт аша. Бүгенге телевизор пультлары бер читтә торсын. Безгә иң кызыгы шул. Пульт ышанып тапшырылган укучы – көн герое ук булмаса да, тәгаен дәрес герое. Диафильм карый башлар алдыннан без классның алагаем тәрәзәләрен (кечкенә тәрәзәле агач биналардан зур таш мәктәпкә күчкәнебезгә санаулы гына еллар) кара чаршаулар белән каплыйбыз. Класска рәхәт тә, серле дә булган караңгылык иңә. Тактага зур ак экран эленгән. Пульт тоткан укучы (андый бәхет миңа да еш эләгә иде) кадрларны алыштыра тора.

– Менә, карагыз, парижлылар Бастилияне штурмлый. Бу – Бөек француз революциясенең башы. «Ирек, тигезлек, туганлык!» Байракка французча шулай дип язылган. Инкыйлабның шигаре бу. Кешелек тарихында беренче тапкыр изелгән сыйныф шундый шигарь белән көрәшкә күтәрелә һәм җиңә. – Шагалиев абый сөйли, бүгенгечә итеп әйткәндә, һәр сурәткә комментарийлар биреп бара.

– Монысы – Максимилиан Робеспьер. Алда әйткән шигарьнең авторы. Революция җитәкчеләренең берсе. Соңрак инкыйлаб дошманнарына каршы террорда гаепләнеп, гильотинада башы кистерелгән революционер...

Жирондистлар, якобинчылар, тагын әллә кемнәр. Революциянең ахырда үз «балаларын» үзе ашавы – фетнә башында торган кешеләрне җәзалап үтерүләр. Безнең колаклар тырпайган, йотлыгып тыңлыйбыз. Элекке дәвердә ниләр генә булмаган бу дөньяда... Шагалиев абый һәрдаим мавыктыргыч, образлы итеп сөйли. Кызыклы чагыштырулар китерә. Менә шундый чакта син тарихны яратмый, даталарны, вакыйгаларны исеңдә калдырмый кара. Мөмкин түгел...

Менә тагын дәрес көткән чак. Коммунистик идеология белән сугарылган Яңа тарихны өйрәнүне дәвам итәбез. Әле үткән дәрестә генә Маркс белән Энгельс язган «Коммунистлар партиясе манифесты»н укыдык. Шагалиев абый бу юлы кистереп әйтте: Манифестның башын, ягъни беренче җөмләсен, кыскача эчтәлеген, азагын һәм дә язылган елын төнге өчтә уятып сорасалар да, без ялгышмыйча әйтеп бирергә тиеш. Башы бигрәк серле һәм хикмәтле инде. «Европада шәүлә йөри – коммунизм шәүләсе». Без күз алдына китерергә тырышабыз: ниндидер алагаем шәүлә, күләгә ясап, Париж, Рим өстеннән очып үтә, кыр, яланнар буйлап йөри, анда барып бәрелә, монда сугыла. Тик барыбер аңлап бетереп булмый: шәүләсе булгач, шәүләне тудыручысы, берәр төрле җисеме дә булырга тиештер бит инде аның. Анысы кая соң? Мантыйк бутала да куя. Бөтенләй үк надан түгел үзебез, коммунизмның ни-нәрсә икәнен чамалыйбыз – ул тәгълимат һәм без кайчан да булса ирешәчәк җәмгыять. Бөтен булган тәгълиматлар әллә шулай башта шәүлә булып буталып йөриләр микән?

Укытучыбыз дәрес азагына таба әлеге серле җөмләнең русчасын да әйтте. Ул «По Европе ходит призрак – призрак коммунизма» икән. Монысын да аңласаң – аңла, аңламасаң – юк. Шәүлә түгел, өрәк йөри икән бит! Бераз куркыныч та булып китә. Бераздан шунысына төшенәбез: сүз бөтен кешене дә чиксез бәхетле итәчәк җәмгыять турында барганда, татарча текстка

«коммунизм өрәге» дип язып булмый да булмый инде. Бөтенләй килбәтсез килеп чыга. Шәүлә – ярый әле.

Бөтен класс шул рәвешле баш ватып, чираттагы дәресне көткәндә, арткы рәттән кемнеңдер хихылдаганы ишетелә. Әллә Хариста, әллә Тимерҗанда шунда, әлеге сүзтезмәне, ягъни Манифестның башын телендә кат-кат әйләндерә торгач, «өчле» капчыгыннан гына чыга ала торган «даһи» җөмлә яралган: «Мәктәптә бер шәүлә йөри – Шагалиев шәүләсе». Моны ишеткәч һәм укытучыбызның озын буй-сынын күз алдына китергәч, бөтен класс тыела алмыйча, буылып көләргә тотына.

Нәкъ шул мәлдә коридорда тәнәфес беткәнне искәртеп, кыңгырау чыңлый. Мизгел эчендә класста тынлык урнаша. Харистан чыккан ул көфер сүз ялгыш укытучыбызга барып җитсә, бетте баш, сигезенче «А» классы өчен тарих мәктәптә төп фәнгә әйләнәчәк – Яңа тарихтагы бөтен даталарны, вакыйгаларны яттан белмичә, рәтле билге алырмын, димә. Хихылдарга яратсак та, укытучылардан без шөлли идек. Шагалиев абыйдан бигрәк тә...

Укытучыларыбызның барысына да татар мәктәпләренә хас булганча, «абый», «апа» дип дәшеп йөрибез. Үзара сөйләшкәндә, Тәкъмилә апа, Рәшидә апа, Роза апа; Әүхәди абый, Мирсәет абый, Сәгыйт абый, Шәйдулла абый.  Тик бер генә укучы да Шагалиев абыйны үзара сөйләшкәндә, исеме белән «Гали абый» дип атамый. Бөтен мәктәп өчен ул – Шагалиев абый. Мондый феноменны әле дә аңлап бетерә алмыйм. Бу хәл, ихтимал, тарих укытучысының үзенчәлекле кеше булуын, аңа аерым хөрмәтне, хәзергечә әйткәндә, абыебызның аерым статуска ия булуын билгеләгәндер дип уйлыйм.

Үзенчәлек тагын шунда, үтәчәк яңа тема тәнәфестә үк класс тактасына язылып куелган булырга тиеш. Тема астында, гадәттә, параграфлары белән бүлекләр, аларның исеме дә языла. Бу эшне иң матур язучы кызыбыз – Римма башкара. Элекке дәрестә үткән, үтеләчәк яңа темаларга кагылышлы зур карталар да укытучы керүгә үз урыннарына эленгән булырга тиеш. ЛЭТИ аппаратына да, кино карыйсы көн булганда, тиешле урынга урнаштырылып, сугышчан әзерлектә тору мәҗбүри.

Берсендә шулай Шагалиев абый кушуы буенча олы карталар, төрле әсбаплар, диафильмнар сакланган кечкенәрәк бүлмә – үзе үк оештырган мәктәп музееннан шул ЛЭТИ аппаратын класска алып кердек тә уртадагы парталарның берсенә урнаштырдык. Бүген дә рәхәтләнеп, тәрәзәләрне томалап, «кино» караячакбыз. Инде аны электрга да тоташтырдык, пульттагы төймәләргә баскалап эшләтеп тә карадык. Ни генә димә, аның ише кызыктыргыч техника аз заман бит. Мин әле башкалар читкәрәк киткәч тә, шуның тирәсендә мәш киләм. Шунда аппаратның аскы өлешенә урнашкан 127, 220 дип язылган, урынына төрлечә куеп була торган кара вилкага күзем төшә. Бала-чага бит инде, кул тик тормый, вилканы тартып чыгарам да 127 санын өстә калдырып кире тыгам. Юк, тәртипсез малай түгел идем мин. Һаман да шул кызыксыну, беләсе килү инде. Аппараттагы лампа, уйлавымча, хәзер тоныграк янарга тиеш. Шуны тикшереп карыйм, тәҗрибә ясыйм, янәсе. Җайланманы төймәгә басып кабызуым булды, лампа дигәнем гадәттәгедән күпкә ныграк янып, яктырып алды да шунда ук сүнде, төймәләргә күпме баскаласам да, бүтән кабынмады. Мин аппаратны яндырганымны аңладым.

Гөнаһымны дәрес башланганчы ук укытучыбызга җиткерергә кирәк

булгандыр. Тик курыктым, гаепне тану да батырлык сорый бит. Бәлки мин икәнен белми калыр. Техника ватылмыйча тормый бит. Дәреснең икенче өлешендә, яңа темага керешкәч, тәрәзәләрне кара чаршаулар белән капладык, утны сүндердек. Тик пульт ышанып тапшырылган укучы кабызу кнопкасына күпме генә басмасын, җайланма кабынмады. Мин исә тынымны да алырга куркып утырам, йөрәк дөп-дөп тибә... Яңадан утны яндырдык та, Шагалиев абый яңа дәресне «кино»сыз гына аңлатты.

Кыңгыр эш кырык елдан соң да беленә, диләр. Минем «җинаять» ачылганчы кырык сәгать үтте микән? Кемдер вилка белән булышканымны да, лампаның бер мизгелгә генә көчле нурлар сибеп балкып сүнүен дә күреп калган булган. Кыскасы, мине әләкләделәр. Аппарат ватылып, өч көн үттеме, юкмы, Шагалиев абый, кырыс кына дәшеп, мине үзенең «кабинетына» – музей бүлмәсенә чакырды. Сөмсерем коелып, гильотинага хөкем ителгән француз революцонеры халәтендә аның артыннан иярдем. Сүзнең ни хакында барачагы билгеле. Каты итеп ачулануын, аппарат бәясен түләргә кушасын көттем.

Шагалиев абый башта ишекне япты, үзе белән дәрескә дип алган китап, дәреслекләрне, указканы урынына куйды да бүлмәдәге бердәнбер урындыкка утырды. Ә мин аңардан бер метрда гына, калтыранмасам да, соң дәрәҗәдә шөбһәләнеп, куркып, башымны иеп басып торам.

– Син яндырдыңмы аппаратны? – Бүлмәдә минутлык тынлык урнашты. Сорауда тавыш күтәрү, усаллык алай сизелмәсә дә, котым ботыма төшү сәбәпле, сүзләремнән алда күздән яшьләр бәреп чыкты. Чыкты гына да түгел, мөлдерәмә тулышкан олы тамчылар битем буйлап тәгәриләр иде. Оят, бик оят иде миңа. Шундый затлы җиһазны яндырганга гына түгел, тәртипсезлегем нәтиҗәсен шунда ук әйтмәгәнгә, гаебемне белгертмәгәнгә. Тамакка тыгылган төер нидер дәшү сәләтен дә юкка чыгарды. Шулай да авызымнан кыска бер җөмлә кысып чыгара алдым:

– Миндер инде, абый, боргалаган идем шул.

Тагын бер минутлык тынлык урнашты. Мин дәһшәтле хөкем карары, җәза көттем. Тик хөкем, ни гаҗәп, шактый йомшак булып чыкты, дөресрәге, ул булмады да. Ихтимал, елавым үзе үк бар сорауларга җавап та, үкенү дә, гафу үтенү дә булгандыр. Дөньяда күпне күргән, сугышта катнашкан Шагалиев абый «башымны кисмәде».

– Елама! Егет кеше еларга тиеш түгел! Шунда үзеңне ток тотса, ни була, кем җавап бирә иде? Икенче алай эшләмә! Күзләреңне сөрт тә классыңа юнәл!

Менә шул!..

Запас частьлар тиз табылдымы, минем «тәҗрибә»дән соң бер ай үтәр-үтмәстән ЛЭТИ аппараты тагын тарихка хезмәт итә башлады. Мин генә, иптәшләремнән, укытучыдан гына түгел, җайланманың үзеннән дә оялгандай, бүтән аның янына якын бармадым.

...Коммунизмны көтүчеләр калмаган кебек, коммунизм шәүләсе дә Европа буйлап инде хәтсездән йөрми, манифестны да искә алучы юк. Тик «Шагалиев шәүләсе» – тарихка гомерлек мәхәббәт тәрбияләгән укытучымның якты образы исән, һаман да минем белән әле.



*«Тәртип» радиосының җитәкчесе, журналист Ризәлә Исмәгыйлеваны белмәгән татарлар сирәктер. Һәрхәлдә, үзен «тәртипле» дип санаучылар, бу ханымны таныйлардыр дип фаразлыйбыз. Ә менә аның нечкә хис-тойгыларга бай лирикасы белән, мөгаен, һәркем дә таныш булмаска да мөмкин. Хәер, үзебез дә һәрчак ачык күңелле, тыйнак һәм мөлаем ханымның илһам белән тулы күңел байлыгын моңарчы абайламый йөргәнбез икән ләбаса! Ул шигъриятендә дә тормыштагы кебек үк итагатьле, иманлы, шөкер кыла белүче, укучысына яктылык, инсафлылык нуры өләшергә омтылган шагыйрә: «Җиде ятка изге теләк тели», Раббыбызга шөкер итә, халык күңелен яктылык, игелек белән сугарырга ашкына, дөньяны агарту, сафландыру, «тәртип»кә салу мәсьәләсендә гамәл кыла һәм шигырьләр, җырлар яза!*

Ризәлә
Исмәгыйлева

# СУГАРАСЫМ КИЛӘ ХАЛКЫМНЫ...

## Кызу-кызу педаль әйләндерәм...

Кызу-кызу педаль әйләндерәм,
Җил җилбәзәк кала көнләшеп.
Раббым биргән уңыш, шуңа күрә,
Саранланмый йөрим өләшеп!..

Кызу-кызу педаль әйләндерәм,
Эшләнәсе эшләр бихисап!
Вак-төяккә бүлгәләнми генә
Яшәп өлгерергә бар исәп!

Кызу-кызу педаль әйләндерәм,
Шартлап сынсын «ялгыш» таяклар!
Тәгәрмәчкә кысылыплар гына
Сүндерелә алмый маяклар.

Кызу-кызу педаль әйләндерәм.
Тигез юлдан җиңел барыла.
Тау менгәндә, беләм, куып булмый,
Биек менгән саен арыла.

Кызу-кызу педаль әйләндерәм,
Шүрләгәндәй туктап калудан.
Чыгырыннан чыкмас минем сәпит,
Раббым саклап барыр янымнан!

Кызу-кызу педаль әйләндерәм,
Төп юлдашым – изге ниятем!
Чик-хисапсыз шөкер Сиңа, Раббым,
Сер бирмәскә мине өйрәттең!

...Кызу-кызу педаль әйләндерәм.

## Иң бәхетле бала булыр идем...

Җиде ятка изге теләк телим,
Теләгемдә – йөрәк ялкыны.
Үзем сусап яшәвем дә җиткән,
Сугарасым килә халкымны.

Җиде ятка изге теләк телим,
Тилмермәсен кеше кадергә!
Таш бәгырьләр нечкә күңелләрне
Кертмәсен дим, иртә кабергә.

Җиде ятка изге теләк телим,
Күңел салып һәрбер сүзенә.
Итекченең итеге юк сыман
Җылы сүзләр җитми үземә.

Җиде ятка изге теләк телим,
Риза җаным ярып бирергә.
Иң бәхетле бала булыр идем –
Теләгемнең меңнән бере генә
Әйләнепләр кайтса кирегә.

## Нечкәрәсең

Елдан-елга нечкәрәсең, күңел...
Ә бит алда – гөлләр генә түгел,
Киртәләр дә була, беләсең.
Ник юк-барга бәгырь теләсең?

Елдан-лга нечкәрәсең, күңел...
Кылларыңа кагылдырып җиңел,
Ялгышмале, тырыш чыныгырга,
Ныклап ябыш вакыт чылбырына!

Елдан-елга нечкәрәсең, күңел...
Әле синең өзелер чагың түгел,
Башланмаган гомер көтә алда.
Барысын да йөрәгеңә алма!

Бәргәләнмә, гел яхшысын уйла,
Шик-шөбһәгә вакытыңны җуйма!
Беләм инде, киңәш бирү җиңел,
Елдан-елга нечкәрәсең, күңел...

## Акка буяр идем дөньясын!

Никтер минем бар дөньяны
акка буйыйсым килә!
Уйларның да гел яктысын
гына уйлыйсым килә!

Ап-ак булсын өметләр дә,
күрсен безнең кебекләр дә,
дөнья чат кара түгел!...
Төшсә дә кайчак күңел...

Андый чакта, бак учакка!
Уттан калган күмернең дә
күренә аксыл ягы! Бар да яхшы!...
Тик йөрәкнең (сүнәр-сүнмәс)
янгыннан калган чагы.

## Рәхмәт инде

Күзге каршысыннан үткән саен,
Алкаларым җемелдәтеп уйныйм.
Гашыйк булган җилкенчәк кыз кебек
Көне буе бүген сине уйлыйм.

Чәчләремне бер таратып карыйм,
Бераз йөргәч, янә җыеп куям.
Тузгып торган чәчләр арасыннан,
Алкаларым күренмәсләр сыман.

Унсигездә чаклар булмаса да,
Бүләк алу барыбер рәхәт инде.
Алка түгел, өмет бүләк иттең,
Игътибарың өчен рәхмәт инде.

## Көз һәм без

Көз дә матур, без дә матур әле,
Гомернең дә кыл уртасы кебек...
Чыбыркылап кумасаң да, атның
бара торган чагы үзе белеп...

Көз дә матур, без дә матур әле,
Тик күңелгә нидер җитми сыман...
Тынгысызлык биләп алган җанга
Әллә нинди хафалану кунган...

Көз дә матур, без дә матур төсле,
Тик сагышлар сарган күңелләрне.
Тыштан көлеп, эчтән сыкрабрак
Үткәргәнбез бугай гомерләрне...

Көз дә матур, без дә матур үзе,
Тик йокылар кача, хәтер барлап...
Уйларында һәркем ялгыздыр ул, –
Яшәлсә дә гомер буе парлап.

Көз дә матур, без дә матур, шиксез!
Чәчкә генә никтер көмеш сарган.
Бер-береңә кадер җитмәүдәнме,
Хис дигәнең гүя бераз арган...

Көз дә матур, без дә матур юкса...
Өмет белән алга әйди гомер.
Учак саклап яшәү нәтиҗәсе –
Йөрәк урынында көл вә күмер...

Көз дә матур, без дә матур. Матур!
Күмердән дә, бәлки, ут эленер.
Бәхет өчен күргән, кичергәннәр
бер беленер әле, бер беленер...

***

*Светофорга гына тукталулар*
*Уйлап баксаң, хәерлегә икән...*

Сабырлыгың сыгып сыный торган
Тукталышлар бар ул тормышта да.
Аттан узып чаба алмый арба,
Әй син кешем, юкка тырышма ла!

Салмак атла, ерак китәрсең дип,
Тәҗрибәдән чыгып сөйли халык..
Артык чабып булмый барган чакта
Юлсыз җирдән яңа юллар ярып...

Алтын балык түгел, Раббым үзе
Ихлас гамәлләрне барлап тора!
Бирәү «ярык» дигән тагаракны
Фатыйхасы белән ямап тора...

Һәр тукталыш – хәл җыярга сәбәп,
Фикер туплап, үргә менәр өчен!
Сынауларын гадел үтүчегә,
Раббым Үзе бирә яшәү көчен!

## Гаилә көне...

Һәркемнең дә үз дәүләте була.
Хәләл яры, бала-чагасы...
Шул дәүләтне саклыйм, яклыйм диеп,
Чабасы да безгә, чабасы...

Шулай яшибез дә...
«Ни хәлең бар?» дигән
Гади сорау калды еракта...
Кемнән, нинди файда алып була? –
Исәп-хисап хәзер йөрәктә...


Көнче кайчы телә өстәвенә...
Күрше «дәүләт» алга китмәсен!
Йә зарлану кирәк, мескенләнү –
Акча сорап килеп җитмәсен…

Вак дәүләтләр дөнья куган чакта,
Игелеген салып бизмәнгә, –
Мөлдерәгән күздән тамчы тама
Тәпи басып киткән идәнгә...

Олы дәүләт онытыла икән –
Газиз әни исән булса да...
«Үстегез шул», – диеп карый сыман
(балачакта)
Утырырга да курыккан бусага...

…«Тормыш шундый», дибез...
Ярар. Булсын.
Гомер үтсен, акыл картайсын…
Ләкин...
Кешелекне, туганлыкны саклау,
Кан тартуы – анысы кайда соң?!

Безнең буын җилкәсенә салган
Иң зур бурыч – тамыр корытмау!
Кешелекнең, көчлелекнең башы –
туган нигез барын онытмау!



*Радик Хәкимҗан (1941) – шагыйрь, Башкортстанның һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Башкортстан һәм Россия язучылар берлеге әгъзасы; «Тауларга үрләгәндә», «Гомер көлтәсе», «Таңнарыма җиләм» һ.б.исемнәрдәге унбишләп шигырь җыентыгы авторы, һәрби хезмәттә чагында СССРның тәүге космонавтларын Галәмгә очыруда катнашкан кеше. Уфада яши.*

Радик
Хәкимҗан

# ХӘТЕРЕМДӘ – ЯНГАН УЧАКЛАР...

## Тәүге сөю уты сүнмәгән

Агачларның толымнарын тарап,
Көзге җилләр йөри сызгырып,
Бар дөньяга хуҗа булып алган,
Яфракларны китә туздырып.

Ут-яфраклар – хатирәләр булып
Сибеләләр көзге юлларга.
Икәү үткән нурлы сукмакларны
Оныттыра алмый еллар да.

Барысы да истә әле һаман,
Тәүге сөю, гүзәл яшь чаклар,
Күз алдымда синең буй-төсләрең
Хәтеремдә – янган учаклар.

Без танышкан матур, нурлы тугай
Һаман күркәм, һаман шул икән.
Әллә яңгыр битләремне юа,
Әллә ул күз яшьләрем микән?!

Сине эзләп, очрашулар көтеп,
Таныш сукмаклардан үткәндә,
Балкып китә җанда тәүге сөю,
Гомер көзләремә җитсәм дә.

Ут-яфраклар, хатирәләр булып,
Сибеләләр көзге юлларга.
Икәү үткән нурлы сукмакларны
Оныттыра алмый еллар да!

## Тайлар чаба

Болыннарда ярсу тайлар чаба,
Назлап кына исә таң җиле.
Шушы тайлар дәртле яшьлегемә
Гүя алып кайттылар мине.

Болыннарда ярсу тайлар чаба,
Кыңгыраулар чыңы колакта.
Әйтерсең лә җитез, яшь чакларым
Җилеп үтеп китә шул чакта.

Ярсу тайлар давыл, җил уйнатып,
Тояклардан утлар очыра.
Көмеш ялкайларын җемелдәтеп,
Никадәрле шатлык эчерә.

Болыннардан тайлар чабып үтте.
Көч-дәрт алдым ярсу тайлардан.
Бар дөньямны онытып, канатланып,
Урап кайттым әллә кайлардан.

Нидер эзләп, ерак офыкларга
Кешни-кешни чапты тайларым,
Гомер көзем якынлашса да бит
Җанда атты яшьлек таңнарым!


## Яшәү көче

Иген уңа, гөрләп үсә,
Сынатмасаң сабанда.
Икмәк – кодрәт, яшәү көче,
Муллык ул һәр заманда!

Күңелләргә көч-дәрт бирә
Тук башаклар чыңлавы,
Сөенечләр тула җанга,
Нинди рәхәт тыңлавы!

Икмәк – олы хәзинә ул,
Балкып торсын һәр өйдә!
Тормыш күрке – икмәкне мин
Алыштырмам бернигә!

---



*Нурислам Айбулатов 1942 елның 6 гыйнварында Татарстанның Кама Тамагы районы, Ишем авылында дөньяга килә. 1964 елны Тәтеш авыл хуҗалыгы техникумын тәмамлагач, Чиләбе өлкәсенә барып, Конашак һәм Чибәркүл районнарында агроном булып эшли. 1972 елдан бирле Чибәркүлдә гомер кичерә. 2002 елда, заводта эшләп, пенсиягә чыга. Бүгенге көндә ул улы белән килене янәшәсендә гомер кичерә.*

*Гомеренең соңгы 59 елын туган төягеннән читтә үткәргән якташыбыз күңел түрендә йөрткән балачагын, туган нигезен сагынып, шигырь юлларына сала. Ә улы Аяз шуларны туплап, китапчыклар итеп, дөньяга чыгара, якташларына юллый тора.*

*«Һәвәскәр каләм тибрәтүче генә булсам да, ул шигырьләр юктан гына тумый. Минем язганнарым да озын-озак, кат-кат уйланулардан соң, күңел түрендә җыйналып торалар да, бервакытны төнге тынлыкта шифалы яңгырдай кәгазьгә түгеләләр», – дип яза Нурислам Минһаҗ улы әлеге китапчыкларның берсендә сүз башы итеп.*

**Фәнил ГЫЙЛӘҖЕВ**

# Нурислам Айбулатов

# ЯШЕМ АРТКАН САЕН УФТАНАМЫН...

## Соңламагыз

Күрешергә кайта алмыйм, саулык ачмый ишеген.
Хәтер – күпер аша уза җанга якын Ишемем.
Шул күпердә һәр көн күрәм күптән таныш йөзләрне,
Ишетәмен күңелемә тансык җылы сүзләрне.
Сәлам биреп үтеп китә дусларым, туганнарым...
Күпер аша уздырамын авылым уңганнарын.
Сабакташның, кордашларның очратып азын гына.
Бар көчемә каты кысып, сыйдырам кочагыма.
Унны, йөзне – бик күпләрне уздырам күпер аша.
Алар белән озак еллар алмадым шул очраша.

Төрле эшләр, мәшәкатьләр уралып кул-аякка,
Күрешүне соңарттылар, җибәрми туган якка.
Ирекне бик яратсак та, без – тормыш кысасында.
«Соңламагыз!» дип язганым күпер култыксасында.

## Күләгәләр

Карт кеше ул – бала диеп, белеп әйткәннәр элек.
Карда эзләр салып йөрим, аякка чаңгы элеп.
Кояш күктә кочыш уйный: күләгәләр-шәүләләр,
Сүзсез генә мине үртәп, эземә ияреләр.
Мин җилләр белән ярышам, күләгәм арттан шуа –
Армаенча, талмаенча куа да мине куа.
Үз күләгәм, үз эземә калмыйча килә басып:
Үзеңнән качып булмый шул, үземнән булмый качып.

## Үгилек

Ардым инде балта, чүкечләрдән,
Соңгы корал булсын каләмем.
Яшем арткан саен уфтанамын,
Милләтемә юк, дип, ярдәмем.

Күпме эшләсәк тә, тырышсак та,
Рәсәй өчен үги бала без.
Үрмәкүчнең тимер ятьмәсеннән
Ычкыналмый кими барабыз.

## Күршеләрем

Уң як күршем – яңа заман бае,
Пулат салып куйды бакчасына.
Сул як күршем хаҗга барып кайтты,
Гомер буе җыйган акчасына.

Икесе дә бүген берсен-берсе
Сәламлиләр, куллар бирешеп.
Шатлыклары йөзләренә чыккан,
Хыяллары чынга ирешеп.

## Кабык бишек

Түрге якта, нәкъ уртада
Асылган кабык бишек.
«Җырлый» бишектә бер сабый,
Сүзләре әллә ничек.

Сөйләшергә иртәрәк шул,
«Җырларга» җиңелрәк:
Җырлаганыннан беләләр, –
Нәрсәдер аңа кирәк.

Аңа берни дә кирәкми,
Тик әни генә булсын.
Күз тимәсен дия-дия,
Сокланып карап торсын.

Тирә-ягы зур бер диңгез,
Көймәдер кабык бишек.
Йөзеп килә сабый бала,
Куллары белән ишеп.

## Күлләр илендә

Матур безнең Көньяк Урал!
Горур әйтәм ул хакта.
Бездә күлләр шундый чибәр –
Диңгез торсын бер якта.

Төрле күлләр: серлеләре,
Түгәрәге, тирәне,
Балыклысы, кыслалысы...
Ярда талы, тирәге.

Исемнәре төрки тарих:
Кисагач та, Сукаяк...
Бар Байкалның бертуганы –
Төче сулы Тургаяк.

Чибәркүлнең чибәрлеге –
Суындагы күп утрау.
Сәяхәтчегә зур бәхет
Ун утрауны да урау.

Чумып, йөзеп мин шул суда
Дәртләнеп тә хисләнеп,
Сизми калдым ярты гасыр
Гомеремнең үткәнен.

Җиләкле дә, җимешле дә,
Күлләргә бай бу төбәк,
Тик шулай да туган якны
Сагынып тибә йөрәк.

## Ашкындыра

Яшь күңел ашкындыра да,
Мәхәббәт алдаттыра,
Төрле милләт кешесен дә
Сөйдерә, яраттыра.

Ятлар безгә катышса да,
Яшәми тел өйрәнеп.
Үпкәләшсәң, әйтүе бар:
Татар, диеп, җирәнеп.

Яшьлек ерактагын күрми:
Татары ни, урысы.
Картайгачтын килеп чыга
Бәлаләрнең зурысы:

Берсе мәчеткә юл сайлый,
Ә берсе – чиркәү якка.
Соңгы көн каберлекләр дә
Әйләнәләр низагка.

## Үлмим әле

Бурычларым бик күп. Бу дөньяны
Ничек шулай ташлап китәсең.
Изгелеккә мактау җырлый-җырлый,
Йөз яшькәчә кил
ә җитәсем.

Бер явызлык күреп хафалансам,
Биш матурлык күреп шатланам.
Мин дөньяны әгәр ташлап китсәм,
Имансызлар итәр тантана.

Алар өчен кемдер гел гаепле:
Йөргән юлын, җирне тарсына;
Этә, төртә, сыймый кабыгына;
Малың талап, җанны кыяр өчен,
Төннәреңдә чыга каршыңа.

Намус сүзен яшел әләм итәм
Явызлыкка каршы көрәштә.
Ватанымда имансызлар бетми, –
Үлмим әле. Җитәм йөз яшькә.

## Гыйбарә

Гаделсезлек төшсә югарыдан,
Оятсызлык үрчи түбәндә.
Белексезләр түрәлекне яулый,
Караклары китте дигәндә.

Замананың затлы, зыялысы
Ил кайгысын йөртеп иңендә,
Бикле ишекләргә бәрелә дә,
Башын тотып кире чигенә.

Илдә канун идарәли сүзе –
Безнең өчен ялган гыйбарә.
Нәфес белән намус, кер һәм пакьлек –
Якынаймый торган зур ара.

# ДӨНЬЯ ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ МИНЗӘЛӘ ТЕАТРЫНДА

## САБИР ӨМЕТБАЕВНЫҢ ТУУЫНА – 115 ЕЛ

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, республикабызның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, «Почёт билгесе» ордены кавалеры Сабир Гаделҗан улы Өметбаев – үзенең озак елларга сузылган режиссёрлык хезмәте белән халкыбызның мәдәни мирасына җитди өлеш керткән, үзенчәлекле мирас калдырган күренекле шәхесләребезнең берсе. Милли режиссура сәнгатенең Октябрь инкыйлабыннан соң киң мәйданга чыккан икенче буын вәкиле буларак, ул утызынчы ел урталарында зур сәнгать дөньясына аяк баса һәм утыз ике ел дәвамында Минзәлә татар дәүләт драма театрының баш режиссёры була.

Еш кына күпмедер вакыттан соң иҗат коллективы белән режиссёр арасында иҗади мөнәсәбәтләр сүрелә, тормыш ваклыгы, амбицияләр көрәше өстенлек ала башлый һәм режиссёрга аралар салкынайган коллективтан китәргә туры килә. Ә С.Өметбаев очрагын сәнгать дөньясында уникаль күренеш дип бәяләргә була. Монда С.Өметбаевның Минзәлә театрын беренче адымнарыннан ук үзе җитәкләве, тирәсенә үзе яраткан, үзе хөрмәт иткән иҗат тарафдарларын туплый алуы мөһим роль уйнагандыр.

Милли театр, иң беренче чиратта, милли драматургиягә таянырга тиеш. Үз халкының тормыш-көнкүреш, яшәеш проблемаларын, кайгысын-шатлыгын, борчу-шатлыкларын, көн геройларын, алдынгы шәхесләрен бөтен барлыгы белән чагылдыру аның төп бурычларыннан санала. Әмма үз казанында гына кайнап, ерак барып булмый. Репертуарда заман темасы белән бер үк вакытта классик драматургия үрнәкләре дә урын алырга тиеш.

Америка ачу булмас, классика – актёрлар, режиссёрлар, гомумән, иҗат коллективы өчен зур осталык мәктәбе һәм, шул ук вакытта, аларның иҗат мөмкинлекләрен, потенциалын ачыклый торган төп билге дә. Нәтиҗәләр мәдәни вакыйгаларны янәшә куеп чагыштырганда ясала. Минзәлә театры коллективының Татарстан күләмендә тоткан урынын, осталык дәрәҗәсен билгеләгәндә, милли классиканы, Россия күләмендә – рус классикасын, ә дөньякүләм фикер йөрткәндә, мәңгелек дөнья драматургиясе үрнәкләрен сәхнәләштерү тәҗрибәсенә таянсак, дөрес булыр. Режиссёр Сабир Өметбаев әлеге хакыйкатьне яшьтән үк үзләштергән була. Шуңа күрәдер дә, аның режиссёр буларак, тәүге эшләре бүген милли драматургиябезнең алтын үрнәкләреннән саналган Ш.Камалның «Козгыннар оясында», М.Фәйзинең «Галиябану», К.Тинчуринның «Зәңгәр шәл» әсәрләренә нигезләнгән.

Бу нисбәттән С.Өметбаев нигез салган Минзәлә колхоз-совхоз театрының тәүге адымнарын искә алып китү урынлы булыр. 1935 елның март аенда Чистай шәһәрендә эшләп килгән театр труппасына директор һәм баш режиссёр итеп С.Өметбаев билгеләнә. 16 артист һәм артисткадан торган коллективка махсус белемле яшьләр җитешми. Шуңа күрә дә режиссёр Татар дәүләт академия театрында эшләгәндә, үзе җитәкләгән Казан кооперация клубы каршындагы театр студиясен тәмамлаган бер төркем яшьләрне Чистайга чакыра. Алар белән һәм элек эшләп килгән өлкән артистлар катнашында ул студиядә чакта куелган «Зәңгәр шәл», «Галиябану», бераз

соңрак «Козгыннар оясында» әсәрләрен сәхнәләштерә. Художнигы Галимов, музыка бизәлешен баянчы Рокыя Ибраһимова, скрипкачы Габдулла Хуҗиәхмәтов, гармунчы Шамил Вәлиев составындагы инструменталь трио алып барган әлеге спектакльләрдә төп рольләрне Хәдичә Сәлимова (Мәйсәрә, Галиябану, Фәизә), Сафин (Булат), Г.Казанский (Хәлил), Мәсрүр Арсланов (Ишан, Исмәгыйль) һ.б. артист һәм артисткалар башкара. Ул елларда С.Өметбаев үзе дә уйный. Мәсәлән, ул «Галиябану»да – Бәдри, «Козгыннар оясында» драмасында Насрыйны  уйный һәм шактый уңыш казана.

Милли драматургиянең классик үрнәкләре булган әлеге өч әсәр буенча куелган спектакльләр режиссёр С.Өметбаевның иҗат принципларын ачыклый һәм шул ук вакытта Минзәлә театрының үсеш юнәлешен билгели. Репертуар сәясәтендә – милли классикага сүрелмәс, даими игътибар. Сәхнә бизәлешендә – тормыш-көнкүреш дөреслеге. Актёрлар уенында – психологик хаклык һәм хис, кичереш тирәнлеге. Болардан тыш, ул тудырган сәхнә композицияләре җыр-моңга байлыгы, музыканың спектакль тукымасында мөһим урын тотуы белән аерылып тора. Режиссёрның музыкага, тамашаларда сурәтләнгән вакыйгаларны моңга төреп бирүгә омтылышы театрның репертуарын билгеләгәндә чагылыш таба.

Татарстан Мәгариф Халык Комиссариаты каршындагы Театр-тамашалар оешмалары идарәсенең 1936 ел 23 март карары белән яшь коллектив Чистайдан Минзәлә шәһәренә күчерелә һәм «Минзәлә татар колхоз-совхоз театры» дип атала башлый. Хезмәт күрсәтү өчен аңа Минзәлә, Красный Бор, Яр Чаллы, Актаныш районнары беркетелә. Яңа урында да С.Өметбаев эшен алда билгеләнгән юнәлештә дәвам итә. Элекке репертуар тулысынча саклана. Труппага Казан театр техникумыннан, башка коллективлардан яңа кешеләр килеп кушыла.

Бөек Ватан сугышы алды елларында да С.Өметбаев иҗади эзләнүләрен дәвам итә. Хәзер инде аның диапазоны киңәя, милли классика белән беррәттән, игътибар үзәгенә рус, дөнья классик драматургия үрнәкләре дә алына. Репертуарда Ф.Бурнашның «Яшь йөрәкләр», Г.Камалның «Банкрот», «Беренче театр», Т.Гыйззәтнең «Чаткылар», «Ташкыннар» әсәрләре белән беррәттән Л.Толстой прозасы буенча эшләнгән «Альбина Мигурская», М.Горькийның «Васса Железнова», Т.Шевченконың «Назар Стодоля», Ф.Шиллерның «Мәкер һәм мәхәббәт» спектакльләре дә лаеклы урын ала. Бу әсәрләрдә актёрлар коллективының осталыгы чарлана, иҗат мөмкинлекләре ачыла, ә режиссёр С.Өметбаев үзен Россия, бөтен дөнья күләмендә танылган пьесаларда сынап карый.

1939 елда Мәскәүдә колхоз-совхоз театрларының Бөтенсоюз фестивале уздырыла. Анда баштагы ике турда җиңүче булган Татарстан, Башкортстан, Удмуртиянең 15 театры арасында Минзәлә театры да катнаша. С.Өметбаев тарафыннан Т.Гыйззәтнең «Чаткылар», Г.Камалның «Беренче театр» әсәрләре буенча куелган спектакльләрне фестиваль жюрие югары бәяли. Коллектив диплом һәм йөк машинасы белән бүләкләнә. Әлеге уңышлар, әлбәттә, күктән төшми. Алар баш режиссёрның тәүге адымнардан ук алган дөрес юнәлеше нәтиҗәсе, милли классиканы сәхнәләштерү өлкәсендә максатчан эзләнү җимеше. Сәнгать өлкәсендә илнең иң дәрәҗәле «Театр» журналының 1939 елгы 11-12 нче саннарында С.Өметбаев куйган әлеге спектакльләргә шактый күп урын бирелә. Анда режиссёрның уңышлы хезмәте белән бергә Г.Мөхәммәдиев (Рамай), Г.Сәетова (Маһисәрвәр), Х.Сәлимова (Гыйльмениса), М.Кичубаев (Гаяз) кебек артист-артисткалар тудырган образлар уңай бәяләнә.

Гитлерчы илбасарлар кинәт башлаган сугыш театрның үсешен шактый вакытка тоткарлый. Ирләр составы тулысы белән фронтка китә. Сабир Өметбаев та, иҗат планнарын билгесез вакытка кичектереп, хәрби диңгезче сыйфатында утка керергә тиеш була. Лейтенант С.Өметбаев узган авыр фронт юллары бары 1946 елның гыйнвар аенда гына тәмамлана.

Үзе төзегән театрга яңадан әйләнеп кайткан режиссёрның тәүге спектакльләре

үк классик драматургия үрнәкләре нигезендә куела. Ш.Камалның «Хаҗи әфәнде өйләнә», Ж.Б.Мольерның «Ирексездән табиб», Ф.Шиллерның «Мәкер һәм мәхәббәт», М.Горькийның «Васса Железнова», Х.Ибраһимовның «Башмагым» әсәрләре була алар. Монда инде иҗатка сусаган художникның бай фантазиясе, тәҗрибәсе өстенә тирән белем, дөнья мәдәниятен иңләрлек фикер киңлеге дә кирәк була. Бер-бер артлы дөнья күргән әлеге спектакльләр С.Өметбаевта саналган сыйфатларның җитәрлек булуын раслый. Бигрәк тә Германиядәге «давыл һәм кысрыклау» чорының ялкынлы вәкиле Ф.Шиллерның «Мәкер һәм мәхәббәт» романтик трагедиясе тамашачыларның игътибарын җәлеп итә. Мәхәббәт хисләренең бөеклеген дәлилләгән, шәхес иреген, азатлыгын буарга азапланган тираннарга каршы юнәлтелгән әсәр төп рольләрдә артистлар Г.Сәетова (Луиза), Т.Кичубаев (Фердинанд) башкаруында аеруча көчле яңгыраш ала. Шулай ук М.Горькийның баш рольләрдә артисткалар Х.Сәлимова (Васса), Р.Шакирова (Рашель), М.Кичубаев (Прохор) уйнаган «Васса Железнова» спектакле дә халыкта тирән тәэсир калдыра. Рус классик драматургиясенә игътибар алга таба да кимеми. С.Өметбаевның тынгысыз эзләнүләре нәтиҗәсендә сугыштан соңгы унъеллыкта әле моңа кадәр татар сәхнәсендә бөтенләй күрелмәгән Н.Гогольнең «Өйләнү», А.Островскийның «Бирнәсез кыз», «Тиенгә тилмергәндә – көтелмәгән байлык», «Кичеккән мәхәббәт», сирәк куелган «Гаепсез гаеплеләр» әсәрләре уңыш казана. Бу елларда Минзәлә театрының репертуарында Г.Камал, М.Фәйзи, Ш.Камал кебек классик драматургларыбызның «Банкрот», «Кызганыч», «Козгыннар оясында» кебек җитди социаль проблемалар күтәргән әсәрләре мөһим урын тоталар. Ә инде җиңел юмор, кайвакытта әче сатира алымнары кулланылган «Хаҗи әфәнде өйләнә», халкыбызның сүрелмәс моңына, традицияләренә нигезләнгән Х.Ибраһимовның «Башмагым» комедияләре Минзәлә театрының беренче адымнарыннан ук С.Өметбаев тарафыннан билгеләнгән музыкаль юнәлешне дәвам иттерәләр.

Гомумән алганда, музыкальлек – теге яки бу дәрәҗәдә Минзәлә театрында С.Өметбаев куйган һәр спектакльгә диярлек хас сыйфат. Бу турыда театр белгечләре дә, сәнгать эшлеклеләре дә даими рәвештә әйтә киләләр. Мәсәлән, илленче еллар башында Казанда Г.Насрый һәм Җ.Фәйзинең «Идел буенда» музыкаль комедиясен карагач, халкыбызның яраткан композиторы С.Сәйдәшев болай ди: «Музыкаль әсәрләрне Академия театрында да болай уйный алмыйлар иде. Сездә музыка көчләре әйбәт икән. Мин дә сезнең театрга «Наёмщик»ны әзерләп бирәм әле».

Кызганыч, бөек композиторыбыз вакытсыз вафат була, теләген тормышка ашыра алмый кала. Әмма аның театрга биргән югары бәясе әле дә игътибарга лаек. С.Өметбаевның милли классик драматургиябездәге «Зәңгәр шәл», «Галиябану», «Башмагым» кебек әсәрләргә кат-кат мөрәҗәгать иткәне мәгълүм. Бу эш илленче, алтмышынчы елларда да дәвам итә.

1956 елда илдәге тоталитар режим фаш ителеп, гаепсезгә репрессиягә эләккән К.Тинчуринның иҗади мирасы халыкка кире кайтарыла. Шул ук елны аның «Зәңгәр шәл» мелодрамасы берьюлы ике театрда – режиссёр Ш.Сарымсаков тарафыннан Г.Камал һәм Минзәлә театрларында С.Өметбаев тарафыннан сәхнәгә куела. Көтмәгәндә иҗади ярышка чыккан коллективларның мөмкинлекләре, әлбәттә, икесенеке ике төрле. Шулай булса да, ике театр да 20 ел дәвамында сәхнәгә куелмый торган бу әсәрне кую, уйнау традицияләрен яңартырга, заман өзгән җепләрне ялгарга омтыла. Минзәлә театры спектаклендә традицион рухта чишелгән Булат, Мәйсәрә образларыннан тыш, артист М.Кичубаевның Ишан образы аеруча хәтердә кала. Режиссёр С.Өметбаев һәм М.Кичубаев шәрехләвендә ул диннең бәясен бик яхшы аңлый һәм халыкның ышанычын үзенең азгын теләкләрен тормышка ашыру өчен бик оста куллана белә торган хәйләкәр кеше буларак гәүдәләнә. Моның өстенә ул – ярлыларны гына түгел, авыл байларын да, Җиһанша кебек намуслары чиста булмаганнарны да кулда тота, үз максатларына буйсындыра белә торган нык холыклы, астыртын шәхес тә.

Ишан образы С.Өметбаевның «Зәңгәр шәл»не 1968 елда М.Мостафин белән бергә куйган спектаклендә тагын да баетыла. Тамашага традицияләргә тугрылыклы булган хәлдә, халык уеннары, җыр, бию, музыка күпләп кертелә. Тормыш-көнкүреш сәхнәләре күп кеше катнашкан эпизодлар белән аралаша. Драматик моментлар көлкеле күренешләр белән чиратлашып килә. Художник К.Камалетдиновның Октябрь инкыйлабына кадәрге татар авылы күренешләре – Җиһаншаның йорт-каралтылары, еракта күренеп торган мәчет манарасы, урман күренеше. Ишанның бай ихатасы – тамашага өстәмә эстетик кыйммәт өсти, вакыйгалар урыныннан спектакльнең актив компонентына әверелә. Режиссёрлар актёрлар уенында бербөтен ансамбль тудыруга ирешәләр. Биредә М.Кичубаев, Х.Сәлимова, Р.Шакирова, М.Зәйнуллин кебек өлкәннәр белән бергә Мәйсәрә һәм Булат рольләрендә театрда әле чагыштырмача күптән түгел эшләгән А.Фәттахова һәм Р.Сабировлар зур уңыш казаналар. Аларның уенына эчке шигърият, беренче саф хисләр аһәңе, йөрәктән чыга торган музыкальлек хас була.

«Зәңгәр шәл»дәге күп кенә сыйфатларны С.Өметбаевның Минзәләдәге иң соңгы саубуллашу җыры – Хәбибулла Ибраһимовның «Башмагым» музыкаль комедиясенә дә күчереп әйтеп булыр иде. Ике гашыйкның көрешүе, танышуы, кавышу өчен көрәше – үзәккә куелган гади тарих – режиссёр һәм иҗат коллективы тарафыннан үтә күренмәле, бәллүрдәй чиста, саф, шигъри поэмага әвереләдерелә. Сәрвәр һәм Галимҗан рольләрен гаҗәеп нечкә, үзара аңлашып башкарган Ания һәм Мәүҗит Фәттаховлар дуэты чын мәгънәсендә спектакльнең затлы бизәгенә әйләнә. Ә аларга каршы көчне гәүдәләндерүче Кәрим исә М.Кичубаев башкаруында башкаларга өстән караучы, үзен бик белдекле, эшлекле санаучы, ләкин гаять надан һәм тупас, кара татар бае була. Актёр, тормыш-көнкүреш дөреслегенә тугрылык саклаган хәлдә беркадәр арттыру, купайту алымнарын да куллана һәм бу тамаша тукымасында бик урынлы тоела.

Халкыбызның талантлы улы режиссёр Сабир Өметбаевның тууына 115 ел тулган көннәрдә, аның иҗатын янә бер кат барлап, кайбер нәтиҗәләр дә ясау зарур. Кырык елга якын гомерен иҗатка багышлаган күренекле сәхнә остасы сиксәнгә якын (төгәлрәк – 76) спектакльне сәхнәгә куйган. Куелган әсәрләрнең яртысы диярлек (32) – татар, рус һәм дөнья классикасы. Бу сан үзе генә дә режиссёрның киң иҗат диапазоны, югары профессиональлеге, фикер киңлеге турында сөйли. Әлеге спектакльләрдә никадәр актёрның осталыгы үскән, белеме тирәнәйгән, никадәр тамашачының дөньяга карашы киңәйгән, зәвыгы тәрбияләнгән дигән сүз.


Әле күптән түгел генә Минзәлә татар дәүләт драма театры тантаналы рәвештә үзенең 85 еллык юбилеен билгеләп үтте. Димәк, нигезенә тәүге ташларны салган, театрны төзегән, үстергән режиссёр Сабир Өметбаевның традицияләр чишмәсе әле тибә, алдагы иҗат планнарын сугара дияргә була.

**Гали АРСЛАНОВ,**
*Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир-әгъзасы,*
*Татарстанның атказанган фән эшлеклесе.*

# ЧЫТЫРМАНЛЫКТА БАР ДА ТӘРТИП

*(Марсель Галиевның «Чытырманлыкта» тәрҗемәләр җыентыгына күзәтү)*

Татарстанның халык язучысы Марсель Галиевның «Чытырманлыкта» (Татарстан китап нәшрияты, 2023) дигән яңа китабы басылып чыкты. Җыентыкка язучы төрле елларда тәрҗемә иткән әсәрләр тупланган. Аерым алганда, китапка рус әдәбияты классигы Максим Горький, япон әдәбияты классигы Рюноскэ Акөтәгава, озак еллар Казанда яшәгән этнограф, табиб, тарихчы, немец Карл Фукс һәм аның хатыны, шагыйрә Александра Фукс, калмык тарихчысы Әренҗән Карадауан, XV гасыр испан сәяхәтчесе, дипломат, язучы, тарихчы Руй Гонсалес де Клавихоның әсәрләре, очерклары, мемуарлары кергән. Эчтәлеккә күз салуга укучыда сорау туарга мөмкин, һәм ул табигый да: тәрҗемәче төрле дәвердә, төрле кыйтгаларда яшәгән бу шәхесләрне бер басмага туплаганда, ниндирәк мантыйкка таянды икән?




Марсель Галиевның иҗаты белән таныш укучылар аның татар рухын квантлар дәрәҗәсендә өйрәнгән язучы икәнен белә, ул һәрбер әсәрендә милли рух дигән үтә дә нечкә материя белән эш итә, шуңа күрә бу җыентыкка кергән тәрҗемәләрнең дә татарлыкка теге яки бу яклап кагылышы барлыгына шик юк. Бу әсәрләрнең күбесе рус телендә кат-кат басылып чыкса да, язучының аларны татар укучысына туган телендә тәкъдим итүенең үзенә бер хикмәте бар. Марсель Галиев – ана теленең дәвалау сәләте барлыгына нык инанган шәхес. Үзенең «Туган тел сихәте» дигән эссесында ул болай дип язган иде: «Туган тел шифасы... Туган тел дәвасы... Туган тел сихәте... – бу гаҗәеп сер, әлегә өйрәнелмәгән могҗиза.

Туган телеңдә иркен-рәхәт сөйләшү – үз тавышың белән үзеңне дәвалау ул. Сөйләм теленең моңы, аерым сүзләр яңгырашы, нәзберек тән күзәнәкләрен тибрәндереп, бөтен вөҗүдеңә тигез тарала. Ана сөте белән кергән телнең көйле агышы тәнеңне сугарып торган су хәтеренә, кан хәтеренә, җан хәтеренә сеңеп, гомерлек хасиятеңә әверелә». Димәк, Марсель ага чит мәдәниятне дә ана телендә үзләштерүнең нәтиҗәлерәк булуына ышана.

Инде китапның эчтәлегенә килик. Китапның саллы гына өлеше Максим Горькийга багышлана. 1868 елда Түбән Новгородта туып, 1884 елда университетка укырга керү нияте белән Казанга килгән Алексей Пешков – киләчәктә бөек әдип Максим Горький – Марсель Галиевның яраткан язучысы. Ул без «Давыл хәбәрчесе» дип белгән Горький турында сәгатьләр буе сөйли ала, аның тормыш юлын һәм иҗатын яттан белә. Совет идеологиясенә корал буларак уйлап чыгарылган социалистик реализм дигән иҗат юнәлешеннән ваз кичкәч, яңа заманның әдәбият тарихы аның авторы Максим Горькийның әсәрләрен дә китап киштәләренең тузан баса торганрак урынына этеп куйды. Китап

кибетләрендә Горький исеме Толстой, Достоевскийларга караганда, күпкә сирәк очрый хәзер. Максим Горькийны тарих чоңгылында оныттырырга ашыкмыйк әле, ди Марсель Галиев. Тәрҗемәгә кереш сүзендә ул аны бүген дә дөньяви бөек әдип дип бәяли: «Аның йөзләгән телләрдә өч йөз миллион данәгә якын китабы басылган. Искиткеч бай әдәби мирасы – кешелеккә калдырган үзе бер пирамида. <…> Лев Толстойдан соң рус әдәбиятының «алтын дәвер» капкасын ябып, мәңгелек кыйбласына юл алган олуг әдип ул... Капканың бу ягында исә бүтән үлчәмдәге эпоха нәүмиз торып калды...» Шунда ук әлеге дөньяви бөек әдипнең татарлар турында әйткән сүзләрен дә китерә: «Китаптан туеп, моңсуланган чакларда Татар Бистәсенә барасым килә иде. Анда ниндидер үзгә, бертөрле, пөхтә тормыш бара, анда эчкерсез, ягымлы, рус телен мәзәк итеп бозып сөйләшүче кешеләр яши; кичләрен мөәзиннәре, биек манарадан моңлы көй сузып, мәчеткә чакыра. Минем уемча, татарларның яшәү рәвеше бөтенләй бүтәнчә корылган, мин белгән, миңа куаныч китермәгән тормыштан нык аерылып тора иде». Һәм ул Горькийның замандашлары – күренекле рус язучылары Лев Толстой, Антон Чехов, данлыклы меценат, мануфактурачы Савва Морозов турындагы язмаларының тәрҗемәләрен бирә. Марсель Галиев үзе дә замандашлары турында калын-калын китаплар язган әдип буларак, аны Горькийның нәкъ шушы юнәлештәге иҗаты кызыксындыруы гаҗәп түгел. Ул гүя «менә болай итеп тә язып була истәлекләрне», дип искәртә.

Алга таба китапка яңа заман япон әдәбияты классигы Рюноскэ Акөтәгаваның «Чытырманлыкта» дигән хикәясе кергән. Башка тәрҗемәләр арасында әлеге новелла гына – матур әдәбият әсәре. Классикага хас булганча, ул бүген дә актуальлеген югалтмаган. Хикәя җиде өлештән торган фабуласы, авторның позиция белдермәве ягыннан гына үзенчәлекле түгел, ул укучыны хакыйкать проблемасына яңа ноктадан карарга этәрә.

Самурай Канадзава Такэхироның чытырманлыкта мәете табыла. Судта шаһитлар да, үтерүдә шикләнелгән юлбасар да, самурайның юлбасар тарафыннан мәсхәрәләнеп, гыйбадәтханәгә тәүбә итәргә килгән хатыны Масаго да самурайны мин үтердем дип таный. Алай гына да түгел, спиритик сеанста рухы чакырып кайтарылган мәрхүм Такэхиро үземне үзем үтердем, ди.

Без «хакыйкать берәү генә була» дигән катгый императив системасында яшәргә нияләшкән. Рюноскэ Акөтәгава тәкъдим иткән субъектив дөреслекләрнең һәркайсы ышандыра: гыйбадәтханәгә тәүбә итәргә килгән кешедән дә ихласрак кеше була аламы? Ә инде спиритик сеанста теге дөньядан чакырып кайтарылган Такэхиро рухы ялганлый аламы? Бу җинаятьтә ялганлау юлбасарның гына гомерен саклап кала ала, ул «мин үтермәдем!» дип, аяк терәп каршы торырга тиеш кебек, әмма ул, киресенчә, җинаятен таный. Кыскасы, Акөтәгава 1921 елда Эйнштейн артыннан ук «ике икең – дүрт түгел»легенә, чынбарлыкның да күп үлчәмле булуына ишарә итә. Әлеге модернистик модель бүген «кем алдан сөйләсә, кем катырак кычкырса – шуныкы дөрес» дип яшәүчеләрне дә шикләнергә өйрәтә.

Карл Фукс тәрҗемәләренә кагылганчы, милли дөнья моделе турында, аның үз/чит бинар оппозициясенә таянуын әйтеп китү урынлы булыр. «Үз/чит» дихотомиясе милли яшәешнең һәрбер катламына кагыла, шуңа да чит мәдәният кешесе белән аралаша башлауга үзара мөнәсәбәтләрдә шундук чикләр сызыла. Үзең турында күбрәк беләсең килсә, читләр әйткәнне тыңлыйсың. Гадәттә, үзең турында барысы да билгеле, аңлаешлы тоела. Ә менә чит кеше әйткән шундук сагайта, уйланырга этәрә. 1805 елда Казанга килеп төпләнеп, гомеренең ахырына кадәр шунда яшәгән алман галиме, табиб, табигать фәннәре белгече, төбәк тарихын өйрәнүче, нумизмат, журналист Карл Фукс – бөтенләе белән чит мәдәният кешесе. Нәкъ менә ул XIX гасырда әле үз дөньясына бикләнеп яшәгән Казан татарлары турында иң күп этнографик мәгълүматны теркәп калдырган һәм шуның белән татар халкына үз кеше булып


киткән шәхес. Китапка Карл Фуксның «Казан татарлары: статистик һәм этнографик җәһәттән», Рамазан, Корбан, Бәйрәм хөтбәсе, Сабан, Җыен бәйрәмнәре, мәдрәсәләр турындагы очерклары, «Татарларда чит ил кунакларын кабул итү», «Кыргыз ханы Җиһангирнең Казанга килүе», «Казаннан мордваларга сәяхәт» мәкаләләренең татарчага тәрҗемәләре кергән. Фукс тәрҗемәләренә кереш сүзендә Марсель Галиев галимнең Казан ханлыгы һәм Иван Грозный чорына караган кыйммәтле архив документларының күчермәсен булдырырга тырышып йөрүен искә төшерә. Ни кызганыч, 1842 елның 24 августында шәһәрдә коточкыч зур янгын чыгып, ул документларны юк итә, Фукс үзенең коллекцияләр салынган сандыкларын гына коткарып кала ала. Әмма татар тарихындагы бик күп ертыкларга җөй салырга ярдәм итәрдәй ул хәзинәнең дә бүген күп өлеше юк инде. «Ике гасыр дәвамында буйсындырылып, руслар арасына сибелгәч тә, гел үзайры яшәгән кебек, гореф-гадәтен, йолаларын, горурлыгын саклап кала алган гаҗәеп халык бу!» дип язып калдырган Карл Фуксның үз исемендәге бакчасында һәйкәле бар да элек Поперечно-Тихвинск дип йөртелгән урамга аның исеме бирелгән. Шулай ук Иске Татар бистәсенең төньягында Мәскәү һәм Г.Камал урамнары кисешкән урында ул яшәгән йортта тактаташ эленгән. Ә Фукс бөртекләп язып калдырган истәлекләрне укырга кирәк. Үзебез турында күбрәк белер һәм горурланыр, ә кайчагында гыйбрәт алыр өчен.

Карл Фуксның хатыны Александра Фукс шагыйрә була. Ул Петербург дамалары кебек Казанда салон тота, әдәбият әһелләре Фукс йортына җыела. 1833 елның сентябрендә А.С.Пушкин Казанга килә, ул да Александра Андреевнаның кунагы була. Китапка Фукс җәмәгатенең Пушкин турындагы хатирәләре кергән.


Әлбәттә, алдагы тәрҗемә дә Казан белән бәйле. Аның авторы – калмык халкының асыл улы, тарихчы Әренҗән Карадауан – 1910 елда Казан университетының медицина факультетына дүртенче курска укырга килә. 1919 елдан революция сәбәпле, Югославиядә мөһаҗирлектә яшәргә мәҗбүр булган Карадауан табиб һөнәрен ташлап, тарих белән кызыксына башлый һәм совет кешесенә билгеле булмаган, чит телдәге чыганакларны өйрәнеп, Чыңгыз ханның үлеменә 700 ел тулуга багышлап, монография яза, әлеге китапка аның шушы хезмәтеннән өзекләр кергән. «Тарихны эзлекле өйрәнү өчен аның чишмә башына төшәргә, тәүге чирканчык алып, ата-бабалар үткән шанлы-канлы гасырларны дисбе кебек бер җепкә тезеп карый белү сорала. <…> Безнең тарихи чишмәбезнең бер тармагында мәһабәт кыя булып, Чыңгыз хан, аның варислары, баһадирлар тора. Алар әмереннән дөнья, гасырлар хәрәкәткә килгән. Шуны белми торып, без меңәр еллык тарихыбызны гадел аңлау һәм төпле кабул итү биеклегенә ирешә алмаячакбыз», дип яза тәрҗемәгә кереш сүзендә Марсель Галиев. Китапка кергән соңгы тәрҗемә әсәре – испан сәяхәтчесе Руй Гонсалес де Клавихоның юлъязмасы да шушы мантыйкка нигезләнгән. Тарихыбызга читләр бәһасен дә тыңлап карыйк, ди әдип. Клавихоның язмасы Тимербәк (Тимерләнг) әмирнең ил-йортына сәяхәт көндәлеге формасында бәян ителгән, Марсель Галиевның зәрканнарча осталыгы белән тәрҗемә ителгән.

Шул рәвешле «Чытырманлыкта» җыентыгына тәрҗемәче Марсель Галиев татар укучысына кадерле һәм файдалы булырдай язмаларны гына туплаган, аларның ана телебездә яңгыравы да – олы әдиптән зур бүләк.

**Ландыш ӘБҮДӘРОВА**



*Абдулла Алиш (1908–1944) – шагыйрь, балалар язучысы.*



Nr 2968

Berlin – Charlottenburg – – , den 26. August 1944

Der Schriftsteller Abdull Alischew, mohammedanisch,

wohnhaft in Kasan, Straße Jerjinaki 18/19,

ist am 25. August 1944 – – um 12 Uhr 12 Minuten

in Berlin – Charlottenburg, Königsdamm 7 – – – – verstorben.

Der Verstorbene war geboren am 15. September 1908

in Kajuki/Rußland

Standesamt Nr.

Vater: Abduil Bari Alischew, letzter wohnort unbekannt

Mutter: Gasisa Alischew, Mädchenname unbekannt, wohnhaft Kasan

Der Verstorbene war – verheiratet mit Rakia Alischew, geborenen Tulbanoa.

Eingetragen auf mündliche – Anzeige des Hilfsaufseher Paul Dürrhauer, Berlin, Manteuffelstraße 10.

Der Anzeigende ist bekannt und erklärte, er sei vom Tode aus eigener Wissenschaft unterrichtet.

Vorgelesen, genehmigt und unterschrieben

Paul Dürrhauer

Die Übereinstimmung mit dem Erstbuch wird beglaubigt.
Berlin Charlottenburg, den 26. August 1944
Der Standesbeamte

Der Standesbeamte

In Vertretung Gluck.

*Абдулла Алишның үлеме турындагы таныклыгы. 1944 ел, 25 август. 12 сәгать, 12 минут.*



*Язучылар, Алиш премиясе лауреатлары, каһарман-шагыйрьнең туганнары Казандагы 20 нче гимназиянең ишегалдындагы Абдулла Алиш бюсты янында.*




*Абдулла Алишның туган ягында –
Спас районы Көек авылындагы бюсты.*




*Алиш мирасы.*



*Казандагы
20 нче гимназиядәге
Алиш музеенда
конференция бара.*

*Сәхифәне* **Рәхимә АРСЛАНОВА** *әзерләде.*

## Аяз Гыйләҗев хатлары

*1988 ел, 2 март. Переделкино*

Марсель, саумы!

Көне-төне повесть белән утырдым да бүген шуны салырга почтага барам. Сиңа хатны төштән соң язып, иртәгә салырмын инде. Килештекме? Синең әсәр турында еш уйланам, үземчә бер тәкъдим дә өлгерде, кабул итәрсеңме, юкмы – белмим...

Рафаэльнең кульязмасын үзенә тапшыр. Аңа да хатны бүген-иртәгә язармын. Кульязма Хәсән абыйча бераз наивный, әмма басарлык. Ялгыш-мазарлар, ипсез нәрсәләр күземә чалынмады, һәммәсе булганча яки булырга мөмкинчә язылган... Фикерләр хатта булыр.

Зинһар, кулыңа килеп керүгә үк Р.Мостафинга хәбәр ит. Гафу үтенәм, килгәч тә укып чыксам да, җавап язарга җитешеп булмады...

*Сәлам вә ихтирам белән Аяз.*

***

*1988 ел, 3 март. Переделкино*

Марсель, саумы!

Повестеңны укыганда, кулга каләм тотып, ян-якларга «шәп, әйбәт, тапкыр!» дип билгеләп барасы килде, кульязма артык чуарлана дип кенә тыелдым. Күзең үткен, караңгыда-яктыда да дөньяның бөтен нечкәлеген күрә аласың, пространствоны тою, мизансценалар кору шул кадәр җиренә җиткереп эшләнгән ки, синең сәләтеңне күреп, үтә куандым. Дөнья сиңа рәссам күзе биргән. Телең шул кадәр җанлы, җыйнак, яшьләрнең үзара киная белән, шуклык белән сөйләшүләре сокландыргыч. (Катокта һәм бүтән урыннарда). Син дөньяның кызыклы гына бер почмагына үз төсмере, үз холкы булган кешеләрне туплый алгансың, аларның яшәү рәвешләре дә, фикер йөртүләре дә, бер-берсенә мөгамәләләр дә мәгънәле генә...

Әсәрнең төп һәм бердәнбер җитешсезлеге: үзең язган вакыйгаларга, шәхесләргә заманча бәя һәм мөнәсәбәт кенә юк. Ни өчен «Алтын тотка»? Исем, ни әйтсәң дә, бөтенләй үк очраклы була алмый, әсәрнең исеменә авторның бик тирәнгә яшеренгән сере дә сыярга тиеш. «Качып, буяу астына яшеренеп калган алтын тотка» әсәргә соң килеп керә, көткән рольне уйнамый. Нәрсә тели автор? Максаты нәрсәдә? Әгәр картлыгым аркасында сизенми калсам, кичер. Бәлки мин синнән бик күпне көткәнгәдер ул?.. Алай да, алай да... Минә Мөхәммәтнең «Бәхилләшү»е. Анда да чәчрәп торган сюжет та, ике икең – дүрт таблицасы да юк, анда тоташ моң, күңелнең туктаусыз агышы, күңел чайпалышлары бар. Синдә ифрат кызыклы кешеләр, аларны син бер ноктага удачно гына җыйгансың, ләкин алар шул ноктадан төрлесе төрле якка юнәләләр, тупланмыйлар, ачыкламыйлар, тормыш сәяхәтеннән кайтмыйлар, һаман китеп баралар, томан кебек таралалар.

Нигә Сирин образына кайтмаска? (Гафу ит, син киңәшләр тыңлау чорыннан үткән художник, алай да чак кына «фантазировать» итеп тә карыйк әле). Сирин, Сирин... Шул кеше борчый мине... Бер нәрсәгә игътибар итик. Аның бер картинасы калган, син аны бик нечкәләп, күңелдә моң-сагыш уятырлык итеп тасвирласаң да, без картинаны күз алдына китерә алмыйбыз. Безнең татар укучысы рәсемнең үзен күргәндә дә, рәссамның хыялын һәм омтылышын аңлап бетерә микән әле?.. Без рәсем сәнгате белән халкыбызны тәрбияләмәгәнбез. Бу – безнең гаеп. Син күңел

кузгатырга теләсәң, рәссамның картинасы белән түгел, аның кыен яшәеше, авыр язмышы, бәхетсезлеге белән күңелләргә ут як! Рәсем өлкәсендә Казанда озак еллар <...> культы яшәде. Музыкада <...> кырык биш еллык тиранлыгы күпме кешеләрнең юлын буып ташламагандыр, аны бәяләр вакытлар җитәр! Әгәр <...> чын сәнгать кешесе булса, ул бөек рәссам Константин Васильевның тиңдәшсез әсәрләрен Казан каласыннан ычкындыра идеме? («Портрет сестры», «Человек с совой» һ.б.) Ни өчен синең Сиринең дә шул елларның корбаны түгел?..

Дөрес, бу темага якын әсәрләр рус матбугатында күренгәләде, әмма синең үз моңың, үз тавышың, үз карашың. Ул бер чакта да кабатлау булмас. Һәм мин картинасын кая куярга белмичә аптырап йөргән рәссамның кино-театр хезмәтчесе булып эшләп ятуын да, шунда буяулар, клейлар, баскычлар, стремянкалар саклана торган ярымбуш бүлмә диварына сакланып калган бердәнбер картинасын элеп куеп, сирәк-мирәк кенә дуслар арасыннан кемнеңдер шуны тамаша итәргә килүенә дә ышаныр идем. Нигә Пассаж җимерелеп, Сиринне атаклы картинасы белән бергә таш-балчык астында калдырмас, дисең? Син бит дөреслеккә ябышып ятып, газета репортажы язмыйсың! Бөтен кешеләрнең, исемнәре аталган персонажларның Сирингә, аның язмышына карата булган мөнәсәбәте – мине, сине көтеп торган коридор! Син яшьләрне, картларны шул тормыш коридоры аша үткәрсәң... Тукта, минем фантазия артыкка китте түгелме?..

«Мастер» – комачаулый. Кеше исеме бир. Күгәрчен дә «Сыңар күз» генә, Потёмкинны бүтән бер очракка сакла.

Син бу әсәреңне чыгарырга ашыкма, дисәм, үпкәләмә. Заман үзгәрде, заман алда тагын да үзгәрәчәк, әдәбиятка мөнәсәбәт, таләпчәнлек авыр булса да, уяныр. Дөрес, <...> үзгәрмәс, мәгәр әдәбиятның үзәгендә алар түгел, әдәбиятның үзәгендә без барасы, сез язып – мин күзәтеп...

Әсәрнең вак-төякләренә кагылып та тормыйм, чөнки аңа бер генә нәрсә җитми... Анысын югарыда әйттем дә шикелле.

Кыерсытылган, кимсетелгән талант, талантның авыр еллардагы юлы – бу мәңгелек тема. Талант дәүләт белән идарә итүче чиновниклар катлавының күзенә ук булып кадалырга тиеш. Талантлы Сириннең баз кебек суык бүлмәдә төн үткәрүен күз алдына китерәм дә... синнән көнләшеп куям. Син үзең дә рәссам, син аның дөньясын кабул итә аласың.

*Сау булып тор, сәлам-ихтирам белән Аяз.*
*1990 ел, 2 ноябрь. Переделкино. Көндез.*

***

Марсель, хәерле көн.

Без, әдипләр, тормыш дигән елгада бер көймәдә йөзәбез. Мин аның бер кадагы булсам, син икенчесе, яки киресенчә, нумерларны теләгәнчә һәм бик иркен алыштырып була. «Беренче нумерлы кадак»ны дәгъвалый икән дип уйлый күрмә, барыбыз да кирәк, беребез генә булмаса да, көймәнең таралып, сүтелеп китүе ихтимал. Ә елга ага, бусагалар аша үтеп, кыяларга кага-кага ага, көймәнең бер урында бөтерелеп, тыелып торган чаклары да була, кемдер кыек, яньчелгән кадак булып кереп утыргач, көймәгә су кергән мизгелләр дә була. Без монда ун татар, үзең юк, ә сине уртак әңгәмәләрдә еш телгә алабыз. Шәүкәт үзалдына гына мыгырдап йөри:

*«Кибет белән баш янәшә,*
*Буш киштәләр сиңа бик килешә, Миләүшә...»*

Шәүкәт җор, шук кеше, син аңа үпкәләмә. Җөмләдән, синең ул җырың бик матур, Хәйдәр үзәккә үткәзеп җырлый, оныкларымның – нәбәрләремнең берсе Миләүшә

исемле булгач, җыр миңа тагын да ошыйрак төшә. Һәркемнең иҗат язмышын чын күңеленнән кабул итеп, кайгыртып яшәүче Миргазиян Юныс: «Эх, шул егеткә әз генә биография өстәргә! Нужаны әз күргән, тилмермәгән... Югыйсә андагы образлы тел, андагы чагыштырулар, андагы сәнгатьчәлек!» – дип уфтана. «Каядыр җибәреп кайтарырга кирәк аны! Йөрсен, нужарсын, тилмерсен!» – дип тә өсти...

Ә мин болай яратып, ышанып уйлыйм. Көймә чайкалып аумасын өчен кадакларның төрлесе кирәк! Мәсәлән, син <...> турында язып чыктың да, моңарчы бик билгеле булмаган кешегә һәйкәл коеп куйдың. Синнән башка моны берәү дә үтеп чыгачак түгел иде. Синең кулыңда көчле корал тел генә түгел – ул бик тирәнтен күрә алу! <...> ярым-йорты иҗатына карашым үзгәрмәде, әмма оста кул бүтән кеше турында язып та үз шәхесен ныграк ача ала. Бу бик мөһим сыйфат. Шул язмаң аша моңарчы син иҗат иткән бик күп хикәяләргә, повестьларга мин бүтәнчәрәк, ягымлырак карыйм.

Әдәбиятның биеклеген, урынын бары тик милләтнең язмышы гына билгели. Әйтик, моңарчы гагауз дигән халыкны җир шарында күпме кеше белә иде икән?.. Мин белә идем, лагерьда Савелий Крайтору исемле бер тоткын, император Вильһельм чорындагы немец офицерлары сыман ап-ак мыек җибәргән, ак чырайлы, сап-сары чәчле берәү яныма килде дә саф татарча: «Син төрекчә беләсеңме, юкмы?» – дип сорады. Ул гагауз икән, танышып киттек. Тәүфикъ Әйди алар арасына барып кайткач, гагаузлар хакында кызып-кызып сөйләп, безгә ят халыкның яшәү рәвешен бераз аңлаткан иде. Ә хәзер? Йөз илле меңле халыкны бүген Россия генә түгел, дөнья белә, гагаузлар үзләрен дөньяга таныттылар... Һәм табигый рәвештә дөнья гагаузның милли батырлары белән дә, милли әдәбиятлары белән дә кызыксыначак. Татар әдәбияты – юаш әдәбият. Тыныч әдәбият. Ул бер ягы белән дә бүтәннәрдән аерылып тормый, аның ярып бара торган үз юлы юк, әдипләребез завод штамповать итеп чыгарган кадаклар төсле. Җиз кадагыбыз – <...> бар иде, ул да әллә ни майтара алмады, нефть вышкалары арасында адашып, тальян гармунын ары-бире тартып, гомерен уздырды. Хәле авыр дигәннәр иде, сүзем гаепләү булып ишетелмәсен, ихлас һәм наив кеше иде. Дүрт йөз утыз сигез ел дәүләтчелеге булмаган икән – димәк, аның дәүләт эшлеклеләре дә, татар исеменнән дөнья агышына өлеш кертерлек галимнәре, бөекләре дә булмаган. Академик Роальд Сәгъдиев (исемен генә кара!) – дөньякүләм галим – Америкага кача. Дөньяда атаклы биюче Рудольф Нуриев (исеме, исеме!) Англиядә. Рональд Рейган – АКШ президенты кабул итеп, соклануын белдергән Ирек Мөхәммәтов та, ниһаять, чит илгә күчте. Өметле талант Гата Камскийны да чит ил йотты. Әле болары без белгәннәрдән. Без белмәгәннәр әле күпмедер?.. Чөнки без тарау, таркау, юаш милләт. Халыкның географик урнашуы да аның холкына, характерына тәэсир итә һәм әдәбиятның, сәнгатьнең эчтәлеген билгели. Татарның таулары юк, диңгезләре ерак, елгаларның берсе дә «татарныкы!» дип горурланырлык түгел, «Волга – русская река!»

Сугышта татарлар батырлык күрсәтте, дибез. Ләкин һәр батырлык рус даны өчен, рус дәүләтенең куәте өчен эшләнә, яман чакта татар – яман, батыр чакта татар – рус! Каян рух алып, тарихның кайсы баганаларына таянып ныгысын татар күңеле? Илһам каян килсен аңа?.. Хәзер төп сүзгә барып җитәм. Казан алынган, җир таланган, дүрт йөз утыз сигез ел дәвамында татарга бер тапкыр да кояш чыкмаган, аны империя гел караңгылыкта, баз белән чокырда яшәткән. Таралган, таркалган, йомшарган булса да, милләт калган лабаса! Тел дә әз-мәз сакланган. Без хәзер көймәдә, елга иркенә баш биреп, теләсә кая агарга тиеш түгел инде! Безгә шәп ишкәкчеләр, адашмас лоцманнар, барыннан да бигрәк бөркет күзле, нык куллы рулевойлар кирәк. Безнең буын онытылып бара торган төп бер сорауга җавап эзләргә бурычлы: ничек сакланып калган татар халкы? Динме? XX гасырда диннең йөзен ерткannar. Тукай да мавыгып киткән, Такташ та дин әһелләре тормышына разбойниклар җибәргән, Гаяз Исхакый да татарның милли тарлыгын мыскыл иткән пьеса калдырган. «Зөләйха»ны куярга курыккан Марсель Сәлимҗанов аның «Җәмгыять» дигән йомшак бер әкәмәтен

сәхнәләштерергә җыена... Кем яшәткән театрны? Ничек яшәткән? Һәм бу яшәү куәте озак елларга бара алырмы? Менә сез, урта буыннар, яшьләр – Ркаил Зәйдулла, Зиннур Хөснияр, Газинур Моратлар аңа ни дәрәҗәдә өлеш кертерсез? Син геройлыктан, җәмәгать хадиме булудан бик ерак торган, урта кул таланттан <...> нинди сыйфат билгеләре таба алдың... Татарны туры юлдан аермаган бүтәннәр булгандыр ич? Мин язучыларны күздә тотмыйм, без аумакай һәм куркак көймәчеләр, татарны кем саклаган? Кем бүгенге көнгә татар итеп китереп җиткергән – моны синнән башка кем яза алыр? Ялкауланма әле, иренмә! Миргазиян хаталана, язучыга иҗат юлы ныгысын өчен үз нужасы гына җитми, ул халык күргәннәрне, милләт кичергәннәрне иҗатының үзәгенә куйсын. Ә татар күргәннәр, татар кичергәннәр, валлаһи, аны дөнья күләмендә «батыр халык!» дип күрсәтергә дә була... Оят түгел. Чаллыяр каласында, Самара-Төмән якларында кызыклы шәхесләр калкынып килә. Әдәбиятчылар шуны күрә алырбызмы?..

Син – талантлы егет. Сәләтле каләм. Синең тере җаның бар. Әйдә әле, берәүләрне шаккатыр, берәүләрне сөендер. Яз әле, татарны сикереп торырлык итеп яз әле!

**P.S.** Бу хатыма, зинһар, гаҗәпләнмә, көн авыр, иләс-миләс утырган чак, буталчык та яздым бугай. Күчереп торырга вакыт юк!

*Аяз.*

***

*1991, 17 август. Көпә-көндез*[1]
*Казан*

Марсель![2]

Көтмәгән идеңме, бу мин, «хәтер яктың»ның нуры бүген таңда, сәгать өчтә килеп кагылды да, хат язарга утырдым. Кичә Зәйдән кайтып төштем, Президент Буш[3] белән ярышка чыкмасам да (ул быел, 32 илгә сәяхәт кылып, 550 мең чакрым җир узган!), Сарманнан башлап, сәфәрем уравыч юллар аша Зәйгә барып тәгәлләнде. Быелгы сәфәрем хатирәләр дөньясына да кайту иде. Югары Әхмәт зиратында һаман-һаман иҗатымны, әсәрләремне җылытып, нурландырып торган Сөләйман бабам белән Зөләйха әбием йоклый. Каберләренә барып башымны идем... Зират шактый йончыган, адәмнәр үлеме бер хәл, зиратлар үлеме – аяныч, аннан да зур һәлакәт юктыр... Әтиемнең атасы Сәхәбетдин хәзрәт, Сарман мәчетенең имамы, утызынчы еллар башында Алабуга төрмәсендә эзсез югала... Яшьли ятим калган әтидән әбинең исемен сорарга башка да килмәгән. Әти үлгәч, кәгазьләре арасыннан туу турында таныклыгы килеп чыкты, Гыйлембаян исемле булган икән минем атама гомер биреп, үзе дөньялыкны куйган изге җан! Сарман зиратлары таланган, мәсхәрәләнгән, юк алар. Ә әби-бабайның исемнәрен яд итәсе, аларны тере итеп күрәсе килә. Төзелергә тиешле Сарман мәчете хисабына 1000 сум акча күчердем. Әби-бабай, әти-әниләр рухына... Сарман янында гына Иске Әлмәт дигән җыйнак, сөйкемле авыл бар, безнең белән утыз бер ел яшәгән, өч улымны үстерергә искиткеч көч салган Нәүбаһәр әбиебез шул авылдан. Анда бардык (Нәкыя белән кайткан идек), матур итеп таш мәчет салып яталар. Мәчеткә 100 сум тапшырдым. Догада булсыннар! Сарманнан туп-туры Зәй ягына тәгәрәдек. Дөнья нык үзгәргән, дөньяны мин таный алмыйм, ә дөнья миңа арты белән борылгандыр сыман тоела. 60 еллыгымда Багражның Минәй чишмәсенә таш куйдырып, «Кадерле әти-әнием Мирсәет белән Мөгаттәрәне озак еллар сыендырган Баграж халкына рәхмәт йөзеннән куйдым бу ташны» дип яздырган идем. Куючылар игътибарсызлыгы аркасында чишмә суы читкә ага башлады. Байтак вакыт шуны уйлап янып йөрдем! Күр инде, иң изге ниятләр белән башкарылган эшең кирегә китә.

[1] М.Галиевкә. «ВМЕ» (ГДР) машинкасында басылган хаты. Пагинациясез, 1 кәгазь. Татар телендә.
[2] Марсель – Марсель Баян улы Галиев (1946).
[3] Буш – Джордж Герберт Уокер Буш (1924), АКШ президенты.

Ниһаять, авылдашлар мине көтмәгәннәр, чишмәне рәтләгәннәр. Суы, күңелләрне тузгытып, моң гына агып ята! Шул чишмә каршысында, безнең элеккеге ындыр артында, биек-биек каеннар шыбырдый. Мин аларны моннан 25-30 ел элек әти белән утырткан идем... Хәзер әти-әнием Зәй төбәгендә, гүзәл тынлыгы белән күңелне кайната торган Бигеш зиратында йоклыйлар... Аларга кагылып чыктык, каберләренә матур күз сачкәләре салдык. Алар догадан аермасын дип, төзелеп ята торган Зәй мәчете хисабына банк аша – 1000 сум, Бигеш мәчетенә 100 сум акча күчердем.

Нык сыйланып, изге эш артыннан йөрелсә дә, әз-мәз хәмер дә капкалап, байтак якташлар белән очрашып, сөйләшеп, кайгырышып, шатланып, мәшәкатьләр бермә-бер артканын тоеп, кичә өйгә кайтып элгәштек.

Атналык почта бер эскерт! Шәһәрдән аерылып торган мәлләрдә, газеталарны җыеп укыганда, милләтнең алга талпынышын ачыграк сизәсең. Бу юлы да шулай булды, бик кызыксынып «Идел»нең[4] 4нче санын караштырдым. Кичә юлдан соң зиһен авырайган иде, бүген таңда уяндым да журнални баштанаяк диярлек укып чыктым. Зәки Зәйнуллин[5] язмаларында үзен бүтән кешеләрдән мактаткан өлешләрен чак кына кыскартырга да кирәк иде! Оста кеше, каһәр, утны җиде кат җир астыннан йөртә белә, аның кылмышларында байтак уңай якларны белгән хәлдә, татарның мактанчыклыгы тагын бер тел аркылы ачылган. Әгәр аның кылган эшләре Латвиядәге милли хәрәкәткә анык ярдәм китерсә, язмалар безнең файдага...

Фәнис Балтачның[6] «Ил гаме» без наданнарга күз даруы булыр иде дип ышанам. И куркак инде без, и надан! Фәнис сүзләрен үзара кайчаннан бирле сөйләшеп, алай гына да түгел, телдән төшермичә йөрибез, ә ул тоткан да һәммәсен дисбе итеп тезгән. Мәкаләнең кыйммәте аның фикри төгәллегендә, фикерләр саннар, документлар белән нык беркетелгән. Рәхмәт аңа!

Син татарлар турында очынып-очынып, каләм очыңа кан тамчылары элеп тә яза аласың икән! «Йа Раббым...» дип исемләнгән язмаңнан аерата шушы мәгълүматларга куандым:

Сәйдәш[7] – Кәрлә Зәйнәп[8] мөнәсәбәтләре.

Сәйдәш – Җиһанов[9] күләгәсе.

Җиһановның гомере буе (Сәйдәш үлгәннән соң да!) Салих абыйдан көнләшеп яшәвен беләбез. Шушы кара юнәлешне куәтләп, аңа көч өстәп яшәгән кешеләр әле дә безнең арада. Бу үтә җитди мәсьәлә төгәллек, ачыклау сорый. Юк ла, Җиһановка ияреп Сәйдәшкә кара ягарга тырышучыларны сафка тезүләрен теләмим; шул кешеләр аша, әйтик, Зәйнәп кәрлә аша, Сәйдәшнең фаҗигасен тирәнрәк ачарга була лабаса! Кызыклы хатирәне күңеленә йозаклаган Фәйзи ага Йосыпов[10]!..

Тагын бер факт мине тетрәндереп җибәрде... 1944 елда университетта татар әдәбияты һәм теле кафедрасы ачылды. Татар театр училищесы оешты (Нур Гайсин[11] – завуч, Сәет Булатов[12] директоры иде). Училище шәкертләре белән без, университет студентлары, бик тыгыз аралаша идек. Ул дәвернең атаклы шагыйре Мәүла Солтан[13] белән аерата якын яшәдек без. Мәрхүм Шамил Бикчуринга[14] кат-кат ялындым: «Училище елларын, Мәүла Солтан, Рифкать Әминнәр[15] хакында хатирәләреңне

4 «Идел» – республика яшьләренең әдәби-нәфис һәм иҗтимагый-сәяси журналы.
5 Зәки Зәйнуллин – Зәки Лотфулла улы Зәйнуллин (1930).
6 Фәнис Балтач – мәгълүмат табылмады.
7 Сәйдәш – Салих Җамалетдин улы Сәйдәшев (1900–1954).
8 ...кәрлә Зәйнәп... – Зәйнәп Хәйруллина (1916–2010), татар музыкасы белгече, тарихчы, «Татарстан» радиосының әдәбият-сәнгать тапшырулары мөхәррире. ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе.
9 Җиһанов – Нәҗип Гаяз улы Җиһанов (1911–1988).
10 Фәйзи ага Йосыпов – Фәйзи Сәяр улы Йосыпов (1910–2001), нәфис сүз остасы, конферансье. Эстрада артистларының I Бөтенсоюз конкурсы лауреаты (1939), ТАССРның атказанган артисты (1957).
11 Нур Гайсин – Татар театр училищесында уку-укыту эшләре мөдире.
12 Сәет Булатов – Татар театр училищесы директоры.
13 Мәүла Солтан – А. Гыйләҗевнең дусты.
14 Шамил Бикчурин – Шамил Мотыйгулла улы Бикчурин (1928–1991).
15 Рифкать Әмин – Казан театр училищесы студенты.

яз, бәлки, синең әдәбиятка керткән төп эшең шул булыр», – дип үтендем, язмады. Искиткеч гыйбрәтле язмышлар бар иде бит, әй!

Мәүла Солтан Фәйзулла Туишевның[16] секретаре булып байтак вакытлар эшләде. Көн саен йортына барып йөрде һәм Фәйзулла аганың квартирасын музей итеп әзерләде... Фәйзулла ага, инде олыгайгач, шигырьләр яза башлады һәм бервакыт, Тукай клубына халык җыеп, әдәби кичәсен үткәрде. Мәүла – театр училищесы шәкерте – аның шигырьләрен сәхнәдән укырга тиеш иде. Кичә башланыр вакыт җитте, ә Мәүла юк. Фәйзулла Туишев халык арасыннан мине эзләп тапты. «Мәүла кайда?» – дип сорады. Мин, ык-мык килебрәк: «Чирләмәде микән, кичә, тамак авырта, дип торган иде», – дидем. Ул, башын чайкап: «Чирләмәгән ул, читенсенә генә, өс-башы начар бит, менә синеке кебек», – дип, минем кыршылып беткән гимнастёрка якасына, тышын әйләндереп теккән сүсәргән бушлатыма төртеп күрсәтте...

Бар иде бит Фәйзулла Туишев музее! Үзе исән чакта ук ныклы нигез салган иде ул аңа! Мәүла андагы экспонатларның төрлелегенә, күплегенә шаккатып, сокланып кайта торган иде. «Очрашулардан алып кайткан пионер галстукларына кадәр саклый!» – дип гаҗәпләнеп сөйләгәне хәтеремдә. Мәүла белән без соңгы тапкыр 1947 елның язында очраштык, соңра ул Горький шәһәре төрмәсендә асылынып үлде...

Туишев музеенда татар мәдәниятенә кагылышлы күпме кыйммәтле хатирәләр булгандыр. Кая таралган алар? Кайтмаслык югалганмы? Нәсел-нәсәбе исәнме аның? Бармы, юкмы?.. И мескен-хәтерсез татар! Инде үз замандашларының да эзен хәтәр җилләргә биреп җуйган халык, бичара буын!.. Юкса Фәйзулла Туишев татар тарихында якты эз калдырган, гыйбрәтле язмыш кичергән шәхесләребезнең берсе ләбаса!.. Ә яшьтәшем Шамил Бикчуринны әйт, әгәр Мәүла Солтан язмышын өйрәнеп кенә әсәр язса да... Бергә укыдылар. А-а, татар яшьләренең иң мәшһүре иде Мәүла Солтан. 1944–1945 елларда матбугатта, шул җөмләдән «Совет әдәбияты»нда[17] да шигырь-поэмалары басылды... Аңа мөнәсәбәтле шактый кешеләрне дөньяга чыгарырга булыр иде. Җөмләдән берсе – Казанның иң атаклы сылуы Соня Чабдарова[18] – училище студенткасы иде. Заманнар үткәч кенә, мин Соняның Рәисә Ишморатованың[19] бертуган сеңлесе икәнен, аның рус генералына кияүгә чыгып, әнисен күмәргә дә кайтмавын белдем. Рус генераллары татар сылуларын яраталар шул, нишлисең...

Фәйзи аганың тагын бер кыйммәтле сүзе бар: «Чит милләт кызына өйләнгән татар иренең язмышы ничек бетсә, Фәйзулла абыйның да язмышы шулай тәмамланды», – ди ул. Бу фикерне син бүтән мисаллар белән ныгытканда да начар булмас иде...

Ә болай – молодец! Минем вә бүтәннәрнең, заманча тавык күзе булганнарның күзе төшмәгән почмакларга нур йөгертәсең. Афәрин!

*Ихтирам белән, Аяз.*

[16] Фәйзулла Туишев – Фәйзулла Кәбир улы Туишев (1884–1958), концерт гармуннарында уйнау остасы. ТАССРның халык артисты (1944).
[17] «Совет әдәбияты» – «Казан утлары» журналы турында сүз бара.
[18] Соня Чебдарова – Рәйсә Ишморатова сеңлесе, Казан театр училищесы студенты.
[19] Рәисә Ишморатова – Рәйсә Гыйниятулла кызы Ишморатова – Чебдарова, (1917–1997), язучы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (1987).

# «ТУГАН ТЕЛ ДИП ЯШӘДЕМ»

*«Асылда, киләчәк буынның язмышы нәкъ менә укытучыга бәйле, ә киләчәк буын исә республикабыз һәм илебез өчен җаваплылыкны үз өстенә алачак».*

Татарстан Республикасы Рәисе
Рөстәм Миңнеханов

Укытучы. Мөгаллим. Тәрбияче. Кеше язмышында, аның шәхес буларак формалашуында, тормышта дөрес юл табарга сәләтле булып җитешүендә мөһим роль уйнаучы һөнәр ияләре. Яр Чаллы шәһәрендәге сигезенче урта гомуми белем бирү мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Сания Мәүҗетдин кызы Нәбиуллина инде дүрт дистә елга якын балаларга аң-белем, тәрбия бирә. 1985 елда – моннан нәкъ утыз сигез ел элек ул үзенең һөнәри эшчәнлеген башлап җибәрә. Ул көннән соң инде ничәмә-ничә тапкыр кыңгырау шалтыраган, күпме бала белем-тәрбия һәм хәер-фатиха алып, олы юлга чыккан...



...Үзен белә-белгәннән бирле җырчы булырга хыялланган Сания авыл сәхнәсеннән төшми диярлек – матур җырлавы, классик шагыйрьләрнең озын-озын шигырьләрен яттан сөйләве белән якташларының күңелен яулый ул. Тамашачыларының алкышлары илһамландырамы кызны, Ходай биргән сәләте дәрт-көч бирәме – район күләмендә үткәрелгән конкурсларда алдынгы урыннарны яулый, мәдәни чаралар аның катнашыннан башка үтми. Шул бәйгеләрдә бүләк итеп бирелгән китапларны әле дә кадерләп саклый ул.

Сарман (хәзерге Тукай) районы Октябрь Бүләге авылында туып үскән кыз күрше авылда сигезьеллык мәктәпне, аннан соң Яр Чаллы шәһәрендә Мулланур Вахитов исемендәге татар мәктәбен тәмамлагач, Алабуга дәүләт педагогия институтына укырга керә. Диплом алуга, яшь белгеч юллама белән туган якларына – Тукай районы Иске Теләнче мәктәбенә юл тота. Биредә ул башлангыч сыйныф балаларына белем бирә, шул ук вакытта директор вазифаларын башкара. Сания шунда үзенең укытучы һөнәрен сайлап ялгышмавына тагын бер тапкыр инана; күзләренә ышаныч, соклану белән баккан сабыйларны белемле итүдә, аларны үз фикере, кыйбласы булган шәхесләр итеп тәрбияләүдә җаваплылык хисе көннән-көн ныгый.

Иске Теләнче мәктәбендә бер ел гына эшләргә насыйп була аңа. Сөйгән егете Фаат армия хезмәтеннән кайтып төшә дә, яшьләр гаилә корып җибәрәләр һәм Яр Чаллы шәһәренә күченергә карар итәләр. Бер ел эчендә ихластан яратырга өлгергән сабыйлардан аерылуы бик кыен була. Нәкъ алар – Иске Теләнче мәктәбе укучылары

укытучы һөнәренә мәхәббәт тәрбиялиләр дә яшь белгечтә. Шуңа да, аннан киткәндә, күз яшьләрен тыя алмый, хәтта укучыларын ташлап киткәне өчен үзен озак вакытлар гаепле хис итә ул...

Ул көннәрдән соң инде бик күп сулар аккан. Мәгариф өлкәсендә шактый үзгәрешләр чоры кичелгән, саллы ук тәҗрибә тупланган. Белем бирү системасында һәрбер фән кирәкле һәм мөһим. Әмма Сания Мәүҗетдин кызы нәкь менә татар теле укытучысы булуы белән бәхетле. Беренче дәрескә кергәндә, бер авыз сүз диярлек татарча белмәгән балаларның мөстәкыйль рәвештә җөмләләр төзүе, уку елы ахырында инде чатнатып диярлек ана телендә сөйләшергә өйрәнүе – шул түгелме тынгысыз хезмәтеңнең җимеше?

Эш дәверендә татар балаларына да, рус телле балаларга да татар теле дәресләре бирә ул. Элек грамматикага күбрәк басым ясасалар, хәзер сөйләм теленә өстенлек бирелә. Дәресләр Роза Хәйдәрованың дәреслекләре һәм «Ситуатив күнегүләр җыентыгы»на нигезләнә. «Тел өйрәнүдә өстенлек бирә торган юнәлешләребезнең берсе – диалоглар кору, бу отышлы алым балаларга да бик ошый. Элек рус телле балалар татарча ярыйсы гына сукалый иде, чөнки татар телен атнасына алты сәгать укыдылар, имтихан да бирделәр. Соңгы елларда җиңелләштердек. Кызыксынуы булган бала барыбер телне өйрәнә. Арада татарчаны бик яхшы белүчеләр бар. Үзем дә укучыларга еш кына әйтәм: «Телләр өйрәнү – зыялылык билгесе. Татарчаны белсәгез, казакъча, үзбәкчә, төрекчә аңларга була. Хәтта инглиз телен өйрәнергә дә җиңелрәк», – ди Сания ханым.

Укучылары турында сөйләгәндә, аеруча җанлана ул, күзләре балкый. «Акыллыларым», «сандугачларым» кебек сүзләрнең мәгънәсе мәктәптәге һәр укучыга таныш, чөнки яраткан укытучылары нәкь шулай эндәшә аларга.

Киләсе елга Сания ханым алтмыш яшьлек юбилеен үткәрәчәк. «Әле эшләргә исәп бар. Балалар янында яшәрәм мин. Алар миңа көч бирә... Якты, матур кабинетым бар. Көн саен эшкә сөенеп киләм», – ди ул.

Тормыш иптәше Фаат белән бер ул, бер кыз тәрбияләп үстергәннәр. Уллары Дамир юрист белгечлеге ала, эшмәкәр, кызлары Ләйсән – фармацевт булып эшли. Дүрт оныклары бар. Адәм баласына йөкләнгән вазифаларның барысы да җиренә җиткезелгән. Һәр ата-ана балаларының тәүфыйклы, тәрбияле, чын кеше булуын тели. Тик укытучы кеше генә бары тик балалары турында гына түгел, укучылары турында да яхшы хәбәрләр көтеп яши. Сания Мәүҗетдин кызына да яраткан укучыларыннан бары тик сөенечле хәбәрләр генә килеп ирешсен иде.

Җырчы булу теләге хыялда гына кала, ләкин Сания ханым моңа һич үкенми. Ак кәгазь сыман саф, самими балалар күңелендә татар теленә карата мәхәббәт тәрбияләү, аларның хөрмәт-ихтирамын казану, милләткә хезмәт итү, укучыларның уңышларына сөенү, инде мәктәп бусагасын атлап чыгып, олы тормышта үз юлын тапкан укучыларының чәчәк бәйләмнәре тотып килүләре, аларның рәхмәт-ярату хисләрен тою меңнәрчә алкышлардан, атказанган исемнәрдән күпкә кадерлерәк Сания Мәүҗетдин кызы өчен.

**Лилия ЯРУЛЛИНА**

*Фәйзи Биккининның тууына – 125 ел*

# ГАРМУННАР ПАДИШАҺЫ

1 октябрьдә виртуоз музыкант, Татарстанның атказанган артисты Фәйзи Биккининның тууына 125 ел тулды.

Татар энциклопедиясендә урын алган мәкаләдә язылганча, булачак музыкант 1898 елда Казанда дөньяга килә. 1915 елдан эстрадада, шул исәптән татар «Сәйяр» драма труппасының инструменталь ансамблендә, скрипкачы һәм концерт гармуннарында уйнаучы буларак чыгышлар ясый башлый. 1918 елда Салих Сәйдәшев белән бергә Буа шәһәрендә театр-музыка студиясен оештыруда катнаша.

1930–1937 елларда Татарстан радиосында, аннары 1963 елга кадәр Татар филармониясендә эшли.

Фәйзи Биккинин Төрле конструкцияле гармуннарда виртуоз уйнау сәләтенә ия була. Репертуарында татар халкының борынгы «Әллүки», «Зиләйлүк», «Кара урман», «Уел», «Тәфтиләү» көйләре, татар композиторлары әсәрләре, төрле халыкларның көйләре һәм биюләре урын ала.

Уфа, Ташкент, Алма-Ата һәм башка күп шәһәрләрдә гастрольләрдә була. Бөек Ватан сугышы елларында концерт бригадалары составында Балтыйк буенда, Польшада, Германиядә чыгышлар ясый. Традицион татар музыка уен коралларында уйнау осталыгын камилләштерүгә зур өлеш кертә.

1968 елда Казанда вафат була.

1991 елдан алып, ел саен Фәйзи Биккинин исемендәге «Уйнагыз, гармуннар» гармунчылар фестивале уздырыла.

Татарстан радиосы фондында Фәйзи Биккининның репертуары тулысы белән чагылыш тапкан, дип әйтеп булмый. Бу аңлашыла да, чөнки тавыш яздыру җиһазлары кайтартылган елларда ул инде өлкәнәеп баручы музыкант була. Иң әүвәлге язмасы 1957 елга карый («Сабантуй» һәм «Зариф» көйләренә тезмә). Ул башкарган әсәрләрнең зур өлеше 1963-1964 елларда язып алынган. Алар арасында Заһид Хәбибуллин – скрипкада, Исмәгыйль Һилалов – мандолинада, Александр Ключарев – фортепианода, Фәйзи Биккинин концерт гармунында уйнап башкарылган «Әллүки», «Уфа Әпипәсе», «Баламишкин» көйләре аеруча кадерле. Биредә һәрберсенең үзенә генә хас алымнары, кабатланмас стиле булган дүрт бөек музыкантның ансамбль составында бер-берсен тулыландырып уйнавы, яңа бер яңгыраш барлыкка китерүе сокландыра.

Журнал укучыларын без Фәйзи Биккининга кагылышлы уникаль бер язма белән таныштырырга булдык. «Көрәш ялкынында туган музыкант» дигән концерт-очерк 1964 елда әзерләнгән. Авторы – Мәгъсум Латыйфуллин. Тапшыруны Камал Саттарова алып барган. Әлеге язма шул ягы белән дә кадерле – биредә Фәйзи Биккининның үз тавышы да сакланып калган, ул иҗат музыка сәнгатенә килеп кергән елларын, иҗатка канатландырган шәхесләрне сөйли. Әйдәгез, милли музыкабызны баетуга зур өлеш керткән кадерле милләттәшебезне рәхмәт белән искә алып тыңлыйк.

# ХАЛЫК ҖЫРЛАРЫНА ГОМЕР БИРДЕ



Хор дирижёры, педагог, сәнгать фәннәре кандидаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Әзһәр Абдуллинның (1923–1993) тууына – 100 ел.

Хәзерге Минзәлә районы Тауасты Байлар авылында дөньяга килеп, халык җырларына гашыйк булып үскән егетнең музыка сәнгатенә юлы гади генә булмый. Башта әле аңа, гармун урынына корал алып, Бөек Ватан сугышы кырларында илебез азатлыгын якларга туры килә.

1952 елда – Казан консерваториясен, 1955 елда Мәскәү консерваториясе каршында аспирантура тәмамлый. Шул елдан Казан консерваториясендә укыта башлый. Бер үк вакытта Татар академия театрының музыка җитәкчесе һәм дирижёры (1957–1967), Татар опера һәм балет театрында дирижёр һәм хормейстер (1958–1959), Җыр һәм бию ансамбленең сәнгать җитәкчесе (1967–1968) булып эшли.

Актив иҗат һәм концерт эшчәнлеге алып бара. 1957 елда Мәскәүдә Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасында татар композиторлары әсәрләрен башкарган СССР Дәүләт симфония оркестрына дирижёрлык итә.

Әзһәр Абдуллин виртуоз музыкант, күренекле хор һәм оркестр дирижёры, күп санлы шәкертләр тәрбияләп үстергән педагог булу белән беррәттән, халык җырларын эшкәртүче композитор буларак та татар музыка сәнгате тарихында җуелмас эз калдырган шәхес. Халык җырының моңын, рухын саклап, аңа заманча яңгыраш сала алу – бик сирәк иҗатчыларга гына бирелә торган сәләт ул. Татарстан радиосы фондында Әзһәр Абдуллин эшкәртүендә җитмештән артык татар халык җыры саклана һәм аларның күбесендә ул дирижёр буларак катнашкан.

Әзһәр Хәниф улы музыка белемен, халык җырларын актив рәвештә пропагандалаучы музыкант та иде. Шушы максат белән ул хор өчен җыентыклар, татар халык җырларын һәм композиторлар әсәрләрен хор, инструменталь ансамбль һәм симфоник оркестрлар өчен эшкәртмәләр, татар фольклорына караган фәнни һәм фәнни-популяр хезмәтләр бастырып чыгарды. Шушы изге бурычы аны еш кына Татарстан радиосына да алып килә иде. Ул биредә татар халык җырларының хасиятенә, аларны башкару үзенчәлекләренә багышланган тапшырулар әзерләде. Журнал укучылар игътибарына нәкъ әнә шундый чыгышларының берсе тәкъдим ителә. Язма 1950 нче еллар ахырына карый. Тапшыруны Әзһәр Абдуллин үзе алып барган.

*Сәхифәне «Татарстан» радиосының шеф-мөхәррире*
**Нәсим АКМАЛ** *алып бара.*

# Ictimaği-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## РӘИС ЮЛЛАМАСЫ

Татарстан Республикасы Рәисе ТР Дәүләт Советына еллык Юллама белән мөрәҗәгать итте. Юллама тулысы белән халыкның яшәү сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән иде. Ул бөтен тармакларны да колачлады. Бик зур өстенлек махсус хәрби операциядә катнашучыларга, аларның гаиләләренә игътибар күрсәтүгә, ярдәм итүгә бирелде. Рәис Көнбатыштан илебез яшьләренә тискәре идеологик йогынты ясау, традицион рухи хәзинәләрне юкка чыгару, тарихи хәтерне бозып күрсәтү шартларында массакүләм мәгълүмат чараларына, мәдәният һәм сәнгать әһелләренә ватанпәрвәрлек рухын тагын да көчәйтү зарурлыгын искәртте. Юлламада фәнне үстерү, производствога кертү мәсьәләләренә дә зур игътибар бирелде. «Фәннең һәм инновацияләрнең алдыбызда торган бурычларны хәл итүдә мөһим ролен аңлап, Россия Федерациясендә Фән һәм технологияләр унъеллыгы, Россия фәненең 300 еллыгы кысаларында киләсе елны «Татарстан Республикасында фәнни-технологик үсеш елы» дип игълан итәм», – диде Рөстәм Миңнеханов.

## БЕЛАРУСЬ РЕСПУБЛИКАСЫНДА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘДӘНИЯТЕ КӨННӘРЕ

Беларусь Республикасында Татарстан Республикасы мәдәнияте көннәре булып узды. Анда төрле күргәзмәләр тәкъдим ителде, татар фильмнары, мультфильмнар күрсәтелде, иҗади килешүләр төзелде. Делегация составында Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Рифат Җамал, Татарстанның халык шагыйре Зиннур Мансуров, язучы-прозаик, Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Ринат Мөхәммәдиев, шагыйрә Дания Нәгыйм дә бар иде. Алар белорус язучылары һәм татар диаспорасы белән очрашты, Җәмигъ мәчетендә булды. Беларусь һәм Татарстан Республикалары Язучылар берлекләре арасында хезмәттәшлек турында килешү проекты әзерләнде. Иҗади интеллигенция очрашуында модератор буларак, «Казан» журналының баш мөхәррире, шагыйрә Альбина Әпсәләмова да катнашты.

## АБДУЛЛА АЛИШНЫҢ ТУУЫНА –115 ЕЛ

Спас районында каһарман-шагыйрь Абдулла Алишның тууына 115 ел тулуга багышланган чаралар узды. Әдипнең туган авылы Көектә тантаналы митинг булды. Ул шагыйрьнең бюстына чәчәкләр салу белән тәмамланды. Килгән кунаклар Болгар дәүләт тарихи архитектура музей-тыюлыгында Алиш музее белән таныштылар. Аннары Болгар балалар сәнгать мәктәбендә Абдулла Алиш премиясен тапшыру тантанасы булды. Быел бу олы бүләккә шагыйрә, Казандагы А.Алиш исемендәге 20 нче гимназия директоры Рәхимә Арсланова белән шагыйрә Фирдәвес Әһлия лаек булдылар. Премияне Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Илсөяр Иксанова тапшырды. Каһарман-шагыйрьнең тууына 115 ел тулуга багышланган чараларда Спас муниципаль районы башлыгы Фәргать Мөхәммәтов, язучылар Рафис Корбан, Хәбир Ибраһим, Йолдыз Шәрәпова, Вакыйф Нуриев, туганнары катнашты һәм чыгыш ясады.

* * *

Казандагы А.Алиш исемендәге 20 нче гимназиядә каһарман-шагыйрьнең тууына 115 ел тулуга багышланган зур тантана булды. Ул Абдулла Алишның гимназия ишегалдындагы бюсты янында үткәрелде. Тантананы гимназия директоры, батыр әдипнең истәлеген мәңгеләштерү максатында эшләнгән эшләрнең, шул исәптән музей ачуның, бюст куйдыруның, эзләнү конференцияләре үткәрүнең башында торган педагог, шагыйрә, Алиш премиясенең быелгы лауреаты Рәхимә Арсланова ачты. Тантанада Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Илсөяр Иксанова, Алиш премиясе лауреатлары Галимҗан Гыйльманов, Йолдыз Шәрәпова, Нурия Сәйяр, Фирдәвес Әһлия, Нәкыйп Каштанов, Вакыйф Нуриев, язучылар Рифат Сәлах, Гүзәл Әдһәмова, Ринат Нуруллин, Алишның туганнары Фаина һәм Фәридә Алишевалар, Гөлшат һәм Азат Сөнкишевлар катнашты. Гимназиядә күркәм традиция бар. Һәр елны Алиш премиясе бер алдынгы, актив укучыга да бирелә. Быел бүләккә XI сыйныф укучысы Айназ Галиев лаек булды.

## ГАРИФ АХУНОВ, РӘШИТ АХУНОВ ҺӘМ «ХӘЗИНӘ»

18 сентябрьдә – Татарстанның халык язучысы, җәмәгать эшлеклесе Гариф Ахуновның туган көнендә бер төркем кунаклар әдипнең туган ягы – Арча районына кайтты. Бу сәфәр язучының «Хәзинә» романын язуына – 60, Гариф Ахуновның улы, әсәрне рус теленә тәрҗемә иткән Рәшит Ахуновның тууына 70 ел тулуга да багышланды. Ул Казанбаш авылындагы Г.Ахунов исемендәге мәктәптәге музейдан башланды. Кунакларны мәктәп директоры Ришат Камалов сәламләде. Арча районы Үзәк китапханәсендә әдәби кичә үткәрелде. Башта китапханә директоры Лилия Дәүләтбаева кунакларны күргәзмәләр белән таныштырды. Кичәдә район хакимияте башлыгы урынбасары Эльвира Вафина, язучы, галим Фоат Галимуллин, каләм ияләре Рәмис Аймәт, Сания Әхмәтҗанова, «Мәгариф» журналының баш мөхәррир урынбасары Фәния Лотфуллина, әдәбият-сәнгать музееның элекке директоры Шәфигулла Гарипов, яшь шагыйрә Маргарита Графова һ.б. чыгыш ясады. Кичәдә Г.Ахунов турында документаль фильм, «Хәзинә» нәфис фильмыннан өзек күрсәтелде. Ул көнне кунаклар район үзәгендәге Язучылар аллеясында булды, Ахун чишмәсенең суын авыз итте, Арча зиратында Гариф Ахунҗан улының, Рәшит Гарифҗан улының һәм Шәһидә Габдерахман кызының (язучы-тәрҗемәче, Г.Ахуновның җәмәгате) каберләрен зиярәт кылды. Алар рухына дога багышланды. Арча районында үткәрелгән чараларда Россия Рәссамнар берлеге әгъзасы Салават Нигъмәтов (ул Казанбаш мәктәбе музеена үзе ясаган Наилә Ахунова портретын бүләк итте), Казандагы балалар әдәбияты музее мөдире Фәридә Сәлимова, журналист Рәйсә Юсупова, районның мәдәният идарәсе җитәкчесе Илфар Әюпов, «Казан арты» тарих-этнография музее директоры Гөлназ Камалова һ.б. катнашты. Һәр чарада Г.Ахуновның кызы, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, шагыйрә Наилә Ахунова чыгыш ясады.

## ИСТӘЛЕК ТАКТАСЫ АЧЫЛДЫ

Актаныш районы Уразай авылында драматург Риза Ишморатовның тууына 120 ел тулу уңаеннан бертуган Ишморатовларның туган нигезендә истәлек тактасы ачылды. Аны ачу тантанасында Татарстанның халык шагыйре Газинур Морат, «Мәдәни җомга» газетасының баш мөхәррире, язучы Вахит Имамов катнаштылар һәм чыгыш ясадылар.

## ТҮБӘН КАМА КУНАГЫ – ЯЗУЧЫ КАМИЛ КӘРИМОВ

Түбән Каманың Г.Тукай исемендәге Үзәк китапханәсендә «Әдәби җәй» проекты кысаларында язучы-сатирик, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт, Мәдәният министрлыгы белән Язучылар берлегенең Ф.Хөсни, Г.Афзал премияләре лауреаты Камил Кәримов белән очрашу булды. Кол Гали исемендәге китапханә белән бергә үткәрелгән бу чарада прозаик Фәрит Имамов, композитор-башкаручы Илһам Хисмәтуллин, «Мунча ташы» эстрада театры җитәкчесе Гамил Әсхәдулла, җырчылар Илшат Хәбибуллин, Җәмил Шәйхетдинов, «Кама таңнары» әдәби берләшмәсе әгъзалары, әдип иҗатын яратучылар чыгыш ясады. Әдәби кичәнең сценарий авторы һәм алып баручысы – Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Гүзәлия Гыйбадуллина.

## ЕГЕРМЕ БЕРЕНЧЕ КИТАП

«ТАТМЕДИА» бинасындагы «Әдәби кафе»да язучы Нәзифә Кәримованың «Изге ат» китабын тәкъдим итү булды. Бу – «ТАТМЕДИА» ярдәме белән «Казан утлары» журналы китапханәсеннән» сериясендә басылып чыккан егерме беренче басма. Яңа китап бәйрәмендә «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең социаль-медиа мәсьәләләре буенча директоры Алсу Исмәгыйлева, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, Бөтендөнья татар конгрессының мәгълүмат хезмәте һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә идарәсе җитәкчесе Гөлназ Шәйхи, галимә Равия Зарипова, язучы Ләбиб Лерон, автор үзе чыгыш ясады. Кариев театры артисты Фәнис Кәлимуллин әсәрдән өзек укыды. Китап тәкъдим итү бәйрәмен язучы Рафис Корбан алып барды.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Шагыйрә, педагог Вәсимә Хәйруллинага – 80 яшь.

2023 елның 1 сентябрендә 74 нче яшендә Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Һ.Такташ исемендәге әдәби премия лауреаты **Рашат Мияссәр улы Низамиев** вафат булды.

Мәрхүмнең җәсәде Әтнә районы Олы Бәрәзә авылы зиратында җирләнде.

*Сәхифәне* **Вакыйф НУРИЕВ** *әзерләде.*

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: исторический роман В.ИМАМОВА «Родник Телекея», роман Г.ГИЛЬМАНОВА «Искушение дьявола», рассказы И.ЗАЙНИЕВА; стихи И.ИКСАНОВОЙ, И.НУГМАНА, З.ДАВЛЕТОВА, Б.ИБРАГИМА.*
*«Драматургия»: драматический рассказ А.АХМЕТГАЛИЕВОЙ «Свет моих очей».*
*«Литература родственных народов»: стихи М.ЫБЫРАЕВА в переводе Р.КУРБАНА.*
*«Литературный конкурс «Учитель – прекрасный человек на земле!»: рассказ Н.ШАРИФУЛЛИНА «Тень Шагалиева».*
*«Новые имена»: стихи Р.ИСМАГИЛОВОЙ.*
*«Свет далёких огней»: стихи Р.ХАКИМЗЯНА и Н.АЙБУЛАТОВА.*
*«Память»: статья Г.АРСЛАНОВА к 115-летию С.Уметбаева.*
*«Обзор книги»: статья Л.АБУДАРОВОЙ.*
*Фотоархив, посвящённый 115-летию А.Алиша.*
*«Памятные письма»: стихи А.Гилязова М.Галееву.*
*«2023 – год Учителя и наставника в России»: статья Л.ЯРУЛЛИНОЙ.*
*«Бесценные голоса»: статьи к 125-летию Ф.Биккинина и 100-летию А.Абдуллина. Рубрику ведёт Н.АКМАЛ.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: Парк Тысячелетия в г.Казани. Фото И.АБРАМОВОЙ; журналистка Р.ИСМАГИЛОВА.*

## IN THIS ISSUE:

*«Prose and Poetry»: historical novel by V.IMAMOV «The Telekey Spring», novel by G.GILMANOV «Devil's Intrigue», stories by I.ZAINIEV; poems by I.IKSANOVA, I.NUGMAN, Z.DAVLETOV, B.IBRAGIM.*
*«Dramaturgy»: dramatic story by A.AHMETGALIEVA «The sunshine of my life».*
*«Literature of kindred peoples»: poems by M.YBYRAEV translated by R.KURBAN.*
*Literary contest «Teacher is a wonderful person on earth!»: story by N.SHARIFULLIN «Shagaliev's Shadow».*
*«New Names»: poems by R.ISMAGILOVA.*
*«The Light of distant fires»: poems by R.KHAKIMZAN and N.AYBULATOV.*
*«Memory»: article by G.ARSLANOV to the 115th anniversary of S.Umetbaev.*
*«Review book»: article by L.ABUDAROVA.*
*Photo archive dedicated to the 115th anniversary of A.Alish.*
*«Memorial letters»: poems by A.Gilyazov to M.Galeev.*
*«2023 the year of Teacher and Pedagogue in Russia»: article by L.YARULLINA.*
*«Priceless voices»: articles to the 125th anniversary of F.Bikkinin and the 100th anniversary of A.Abdullin. The column is l headed by N.AKMAL.*
*Diary of public and cultural life.*
*On our covers: the Millennium Park in Kazan. Photo by I.ABRAMOVA; journalist R.ISMAGILOVA.*

---

*Тышлыкның беренче битендә:* Казанның Меңьеллык паркы.
*И.АБРАМОВА фотосы.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* журналист Ризәлә ИСМӘГЫЙЛЕВА.